КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

# Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Илсөяр ИКСАНОВА. Йөзем куйдым җилләргә... *Шигырьләр.* .................... 3
Зиннур ХӨСНИЯР. Әллүки. *Роман.* ....................8
Рүзәл МӨХӘММӘТШИН. Таш. *Поэма.* ....................47
Рафис КОРБАН. Танкистлар. *Документаль повесть*. .................... 58
Гөлзадә ӘХТӘМОВА. Өметләр һәрвакыт була ак... *Шигырьләр.* ....................82
Нәзифә КӘРИМОВА. Озын-озак язмышлар. *Повесть-истәлек.* ....................86

ЯҢА ИСЕМНӘР

Фирдәүсә БИКМӘТОВА. Таулар түбәсендә кылдай хыял… *Шигырьләр.* ....................132

«ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ...» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Фәнүзә ЯКУПОВА. Гыйбрәтле хата. *Хикәя.* ....................136

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

Сагыныш МОХИТ КЫЗЫ. Ана телем – алга әйдәр байрагым! *Шигырьләр.* ....................149

ЮБИЛЕЙЛАР

Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Киләчәккә йөз тотып....................152

*Фотоархив.* Дания Заһидуллинаның тормыш мизгелләре. ....................159

Г.ИБРАҺИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНА – 85 ЕЛ

Яшь галимнәребезгә юл һәрвакыт ачык. (*Институт директоры Илгиз Халиков белән Алинә Хәбибуллина әңгәмәсе).* ....................161

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Рифат СВЕРИГИН. Хемингуэйлар бездән еракмы?.................... 167

МИЛЛИ МӘГАРИФ

Руфия МӨХЕТДИНОВА. Шәхес тәрбияләү – төп бурычыбыз! .................... 178

ӘБУГАЛИСИНА МӘГАРӘСЕ

Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. Насыйриның Казан рухани семинариясендә укыту-методик һәм гыйльми эшчәнлеге.................... 180

ЗАМАНДАШЫБЫЗ

Руфия МӨХЕТДИНОВА. Янып-балкып яшәүче Фәрид Миңнеәхмәтов ....................187

Әдәби сканворд. *Рәис ГАБДУЛЛА төзеде.* .................... 189

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....................190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 10 (1224) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.09.2024, график буенча 30.09.2024, басылып чыгу вакыты 04.10.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-2210. Тираж 4515.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.
12+
© «Казан утлары», 2024 ел



Илсөяр
Иксанова

# ЙӨЗЕМ КУЙДЫМ ҖИЛЛӘРГӘ...

## Нәваине уйлап

Тәхет тирәсендә тапмас Шагыйрь бәхет, –
Тынгы бирмәс аңа сарай яраннары.
Нәваидән алып бүгенгегә кадәр
Күпме Шагыйрьләрнең җаны яраланды.

Дәвер алмашына – ысул һаман шул ук, –
Хөр рухлыга – агу.
Агу төрле-төрле.
Күктән «Шагыйрь!» диеп тәгаенләнгәнгә
Ябышалмас ләкин заманының кере.

Гаделлекне уйлап, кошлар теле[1] белән
Сайрап карый Шагыйрь уянсын дип гавәм.
Мәхәббәткә тугры Фәрһәд-Шириннәрнең[2]
Ихлас хисләреннән яктырыр тик галәм.

Гадел-камил хаким Искәндәрләр[3] булса,
Бәрәкәте иңми калмас иде илгә.
Хөрлек белән тарлык,
Хыял һәм чынбарлык
Тарткалаша һаман Шагыйрь каләмендә.

[1,2,3] Нәваинең «Кошлар теле» («Лисаи әт-таир»), «Фәрһәд вә Ширин», «Искәндәр дивары» («Сәдд-и Искәндәрий») әсәрләренә ишарә.

Илсөяр ИКСАНОВА (1966) – *шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. «Ышанасы килә», «Кырык кыл», «Гомер сурәте» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Очыш

*Кошлар нәселеннән булсам да, тик*
*дәрьяларда гына оча алам!*
Равил Фәйзуллин

Дулкыннар күккә күтәрә,
Дулкыннар сөйри төпкә.
Дулкыннарны йөгәнләүнең
Серләре нечкә күпкә!

Тиңдәшме син, көндәшме син,
Үзме, ятмы дулкынга? –
Йә күтәрер ул Кояшка,
Йә салыр ул упкынга.

Ике игез – күк һәм диңгез,
Оч, булса канатларың!
Аңларсың шунда Күкләрнең
Кем итеп яратканын.

## Мисыр дәфтәреннән

*Дахаб[4] – җилкәнлеләр иле*

**1**

Дәрьяларны кичәр өчен
Кирәк җилкән.
Дөнья-дәрья гарасатлы
Диңгез икән.

Җилкәннәрне киерергә
Җилләр кирәк,
Җилләр кебек җилбер-җилбер
Җилкен йөрәк.

Йөрәкләрне җилкетергә
Кирәк киңлек.
Киңлекләрне тояр өчен
Кирәк тиңлек.

Киңлекләрне колачларлык
Бармы хисең?
Җилләр белән җиңешерлек
Бармы көчең?

**2**

Җилләр монда җылы икән,
Йөзем куйдым җилләргә.
Усал җилләр исеп калды
Минем туган илләрдә.

Усал җилләр кисә анда
Ап-ак каен башларын.
Йөрәгемнең сыкравыннан
Сискәнмәс шул ташларың, –

Ташлар иле, комнар иле,
Миннән ерак ил лә син.
Газиз туган илкәемне
Җылы җилләр имләсен!

Имләсен, игә китерсен,
Җиңсен усал җилләрне.
Йөзләремне җилгә куйдым,
Уйлап туган илләрне.

**3**

*Ил корабын җил сөрә.*
Дәрдемәнд

Җилкәнлеләр илендә мин,
Уемда – ил корабы.
Өстебезгә ишеләм дип
Дулкын килә каралып.

Упкынга сөйри бу дулкын,
Юл бирәбез без аңа.
Чоңгылларга төшкән көннәр
Хәтеремдә яңара.

[4] Дахаб – Мисырда Кызыл диңгез ярындагы шәһәр. Җилкәнле спорт төрләре белән шөгыльләнүчеләр үзәге.

Кешелекнең хәтере бик
Кыска икән чынында.
Акны таный кара диеп,
Ялган дияр чынын да.

Уйлый идем, кешелекне
Уятырга җитәр сүз.
Мин җилкәнлеләр илендә.
...Илдә күпме җилкәнсез.

## Мисыр күгәрчене

Гөлдер-гөлдер
Таңда кемдер
Ала татлы йокымны.
Аһ, син, мисыр күгәрчене –
Изгеләрнең токымы!

Риваять булып яшисең
Халкымның күңелендә.
Мин ышанам риваятьнең
Уйдырма түгеленә.
Мин ышанам игелекнең
Яманны җиңәренә.

Үзенең Әбүҗаһилы
Һәр чорның була икән.
Пәйгамбәр чорыннан калган
Күгәрчен куна микән
Бүген хаклык куышына, –
Оясын кора микән?

Куа киләләр безне дә
Атланып ялган атка.
Ялган атларга буйсынган
Батачак яманатка,
Яраклашу ятьмәсендә
Әйләнер ярканатка[5].

Ярканат язмышларына
Тармасын дип ахырдан,
Милләтемә куыш эзлим, –
Коткар Әбүҗаһилдан!
Гөлдер-гөлдер...
Таңда кемдер
Юрый ни күрәсене.
Куышыма оя корчы,
И мисыр күгәрчене!

## Тур тавында

*(Бихисап файдалары булган) Инҗир һәм зәйтүн белән ант итәмен! Һәм (Мусаның (галәйһиссәләм) Аллаһы Тәгалә белән сөйләшү урыны булган мөбарәк) Синадагы Тур (тавы) белән (ант итәмен)! Һәм шушы имин шәһәр (булган Мәккәи Мөкәррәмә) белән (ант итәмен)! Без кешене иң күркәм кыяфәттә яралттык.*
Әт-Тин сүрәсе, 2 нче аять

**1**

Тауларга мендем. Тауларның
Күрдем мин төрлеләрен, –
Ак чалмалы биеклеген,
Томанга төренгәнен.

Ә син үзгә, исемең белән
Аллаһ ант иткән Синай.
Муса тавында тора хач,
Таулардан биек – ак ай.

Хачка тигән кеше кулы,
Ай – иҗаты Илаһның, –
Карап тора, барлап тора
Хаклыгын вә хилафын.

Син гаҗәеп тау икәнсең,
Могҗизалы чыннан да.
Могҗизага ышанма, ди,
Яңгырыңа чылан да?!

Мисыр җирен өтә Кояш,
Таммый җәен тамчы да.
Бары монда яңгыр ява,
Сусыл үзән ачыла.

---

[5] Ярканат – татар мифологиясендә яраклашучы, икейөзле. («Ни өчен ярканат яктыда очмый?»)

Яшел зәйтүн агачлары, –
Җимешләре бөредә.
Коръәне дә, Тәүраты да
Искә төшә биредә.

Янәшә мәчет һәм чиркәү, –
Хакка бәндә бертигез.
Бу куышта булган Муса
Һәм Мөхәммәт (с.г.в.) изгебез.
Тауларга мендем. Синайның
Иңендә басып торам.
Үзең яралткан сыйфатта
Яшәргә язсын, Ходам!

**2**

Утта янмас куак ялкынында[6]
Аллаһыдан иңгән ун әмер –
Кешелеккә яшәү кагыйдәсе, –
Һәр Китапта мәгънә бергә-бер.

Кагыйдәне яхшы беләбез дә
Бозмый калган бармы арада?
Гамәлеңә хисап тотар өчен
Менү кирәк, ахры, тауларга.

Көтмәгәндә купты ком бураны
Таулар пышылдаган кайтаваз.
Сынавыңмы безне, Илаһым?!
Шаярткандай берсе әйтеп куйды:
Арабызда кемдер гөнаһлы.

Һәм һәркайсы чумды үз уена, –
Бер гөнаһсыз бәндә бармы соң?
Язмыш белән күзгә-күз калганда,
Кылган гамәлләрең барлыйсың.

Кылган гамәлеңә үкенү – бер,
Кылмаганга кемнәр үкенә?
Битарафлык – үзе үлемгә тиң.
Пышылдады таулар: «Үтермә!»

Әмерләрнең берсе бу Күкләрдән
Тур тавында иңгән Мусага.
Мәгърур таулар Җир-Күк арасында,
Күрәсең, бер серле бусага.

Күкләр белән җирне тоташтырган
Ком бураны урап алды да
Җанны сискәндерер сорауларны
Китереп салды минем алдыма.

Кинәт башланган күк кисәк кенә
Тынды буран. Күкләр чалт аяз.
Биеклектән төштек. Ә күңелдә

## Ромашкалы туйлар җәйләрдә...

Туй күлмәге кигән ап-ак болын –
Ромашкалы туйлар җәйләрдә.
Таңнарның ал, хисләренең саф мәле,
Мәхәббәттән башлар әйләнә.

Көләч ромашканың ак чуклары –
Бу тормышның якты шатлыклары.
Шатлыкларны бергә өзәргә!
Гел шатлыктан тормый диеп дөнья,
Үзегенә сагыш корган оя, –
Сынауларга бергә түзәргә!

Болын өсләрендә тургай җыры,
Тиң бәхеткә телим юрарга.
Ромашкалар ак таҗларын сибә
Җитәкләшеп үтәр юлларга.

Көләч ромашканың ак чуклары –

[6] Ут кабып та янмый торган куак (Неопали́мая купина́) ялкыны аша Аллаһы Тәгалә Муса пәйгамбәргә ун әмер җиткерә.

Бу тормышның якты шатлыклары.
Шатлыкларны бергә өзәргә!
Гел шатлыктан тормый диеп дөнья,
Үзәгенә сагыш корган оя, –
Сынауларга бергә түзәргә!

***

Офыкларга шәфәкъ нуры тамган,
Тәрәзәңдә синең ут микән?
Мин сагынып сиңа килгән идем,
Син аңладың микән, юк микән?..

Эңгерләрен томан сарган көз бу, –
Адаштырмас ләкин бу томан.
Тойгыларым йөрәгемә төйнәп,
Китеп барам синең йортыңнан.

Горурлыгым үземнән дә зур шул, –
Башым имәм сөю үтенеп.
…Тәрәзәңә ут алмаган өчен
Син яшәрсең ләкин үкенеп.

## Адашкан яз

Болыт булып төшеп калган микән
Бер каурые аккош канатының?
Аккошларның сагышлары сыйган
Күзләреңнән күрдем яратуың.

Сискәндерер аккош авазлары
Тынлыгында көзге кичләрнең.
Адашкан яз кебек бөтерелеп,
Әйләнә дә кайта хисләрем.

Каурый кебек ак болытлар ага
Киткән аккошларның юлларында.
Канат җилпеп кенә узды яшьлек,
Сагыш ташлап килер елларыма.

Сискәндерде аккош авазлары
Тынлыкларын көзге кичләрнең.
Адашкан яз кебек бөтерелеп,
Әйләнде дә кайтты хисләрем.

***

Дөнья матур.
Гомер бер генә.
Күңелеңә
Кояш эл генә!
Сакла Кояшыңны,
Сүндермә!



Зиннур
Хөснияр

# ӘЛЛҮКИ[*]

РОМАН[**]

## СҮЗ БАШЫ

Бу як кешеләре шулкадәр кыю һәм батыр ки, мин татарлар белән хәтта төшемдә дә очрашырга теләмәс идем.

*Немец ефрейторы Рудольф Вольфгангның сугыштан абыйсына язган хатыннан.*

Татар ат өстеннән бәреп төшерелсә дә, бернинди коралсыз килеш, хәтта яралы хәлдә куллары, тешләре, аяклары белән каршы торачак, соңгы сулышына кадәр көрәшәчәк.

*Сигизмунд фон Герберштейн, австрияле дипломат.*

Мин бар Европаны йөреп чыктым, дөньяның кайсы гына ноктасында татарларны очратсам да, аларның изге ниятле икәнлекләрен күрдем. Алар һәрчак бергә булырга тырыша, бер-берсенә ярәм итәргә әзерләр

*Габдулла ибн Гали Басфар, гарәп галиме.*

Казан алынганнан соң Мәскәү дәүләте ошбу ханлык хисабына ныгый бара, Көнбатыш аны Казан ханлыгы варисы итеп кабул итә. Ул вакытта Мәскәү дәүләте дигән хөкүмәтне танымыйлар, санга сукмыйлар әле. Европа белән мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен, бигрәк тә Голландия һәм аның күрше

---

[*] Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең татар халык мәдәниятен саклау, үстерү һәм популярлаштыру грантына язылды.

---

[**] Журнал варианты

---

Зиннур ХӨСНИЯР (1961) – *прозаик, шагыйрь, драматург; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, М.Җәлил исемендәге республика, Ф.Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Таң ата да кич була», «Тәгәри китте язмышлар», «Терсәк сугышы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

илләре белән сәүдә мөнәсбәтләре булдыру максатыннан «Печать царства Казанского» дигән мөһер эшлиләр. 1578 елда Мәскәү иң көчле илләрнең берсе булган Голландия белән килешү төзи, башка илләр белән ясалган килешүләрдә дә әлеге мөһер сугылган. Бу 1583 елга кадәр шулай була. Бар Россияне дөнья «Тартария» дип кабул итә.

Чит илләр русларны Европа киемнәренә киенгән татар кешеләре дип белгән. Татар иленең беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең туган көненә Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин, моңа ишарә ясап булса кирәк, «Тартария картасын» бүләк иткәнен күпләр хәтерлидер әле.

*Индус Таһиров, академик.*

Татар тарихын, аның телен өйрәнү буенча немец галимнәре бик зур эшләр башкарган. Моны дәлилләү өчен кайбер мисаллар: XVIII гасырда андый кеше Герард Фридрих Миллер (1705–1783) була, XVIII-XIX гасырларда медицина профессоры Карл Федорович Фукс (1776–1846) зур хезмәт яза.

*Автор.*

Инде берничә гасыр Кремль астыннан һәм Мәскәү тирәсендәге 60лап шәһәрдә, шул исәптән Касыйм каласында да Либерияне (Латинча liber – китап; либерия – китапханә) эзлиләр. Алар татар халкының Борынгы һәм Урта гасырлар тарихы турында кулъязма китаплар булырга тиешле Казан ханлыгы китапханәсен һәм башка кыйммәтле китаплар яшерелгән урыннарны табарга ниятли. Кайдан гына эзләмиләр, ләкин бик зирәкләре Казан ханлыгы китапханәсенең бер өлешен Иван IV чиркәү асларына яшергән дип фаразлый, чөнки башка урыннардан аны татарлар барыбер табып алырга мөмкин дип шикләнгән рус патшасы.

Шунысы кызык: аның бу хәйләсен, гасырлар узгач, татарлар үзләре дә файдалана. 1905 елгы революция алдыннан бериш укымышлы татар байлары Идел буе Болгар дәүләте, Казан ханлыгы чорындагы төрки-татар тарихына, күп кенә нәсел шәҗәрәләренә бәйле кулъязмаларны үзләре махсус рәвештә чиркәүләр һәм христианлык белән бәйле биналар астына яшерә. Митрополит Макарий һәм аннан соңгы епископ Лука Конашевич заманындагы кебек мәчетләрне җимертергә, юкка чыгарырга боерык бирелгән очракта чиркәүләр исән калыр дип уйлый алар. Казан ханлыгы китапханәсенең бер өлешен Тәһран һәм Багдад китап саклагычларына алып китәләр.

*Автор.*

## БЕРЕНЧЕ КИСӘК

### Алла каргаган татар авылы турында сүз башы

Зиратта кабер тынлыгы. Җил исмәгәч, каберләрнең баш очында үскән агач яфраклары ник бер селкенеп карасын.

Ике атна рәттән кыздыра инде, күктә болытның әсәре дә күренми.

Кабер казучылар моны яңгыр буласына юрады. Башта сөенгәннәр иде, аннан соң эчләренә барыбер хәерсез шом керде, чөнки мондый кызу

көннәрдән соң, гадәттә, әүвәл көчле давыллар була, ул читән-коймаларны аудара, кайбер өй түбәләрен куптарып ата, чалгы белән чапкандай, зираттагы карт агачларны кырып чыга, алары исә, чардуганнар өстенә төшеп, һәр нәрсәне вата-сындыра; чиләкләп койган яңгыр сулары болындагы печәнлекләрне басып китә, буразналар буйлап ташыган су бәрәңгеләрне казып-актарып чыгара... Иң куркынычы: Ходай күктән яшен утлары атарга керешә. Көенүләре дә менә шул сәбәпле: ул шарсыман яшеннәр нәрсәнедер, кемнедер суга, яндыра, көйдерә, үтерә торган иде...

Зираттагы ирләр дүрт айлык нарасыйның мәетен яңгырга кадәр тизрәк гүргә индерергә ашыкты. Өлкән кешене күмгән кебек хөрмәт белән җирләделәр. Сабыйның атасы Тугаш Якубы ләхет алучының һәр хәрәкәтен игътибар белән күзәтеп торды: бу хакта, хәтере юклыкны сәбәп итеп, Туксаба авылында мөәзин вазифасын башкаручы Гәрәй карт аңа алда ук үзе әйтеп, кисәтеп куйды, башым эшләп бетерми диде.

Атна-ун көн эчендә бишектә килеш җан тәслим кылган өченче сабыйны күмүләре. Шуңа күрә Гәрәй мөәзиннең генә түгел, бар халыкның башы чуалган вакыт иде.

Нарасыеның үлеменнән соң Якуб кара кайгыга батты. Беренче хатыныннан булган малае Ямаш инде буй җитеп килсә дә, бала барыбер бала инде, һәрчак йөрәкне телгәли. Әүвәл ул байтак еллар өйләнмичә йөрде, тик карт әнисе үлгәч, өй бушап калган кебек булды, аннан да бигрәк, Ямашына хатын-кыз җылысы кирәк, әти кеше көннәр буена урманына китеп югалган чакларда малай бөтенләй караучысыз кала. Бәхетенә, үзенә хатын, ятимгә ана булырлык хатын-кыз табылды. Хуҗабикә вафатыннан соң, өйне караштырып торырга дип, кала ягыннан ерак туганы килеп йөри башлаган иде. Карт кыз булып утырып калган кырык биш яшьлек Сәрия, барысын да шаккаттырып, бик матур бер кыз да алып кайтып бирде. Тик бәхетләрен ай күрде, кояш алды, сабый хәзер гүр куенында.

Кабер казучылар эшне тәмамлагач, ирләр, бердәм кубып, зират капкасына таба кузгалганчы, Якуб мөәзиннең колагына пышылдап өлгерде:

– Инде дүрт якка дүрт кеше бастырыйк, хәзрәт... – диде ул.

– Ие шул, ие, исемдә, – дип җөпләде тегесе.

Бая, баланы өйдән алып чыкканда, кайсыдыр бик белеклесе:

– Башын алга каратырга кирәк! – дип, ялгыш фикере белән күңелгә шом салганнан соң, хәзер Гәрәй карт икеләтә уяу һәм һәр гамәлен бик уйлап башкарырга тырыша. «Хәтта мәет җирләү әдәпләрен дә онытып барабыз! Йа газиз Аллам! Кичерә күр без томаналарыңны!» – дип уфтанган иде карт шулчакта.

Ул кабернең дүртенче почмагына, Якубның каршысына, үзенең Хәтмулласын бастырды. Әле мәктәп яшендә генә булса да, «Колһуалла» белән «Фатыйха» сүрәсен яттан әйтә белүе өстенә (монысы качып кына, күрше хатыннары алар өенә аш мәҗлесенә җыелганда гына) мәктәп олимпиадаларында мактаулы урыннар яулаган түгәрәк башлы бик белдекле яшүсмер иде Хәтмулла.

Кугуй урманы ягыннан килеп чыккан кургаш бүксәле болытлар бу юлы бик акрын кыймылдый. Юраулары рас килә бугай: Ханкала шәһәре ягыннан турылап очкан кыр казларының бер төркеме генә авыл өстеннән

каңгылдашып узды да башкалары күренмәде; тегеләре дә, кире борылып, яңадан кала ягына китеп бардылар. Анда яшен вакытында качып торырлык урыннары булса кирәк.

Тәгаен көчле яшенле яңгырга иде бу. Әгәр Ислемай тавы артыннан кинәт җил исә башлап, болытларны Хәлүш урманына таба кумаса, яңгыры хәзер үк башланасы иде. Әнә урман артында, тонык кына булып, күк күкрәгәне дә ишетелде. Беркавымнан кайтаваз, Туксабаның ике туган Дәүбаш Дәриясе белән Тәбә Тәслимәсенең, үз капка төпләреннән генә торып, дүрт өй аша кычкырышкан чагында, бер-берсен басар өчен кулларындагы чиләк төбен каккан тавыш кебек көчәйде, куәтләнде.

Атна-ун көн буена җанына хәерсез шом кереп оялаган авыл куркып көтте: «Хәвеф-хәтәрсез генә узып китсә иде, Раббым!» – дип, теләкләр теләде сабыйлар үлеменнән әле һаман айнып җитә алмаган халык.

Җил Путанай чиркәве кыңгыравын (күптән түгел аны ташландык чиркәүгә Путанайның Кирьян малае Кирилл элеп куйган дип сөйләштеләр) үзенә бер тавыш белән кагып ала, әйтерсең афәт киләсен алдан хәбәр итә.

Күктән яшен ташы – шарсыман ут йомгагы очып төште. Ул Ислемай тавының Кугуй урманы ягында янгын чыгарды. Коеп явуга карамастан, һаман саен өскәрәк күтәрелә барган озын муенлы ялкын сүрелмәде. Тауга ут капкан кебек иде. Менә берзаман анда карачкы күренде, ул, ни беләндер айкана-айкана, утны сүндермәкче була, ахрысы...Тиле димәсәң соң: берүзе нишли ала?

Каядыр тау аръягында бик каты дөбердәде, яшен ташы һавага күтәрелде һәм, турылап, теге адәмгә таба китте! Күмергә әйләндерде, ахрысы: карачкы сурәте юкка чыкты. Аны яшен башланганчы зираттан ашыга-ашыга кайтып килүче Якуб белән Гәрәй карт аермачык күргәннәр. Хәлүш малае Макайга охшаган иде ул диделәр.

Ходай рәхмәте: Макайга берни булмаган! Икенче көнне Макай Туксаба кибетенә ипигә килде. «Яшен утыннан ничек качып котыла алдың?» – дип гаҗәпләнеп сорауга каршы ул: «Үз утым куәтлерәк минем!» – дип, гадәтенчә, күзгә төшмәсен дигәндәй, бөдрәләнеп торган маңгай чәченә кагылып алды. Соң чиктә шул билгеле булды: Макайга яшен ташы чынлап та кагылган һәм, ул хәтта күпмедер аңсыз да яткан, бәлки, кыска вакытлы үлем кичергәндер, чөнки егет беркадәр сәерләнгән кебек. Менә ул чыгып киткән җиреннән кибеткә кире әйләнеп керде, бая сорау биргәнгә: «Сез күргән яшен уты минем күкрәктәге ут иде ул. Сезнең Туксаба кызы кабызган ут. Үзе күптән югалса да, уты калды. Күпме саклап йөрергә була сине дип, күккә аткан идем...Үз утың үзеңә дип, Күкләр тәгаләсе кире үземә кайтарды». Макай шаяртып сөйләшергә керешкән! Моңарчы авыз эченнән гел ботка пешерә, нидер бытырдый, әйткән сүзен дә аңлап булмый иде. «Кешечә» сөйләшә башлаган Макай! Алайса, тәгаен яшен суккан моны, утлы яшен ташы баш мие шәрифләрен рәткә китергән!

Ләкин Макай шаярып сөйләшми иде. Ул Туксабаларга чын дөресен дә әйтеп бетермәде: яшен сугып, кабат аңына килгәндә, үзенең кинәт кенә сабый балага әйләнгәнен «күрде»! Хәзер нәкъ бишек баласы кебек иде!.. Әнә ул, чыннан да, бишектә ята: гәүдәсе бишеккә сыярлык кына калса да, нишләп болай өлкәннәр кебек уйлый ала соң әле?! Башы үзенеке, гәүдәсе

сабый баланыкы?! Чү! Үзе генә түгел икән бит! Янәшәсендә тагын бар аның кебек «сабыйлар»! Ул ими сорагандай илереп елый, ә калганнар барысы да тыныч. Хәтта бишекләре дә селкенми. Бер аныкы гына бишек сиртмәсенең шыгырдаган тавышын чыгара: җай гына тирбәлә.

Ул балаларның күз карашлары өлкәннәрнеке кебек акыллы. Менә ул нарасыйлар, бер-бер артлы, бишектә яткан килеш, җан тәслим кылырга кереште: үлә, сүнә бара иде алар! Һәр минут саен берсе күзләрен йома!.. Бишекләрен селкетсәң, үлмәсләр кебек. Макай кулларын суза, имеш. Әмма анда кадәр җитә алмый, алар сабый куллары кебек кечкенә, хәлсез.

Имеш, ул балаларның барысы да Туксаба авылы кешеләренеке икән?!.

Нинди саташу булды бу? Төш тә күрмәде бит Макай?!

Бу юлы болыт Кугуй урманы ягыннан килеп чыкты.

Кичәге тагын бер хәерсез шомнан айнып бетә алмаган иде әле авыл...

Кичәге көн башкасыннан искитмәле хәл белән аерылып тора: кичә Мирсәетләр килене Сәрвәр райүзәктәге бала тудыру йортыннан качып кайтты! Баласын тапмыйча, борынына кадәр җитә язган корсагын күтәреп, ташлап кайтты хастаханәне!.. Килен кайсыдыр якын буында ире – Мирсәетләр нәселе белән туган тиешле икән, ди! Алай гынамы соң: Мирсәетнең уйнаштан туган кызы, ди, Сәрвәр килен! Теге чакта Сәрвәрнең анасы Сәрбиназ оятыннан авылдан җәяүләп качкан булган!

Имеш, әлеге серне киленгә аларның гаилә хәлләрен яхшы белгән райүзәкнең Сөмбелә атлы бер хатыны чишкән, ди! Бала тудыру йортында туры килгән, ул да табасы икән... Моңа кадәр ник әйтмәгәндер, нәрсә карагандыр, мәлгунь! Бәлки, алай ук түгелдер әле? Теләсә нәрсә сөйләп йөрмәсә соң, теленә тилчә чыккыры!..

Бу авыл болай да яңа туган балаларның бишектә үлү очрагы буенча тирә-юньгә билгеле. Өстәвенә кайберләрендә ике-өч яшьтә аутизм чире килеп чыга. Җитлекмичә дөньяга килгәннәре күп. Табиблар бу хәлләрне генетика белән бәйләп аңлата.

Ни сәбәпле кан шулай дулый соң әле?! Соңгы вакытларда, бигрәк тә Башкала табиблары эш генетикада дигәч, сәбәбен туган белән туганның никахлашуыннан күрә башладылар. Ерак нәсел шәҗәрәсендә яки чагыштырмача өч-дүрт буындагы туганнар канының катнашуы бик яман нәрсә, ди... Ә бишенче буында, мәсәлән, килен буласы кызның малаеңа – нәселеңә кардәш икәнлеген ничек ачыклап була?! Һәм, киресенчә, кияү буласы ир-егет дүртенче буыныңда ук туганыңдыр әле, бәлки? Геннар бит буыннан-буынга тапшырылып килә!..

Шул рәвешле, төп сәбәп барыбер ачыкланып бетә алмады: чыннан да, серле генетика өлкәсенә килеп терәләме бу, ягъни туганнарның кан катнаштыруы галәмәтеме? Ни генә булса да, халык үз башына төшкән афәт-кайгылар аша үткәннәрне белү зарурлыгын аңлый башлады. «Тарихи әкиятләр»нең, ягъни ялган тарихның, дөрес булмаган шәҗәрәнең ничек куркыныч икәнлеге көн кебек ачык иде хәзер...

Әлеге яман хәбәрләрдән соң ташлап кайтты Сәрвәр килен бала тудыру йортын...

Алла язмаганны!.. Барыбер табасы бит инде аны!

Шуның артыннан ук Туксаба авылы халкын икенче бер яңа хәбәр аяктан егарлык итте: имеш, күрше Путанай авылы чиркәве нигезендә тагын хәзинә булырга тиеш! Хәзинә дигәне чүлмәкле алтын булмыйча (Путанай авылының Паратовлар малае теге чакта тапкан булган икән бит инде алтын тулы чүлмәкне!), ул – бу як авылларының гаилә-нәсел шәҗәрәләре, ди, имеш. Кайсы нәселнең кайсысына ничәнче буында туган икәнлекләре акка кара белән язып куелган булган, ди, анда. Чиркәүне сүтеп ташлап, нигезен генә актарасы, ди!

Иван Грозный башкисәрләре урлап киткән Казан ханлыгы китапханәсенең бер өлеше дә булырга мөмкин, ди, анда!..

Беренче хәбәрнең хаклыгы күз алдында – килен өйдә!.. Борынына җитә язган корсагы белән кире кайтты Сәрвәр!.. Киленнең Хәйдәровләр нәселе белән туганлыклары исә шик астында ди әле, чөнки Сәрвәр киленнең үз анасы бик еракта, кыз әнисенең бертуган апасында үскән!.. Әлеге гаилә Сәрвәр бишектә чакта ук Туксаба авылына читтән килеп урнашкан.

«Шәҗәрә, тарихи документлар чүлмәкле алтынга караганда да кадерлерәк, – дип сөйләп торган, ди, бригадир Мирсәет. Килен турындагы сүзләрне бераз булса да сүрелдерергә теләгәндер. – Менә шуннан соң чынлап та кемнең кемгә ничек туган икәнлеге беленәчәк! – дигән, ди, ул. – Шул ачыклангач, туган белән туганның өйләнешүенә чик куелачак, димәк, кан катнаштыру булмаячак, балалар сау-сәламәт туып үсәчәк!..»

Дөрләп янган учакка ут өстәде Мирсәетнең әлеге сүзләре.

Күп итеп көнбагыш үстереп, сугымлыкка ат асрап, Башкала шәһәре базарында айбагыр һәм затлы казылыклары белән дан алган халык сиксәненче еллар уртасында, яңа сәясәт башлангач, нәрсәгә ышанырга да белми.

Ләкин әлеге хәбәрләргә ышанмыйча буламы соң?! Теге чакта көтүче алтын тапканмы – тапкан, Мирсәет килене качып кайтканмы – кайткан!..

Шулай булгач, ышанмый да хәлең юк...

Чиркәү Туксаба авылыннан ерак түгел, борын заманда аны күрше русларга татарлар салырга булышкан дип сөйлиләр. Ташландык һәм ялгыз булса да, мин монда дигәндәй, әле һаман мәслихләре кебек кукраеп утыра. Сиксәненче еллар уртасы җитеп, ил кайный башлагач, рус кешесе Гаврилов та Туксабада яңа мәчет салырга ярдәм итте. Әүвәл чиркәүне төзекләндерәм дип купкан булган ул. «Барыбер яшьләр тормый бит, безгә чиркәү нәрсәгә кирәк?!» – дигәннәр аңа Путанайда.

Моңарчы да ике авыл бер булып яшәделәр. Путанай яшелчә үстерде, Туксаба урысларга ипи пешереп ашатты, чөнки җитмешенче елларда ук колхоз авылда пекарня салып чыкты, аңарчы ипине Ханкала шәһәреннән ташыдылар.

Туксаба Сабантуйларын Путанай халкы белән бергә бәйрәм итте, кыскасы, ике авылның бары бергә, югы уртак иде. Урып-җыю вакытында Туксаба басуларында Путанай комбайннары да эшләде, кара көздә Путанайның кәбестә, чөгендер ише яшелчәләрен татар хатыннары алышты. Дөрестерме, юктырмы, элегрәк бер гает намазын Туксаба ирләре, хакимияттән качып, Путанай карчыгы өендә укыганнар, имеш!.. Булгандыр, чөнки гает алдыннан, коммунист Мирсәет Хәйдәровка ышанмыйча,

районнан партия вәкиле килеп, төн куна торган иде. Кичтән вәкил иптәшне Путанай көмешкәсе белән каты гына сыйлыйлар да, тегесе, иртәгесе көнне дә уяна алмыйча, гает вакыты үткәнне дә сизми.

Путанай урысы белән очрашканда, Туксаба татары, тегенең татарча сөйләшкәнен абайламыйча, русчага күчә торган иде...

...Теге чакта да халык бер шаулап алды. Кайберәүләр башта алтын табылуга бигүк ышанмаса да, соңыннан мәгълүм булды: Денис атлы көтүче малай, чыннан да, ул вакытта хәзинәгә тап булган. Денисның атасы Паратов Абрар ага моны беркемнән яшермәде.

Ошбу хәбәрләр Туксабадан күптән башын алып чыгып киткән ерактагы авылдашларга кадәр барып иреште. Туксаба авылы янындагы Ислемай таулары өстеннән йөзеп барган каурый болытлар да әлеге хәбәрдән соң, сискәнеп, тагын яңасы булмасмы дигәндәй, ары китәселәре килмичә, тау түбәсендә утырып торалар иде.

## Кара исемлек

Сәрвәр киленнең көмәнле килеш кире кайтуы күз алдында булса, табылдык турында исә бигүк җәелеп сөйләмәделәр, таралып китмәделәр, моны аерым кешеләр генә белде. Туксабаның Әлли дип аталган инеш артында туып үскән яшьтәшләр иң беренче булып ишетте.

Туксаба авылында колхозның үзәк утары – кәнсәләр, мәктәп, клуб һәм кибет урнашкан өлеше – «Кала ягы» (Ханкала шәһәренә шуннан барасы) дип аталса, Ислемай тавы итәгендәгесен «Әлли» ягы дип йөртәләр.

Авылга исем булган «Туксаба»ның килеп чыгышын да, мондагы тауларның нигә «Ислемай» дип аталуын да, «Әлли» атамасының кайдан икәнлеген дә беркем белми.

Һәм моңарчы белергә дә теләмәде...

Хәер, «Әллүкәй» дигәне дә бар әле бу якларда. Нишләптер халык әлеге исемнең кайдан килеп чыкканлыгын онытмый. Мәгънәсен олысы да, кечесе дә шартлатып әйтеп бирә ала. Күл, елга, тау исемнәре һәм башка атамалар сер булганда, чишмә исеме һәркемгә мәгълүм булсын инде?! Урман чишмәсе ул. Изге икәнлеге дә билгеле. Чишмә Тәбәнәк тау дип аталган урман аланында.Төрле яктан юкәлек, өрәңге, карама һәм каенлык белән әйләндереп алынган, ләкин урман авызында – бу Тәкә елгасы яры – зур ачыклык бар, җил шул яктан искәндә, агачлык колакка ятышлы көй чыгарып шаулый. Нәкъ шуның аркасында «Әлли» атамасы янына «Кәй-көй» дә кушылып, «әллүкәй» дигәннәр. «Әлли»гә тагылган «көй», бәлки, әүвәл «кое» булгандыр әле? «Кое»ның «көй»гә әйләнеп китүе мантыйкка сыя, әүвәл монда, урман уртасында, кое кебек чокыр булгандыр да аннары ул чишмә кебек кенә калгандыр, шул рәвешле «кое» «көйли» башлагандыр. Сакау-ялкау бит татар, гадиләштерә, сүзне тутырып әйтергә иренә. Тора-бара ошбу атама «Әллүкәй»гә әйләнеп калгандыр...

Район газетасында Туксаба халкын шаккатырган язма чыкты. «Әллүкәй»нең этимологиясе турында иде ул. Имеш, мари сүзе икән бу! Урманы мариныкы, димәк, чишмә исеме дә марича! Мантыйк юк түгел. Өстәвенә мари телендә «әкәй» («Экэй», «Окай») дигән сүз бар, апа-сеңелгә шулай диләр?! Автор моңа төпле мисаллар да китерә: «Тол, экэй, мемнан

деке, ме тыланет шулдырым пуэна. (Кил безгә, апа (сеңел), без сиңа канатлар бирербез!) Ик совлам ала пуэт, Марина экэй? (Бәлки, бер кашык бирерсең, Марина апа?)». Хатыннар, апалар чишмәсенә бер ишарәдер бәлки?!

Ниткән Әкәй чишмәсе булсын ул дип тузынды туксабалар. Теге чакта әдәбият укытучысы Зөләйха ярдәме белән Туксаба авылының Әлли ягы малайлары Ямаш белән Солтан район газетасына язма да юллады. Турыдан ярдылар, бу сүз Тукайдан, «Әллүки»дән диделәр. Монда әкәйнең – мари хатынының – бернинди катнашы юк дип яздылар. Әйтелгәнчә, бу фикерне башта укытучы Зөләйха апа да куәтләгән иде, тик беркавымнан ул: «Егетләр, Чурахан абыегыз Ханкала архивыннан документлар соратып алды. «Әллүкәй» чишмәсе гасыр башындагы тарихи документларда телгә алына! – диде. – Ул чакта Тукай тумаган да була, димәк, аның «Милли моңнар» шигыре дә язылмаган, һәм Сәгыйть Рәмиев белән дә көрешү була алмый әле!»

Бу хакта үзләре генә белделәр. «Тумаган булса ни, язмаган булса ни! Туар да, аннары язар әле! Шуңа күрә дә Тукай бит ул!» – дип, борынын тартты Ямаш. Киләчәктә журналист булырга хыяллана ул.

Бары урман гына, чишмәнең челтерәгән тавышын үз көенә кушып, тирә-юньгә таратып утыруын белде...

Ә менә Тәкә елгасының исемен халык башта бөтенләй кабул итә алмаган иде. Борын заманда карасу дулкынлы бу ашкын елганың исеме «Агымсу-Аксу» булган диләр, рәсми кәгазьләрдә «Тэкэ» дип язылса да, чынлап та, элек аны күпләр «Ашкынсу» яки «Аксу» дип атаганнар, имеш... Күлтәк күленә кушылган урынында, дулкыннары кара сыртлы булганга «Аксу» дияселәре килмичәме, соңгы вакытларда «Тәкә» исеме дә телгә керә башлады. Мөгаен, борынгы заманда бабалары тәкә көтүен шушы елга буенда аерым көткәндер?.. Нигә борынгылар тәкәләрне сарыклардан аерды икән?

Бу табышмак ансат кына чишә алмаслык очы чуалган төен кебек иде...

Туксаба элек дүрт мәхәлләле искиткеч зур авыл булган. Инкыйлаб вакытында дүрт мәчетнең манарасын бер көн эчендә кисқәннәр! Дүртенчесенә менеп барганда, кисүче, ычкынып китеп, җиргә мәтәлә һәм шунда тончыгып җан бирә. Аллаһы Тәгалә каргышы төште Котбыйга дип сөйлиләр ул хакта сүз чыкканда...

Алайса, каргыш төшкән инде бу авыл халкына?!

Алла каргышы булса, бигрәк яман бит әле!..

Сәрвәр киленнең бала тудыру йортын ташлап кайтуы беренче хәбәрне оныттыра язды. Аеруча Мирсәет ага белән хатыны Мәдинә апа зур хафага калды. Киленнең табар вакыты җиткән, киткәненә атна була, көн саен онык туу хакында сөенечле хәбәр көтеп ятканда диген син!..

Ләкин Мирсәетне нәрсәгә булса да болай гына инандырырмын димә. Каргыш дигәннәре дә бик ышандырмый карт коммунистны. Киленнең «туганлыгына» да бармак аша карады; нинди кардәшлек, ди?! Күз алдында үскән кыз лабаса Сәрвәр!..

Әмма күңелгә шик керсә, аннан ансат кына котылырмын димә икән, кимерепме кимерә инде ул җанны. Бу юлы да шулай булды. Ошбу «корт»

Мирсәетнең шик-шөбһәле уйларын әле Тәкә елгасы дулкыннары кебек кайнатты, әле Ислемай тавы түбәсенә чаклы ук алып менеп китте, алар тау сыртындагы Әлли мәгарәсенә кереп югалдылар; андый чакта уйларның «койрыгын» тотарлык түгел, алар акылдан бәйсез була.

Белмәде бит татар моңарчы үзенең үткәнен: читтән килгән укытучы Чуракан Илдарханов (Аның үзенә монда исемен паспортындагыча «Чурахан» дип үзгәртмәүләре ошый, чөнки туган ягында да «х» ны «к» га алыштырып әйтәләр – Чуракан булып йөри. Гадәттә, башка укытучыларны фамилияләре белән атыйлар, аңа исә «Илдарханов» дигән кеше юк.) әйтмешли, милләт һәм нәсел шәҗәрәсен белә алмады!

Хәзер генә ул, берсеннән-берсе уздырып, һәркем шәҗәрә агачын ясый башлады. Әлбәттә, акчалы кешеләр, үзешчән тарихчыларны яллап, җиденче бабаларын мулла, морза яки берәр уңган бай нәселенә үк китереп териләр, шәҗәрә төзүчеләрдән шуны таләп итәләр. Моңарчы Мирсәет шәҗәрә белән кызыксынмады. Җиденче бабасының исемен белә ул, кайда яшәгәнлеге дә мәгълүм. Тик менә шуннан башкасы билгеле түгел лабаса?! Кем булган, балалары, туган-тумачасы, кыскасы, кавем хакында башка берни юк! Алтынчы бабасы турында да мәгълүмат юк, бишенчесе кем булган? Мирсәет имәнеп китте, хәтта дүртенче бабасы турында да җүнләп белми түгелме соң? Дүртенче баба бик якын бит инде канә! Ул чакта дөньяда нинди вазгыять булган?! Татар ни рәвешле гомер кичергән? Гыйлемле булганмы ул, яки, рус галимнәре тәкрарлаганча, дөм томанамы? Югалтулары, табышлары ни – кыскасы, тарихы нинди? Дүртенче баба әтисе Хәйдәрнең дәү атасы булган бит! Исеме Корбангали икәнлеге билгеле. Революция ясап йөргән, ди, Ханкала якларында. Шәхес культы заманында, инглиз шпионы дип, алып китеп япканнар. Юк бит шуннан ары хәбәр аның турында!.. Корбангалинең атасы Сәйфетдин хакында исә исеменнән башка берни билгеле түгел?! Тугандаш каннар кушылырга бик мөмкин бит?!

Мирсәет әлеге уйларыннан үзе дә көлеп куйды. Алай ук түгелдер лә инде!.. Алла язмаганны!

Карт коммунист Алла исемен еш телгә ала түгелме соң әле?!!

Алырсың да... Татарның хун-сөн ханлыкларына ук барып тоташкан борынгы тарихы турында кытай елъязмалары буенча инде китаплар да чыга. Ә менә якынрак килгән саен, тарих һаман томанлана бара. Хәтта Ханкала ханлыгы чоры да анык кына ачыкланып бетмәгән. Татар гомер буе томана инде, ул бары рус аркасында «кеше» булган дигәнен аларның гына түгел, укыганда хәтта балаларының да башларына чөйләп төяләр. Хәзер дә шулай. Кысык күзле, явыз монгол токымыннан булган алар!.. Татар – ул бары кушамат кына. Без – болгарлар!.. Себер татары аерым халык, нугайлар башка токым, мишәр дигәне бөтенләй Аурупадан ук килеп урнашкан!.. Керәшен тармагындагылары күктән төшкән, ягъни чиркәү башыннан «коелган»! Тора-бара русның диалекты ук димәсәләр аларын!.. Русның гаярь кенәзләре булмаса, эшләре харап икән белемсез һәм томана татарның... Тарих дәресләре шулай дип тәкрарлый...

Моңарчы, ул үзе әйтүенчә, «идиотлар идеологиясе» коммунист Мирсәетнең дә телендә иде. Ул үзе үк гомере буе шушы идеология өчен көрәшкән булып чыга түгелме соң?! Менә, тора-бара, әлеге буталчык тарих үзенә үк китереп бәрде!

Миңа кагылмый ул һәм кагылмаячак дип, безгә катнашы юк андый сәясәтнең, мондый вазгыятьнең дип йөр син!..

Шулчаклы итеп бәрде бу аның гаиләсенә, югыйсә кем уйлаган ул чакта Үзәк Хөкүмәт алып барган ялган идеология, берзаман аның капкасыннан да килеп кереп, күсәге белән хуҗа кешенең маңгаена тондырыр дип?..

Йа Алла!..

Йа Алла дими хәлең юк. Каенанасыннан яшерен сере буламыни, ул кайтуга, эчке хәсрәтен тутасына түгел (Авылның Кала ягында әнисенең сеңлесе тәрбиясендә үскән кыз бит ул!), нәкъ менә Мәдинәгә чиште:

– Әнкәй, мин анда өч көн рәттән бер төш күрдем! Куркыныч төш! Бала бик елак булачак икән, имеш!

Кыз баланың елак булуы бу якларда яңалык түгел. Елый-елый, күз яшьләренә буылып, бишектә үк үлү очраклары күп!..

Мәдинә аның бу сүзләрен көмәнле киленнең җаны чуалган чак белән бәйләде. Әмма тегесе:

– Әнкәй! Төш тә түгел иде бугай ул мин күргәннәр! Уяу яттым бит мин! Тәгаен менә, әни!.. – дип өзгәләнгәч, тегесе куркуга калды. Җитмәсә, килен: – Әнкәй, миңа ул төштә кемдер, балаңны монда тапма, авылыңа кайт, шунда тап дип пышылдады.

Әлеге сүзләрдән соң Мәдинә куырылып килде, әмма башта иренә дә сиздерәсе килмәде, һаман да шул күңел чуалуыдыр дип уйлады. Кем пышылдасын, ди, инде аңа! Булмаганны!..

Әгәр киленнең әйткәннәре чын булса?! Беркөнне Мирсәете сөйләп торды, имеш, алар гаиләсе дә теге чакта манаралар кискән Котбый кавеме белән чыбык очы гына бәйле булырга тиеш икән! Каргыш яман нәрсә, бигрәк тә ул Ходайдан булса, җелегеңә үк үтеп керә икән, ди!.. Җиденче буыныңа кадәр... Тагын да арырак китмәсә әле...

Димәк, бүген бар авыл Ходайның «кара исемлегендә»...

Тик нигә хастаханәдә тудырырга ярамый баланы?! Нишләп авылда табарга куша?!

Шайтан үз вәсвәсәсен салып өлгергәндер әле киленнең күңеленә!

Бәхеткә, Туксабада кендек әбисе бар иде, Мәдинә аның катына йөгерде. Әби аны тынычландырды, үз тормышыннан берничә мисал сөйләде һәм шуннан соң баланы авылда табарга дигән уртак бер карарга киленде...

Мирсәет ага да әүвәл күтәрелеп бәрелмәкче иде, хатыны Мәдинәнең бер сүзе җитте, ул тынычланды һәм, гадәтенчә, иңбашларын гына сикертеп алды да өнсез калды. Хатынның сүзләре ышандырырлык иде, имеш, килене каенанасына:

– Әнкәй, анда беркөн дә торасым юк бүтән! Мин бит шәп-шәрә килеш ятам. Колга буйлы яшь бер студент-практикант өстемдәге җәймәне ача да карый, ача да карый! Бушка кино күрсәтәләрмени! Үзе бер сүз дә әйтми! Күз тидереп бетерде бугай инде, – дигән. Теге төшне яшерделәр инде... Мондый карарны Мәдинә шайтан вәсвәсәсе белән түгел, нәкъ менә киленнең оялчан холкы белән аңлатты. Мирсәеткә дөресен әйтсә, ул – коммунист кеше, икесен дә пыр туздырып атачак һәм бала тудыру йортына кире озатырга да күп сорамас. Талканы коры аның...

Аптыраганнан суям, кәҗәкәем, диләр бит әле, бу юлы да шулайрак

килеп чыга бугай: Мирсәет агай үзен генә юата яисә киленне генә аклый сыман. Әнә анда Вәиснекеләр бала табарга тиешле киленнәрен Башкала шәһәренең үзенә үк илтеп куйганнар, табибка күп акчалар түлиселәр, ди. Имеш, анда табиблар яхшы икән! Вәис карт әйткән, ди: «Быел айбагар уңышы күп булачак, акча кызганмагыз, кирәк булса, Американың үзенә җибәрәбез», – дигән, ди, имеш. Алар гаиләсендә өч баланың икесе акылга зәгыйфь туды. Берсе генә бар яктан да җитеш: Мирсәетнең үз малае Солтан белән яшьтәш Сәрдәре, Аллага шөкер, менә исән-имин килеш үсеп җитте...

Әлли ягындагы йортларда бер хуҗаның да кибәне туры түгел. Якубның олы кызы өйдән үк качып китте, хәзер Ханкала шәһәрендә фахишәлек юлында, ди. Гөлшат – Якубның беренче хатыныннан туган иң өлкән баласы. Өстеннән йөри башлагач, хатынны шундук аерып җибәргән иде. Кызын үзенә алып калды. Хәер, хатын баланы даулап та маташмады, үз юлы белән китеп барды. Рәхәтлән инде хәзер чит ир-ат кочагында дип калды аның артыннан Якуб. Дөрес әйтте, чөнки теге игә килә торган түгел. Килен булып төшкәннең икенче көнендә үк: «Минем самавырым гел кайнап тора. Ташларым гел кызган!» – дия торган иде. Күрәсең, ире генә суытып бетерә алмаган ул ташларны. Кызы Гөлшат та шул юлдан тәгәрәде. Үсеп җитеп, җиләк кебек пешүгә, суга киткән җиреннән дә кем белән туры килсә, шуның белән чуалып кайта, һәм шул көнне үк моны Якубка җиткерәләр. Тора-бара кыз узгынчы машиналарга утырып йөри башлады. Берсендә шулай атна буе югалып торды. Анасы янына киткәндер дип юаткан иде үзен Якуб. Тик Гөлшат Ханкалада ирләр тулай торагында яшәп алган булып чыкты. Игә китереп булмады аны. Анасының каны иде. Һаман да шул кан! Кан һаман да!..

Якубның ул хатыны өченче буын туган иде... Яратышып өйләнештеләр. Кеше буларак та әйбәт иде ул. Хәтта бик әйбәт иде. Тик «ташлары гына суына» алмады бахырның. Тора-бара аны каядыр Башкала шәһәре ягына китеп югалган дип сөйләделәр. Геннарның мутациясе белән аңлата моны укытучы Чуракан. «Физик сәламәтлек белән рухи тазалык икесе бер шүрлектә», – ди ул акыллыбаш. Шөкер, икенче хатыныннан туган малае Ямаш, бик хыялый булса да, физик яктан сәламәт Якуб кордашның. Ә менә кечкенә кызы – яңа туган сабыйлары озак яшәмәде...

Мирсәетләрнең үзләрендә дә хәзер шул ук хәл.

Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына дигәндәй, Мирсәетнең капка төбенә Путанайның Гавриловы килеп туктады. Киленнең бәби алып кайтасын ишеткән дә шул хакта сөйләшергә килгән. Гаврилов – тумышы белән Путанай дигән рус авылыннан булып, бүгенге көндә Ханкала читендәге бик зур комбинатта генераль директор. Аларның әтиләре үк дус булган. Дуслык балалары арасында да дәвам итә, йөрешә, аралашалар иде. Гаврилов машинасыннан төште дә аны капка төбендә каршы алырга чыккан Мирсәеткә сәлам дә биреп тормады:

– Әйдә, кайда киленең? Ханкалага җибәрәм! Хәзер үк монда вертолёт чакыртам да! – диде. Һәм фикерен дәвам иттерде: – Ханкалага гына риза булмаса, чартер заказать итәм. Самолёт белән! Башкаланың үзендә тапсын!

Мирсәет, аптырап, иңбашларны сикертеп куйды. Бу вакытта аларның капкасына кендек әбисе Шәкәр түти якынлашып килгәне күренде. Ул ирләрнең ни хакында сөйләшкәннәрен аңлады булса кирәк:

– Монда гына табарга уйлаган икән, кыстамагыз. Киленнең сүзенә каршы килергә ярамый. Күз тия, ди, бит үзе. Корсаклы хатын бик нәзберек була ул. Курка торгандыр, – дип, өйгә кереп китте.

Шәкәр әби Мирсәетнең генә түгел, Гавриловның да кендек әбисе иде. Шуңа күрә әүвәл аның бу сүзләреннән икесе дә каушап төште. Мирсәет тагын иңбашларын сикертеп алды. Гаврилов каты итеп тамак кырды һәм, Мирсәетнең риза булмаячагын аңлап, машинасына таба китте.

**Кан...**

Сәрвәр яшь чакта көзге алдына басып: «Мин кемгә охшаган? Сәрбиназ әнигә охшаганмы?» – дип сорый иде. Сабира әнисе фәрештә кебек изге кеше, бер каты сүз әйтмәс, «балам» дип өзелеп тора ул. Бу юлы да: «Патша кызы кебек син, кызым!» – дип күңелен күтәрә. Кызның маңгай чәче матур булып бөдрәләнеп тора, ул бөдрәләре бары алда гына. Бу Сәрвәрнең үзенә дә бик ошый, бизәнгәндә-ясанганда, ул әүвәл шул бөдрәләрен күпертә, күзгә чалынсыннар дип, алга ук чыгарып куя торган иде. Кыз тагын: «Сабира әни, Сәрбиназ әнинең дә шундый бөдрәләре бар идеме?» – дип сорап куя. Сабира әни алдамый, дөресен әйтә: «Юк, кызым, безнең Сәрбиназның чәчләре бөдрә түгел иде. Кыз бала, гадәттә, атасына охшап туа», – ди.

Кайнатасы Мирсәеткә әнисе хакында сүз кушып булмый; кая ул, шул хакта авыз ачуга тегесе сүзне гел читкә бора, алай гына да түгел, карашын ук яшерә. Әйтерсең Туксабаның Кала ягы кызы Сәрбиназны ишеткәне дә юк! Югыйсә замандашлар бит алар, тугыз-унны Ханкала читендәге бистә мәктәбенә бергә йөреп укыганнар. Ул заманда хәленнән килгән кеше баласын рус мәктәбенә биргән, шулай итсә, баласы кеше булыр дип уйлаган...

Әйтәсе калган икән каенатасына әнисе турында...

Башы чуалган чак. Шул чуалган башта төрле уйлар ыгы-зыгы килә, зыр-зыр туглана уйлары. Сәрвәр әүвәл аларны рәткә китерергә азапланды. Иң кыены чуалганнан тәртип ясау икән...

«Тынычланырга кирәк башта» дип уйлады яшь килен. Һәм хәлне азагына кадәр тагын бер кат саф акыл аша уздырырга тырышты. Әнисе турындагы өзек-төтек хәбәрләр дә томан эчендә калды.

Имеш, баласы Миргалидән түгел, ди, малайның атасы каенесе икән бит!

Сәрвәр куырылып килде. Дөрес бит бу!.. Көмәне шактый беленә башлагач, ире Миргали Солтаннан, идән уртасына басып, җырлавын үтенә иде. «Энем, минем колакка аю баскан, ә син матур җырлыйсың! Җырла әле минем малай өчен!» – ди торган иде. Баштарак моны барысы да көлкегә алалар иде. Беркөн Солтан: «Җырлыйм, алайса», – дип риза булды һәм, сузып-сузып, бик матур җыр башкарды. Моңарчы эчендә арлы-бирле тугланган бәби шуннан соң тынычланды, бик сирәк кенә әллә аяклары, әллә куллары белән төрткәләп кенә ала. «Музотерапия!.. – дип авызын ерды Миргали, сиксәненче елларда телгә керә башлаган психологик төшенчәне авыз эчендә әйләндереп. – Чит илдә күптән кулланалар инде аны. Без мокытлар гына белмибез!»

Тагынмы? Тагын шул: балага узгач, Сәрвәрнең бик тә кызыл бөрлегән ашыйсы килде. Тик ул бөрлегән Әлли мәгарәсе янындагы куаклыкта

үскән булырга тиеш икән – кыз чакта шунда җиләккә йөри торганнар иде. Миргали, үзенең вакыты булмагач, энесеннән бөрлегән алып кайтуын үтенгән иде. Каенесе җиңгәсенә Ислемай тавыннан тәлгәше белән кып-кызыл бөрлегән алып төшеп бирде.

Туксабаның Әлли ягында гына түгел, Кала ягында да Шәкәр әбинең җиңел кулы белән дөньяга килгән балалар күп. Көмәнле чакта төрле төшләр керә инде ул. Тик киленнең бу төше бик сәер тоелды карчыкка. Аптыравын сиздермәскә тырышты күпне күргән кендек әби, әмма Сәрвәр аңа тулы исеме белән: «Маһишикәр апа» дип эндәшкәч, тагын бер аптырады. Аның тулы исемен авылда берәү дә белми; хәер, өлкәнрәкләр элек «Маһишәкәр» дияләр иде диюен, әмма аның метрикәсендә, чынлап та, «Махишикэр» дип язылган; ул туганда кәнсәләр Путанай авылында була, андагы исерек авыл сәвите сәркатипләре татар исемнәрен үзләре теләгәнчә бозып язганнар. Шәкәр әби, әллә ялгыш ишеттемме икән дигәндәй, килен ягына борылып карады, әмма сүз катмады. Тегесе тагын «Маһишикәр» дип эндәште, бу исә әбине бераз шомландырып куйды; шуның белән ишеткән төш тә аңа сәер шикелле тоелды. «Әллә?!» – дип уйлап куйды карчык шулчак, мизгел эчендә Мирсәет килененең авыл телендә йөргән мәхәббәт хәлләре исенә төште.

Кала ягы кызы Сәрвәр белән Миргали бер сыйныфта укыдылар. Укыганда ук мәктәптә иң чибәр кызларның берсе иде ул. Озын толымнары, кара шомырт кебек зур матур күзләре, зифа гәүдәсе бар малайларны әсәрләндерсә дә, башка кызлар кебек чәчрәп тормый; читләрдән матур күзләрен дә, сихерле карашын да яшерергә тырыша. Шуңа карамастан Миргали аның карашында ниндидер яшерен сагыш барлыгын күрә. Дөрес, бу аны тагын да матурлый гына. Кыз-хатын, карашында сер-сагыш булса, матур. Миргалинең бик тә шул сагыш эченә кереп адашасы килә. Әмма оялчан Миргали Сәрвәргә күптән кызыгып йөрсә дә, сүз кушу түгел, озата барырга да кыймый; эчтән сыза егет. Берзаман Миргали Сәрвәрне энесе Солтан озата барган дип ишетә. Бертуганының изүеннән эләктерә дә күтәреп селки. Тегесе шундук аңлый инде. Баксаң, елгыр энесе кыз артыннан Кала ягы егетләре чабулый башлаганын сизеп ала, кечкенәдән сугыш чукмары булган Солтан, йомшак холыклы абыйсын коткарырга теләп, Сәрвәр апасы артыннан үзе китә; Кала якларының эзләре суынгач, абыйсына юл бирә, имеш...

«Әллә?! – дип шикләнеп уйлады Шәкәр әби. – Белмәссең тагы... Хәзерге яшьләргә ышансаң!.. Чибәр җиңгәсенә күзе төшкән булса яшүсмернең?..»

Шәкәр әби үзенең колак яфрагын чеметеп алды: уян, янәсе, төрле яман уйларыңны куалап җибәр яныңнан. Син дөньяга килергә ярдәм иткән балалар, барысы да бер гөнаһсызлар... И әби, әби... Өстәвенә кендек әби әле тагы үзең...

Ләкин киленнең күргән төше бер каптырмалы гына түгел. Нишләп мәгарәдән чыккан кеше гарип бала туу куркынычы хакында кисәткән?! Салават күпере, имеш... Хәзер андый әкиятләргә яшьләр генә түгел, әбиләр дә ышанмый инде. Әмма һәммәсе дә бер хакыйкатьне белә: балалар гарип туа... Котбыйга төшкән каргыш та бар бит әле...

Алла сакласын инде!..

Туксабаның ата коммунисты булган Мирсәеткә төш турында сөйләргә

шүрләделәр... Бер дә дөрес эшләмәде инде болар куркып. Мирсәет коммунист булса да, утын агачы түгел – күреп тора. Миргалие Туксаба кызын алып кайтып утырткач (әүвәл таныштырырга алып килде), җаны бер кузгалып алган иде – кызны кемгәдер охшатты Мирсәет. Теге чактагы «шик-корт» галәмәтедер инде бу!.. Тик кемгә охшата? Кемне хәтерләтә бу сөйкемле кызның көлүе? Тавышына кадәр таныш кебек... Шул көнне үк кыз хакында тагын белешмә алды. Туксабаның иң тәртипле гаиләсендә тәрбияләнеп үскән бала. Монда каяндыр – Башкала якларыннан икәнлеген соңрак белде – күченеп кайтканнар, атасы алтын куллы эретеп ябыштыручы; аны колхозда шунда ук күтәреп диярлек йөртә башладылар. Өстәвенә, техникага кулы ята, трактор моторының тавышыннан белә кай җирендә гаеп бар икәнлеген!

Мирсәетнең йөрәгенә теге чакта ук кара кан сауган иде инде... Хәер, табиблар ул хакта каян белсен?.. Бу турыда Туксабада да сирәк кеше генә хәбәрдар. Сәрбиназны, Кала ягының озын толымлы коңгырт күзле гүзәл Сәрбиназын, авыл хәтерләми дә торгандыр инде... Мирсәетнең йөрәк сере ул...

## Йөрәк сере

### Беренче хикәят

Туксаба авылының Әлли ягында яшәүче Мирсәетнең йөрәк сере хакында хатыны Мәдинә дә белеп бетерми. Хәер, кемгәдер мәгълүм икән, сер булмый инде ул! Яшь чакта әлеге серле йөрәк Сәрбиназ атлы кыз дип дулаган иде. Коңгырт күзле, сихри карашлы Сәрбиназ төскә-биткә генә чибәр түгел, гәүдәгә дә бик сылу. Көлүе көмеш чишмә чылтыравы кебек, тавышы аһәңле, кайчак сихри күзләре моң белән тула да кызның карашы сине үзенә бәйләп куя, ул серле карашның ниндидер гайре табигый тылсымы бар сыман. Авылда Сәрбиназга олысы-кечесе гашыйк иде, шул матур кыз дип хыялланмаган егет-җилән булмагандыр.

Менә әлеге гүзәл зат, буй үстергәч, Мирсәетне үз итте. Башка егетләрне якын җибәрмәде, үзенең серле карашын бүтән беркемгә дә бүләк итмәде. Кала ягының участок милиционеры Салихҗан малае Хәмит кызны үзенә карату өчен ниләр генә кыланмады. Хәмит атлы бу малайның мәктәп тәмамлаганда да чын исеме бар кешегә мәгълүм түгел, аңа шүрәлегә охшаган кыяфәте аркасында «Шурулла» кушаматы тагылган, җитмәсә, ул куркусыз бер сугыш чукмары. Хәмитнең куллары шүрәленеке кебек озын, сугыша башласа, сүз белән мавыкмый, хәзер ияк төбеңә менеп төшәргә әзер тора. Хәмитнең күзләре майлы, алар гел ялтырый, шуңа күрә аның кайчан һәм ни өчен синә китереп тондырасын алдан белеп булмый. Үзенең кабыргалары беленеп тора, ябык, зур куллары гел сөяктән генә. Мәктәптә укыганда ук, даны башка яктан да чыккан иде Хәмитнең, ун ел буена ул бер генә дәрестә дә җавап бирмәде, өй эшен сөйләп күрсәтмәде. Укытучы сораган чакта да, башын аска иеп, әмма каш астыннан усал итеп карап, тик басып тора иде. Укытучы орышса яки «икеле» чәпәсә, шул көнне үк аның малаен йә берәр туганын тотып кыйный иде. Аның өстеннән яуган әләкләрнең барысы атасы кулыннан уза, алар һәрчак җавапсыз кала. Фахишә анасы аркасында болай да үзен ким-ятим итеп хис иткән малаена

кулы күтәрелми тегесенең. Кызгана, җәлли инде үзенчә... Дөрес, Хәмитнең халык теленә кергән уңай яклары да бар.

Салихҗан милиционер Хәмиткә ун яшьләр чагында хатынын куып чыгарган. Ул хатынын зина кылганда тоткан һәм күп сөйләшеп тормаган, ике бала анасын өеннән сөргән. Ир-ат кисәгенең дә кем икәне мәгълүм: Салихҗанның Ташкаладан кунакка кайтып йөргән туганнан туган абыйсы. Партиянең Төбәк Комитетында кемдер булып эшләгән бу кеше беркайчан да өйләнмәгән. Электән энесе Салихҗанның хатынына кызыгып йөргән икән, мәлгунь.

Йорттагы бар хезмәтне Хәмитнең сеңлесе башкара. Әниләре балаларын үзенә кайтару өчен йөреп караган, әмма шул чакта Хәмит: «Без синең белән яшәмибез! Өйдәге телевизорны да алмыйсың, мотоцикл да безнеке!» – дигән, ди, имеш. Сөйлиләр инде. Алай дип әйткәндерме, юктырмы?.. Хәер, бу Хәмитнең холкына туры килеп тора, аннан көтәргә була.

Шурулла Сәрбиназга беркайчан да мәхәббәт аңлатмаган, клубтан озата бармаган. Берәрсе кызны капка төбенә чаклы озатып куйса да, әүвәл артыннан куып җитеп, теге малайны тотып кыйнаган, аннан соң ишегалдына койма аша гына сикереп төшеп, кызны чакырып чыгара икән. Әлбәттә, Сәрбиназ аяк терәп каршы тора, күрешү түгел, Хәмит белән сөйләшергә дә теләми. Шурулланың холкын белгәнгә күрә, Сәрбиназны озата баручы булмый.

Бер дә бер көнне андый батыр егет табыла. Әлли ягыннан Хәйдәров Мирсәет атлы көрәшче була ул. Мирсәет Әлли ягында гына түгел, Туксабада беренче егет! Инде күптән авыл мокыты түгел, райүзәктә комсомолда эшли. Районга комсомолга керергә барган кызны бер күрүдә ошата ул. Тыныч кына аның мәктәп тәмамлаганын көтә. Ә менә Туксабаның Кала ягы Хәмите көтеп тормый: Сәрбиназ артыннан чаба башлый. Ләкин кызны унынчы сыйныфны тәмамламый торып клубка чыгудан тыялар.

Кыз мәктәпне тәмамлаганда, Мирсәет инде басыла төшкән була. Әмма Хәмит һаман Сәрбиназ дип яна икән әле. Кыз капкасын каравыллый. Ул шул рәвешле очып йөргән көннәрдә Сәрбиназ Мирсәеткә кош теле чаклы гына хат язып җибәрә, Ханкалага укырга керергә теләгән кызга комсомолдан тәкъдимнамә кирәк икән. Кирәкле кәгазьне Мирсәет Туксабага үзе алып кайтып бирә. Сәрбиназ алма кебек булып пешеп җиткән. Кичен алар очрашырга сүз куешалар. Тик арага кара мәче булып Шурулла керә. Бары Шурулладан өстен чыгу өчен генә Мирсәет көн дә кыз янына кайтып йөри башлый. Туксабада аны җиңәргә тиешле кеше әле тумаган дип фикер йөртә ул, Хәмитнең арага керергә теләве аның горурлыгына тия. Шурулла да – Мирсәет кебек үк Сабан туе батыры. Гел сөяктән генә торган Хәмит-Шурулланы берәү дә аста калдыра алмый. Менә Мирсәет белән көрәшәләр. Мирсәет, озын буйлы спортчы егет, алып чөя тегене. Менә шуннан соң Сәрбиназ мәсьәләсе тагын да куера, Шурулла Мирсәетнең кыз капкасы янына килгәнен каравыллап йөри башлый.

Очраша болар. Сәрбиназларның капка төбендә була әлеге хәл. Ике егет якага-яка ябыша. Шурулла ярдәмгә дусларын да чакырган була. Үзенең җиңеләсен сизеп, сугышның иң кызган чагында, тегеләргә ым сала, һәм дуслар йөгерешеп килеп җитә. Шулчакта Сәрбиназ, капкасын ачып,

сөйгәнен ишегалдына тартып ала. Төне буе каравыллыйлар, чыкканын көтәләр Мирсәетнең. Кыз егетне мунчада кундыра. Иртәгесен исә Мирсәет Сәрбиназны качыра. Шурулла гомерендә беренче мәртәбә Әлли ягы малаеннан җиңелә. Бу хәл атасы Салихҗанның да эчен пошыра. Хәмит кызны, чынлап та, яраткан була. Ашаудан баш тарта, көннән-көн кибә, саргая сугыш чукмары. Аптырагач, Салихҗан кызны үзе эзләргә керешә, әмма файдасыз, Сәрбиназ суга төшкәндәй юкка чыга! Кызны качырырга Мирсәетнең әтисе Хәйдәр абзый ярдәм иткән була.

Ике гаилә арасында бик озак елларга сузылган низаг башлана. Низагның уртасында урманчылар торганын да белеп ала Салихҗан. Милиционер булсаң да, мари урманчысына каршы бара алмыйсың – мондагы законнар Мари ягында да шул ук булса да, урман кануннары караңгы, аларга каршы бару – үлемеңә таба беренче адым. Соңгысы булмаса... Кугуй да, Хәлүш тә, кеше буларак, искиткеч гаделләр, өстәвенә алар кулындагы урман бу якларны җылыта, ашата, эш бирә.

Салихҗанның Ханкалада зур урында утырган туганы Абтюковка да ялынасы килми. Ул бәндә хатыны белән чуалып, фаш ителгәннән соң да әле һаман энесе белән араларны көйләмәкче була булуын. Әгәр сүз катса, кулыннан килгәннең барысын да эшләячәк. Әмма Салихҗанның горурлыгы ирек бирми, Хәмите саргаеп, кибеп бетә язса да, Абтюк катына аяк атламады.

Хәмит, Сәрбиназ югалгач, үзләренең лапасларына кереп асылынды...

Салихҗан гомере буе моңа үкенеп яшәде... Мирсәеткә, Хәлүшнең асрамага алган малае Абрарга һәм кызны яшерергә атын биреп торган Вәискә булган үче йөрәгендә кара кан булып укмашты...

...Сәрвәрнең каенанасы Мәдинә апа исә килене күргән төшләрне укытучы Зөләйхага да сөйләде. Зөләйха – Сәрвәрнең чыбык очы, ләкин алар кан туганнар түгел. Шулай да аңа сер сыя. Ирең Чураканга сиздерә күрмә дип, бик каты кисәтте...

Мәдинә лакмус кәгазе кебек: уйлаганы хәзер йөзенә чыга, күпме генә яшерергә тырышса да, хәзер сизә Мирсәет аның бу халәтен. Үз җаны тулы борчу булуга кармастан, андый вакытта хатынын тынычландырасы килә. Дөресрәге: «Мәдинә, алай бик бетерешмә әле... Җайланыр... Сабыр булыйк!..» – дип хатынын юатуы үз күңелен дә урынына утыртырга тырышу иде.

– Нәрсә уйларга да белгән юк инде, Мирсәет, – ди Мәдинә, иренең сүзләренә каршы. «Мирсәет» дип, исеме белән эндәшүенә тегесе сискәнеп китә, чөнки алар бер-берсенә күптән исемнәре белән әйтешмиләр. Бер-берсенең сулышыннан да ни әйтергә теләгәннәрен белеп яшиләр.

Аның исемен болай матур итеп, үзенә аерым бер көйле мәкам белән Мәдинә генә әйтә ала. Һәм Сәрбиназ... Мирсәет Сәрбиназ турындагы уен читкәрәк «этәрде».

– Сабыр булыйк, – диде ул тагын бер мәртәбә хатынына. Мәдинә, ризалашканын аңлатып, күз сирпеп алды, син әйткәч, шулай итәрбез инде, янәсе.

Укытучы Чуракан берәр әмәлен табар, һәрхәлдә, аның белән киңәш-табыш итү җепнең очын эләктерергә ярдәм итәр шикелле иде.

## Чуракан

Чуракан-Миутынның үз мәшакате дә муеннан ашкан булса да, элеккеге зур түрә һәм тирә-юньдә абруй казанган кешенең сүзен аяк астына салып таптый алмады. Хәер, Мирсәет ага әйтмәсә дә, үзе дә күптән архивларда эзләнә укытучы Чуракан. Бу якта балаларның тиктомалдан үлеп китү мәсьәләсе аны да борчый. Мәсәлән, моннан йөз-ике йөз ел элек мондый хәл булганмы? Мәгълүмат кайда да булса сакланырга тиеш бит!..

Теләсә нәрсә әйтсеннәр, ышанмый монда йөргән сүзләргә Чуракан! Тамчы да ышанмый! Мутацияне дә, хромосомалар турында да яхшы белә ул, туганнан туганың, бәлки, өченче туганың белән никахлашырга ярамый торгандыр! Әмма дүртенче, бишенче буында кан катнашу шундый афәткә китерәме икән соң?! Мәсьәләне артык куерталар бугай... Тик Мирсәет Хәйдәровка алай дип булмый бит. Каргыш турында да кистереп әйтә алмый. Күз тию, каргыш, нәзер дигәннәре пәйгамбәр заманыннан ук килә. Чураканның, шәҗәрәләрне өйрәнеп, Котбый нәселенә барып тоташкан гаиләләрне бик тә ачыклыйсы килә. Бу нәсел кешеләре бер-берсе белән туганлашырга, ягъни кыз бирешергә, малай өйләндерергә тиеш түгел...

Химия белән биология фәнен үзләштергән Чураканның шундый фикердә булуы гаҗәп инде, әлбәттә. Имеш-мимеш, ырым-шырым укытучы кешенең дәрәҗәсен күтәрми. Ләкин нишләсен, әле моңа чаклы бер генә дөньяви фәннең дә каргыш дөрес нәрсә түгел, күз тиюгә дә, нәзер дигәннәренә дә ышанмагыз, алар фән белән расланмаган дигәне юк. Атап бу хакта кисәткәне юк... Күренекле галимнәр дә әйтергә кыймый, хәтта кайберсе үз теләге белән ислам динен үк кабул итеп куя...

Сәрвәр – күңел хәтеренең бер читендә якты сурәт. Әйе, сурәте нәкъ менә якты иде, хәтта нигәдер бик якты булып тоелды аңа... «Җизни» дип шундый матур итеп әйтә ул, шул чакта бик рәхәт була. Беренче карашка, бала тудыру йортыннан качып кайтырлык дуамаллыгы да, сәерлеге дә юк кебек сөйкемле киленнең. Баласын хастаханәдә табарга теләмәве гаҗәпләндерде аны. Сәбәбен үзеннән сорашасы килде, бу аның өчен бер ачкыч булыр сыман иде. Алар катына тиктомалдан ничекләр итеп барасың? Җитмәсә, Зөләйхасына туган тиешле гаилә дә әле...

Чуракан авылга үзе белән үзешчән тарихчы, телчеләрне дә ияртеп кайта. Күрәсең, чын галим-голәмәнең вакланып торасы килми. Аларны эшкә тарту өчен гонорар кирәк дигәч, Путанайның Паратов дигән кеше түләргә дә ризалашкан иде; бары эшләсеннәр генә: авыл тарихын тапсыннар, гаиләләрнең нәсел шәҗәрәләрен эзләсеннәр. Тик ул вакытта Чураканның үзенең зурдан кубасы килмәде бугай.

Менә Сәрвәр гүзәлнең гамәле тагын әсәрләндерде әле... Хәер, гамәлеме, әллә сөйкемле килен үземе икән?

Бу як сөйләше ни мишәр диалектына, ни башка бер сөйләшкә охшамаган; үзенчә ул, башкалар белән һич чагыштырырлык түгел. Тора-бара әлеге сөйләшнең Ака елгасы буенда яшәгән Касыйм, Мордовиядәге, Сармат ягындагы татарлар сөйләше белән охшаш икәнлеген белде Чуракан. Әмма бу тәгаен түгел иде. Ханкалага нигез салган беренче хан дәүләт чикләрен саклау өчен монда казакларны чакырткан дигән хәбәрләр дә йөри. Мәсәлән,

«Өлә» дигән атама тикмәгә кайбер авылларга исем булып ябышмагандыр... «Өлә, ола» мари телендә «шәһәр» дигән сүз; димәк, борын-борыннан анда яшәүче угро-фин кушкан исем... Борынгы төрки-татар телендә «казак» гаскәри, ягъни сугышчы икән.

«Кайсы Ука-Агымсу яки Туксаба ягы татары, кайсылары мишәр яки казак икәнлеген бер Алла белә!..» – дип, үзе дә аптырый Илдарханов андый чакларда. Тик башында тагын бер уй кайный: «Үзләрен кыпчак-төрки-мишәр дип йөргәннәрнең кыяфәте тач угро-фин (!) бит, зәңгәр күзләре, сары чәчләре, кызгылт чырайлары бер дә төркиләр файдасына сөйләми! Ә Туксаба татарлары (лыкырлар) нугай туганнары кебек киң чырайлы, мишәрләрнең төрки төркеме кебек үзгә сөйләш-телле булсалар да, угро-фин белән тамчы да кушылмаганнар. Миутын Илдарханов шундый нәтиҗәгә килә дә аннан соң үзе үк: «Тел гыйлеме белән минем кебек химиклар да, үзешчәннәр дә түгел, түрә-сәясәтчеләр дә түгел, чын белгечләр шөгыльләнсен икән ул!» – дип, үз-үзенә каршы төшә һәм авыр итеп көрсенә. Бу каршылыклы фикерләрен хатыны Зөләйхага да әйтми.

Аның каравы мәктәп директоры Чураканны, барыбер әкият сөйләргә дә оста син дигәндәй, тарих укытырга куйды. Тегесе читтән торып тарих факультетына укырга ук керде. Ханкалада чакта тарихчы күренекле академик Фазыл Шәриф белән танышып, дуслашып ук киттеләр. Чуракан белмәгәнен Фазыл абыйсыннан сорарга гадәтләнде.

Директор хак әйтәме, әкият дип шыттырамы – белгән юк; аның уенча, тарихка барыбер җитди фән итеп каручы юк, булган хәлләрнең барысы монахларның тәхеттәге патша әмере белән шәм яктысында язган әкиятләренә корылган, бала-чагага ярамаган тагын дип уйлады тегесе, химия укытучысы укытамы аны, әллә тарихчымы...

## Мәхәббәт дәрәҗә белән дә, тәрәзә белән дә исәпләшми

### Сыйныфташлар

Моннан байтак еллар элек Туксаба авылының Әлли ягы яшүсмерләре – бер сыйныфта укучы берничә малай һәм кыз – Күлтәк күле буенда «киләчәккә хатлар» язып күмде. Бу Тәкә елгасының күлгә койган биек ярлы урыны иде. Әүвәл учак яктылар...

Бер сыйныфта егерме бер кеше укысалар да, Әлли ягы яшүсмерләре ул чакта аерым җыелды. Солтан, Ямаш, Сәрдәр, Гафият һәм Зөлфәкарь янына тагын ике бөртек кыз Мәликә белән Ясминәне дә кушсаң, җәмгысы җидегә тула. Болар әти-әниләренең, башка нарасыйлар кебек бишектә үк җан тәслим кылмыйча, зур егет һәм кызлар булып үсеп җиткән йөрәк бәгырьләре иде.

Кызыл балчыклы яры бик текә булганлыктан, бу урын бик аулак җирдә. Ерактагы кашлакта, Путанай кырыендагы чиркәүдән арырак, көтү көткән Путанай малае Путята һәм аның сарыкларыннан башка беркем дә юк.

Чыгарылыш имтиханнарына әзерлек башланыр алдыннан сигезгә чаклы әдәбият укыткан һәм класс җитәкчесе булган укытучы Зөләйха инша яздырды. Тугыз-унда тел дәресләре укытмыйлар, директор рөхсәте белән үзе җиткәләгән сыйныфка программадан тыш керткән иде аны Зөләйха. Бу

җыелу шул иншаның шаукымы булды бугай: исәпләре, «киләчәккә хатлар» язып, Тәкә елгасы буенда үзләре генә белгән урынга күмеп кую иде.

Учак янына Зөләйха апаларын да чакырдылар.

Мәхәббәт, тәрәзә белән дә, дәрәҗә белән дә исәпләшмәгән мәхәббәт яшь белән санлашмый да санлашмый инде. Ләкин укытучының хикмәтле уй-гамәле моның белән генә бетмәгән. «Иншаларны бары мин генә укырмын, аннары яшереп куярсыз да, еллар узгач, бер-берегезгә укып серләшерсез», – диде. Тегеләренең фантазиясе тагын да көчлерәк булып чыкты, алар киләчәккә яшьлектән хат итеп язарга дигән карарга килделәр. Моңа яңа шартлар да өстәлде: Зөләйха апага укытмаска, вакыт җитмичә казып алмаска!..

Кызылъярга турыдан юл юк. Җәйләрен төнбоеклар үсеп утырган сазлы үзәнлек аша элек ат юлы узган диләр; күрәсең, якынрак булган инде ул. Машиналар казый-казый, анда хәзер чокыр хасил булган, кырыйларын тигәнәк басып алган. Анда мари урманчысы малае Макай сукмаклары бар барын. Әмма аларны Макай үзе генә белә.

Малайлар мотоциклы өчен Солтанны бигүк өнәп бетерми кайчакта, өстәвенә ул кыланчык матаена Ясминә белән Мәликәне икесен берьюлы утырта ала! Ләкин Ямаш Мәликәгә алдан ук үзем алып барам дип әйтеп куйган иде; кызның Ясминә белән бергә утырып барасы килми.

Нәкъ менә шул матайлар аркасында Әлли малайлары арасында көнчелек тә уянып ала иде. Бу хис кыш көне генә сүнеп тора, кыш барысын да тигезли, чөнки карлы юлдан матай белән йөреп булмый.

Гафият матай турында әнисенә дә әйтеп карады: «Бүген генә мотоциклны биреп торсын инде әти», – диде. Малаен һәрчак якларга әзер торган Гамилә апа Газинурын сүгеп үк атарга уйлаган иде, ләкин тегесенең Ямашның әтисе Якуб белән урманга барасы булып чыкты; диләнкә карап кайтырга уйлаганнар икән. Газинур агай яңа йорт җиткерергә исәпли, Гафиятләре үсеп җитте, кайчан да булса барыбер аны башлы-күзле итәргә кирәк булачак; Ташкалага барып укып кайтса кайтыр, әмма малай авылда яшәргә тиеш, аның яңа ачкан «Тимер» кооперативы малайга калачак бит! Гамилә апа да бирешергә уйламады, ахирәтенең ире Саматның яз башында гына тырылдап ала торган «Иж» матае бар, ул шуны сорап торырга ниятләде. Ләкин Самат мотоциклын Беренче май бәйрәмендә генә алып чыккан да хәзер лапас янында эшсез тора икән. Самат:

– Хәзер, хәзер, безнең Акбай пес иткәнче кабызам мин аны! – дип, күкрәк какса да, мотоцикл бишеген күргән Гамилә үзе үк баш тартты. Улы сыйныфташ кызларын да утыртып барыр дип шүрләде! Буй җиткергән Гафиятенең Ясминә белән дә, Мәликә белән дә якынаюын теләми. Авыл кызлары белән чәче чәчкә бәйләнүеннән коты оча!

Гамилә апа шул рәвешле баштагы ниятеннән баш тартты, һәм Гафият велосипедка калды.

Солтан мотоциклын кабызыр алдыннан Мирсәет:

– Хәрисә малаен да утыртып бар, – диде.

Алар – Зөлфәкарь белән күршеләр. Күптән түгел әтиләре ташлап китте. Халык моңа башта бик аптырады. Югыйсә Әлли ягы Хәрисәсе белән Кала ягы Мәхмүтнең фамилияләре дә охшаш, икесе дә Котбыевлар иде. Хәер, Мәхмүт «Кылтыев» иде бугай.

Сөйлиләр инде авылда, имеш, яшь чакта Мирсәет Хәрисәгә кызыгып йөргәнме, әллә киресенчә булганмы? Шулай да алар бүгенге көнгә чаклы дус һәм аралашып яшәделәр.

Солтаны да үсеп җитте Мирсәетнең, хәзер аны урнаштыру хакында уйлыйсы бар. Абыйсы Миргали авыл җанлы, йорт җанлы булгач, techinститутка барып керде, авылда калырга исәп тота. Солтан башка, тик анысы да авыл хуҗалыгы институты дип йөри дә йөрүен, тик ул барыбер авылга гына риза булмас. Элегрәк Солтанның тавышы искиткеч матур булгач, аны җырчы булып китәр дип уйлыйлар иде. Яшүсмер чактан зур концертларда катнашты. Мирсәет аны райүзәккә музыка мәктәбенә дә йөртте. Әмма язмыш тагын үз төзәтмәләрен кертте, ундүрт яше тулган көннәрдә малайның тавышына зыян килде: салкын тиеп, шулай булдымы, әллә артык «тырышып» җибәрделәр, хәзер Солтан концертларда бик катнашмый. Шулай да әти-әнисе малайның авылда калуын теләми, шәһәргә чыгарып җибәрергә ниятлиләр. Ул турыда сөйләшми калган көннәре юк. Икесенең дә эчтән генә малайны зур түрә итәселәре килә. Тик Мирсәет язмышын кабатламастыр, анысы яшь чакта министр булам дип, артык югары сикерде һәм бүгенге көндә гади бригадир булып эшләп йөри. Икенче улын түрә итәсе килү, күрәсең, Мирсәетнең үзе ирешә алмаганын малае дәвам итсен диюедер. Телевизорда моны «триггер» дип атыйлар бугай. Имеш, психологлар уйлап тапкан төшенчә. Кем уйлап тапса да, ул бүгенге көндә Мирсәеткә тач туры килеп тора. Шундый уе күңел түрендә үк яши һәм хәтта Мирсәет белән идарә дә итә шикелле. Солтанының буена кадәр нәкъ атасыныкы хәтле, Мәдинә әйтә: «Малайның аяк атлауларына кадәр синеке, – ди. – Солтан белән сөйләшкән чагында кайвакыт сискәнеп китәм, синең тавышың чыгып куя», – ди. Исән-сау булсын, юлына Абтюков кебек түмгәкләр очрамасын дип тели Мирсәет.

Әнисе Мәдинә апа Солтанның Тәкә елгасы буена җыенганын белгәнгә күрә:

– Көтүгә дә күз салып китәрсең әле, улым. Кара сарык бик авырдан чыгып китте. Җибәрәсем дә калмаган. Әтиең күпне белә бит, бүген генә бәрәнләми әле ул дип, каршы төште, – диде.

Денистан соң кулына чыбыркы алган рус малае көтүен соңгы вакытларда нишләптер гел Путанай чиркәве янында көтә, Солтан туп-туры шунда таба китте.

Авылны чыгуга урта басу дип аталган кашлак җирдә аңа кәҗә көтүе очрады. Бу аерым токым кәҗәләр, аларны көтүгә дә кушмыйлар, имеш, алар гел кояшта гына йөрергә тиеш икән. «Оренбург кәҗәләре» дип аталган нәселдән иде алар. Туксабага әле күптән түгел генә алып кайттылар. Болар йоныннан бәйләнгән шәлләр бик кыйммәт йөри, чөнки йоннары кояш нурын күбрәк «эчкәнлектән» бик затлы була, имеш. Кәҗәләрне Зөлфәкарьнең ташлап киткән әтисе Мәхмүт Оренбургтан алып кайткан иде, мин барыбер шәл бәйләмим дип, ул аларны көтүе белән Хәрисәгә калдырып китте. Аларны көтәсе дә юк, чөнки кашлакта гел кояш булганлыктан, алар басу буйлап чәчелми.

Укытучы Чуракан күп белә инде, ни ара ул әлеге нәселле, затлы кәҗәләргә карата халык мәхәббәтен тудырып өлгерде: имеш, Оренбург

диңгездән йөз дә җиде метр өстәрәк урнашкан. Аның далаларын көньяк кояшы кыздыра. Ул җан иясе өчен бик файдалы нурлар икән. Имеш, Тукай да шагыйрь буларак шул «кояш» астында шытып чыккан! Казанда исә бары алты ел гына яшәп калган. Җаек белән Оренбург бер төбәк бит инде...

Оренбург татарның Казаннан кала икенче зур мәркәзе булган!

Булган... Ни кызганыч, хәзер туган телен югалтып бара!.. Милли менталитетны «саклау эше» бүген мамык кәҗәләре сыртында! Оренбург шәлләре татар хатын-кызларының иң күркәм бизәге генә түгел, әлеге шәлне ураган кыз-хатын менә дигән сәламәт балалар табачак! Чөнки бар хикмәт Кояшта! Кояш теге чакта төрки-татарны да олуг милләт итеп күтәргән! Зур, дәһшәтле халык ясаган Кояш татардан! Хәзер дөньяга сибелгән татар шул Кояш астында Алтын Урда нигезендә шытып чыккан! Бүгенге Рәсәйнең нигезе – Алтын Урда! Кояш ул халык өчен нәкъ Ирек кебек үк хикмәтле бер нәрсә икән, ди, имеш.

Әйтсә әйтә инде Чуракан!.. Һәм шуннан соң Зөлфәкарьләрнең кәҗә мамыгына бар авыл хатыны чират тора башлады. Колхоз җирендә эш юклыктан интеккән авыл хатыннары кышкы озын көннәрдә шәл бәйли, тормышны шул рәвешле өстери, балаларны шулай итеп үстерә, аякка бастыра...

Хыялый ул Чуракан! Ничек тора торгандыр аның белән Зөләйха апа дип, бар мәктәп аптырый.

...Сарыклар ташландык чиркәү күләгәсендә ята. Солтан күз карашы белән үз сарыкларын эзләде. Тиз тапты ул күләгәдә әлсерәп яткан сарыкны. Тик бәрәнләгәнме ул, юкмы икәнлеген каян белсен инде малай, янында бәтиләре күренми. Исәнме – исән дип уйлады һәм матаена атланды. Шулчак медер-медер сөйләшкән тавышлар ишетелде. Чиркәү алдындагы чокыр кебек иңкүлектә көтүче малай Путята шалаш кебек нәрсә әмәлләгән, шунда икән, янында бер хатын-кыз да бар. Анысы көтүче ашатырга килгән Туксаба хатыны булырга тиеш. Шул яктан искән җил тәмле пәрәмәч исе алып килә.

Ә менә Ямашка капкадан чыгар алдыннан әтисе Якуб:

– Газинур белән диләнкә карап кайтырбыз дип уйлаган идек, сәпиттә генә бармыйсыңмы? – дип шартлатып әйтте.

Әтисенең әле генә телефоннан Урман хуҗалыгы кәнсәләренә шалтыратканын ишеткән иде ул. Әтисе тегеләрдән машина җибәрүләрен үтенде. Әмма машина юк диделәр, ахрысы. Урманчыга бирелгән мотоциклны малае кабызып маташа. Күрәсең, аңа транспорт бик кирәктер. Шуңа күрә әйтә инде.

– «Ковровец»лары бар! Нишләп шуның белән бармыйсыз соң? Агач аларга кирәк бит! – дип киреләнде Ямаш. Үзе, мәгез сәнә дигәндәй, матайны «аягына» бастырып куйды да лапастагы велосипедына китте.

Яшьтәшләрдән Сәрдәр килеп җитә алмаган. Велосипедта гына булганлыктан, ул Төнбоек сазлыгы аша турыдан чыгарга уйлаган. «Май ае быел явымсыз, сазлык аша узган бердәнбер кәҗә сукмагы кипкәндер», – дип әйтте аңа күршесе. Әмма сукмак алдавыч булып чыкты, малай бил тиңентен ләмгә чумды. Каяндыр урманнан килеп чыккан Макай килеп коткармаса, эшләре харап иде. Макай бу урыннарны яхшы белә. Туксаба кибетенә ипигә килә ул. Башкалар кебек урау юллардан йөрми, Төнбоек

сазлыгы аңа үз ишегалды кебек кенә. Бу якта туры юлны «Макай юлы» диләр.

Пычрактан араланганчы байтак вакыт узды, шул сәбәпле Сәрдәр соңга кала язды. Аңа кадәр килгән малайлар хатны кемгә дә булса атап язу фикерен куәтләсә дә, оялчан кызларның бит очларына ут капты. Тик сыйныфтагы ике бөртек кыз тиз ушларына килде, хәтта, Ясминә, Гафияткә карап:

– Газый! Минем исемне язма түлке! – диде. – Язсаң да, кешегә әйтмә! – дип шаяртты.

Мәликә исә:

– Бу Ямаш точно мине яза инде! – дип, калганнарны көлдереп алды.

– Кирәгең барые!.. – диде Ямаш үпкәле тавыш белән. Аннан соң: – Атаң клубка да чыгармый бит сине! – дип өстәде.

Мәликә чынлап торып үпкәләде һәм Ямаштан үч алырга уйлады. Бу очракта үч алуның бердәнбер үтемле юлы башка кеше исемен язу иде. Хәер, кемнең кемне атап язганын берәү дә белергә тиеш түгел бит! Үч алу булмый бит инде ул, алайса.

Мәликә, еламсырап, читкәрәк китте. Янына Зөлфәкарь килеп басты.

– Борчылма, Мәликә, мин хатны сиңа атап язам, яме! – диде.

Малай әлеге сүзләрен шундый беркатлы итеп, ихластан әйтте ки, калганнар көләсе урынга авыр итеп көрсенеште. Мәликә ачудан Зөлфәкарьне төртеп җибәрде:

– Хатымны мин лучше, әнә, Путятага язам! – дип куйды, усалланып. – Паратовлар малае кебек Путята да көтү көткәндә чиркәүдән алтын табып алса әле!..

Ни өчендер барысы да Мәликәнең сүзләреннән түгел, Ямаш ягына карап, көлешеп алдылар. Сигезенче сыйныфтан ук беренче шигырьләрен ерак Казандагы «Яшь ленинчы» газетасында бастыра башлаган Ямаш Такташка охшатып алдырган чәч учламын сыпырып куйды да:

– Мин дә хатымны бер кызга атыйм! – диде. – Аңа багышлап «Чибәр кыз» дигән поэма да язачакмын! – дип өстәде.

Тагын көлеш китте. Бу юлы инде Мәликә ягына карап куйдылар. Гафият Ясминәдән:

– Ә син кемгә атыйсың? – дигән булды. Аның кыздан бик тә: «Сиңа бит инде! Шуны да белмисеңмени?» – дип әйттерәсе килде.

Чыннан да, зур коңгырт күзләренең януына караганда, Ясминәнең җавабы әзер иде, тик ул башта, шуны да белмисеңме дигән кебек, матур кашларын җыерды. Тик кыз кеше шул ул, ачылмады, бары: «Анысы сер була инде!» – диде, аннан соң мөлдерәп торган сусыл алсу иреннәрен бөрештерде. Ә Гафият, үз чиратында: «Солтанга» дип язар инде бу Ясминә!..» дип уйлап, күңелсезләнеп китте. Беләләр бит: Ясминәнең әнисе дә Солтанның атасы Мирсәет дип шашкан булган яшь чагында. Имеш, араларына Кала ягының Сәрбиназ атлы кызы кергән, бергә була алмаганнар.

Гафият кызга тагын нидер әйтәмәкче булган иде, үзенең тотлыгуын сизеп, туктап калды. Чынлыкта Гафиятнең беркайчан тотлыкканы юк! Ә менә Ясминә белән сөйләшә башласа, тотлыгырмын дип уйлый иде ул үзен. Тел очында торган сүзен дә әйтә алмый, өстәвенә уттай кызара. Мәликә яисә Мариҗан белән дә сәгатьләр буе сөйләшергә мөмкин, Ясминәгә сүз

кушарга уйласа, «тотлыга» башлый. Шуңа күрә ул мөмкин кадәр кыз белән сөйләшмәскә тырыша, тегесе, үз чиратында, Гафият миннән тел яшерә дип үпкәли.

Кызларның Мәликә атлысы:

– Күлтәк суы өскә казып чыгарса? Аннан соң серләрне кеше белсә?! – диде. Мәликә беркайчан да кеше сүзе белән шундук килешми, әүвәл сорау биреп аптыратып бетерә, йә үзенең фаразларын әйтә, күп вакыт кызның йөгерек хыялы уйнап алып: «Их, шулай булсачы! Һәй, болай килеп чыкса!» – дип тә куя; шулчакта аның моңарчы сизелер-сизелмәс кенә беленгән сипкелләре тагын да ишәеп китә, ләкин сары чәчле, җете зәңгәр күзле кызга алар бик тә килешә. Мәликә шулай дигән саен, Ямаш, көлеп: «Хыялый», – ди. Үз итеп әйтә ул моны. Шуңа күрә Мәликә бу сүзгә тамчы да үпкәләми, әмма эчтән генә: «Барыбер синең турыда уйлап хыялланмыйм!» – ди кебек. Шул рәвешле Ямаштан үч ала, ә үзе Солтан ягына карап куя.

Ясминә баягы сүзне гүя ишетмәде, үзенекен өстәп куйды:

– Тагын егерме елдан соң алып укыйбыз ул хатларны!

Әлеге фикер яшьтәшләре Ямаш белән Сәрдәргә дә ошады. Ә Ямаш атлы сыйныфташ хатны күңеленнән шигырь итеп яза ук башлаган иде, шигырьләр чыгарган кешегә хат язу берни тормый шул. Аннары ул:

– Безгә... Безгә тагы егерме елдан соң?.. – дип маңгаен кашып алды.

Сәрдәр, аны бүлдереп:

– Утыз өч була! – диде. Башка сыйныфташ малайлар сыман Сәрдәр Ясминә һәм Мәликә дип янмый бугай, әмма ул да калганнар кебек үк яшерен генә Мариҗан турында уйлый булса кирәк. Кайсы төшенә кызыгадыр инде болар шул марҗаның?!

Мариҗан исемле кунак кызы искиткеч гүзәл шул! Ханкаладан Галимә апаларга кайтып йөри ул. Аларның бер туганы урыста кияүдә, Мариҗан исемле бу марҗа – шулар кызы. Пәри кызы кебек чибәр булуы өстенә Мариҗан авыл кызлары кебек киенмәве белән дә буй җиткергән егет-малайларны үзенә тартып тора. Матур балтырлы кызга кыска итәк бик килешә.

Тәкә елгасы буендагы комлыкта су кергәндә Мариҗан марҗа авыл малайларын бөтенләй әсәрләндерә, чөнки ул ярымшәрә калып диярлек коена. Тегеләренең күзләре кыза инде. Ялангач Мариҗаннан көлгән булып пырхылдаган малайларның авыз сулары селәгәйгә әверелеп, кылкына ук башлыйлар. Солтанның абыйсы Миргали, аларга бармак янап: «Котыртмагыз, маңкалар! Сүз әйтәсе булмагыз Мариҗанга!» – дип кисәтә. Солтан, абыйсының бу шелтәсеннән соң: «Әллә моның марҗага күзе төшкәнме? – дип уйлый. – Әти белсә, бетерә бит моны!»

Чибәр иде шул Мариҗан! Гәүдә-сыны гына, йөз-кыяфәте генә түгел, тавышына кадәр үзенә бер аерым матур иде. Сихерле тавыш.

Миргали исә Мариҗанга күзе төшкәнме, юкмы икәнлеген әлегә үзе дә аңлап бетерә алмый. Тегесе, Миргали абыйсы су коеныргa килгәндә, «ялтыравыклы» җирләрен ашыга-ашыга комга күмә, шул рәвешле яшерә, комнан башы гына чыгып кала. Миргали аның ягына борылып та карамагач, кызның отыры ачуы чыга, һәм ул ком астыннан озын матур аякларын чыгара. Бу кыланыштан соң ул матурлыкны күреп торган бакалар да телсез

кала!.. Тәкә елгасы кайный башлый... Һәрвакыт җитди кыяфәтле бу егетнең үзенә игътибар итмәве бик үрти аны, тегенең кытыгын китерәсе килә. Күрә икән бит аны Миргали; беркөнне кыз шулай күл буенда комда кызынып ята иде, кемдер өстенә янәшәсенә салып куйган киемнәрен ыргытты. Җәлт кенә башын күтәреп караса, яныннан берни булмагандай Миргали узып бара иде. Кызның моңа бик ачуы килде һәм ул, Миргали суга керүгә, аның артыннан чумды. Шәһәрендә балык кебек бассейнда йөзәргә өйрәнгән кыз, су астыннан барып, Миргалинең каршына ук килеп чыкты. Миргали, бу алиһә суда батмасын дигәндәй, аны коткармакчы булды...

Туксаба кызлары аның ише купальниклар кими, су кергән чагында да өсләрендә күлмәк була. Дөрес, суга чылануга, авыл кызларының юка күлмәкләре тәннәренә сыланып бетә дә, Галимә апа әйтмешли, аның аша кызның бар «житиясе» күренә.

Мөгаен, алар өчен ул вакытта Мариҗанның гүзәллеге – шәрәлеге булгандыр. Миутын да әйтә бит: «Хатын-кыз ул оялчанлыгы белән матур», – ди. Кыскасы, сүз шул кунак кызы турында иде.

...Моңарчы сүзсез торган Гафият тә кушылды:

– Хәерсез сан ул – «өчле» саны... Әйдәгез, шуңа тагы бишне кушыйк!

– Газый! Алай итсәң, утыз сигез була! – диде Ясминә. Гафият атлы малайны, Газыев фамилиясенә басым ясаптыр, үзара «Газый» дип атыйлар, бу – аларның нәсел кушаматы. «Газый» дип әйткәне өчен Гафият Ясминәгә үпкәләми, башкалар шулай дисә, хәзер сырт йоннары кабарырга тора. Шуңа күрә калганнар исем белән дәшә.

Ямаш Гафияткә таба борылды:

– Ә нигә нәкъ утыз сигез?

– Кырык туларга тагы ике ел кала... Минем бабай әйтә: яшең җитсә кырыкка, эшең китәр шырыкка, ди. «Шырык яшьтә» мәхәббәт турында сөйләшәсе килерме икән?

– Мәхәббәт ул үзе иске нәрсә, ләкин һәрбер йөрәк аны... Аны яңартмый!

– Бозма Такташны! «Яңарта» дигән ул!

Зөлфәкәрь белән, җитди итеп:

– Яңарта, пычагым. Безнең әби-бабайлар димләп өйләнешкән, берберсен никахка чаклы күрмәгәннәр дә! – дип куя.

Яшүсмерләрнең Солтан атлысының битендәге бетчәләре юкка чыгып, күзләрендәге малайлык сүнгәч, бик чибәр, кызларның ушын алырлык гренадёрдай егет булыр дип фаразлый авылдашлар. Эре сөякле малай, тавышы да матур, ул пыскып чыкмый, әле иртәрәк булса да, тәмам утырган шикелле иде. Солтан капылт кына тагын химия һәм тарих укытучысын искә төшерде:

– Миутын абый әйтә: «Мәхәббәт ул һәр яшьтә дә матур була, үзенчә була», – ди.

Болардан аермалы буларак, Солтан Мариҗан дип уйлап та авыз суын корытмый бугай. Киләчәктә йөрәген яулап алачак сөйгән кыз читтә яшидер кебек тоела аңа. Мариҗан үзенә елмаеп караса, ни дияр иде икән? Дөресен әйтик, бу кадәрлесен Солтан үзе дә белеп бирми. Өстәвенә Мариҗанның аңа хәтта күз дә сирпегәне юк. Бар кешегә дә бертөсле елмая сөйкемле марҗа.

Солтанга Гафият каршы төшә:

– Әйтәм җирле, Хәсән чирле... Миутын үзе өч мәртәбә хатын аерган ул!

Күренеп тора, бу сүзләре белән Солтанга төрттерүе Гафиятнең. Сезнең нәсел кебек, имеш, Миутын да хатын сайлаган, берничә мәртәбә өйләнгән диюе. Сизә бит, Ясминәнең Солтанга битараф түгеллеген күңеле белән тоя малай.

Бу сүзләрдән соң Ясминә көлеп куйды, ә Мәликә күзләрен зур итеп ачты һәм:

– Синең шул булыр инде, Газый! Беренче хатыны аның Зөләйха апа! – диде.

Зөләйха апа исемен ишетүгә барысы да дерт итеп китте. Үзе дә килеп җитәчәк бит хәзер монда. Ул вакытта авыл җирендә укытучының гайбәтен сөйләү гадәте юк! Укытучы – бөек зат! Укытучы исемен йөрткән асыл кеше Ходайга тиң иде. Миутынның да һәр сүзенә ышанулары юкка түгел – укытучы бит. Каяндыр көтмәгәндә Ислемай тавы артыннан килеп чыккан «сиксәненче еллар», вазгыятьне үзгәртә башлап, укытучының да гайбәтен сөйләр чак якынлашып килгәнен балалар сизенделәр, ләкин «укытучы» диюгә күз алларына Зөләйха апалары килеп баса да тәннәре буйлап юеш аяклы кырмыскалар йөгерешә. Зөләйха апа янында шулай ук изге зат булган Миутын абый да бар бит әле!

Әлеге авыр тынлыкны Ямаш бүлде:

– Әйдәгез, чүп чәйнәмик! Хатларны язый́к та берәр шешәгә салыйк! Ямаш Ясминәгә карады, ни әйтерсең, янәсе. Әмма Ясминә авызын ачып өлгергәнче, Зөлфәкарь телгә килде:

– Аннары Күлтәк комына күмик, име бит? – дип, ул Ямашның сүзен җөпләде. Малайның сыйныфташларыннан яшерен сере барлыгы болай да мәгълүм бит. Әмма аның үзенең дә һаман сүз саен шуңа ишарә ясыйсы килә бугай: ул судан тапкан чүлмәктәге язулар кебек кайчан да булса әлеге серләрне дә ачып укырлар!

– Шешәгә салмыйбыз инде. Бигрәк тагы сез... Әтидән нәни генә тимер сандык ясатып алырмын! – диде Гафият, үзенең тимерче малае икәнлеген искәртәсе килеп. Гафият үзе дә тимерче чүкече кебек кыска буйлы, әмма киң бәдәнле бер егет булып үсеп җитәргә охшап тора.

Моңарчы сүзсез торган Сәрдәр:

– Беләсең килсә, тимер кәгазьне күгәртә ул. Пергамент түгел бит! – дип куйды. Күп сөйләшергә, сүз белән ботка пешерергә яратмаса да, әйтеп куйса куя инде малайларның Сәрдәр атлысы. Өстәвенә ул әллә нинди ят сүзләр белә, әле дә әнә, үзенең белдекле икәнлеген күрсәтәсе килеп кенә каршы төшеп маташуы бугай. – Борынгы бабаларның пергаментка язган язулары гасырлар буе сакланган!

Сүзнең ни турында барганлыгын бигүк аңламаганлыктан, аңа каршы бәрәү дә дәшми. Беравыктан Зөлфәкарь генә басып торган урынында кузгалып куя һәм, син генә гыйлемле түгел әле монда дигәндәй:

– Бозау тиресен киптереп, пергамент дигән язу кәгазьләре ясаган борынгы бабайлар! – дигән ачыклык кертә. «Борынгы» дигән сүздән Сәрдәр нигәдер сискәнеп китә һәм, зәңгәр күзләрен зур итеп ачып, иптәшләренә карый. Сәрдәрнең кызыл башы көн яктысында тагын да яктырак яна, борын очындагы сипкелләренә кадәр ут каба, кызгылт йөзе алсулана.

– Пергаментны, элек эшләгәнне дим, хәзер дә ясап булмыймы соң? – ди ул. Солтан, юк дигәндәй, башын айкый. Ясминәнең үзенеке куәтле, ул аларның сүзләрен ишетми дә:

– Хатларга... Хат башына бүген үзеңә охшаган кешеңнең исемен генә куябыз... Утыз сигез яшьтә ул исем башка була икән, өстәп язарга урын калдырабыз!

– Килештек! – диделәр барысы да.

Солтан белән Гафият хат башына «Мариҗанга» дип куярга ниятләде. Гафият әүвәл «Ясминә» дип язмакчы иде, ләкин соңгы арада кызның Солтаннан озаттырганын ишеткәч, фикере үзгәрергә тора. Мариҗан – алардан берничә яшькә кечерәк һәм сылу яшь марҗа. Аның чибәрлеге һуштан яздырырлык! Тик Гафият, башкалар кызыга дип кенә, Мариҗан дигән була, йөрәк түрендә барыбер Ясминә урнашкан. Әле тагын Гафиятнең үзе генә белгән яшерен нияте дә бар, татлы хыял ул! Беркөнне әтисе тимерче Газинур абый бик матур бронза чүлмәк алып кайтты. Аңа тирә-юньдә авыллардан гына түгел, Ханкаланың үзеннән дә кешеләр төзәтергә дип иске комганнарын, борынгы чүлмәкләрне китерә иде. Рәтләп булганнарын хуҗалар кире ала, кайберләре тимерчедә онытылып кала. Әтисе тимер-томыр арасыннан табып алган әлеге чүлмәкне. Тоткалары сынса да, бик затлыга охшаган, оста ясалганлыгы күренә. Тимерләр арасында яшеренеп калган инде. Гафият аны бик хасиятләп чистартты, күгәрегеннән аралады. Чүлмәк бик авыр, төбе чуеннандыр ди әтисе. Малайның кулы да тимер эшенә ята иде. Тотка-куллар ясады. Берзаман бик озаклап кыра, чистарта торгач, бәллүр вазалар белән рәттән куярлык искиткеч матур чүлмәк килеп чыкты! Хәзер өч ягында өч төрле кош сурәте аермачык булып күренеп тора. Кошларның томшыклары әле Гафият аңлап җиткермәгән бик затлы металлдан булырга тиеш. Ул кошларның берсе янында ясмин чәчәкләре сурәтләнгән. Гафият нәкъ менә шуның өчен дә аны Ясминәгә бүләк итәргә ниятли. Әтисе сөйли бит: әнисенә кыз чакта иске беләзектән матур алкалар коеп биргән ул: «Гамиләне бары шуның белән генә үземә караттым», – дигән була.

Ясмин куагы аларның бакчасында да бар. Әбисе, киптереп, аны чәенә сала. «Күзләрне ачып җибәрә», – ди. Ә менә хуш исе, чынлап та, күңелне «ача»: монысын Гафият үзе дә белә. Ап-ак булып утырганга күрә, аны борын-борыннан «килен чәчәге» дип атаганнар икән. Апасы шулай ди, бик ярата ул аларны. Гафият исә үзенә охшаган сыйныфташы исеме аркасында үз итә бугай... Күгәректән тәмам арындырып бетерәсе бар. Аннан соң кошлары янына Ясминәгә охшарлык нинди дә булса матур сүзләр уясы килә. Шигъри такмаклар да язып карады, тик килеп кенә чыкмый. Матур сүзләр табарга оста булган Ямаштан ярдәм сорарга исәпли, әлегә җае гына туры килми. Менә шуны кызга бүләк итсә, Ясминәң берninди Солтаннарга да әйләнеп карамаячак! Әбисе әйтмешли, бәлләһи-газыйм менә дип куя Гафият эченнән.

Сәрдәр хатка «Алтынчәч» дип куярга уйлады. Бер китапта Болгар ханының шул исемдә бик сылу кызы булган дип укыганы бар. Чукынып китсен марҗалары! Урал якларыннан кунакка килгән чибәркәй әле дә булса төшләренә керә.

Зөлфәкарь Миңниса исемен куярмын дип уйлады. Әмма бик икелә-

нә иде. Ул уйлаганча, шешә табылып, язуны укысалар?! Аның «Миңниса»сын читләр белсә дигән шик гел кабыргасына төртеп тора. Бу хакта малайның кычкырып әйтәсе, яшьтәшләрен кисәтәсе килә.

Мәликә белән Ясминә икесе дә «Солтан» дип язарлар. Тик Ясминә бик икеләнде, әллә «Гафият» диясеме дип аптырап бетте, кушаматы белән «Газый» димәссең бит инде...

Шулчак көтелмәгән хәл булды: моңарчы тыныч кына суга карап торган Зөлфәкарь, капылт алга тартылды да, яр буена ук килеп, суга сикерде! Киемнәре белән чумды «алтылы» Зөлфәкарь! Аның балык тотуга хирыс икәнлеге мәгълүм, килүгә кармак салган да, шунда балык капканын күреп, чумгандыр дип уйлап алдылар. Тик Зөлфәкарь кармак та салмаган, зур балык та күрмәгән – кара сыртлы дулкыннар монда таба шешәгә охшаган савытны куа икән. Шуны күреп алган Зөлфәкарь. Табылдыкның эче буш булып чыкты – капкан саен калҗа булмый шул ул...

«Киләчәккә хатлар»ны Зөлфәкарь судан тапкан шешә рәвешле чүлмәк эченә салмадылар, Солтан чормадан тапкан имән тартма бик ярап куйды.

Балаларының шул рәвешле хатлар язып күмгәнлеген ишеткән өлкәннәр җанына борчу керде. Минем балам кемгә атады «киләчәккә язган хат»ын дигән уй талкыды аларны. Элек Әлли яклары бер-берсе белән кавышып гаилә кормаган. Бу борын заманнан килә. Әлли ягы кызы шундагы егеткә кияүгә чыкса, гадәттә, бер балалары җитлегеп тумаган. Үзләренчә моны судан килә дип уйлаганнар. Мондагы чишмәне икенче төрле «Изгеләр чишмәсе» дип атыйлар бит. Аның тылсым серен берәү дә төгәл генә белми. Әмма яшьтән шул чишмәнең суын эчеп үскән малай белән кыз, зур үскәч, бергә кушылса, каннарында нәрсәдер бозыла да нәтиҗәдә нәселнең дәвамына куркыныч яный. Ходай моны гарип балалар белән дәлилли, уяу булыгыз дип кисәтә кебек...

Бәлки, манара кискәне өчен Котбыйга төшкән кара каргыш шулай арттан сөйрәлеп килә торгандыр – Алла белсен!.. Йа Ходай, тагын нинди хикмәтләрең бардыр?! Балаларыбыз бәхетле булсын! Зинһар, үз ярдәмеңнән ташлама!.. Яшерен хикмәтләреңне, Әүлия чишмәсенең серен безгә дә ачып салчы, Аллаһы Тәгаләбез!.. Безнең үз баларыбызны бик тә бәхетле итәсебез килә!.. Бик тә...

Малайларның кайберсе «киләчәккә хат»ын гүзәл Мариҗанга атап язарга уйлады дигән идек. Җете зәңгәр күзле, алтын чәчле бу кыз хакында егет-малайлар арасында тагын бер фикер яши: шәһәр кызы булгач, әйбәт үбешә торгандыр Мариҗан дип уйлыйлар. Аннан үбешергә өйрәнмәкче булалар.

Тәкә елгасында су коенган чагында Мариҗанның чибәр пәри кызына әйләнүе хак иде. Шәһәр кызы янәсе, тартынып, уңайсызланып тормый, шәрә корсагы белән кайнар комга ятып, арка яктан купальнигының каптырмасын да ычкындырып җибәрсә, яр буйлары кайный башлый! Малай-шалай да шулай кайный, егет кисәкләре дә күбекләнә шул рәвешле!

Солтан уен хәтта кычкырып та әйтте һәм шуның белән Ясминәне дә, Мәликәне дә нык үпкәләтте. Кайтканда аның матаена утыручы да булмады. Ясминә – Гафият велосипедында, Мәликәсе Ямаш белән кузгалды.

Ямаш хыялый һәм һәркайчан үзенчә эшли иде, бу юлы да туры юлдан китмәде, бу якларда «Биектау» дип аталган әйләнеч юлдан кайтырга

уйлады; Мәликә какы бик ярата, Биектау үзәнлегендә котырып үсә инде ул!

Ул «Биектау» дигәннәрендә бернинди тау юк. Хәтта тауны хәтерләткән калкулык та күрмәссең! Әмма исеме халыкка ни өчендер «Биектау» булып кереп калган... Гади урын түгел, ул җирләрдән вакыт узган саен имән багана төпләре, чүлмәк ватыклары килеп чыга тора. Җире дә бик ташлы. Әмма ул табигый ташлар түгел, анда заманында борынгы биналар булган диләр. Исеменең нигә шулай аталуын берәү дә әйтә алмый.

– Үзәнлеккә, тигез җиргә тау дип исем куш инде син! Име бит, Мәликә? – диде Ямаш, берара җир узгач. – Минем бик тә, бик тә үзебезнең яктагы сәер исемнәрнең серләрен беләсем килә! – дип өстәде.

Мәликә башта сискәнеп китте. «Мәликә, минем сиңа сүзем бар диясе урынга, тау атамасы хакында чәйнәлә Ямаш!» Кыз, үпкәләп, велосипедтан сикереп үк төште. Чынлап та, әнә иреннәре турсайды, бит очындагы миңенә кадәр каралып киткәндәй булды.

Әлбәттә, Ямашның: «Үзебезнең дә, сезнең дә шәҗәрәләрне беләсе килә. Дөресен ачыклыйсым килә, безнең теге чакта каргыш йоткан лотпыйлар нәселенә катнаш юклыгын сиңа да, үземә дә дәлиллисе килә. Бигрәк тә, әти-әниләргә... Безнең бергә булуыбызга каршы килмәсеннәр! Югыйсә безнең тарих та, шәҗәрәләр дә карурман кебек!» диясе килде. Әмма ул чакта мондый акыллы сүзләрне әйтеп булмый иде шул әле. Ул учына Мәликәнең ут кебек кайнар кулын алды. Аның күңеле бик тә йомшарган иде, күрәсең. Зөләйха апалары, Майков язган мәгълүм шигырьнең мәгънәсен аңлатырга кушып, өй эше бирде. Сезгә соңгы өй эше булыр диде. Шигырь болай иде:

Ему ты песен наших спой,
Когда ж на песнь не отзовётся,
Свяжи в пучок емшан сухой
И дай ему – и он вернётся.

Сүз башка халыклар арасында адашып йөргән төрки-татар кавемле баһадирны туган якларына кире кайтару турында бара. Ничек кенә үгетләсәләр дә, аның бер дә кире кайтасы килми, чөнки торган җирендә дә рәхәт була аңа. Ямаш аның мәгънәсен бер куплетка сыйдырырга булды, Майковтан ирекле тәрҗемә булса да, уңышлы килеп чыккан иде кебек.

Тыңлат аңа безнең җыруларны,
Иснәт әрем исен бер тапкыр.
Көйләп күрсәт яки әллүкиен –
Йөгерә-йөгерә ул кайтыр.

Зөләйха апа бик мактады, калганнар исә, ни нәрсә бу дигәндәй, мыскыллы көлделәр. Мәликә исә шаулатып кул чапты, кызга бик ошаган иде. Ямашның шуңа бик күңеле булды. Башкаларның фикере кирәк тә түгел иде инде Мәликәдән соң.

Кыз карышмады, нәфис кулларын тартып алмады... Бу Ямашка көч өстәде, ул беркавым гөр-гөр килгән йөрәгенең тынычланганын көтеп торгандай булды да аннан соң:

– Мәликә! «Карурман» дигән роман язасым килә! – дип куйды.

Мәликәнең иҗади фантазиясе куәтле иде:

– «Карурманда аю бар...» дисәң, кызыграк була, – диде ул һәм сак кына кулын тартып алды.

– Йә, «Хәлүш урманында аю бар» дип, име?

Кыз иңбашларын сикертеп алды.

– Мәликә, – диде Ямаш, тагын сүзне дәвам итәсе килеп. – Мин исемемне үзгәртәм. Метрикәдәге исем белән йөри башлыйм моннан соң.

Мәликә, аптырап, Ямашка карады.

Фамилиядән чыгып куелган булган минем исем, Тугашевтан. «Тукаш» дип язылган булган. Мулла да колакка шулай дип кычкырган. Миңа бер яшь тулганда, әти Ямашка үзгәрттергән.

– Тукаш?

– Тукаш шул. Мин аны киләчәктә псевдоним итмәкче булам. Син дә миңа моннан соң Ямаш димә, яме. Өйдә күптән «Тукаш» диләр инде мине, – дип куйды.

– Һе... Такташ!

– Такташ түгел лә инде: Тукаш!

Мәликә аның саен:

– Тукаш, Такташ! – дип үчекләвендә булды.

– Әти шәҗәрәне ясатты. Тукаш бабай, рәттән китсәң, җиденче баба безнең. Тик ул кем булган, нинди кеше булганлыгы билгесез. Минем бик тә шуны беләсем килә. Әти әйтә, белә алмыйбыз без аны ди. Татарның тарихы чиркәү асларында аның ди.

– Сәлам, Тукаш! – дип куйды Мәликә, көлеп.

Беркавымнан икесе дә көлешә башлады. Ләкин Мәликә шулчак үзалдына: «Солтанны үпкәләттем бугай. Мин дә, Ясминә дә үпкәләттек» дип уйлап куйды. Әллә Ямашның капылт кына Тукашка әйләнүен кабул итә алмады инде кыз, нигә тиктомалдан Солтан турында уйлый соң әле ул? Үпкәләтүенә эче пошамы?

Солтан кызларга тамчы да үпкәләмәгән иде. Аның бу вакытта үзенеке куәтле, егетнең тизрәк өйгә кайтып, чормада чәчелеп калган әйберләрне актарасы, һәрберсен җентекләп карыйсы килә иде.

Үзенә кирәклесен тапты да бугай: сары кәгазьгә язылган язуны укыды. Анда: «Ходай йорты хәзинәсе төшкә кереп ялтырый» диелгән иде... Кәгазьдә күренер-күренмәс мөһер эзе дә калган. Бер аягын югары күтәргән аждаһа сурәте. Астына: «Башкала патшалыгы мөһере» дип язылган... Русча язылган икән бу дип кенә уйлады Солтан, калганы аңа караңгы иде. Калганы нәкъ карурман кебек караңгы иде...

Малайның башы отыры эшләргә кереште. Бу юлларны тагын кайда күрде соң әле ул?! Капылт исенә төште тагы: теге чакта Денисны акылга утыртырга барган чакта, аны егып салып дөмбәсләгәндә, чыбыркысын кулына алды бит. Чыбыркы сабына да нәкъ шундый сүзләр язылган иде ләбаса!

...Җаны һаман тынычлана алмый. Зөйләха апалары яр буенда күңелендә кайнаганны әйтте. Ул елый язып:

– Бәхетле чыгарылыш сез. Туган телегездә укып чыктыгыз. Киләсе елдан

барлык фәннәр диярлек русча укытылачак. Районнан күрсәтмә килгән, – диде. Бу хәбәрне нигә әйткәнен үзе дә аңламады бугай ул. Тик әлеге сүзләр инде үзләрен зур итеп тоя башлаган яшүсмерләрне сискәндереп куйды. Димәк, Зөләйха апалары мәктәптән китәргә мәҗбүр булачак... Кызлар еларга ук кереште. Малайлар иреннәрен кысты.

Шундый күрсәтмә чыгуына авыл халкының да бик ачуы килде. Күпләр Башкала хөкүмәтен гаепләде. Туган телне кысу бит бу дип зарландылар. Икенче берәүләр аларга каршы төште:

– Аккаланың ни гаебе бар монда?! Күрсәтмә районнан килгән бит!..

– Ие шул, район үзе маташтыра!..

– Юк, Башкала гаепле моңа!..

– Башкалада синең Туксаба мәктәбең хакында гына уйлап утыралар дип беләсеңме! Безнең мәктәп кенә күчә икән ди бит!..

– Алайса, район гаепле!..

– Юк, Башкала гаепле!..

Шул рәвешле Башкала гаеплеме, районмы дигән сүз көрәштерү шактый озак барды. Әмма катгый карарга килә алмадылар, кыскасы, моңа район гаеплеме, Башкаламы икәнлеген ачыклый алмадылар... Дөрес, Миутын әйтеп куйган, ди, имеш:

– Башкала да, район да түгел, шуңа риза булган без үзебез гаепле, – дигән, ди.

Чуракан әйтсә, әйтә инде ул, теле сөяксез аның...

Шулчак болынның аргы башында, Тәкә елгасының шарлавыкка килеп җиткән урынынннан ерак түгел, көтүченең чыбыркы шартлаткан тавышы колак яфракларын ярып узды. Путанай малае көтү башын Туксабага таба борган иде. Зәһәр тавыш әүвәл чирәм буйлап тәгәрәп барды да, ярга килеп җиткәч, Тәкә елгасына сикереп төште һәм карасу сыртлы дулкыннар өстендә тирбәлә-тирбәлә бире таба агарга кереште.

Аркасына киндер капчык аскан Макай, әле көтүче ягына, әле Тәкә буенда кайнашкан Туксаба яшьләре ягына карап торды-торды да Төнбоек сазлыгына кереп китте... Түмгәк артына посып, бер күзе белән байтак күзәтеп ятканнан соң, урмандагы өенә таба китеп барышы иде Макайның.

Чыбыркы тавышының кайтавазы кабатланды...

## Татарныкы – бисмилла, русныкы – памилуй...

Көтүчегә бөтен авыл бурычлы булыр, ди.

Теге чакта Туксаба көтүен рус Путанаеның Паратовлар малае Денис көтте.

Денис Паратов хәзер авылга үзе бурычлы булып калды...

Артына көтүче чыбыркысы тагылган булса да, Денис инде күптән үзен башка сурәттә күрә. Малай чактан ук, Туксаба көтүен көтә башлаган вакыттан ук килә бу. Денисларның гаилә тарихын бу якларда сирәкләр белә. Югыйсә, малай тумышы белән дә шул ук Путанай авылыннан. Путанайда аларны ни өчендер «килмешәк» дип атаганнар. Нәсел кушаматы шундый булган, имеш. Бәлки, мондый кушамат тагу хата булгандыр, имеш, ата-бабалары затлы, бай нәселдән булган, ди. Хәер, көтүче булганнар диючеләр

дә бар. Каядыр Мордовияме, Касыйм якларындамы сыер-сарык көткәннәр, әүвәл хуҗалыкныкын, аннан соң колхоз көтүен...

Денисның әтисе Абрар агай (Абрам дип тә йөртәләр) җиде бабасын түгел, хәтта туган атасын да белми диючеләр дә бар. Шулай булгач, бабалары ничек көтүче булсын ди инде?!

Чынлыкта, Денис Паратов көтүче кавеменнән түгел иде. Әтисе дә көтүче булмады – сәүдәгәр, зәркәнче һәм чүлмәкче Абрар – Абрам ага. Ләкин аларның лапасында көтүчелек белән бәйле кыска чыбыркы саклана. Гади чыбыркы түгел ул. Сөяк сабы аңлаешсыз язулар белән сырланып беткән. Менә берсе: «Пастух носил с собой тяжёлую дубинку с шипами из острых камней для защиты от зверей». Чыбыркының сөяк сабына әле тагын аңлаешсыз юллар уелган: «Хочешь стать богатой, Найди клад золотой».

Нинди хәзинә икән соң ул һәм кайдан табасы ди аны?

Чыбыркы күпме гомер эшсез торды. Шулай да өлкән Паратов, бик сирәк булса да, аны бер шартлатып куя. Бу, гадәттә, кич көтү кайтыр алдыннан була; Путанайда янгын сүндерүче хезмәтен башкарган Абрар абзый аннан соң тау башындагы каланчага менеп китә, шул рәвешле аның кичке кизүе башлана иде.

Сөяк саплы чыбыркыны Дениска малай чакта, авыл көтүен көткән чакта да көн саен бирмәде Абрар агай; шул язу аркасында дип уйлый малай.

Абрар агай түгәрәк башлы, зирәк бер кеше иде. Дөньяның кысан чагында тиктомалдан шәраб ясый башлады. Бу шөгыле аның гаиләсен хәерчелектән коткара... Югыйсә, Абрар хәерче хәяттә яшәргә тиешле кеше түгел, чөнки ул урманчы Хәлүш гаиләсе йортында тәрбияләнеп үсте, урманчы беркайчан да ипигә аптырамый, урман бәндәләрне ашата, урман киендерә иде. Тик яшүсмер чакта аларны ташлап киткән Абрарны Хәлүш үз йортына башка аяк бастырмады. Үпкәләгән, рәнҗегән иде ул Абрарга. Абрар кире кайткач, аны кабул итмәгән, имеш. «Бүрене бүреккә салсаң да, урманга карый диләр. Син урманны да ташлап киттең!» – дигән. Хәлүшнең бигрәк тә хуҗасы Кугуй малае Макай өчен ачуы килгән иде. Абрар Макайны кыйнап имгәткән. Кугуйдан куркып качты бугай инде ул теге чакта. Хәзер менә, еллар узгач, Абрар урман кырыендагы Путанай авылына килеп урнашты.

Аек яшәү рәвеше дигән булып, эчемлек сатуның кысылган вакыты. Спирт заводларын җимереп, йөзем плантацияләрен сөреп-сукалап чыктылар. Рус иленең айнырга маташкан чагы иде ул. Аракыны итәк астыннан җибәреп ятучыларга җай чыкты, идән асты кәсебе чәчәк атты. Тик бу якларда моны хупламыйлар, итәк астыннан аракы сатучыны «шинкар» дип атыйлар. Абрар аптырап калмады, Путанай кырыендагы Кызылъярда шәп үзле балчык бар, шунда чүлмәк остаханәсе ачып җибәрде. Бу рәсми булмаса да, кызыл балчыктан эшләнгән әйберләрне түрә халкы сувенир буларак бик ярата; төрледән-төрле графиннар, чүлмәк-шешәләр бүләккә әйбәт дип мактыйлар. Абрар агай шәрабны шул сувенир савытлар эченә сала һәм итәк астыннан гына түрәләргә шудыра иде. Өстәвенә, туган якны өйрәнү музееннан да сораулар килә башлады; чүлмәкче, борынгы рәсемнәргә карап, аларга шул чордагы кебек чүлмәкләр, савыт-саба ясарга да алынды. Менә дигән «тарихи» экспонатлар бит инде... Эшләре хутка китте китүен. Тик торган саен нәфесе ачылды гына Абрар агайның, ул, яшерен кәсебе

участок милиционеры Салихҗан күзенә чалынмасын өчен, кызыл балчыктан төрле сыннар да ясарга кереште. Алтын эшенә кулы барган Абрар агай бар нәрсәне булдыра иде. Малае Денисның Туксаба көтүен көтәргә алынуы исә күпләрне бик аптыратты. Ләкин Абрар андыйларга да җавабын тапты, ышандыра торган бик шәп җавап иде ул: «Безнең яһүди пәйгамбәрләрнең күбесе көтү көткән, Муса пәйгамбәрнең күзендәге яше кипмәгән, кулындагы чыбыркысы төшмәгән!» – дигән сүзенә каршы килүче юк, чөнки халык бу тарихны түгел, өченче бабасын да белми иде.

Туксабаның җирле хакимият башлыгына Абрар агай бер сәер, ләкин моңарчы беркайда да булмаган бер сын-композиция ясап бирде. Кызыл балчыктан катырылган бу сын зур сиртмәле бишеккә дә охшаган, зур суда дулкыннар аралаучы корабны да хәтерләтә, кыскасы, гади күзгә берни дә аңлашылмый иде... Адәм аңлый алмаган нәрсә шулай серле була инде ул...

Абрар агай композициягә су анасын хәтерләткән балык койрыклы сылу кыз сурәтен өстәде. Җирле хакимият рәисе, тагын ни бу дигәндәй, башын кашып карап торгач, аңа басма хәрефләр белән «Әүлия көймәсе» дип язды. Якуб абзыйның малае Тукаш әлеге сынны фоторәсемгә төшереп алды да Миутын абыена күрсәтте. Тегесе сынга байтак текәлеп карап торганнан соң: «Әллү көе» дияргә кирәктер моны. Шулай итсәк, яхшырак аңлашылыр! Көймә суда тирбәлә бит. Җан ияләре бер тамчы судан барлыкка килә. Бу – кешелекнең бишеге!» – диде. Әлли-Әллүнең нәрсә икәнлеген бу якларда яхшы беләләр, Туксабаның Ислемай тавы ягындагы өлеше дә, андагы мәгарә дә нәкъ шул исем белән аталуы мәгълүм.

Тегесенең бик күңеле булды. Паратовның төрле кәсепләренә дә күз йомды Туксаба сәвите башлыгы....

Денис, ул алтынчы сыйныфка барасы ел, үзенең көтү көтәргә туры килгәненә бик хурлана, әнисе Сара түти күпме генә үгетләсә дә, Путанайда хуҗалык көтүен алырга аяк терәп каршы булды. Әмма атасы каты торды, кавемнең гореф-гадәтләре белән авызын томалады. «Мәктәп тәмамлауга фамилияне үзгәртәбез, үзебезнекенә (пычагым да белми ул үзенең чын фамилиясен!) кире кайтабыз. Безнең пәйгамбәрләрнең күбесе көтү көткән, син дә шуннан башларга тиеш», – дип кырт кисте. Ләкин чын серне (Үзе белмәгәнне!..) гаиләсенә дә ачып бетермәде. Ул бары көтүне ташландык чиркәү тирәсендә ешрак йөртергә кушты.

– Анда яңгырлы көндә ышыкланырга һәм эсседә күләгә астына качып була, – диде...

Кояш чыгуга, Туксабага җәяү йөрсә йөрде, әмма үз авылында кулына чыбыркы алырга хурланды горур малай. Туксаба көтүен Ислемай тавы артындагы үзәнлектә дә, Тәкә елгасы буенда да көтәләр, монда сине авыл кызлары да, олы юлдан үтүче-сүтүче дә күрми; кич көтүне тауның авыл ягына алып чыгып куйганнан соң, болын аша яшеренеп, Путанайга да элдерергә була.

Җиденчегә күчүгә, көтү көткән акчасына әтисе иске генә велосипед алып биргәч, эшләр җайлашты, чакрым ярым араны көтүче малай велосипедта уза. Ни кызганыч, башка малайлар кебек велосипед белән көндез авыл урамында киләп сарып йөрергә бик туры килми, иртүк аны Әлли ягының йөздән артык аңгыра сарыгы көтә иде.

Җәйләрен көне буе эссе кояш һәм яңгыр астында йөрүне исәпләмәгәндә, сарык көтүен көтү авыр эш түгел, әмма ялгызлыктан эч поша, ел кебек озын көн бик акрын уза. Бераздан Денис моның да җаен тапты: Путанай авылының иске чиркәве янында тигәнәк котырып үсә, шуңа күрә кеше йөрми – чиркәүгә ияләште. Аеруча эссе көннәрдә, чыннан да, чиркәү күләгәсе коткара иде малайны. Сарыкларны өйлә вакытында Тәкә елгасы ярындагы комлыкка туплый да үзе шул чиркәү күләгәсенә кача. Тора-бара, куркуын җиңеп, чиркәүнең эченә үк керергә батырчылык итте. Малайның беренче табышы тыштан кара сумалага катырылган чемодан сыман шактый зур сандык булды. Бигенә йозак эленгәнен күргәч, малайның йөрәге нindидер хикмәт көтеп тасырдый башлады. Таш белән бәреп йозакны ватты, сандыкны ачты. Борынына черек, дымлы күгәрек исе килеп бәрелде, башы әйләнеп китте, күз аллары караңгыланды. Беркавымнан ул, кабалана-кабалана, сандыкны актарырга керешә, төбеннән каты күнгә охшаган тупас тышлы берничә китап килеп чыкты; малай хыялланган алтын-көмеш күренмәде. Ачуы килеп, китапларны сандыкка кире ташлады. Теге яман ис гайрәтен чигергән иде, башка актармады да. Ул җәйне дә, киләсендә дә Денис чиркәү эченә бүтән кермәде, кызыгырлык нәрсәләр юк иде бугай анда.

Бер җәйне Путанай белән Туксаба арасындагы Ябалак урманы аланында Ханкала түрәләре ике катлы зур йортка нигез салып куйды. Аучылар йорты булачак диделәр. Шулай икәнлеге аңлашыла да, чөнки Ябалак урманында соңгы елларда кабан дуңгызлары үрчегәнен ишеткән иде малай. Киләсе җәен төзелеш барган урман кырыенда көтеп үткәрде, чөнки чиркәүгә Макай ияләште. Кайчан барса да, ул шунда утыра. Дәшми, сөйләшми. Денисны күргәч, матур итеп елмайган була тагын үзе. Кырынмаган кешенең елмаюы да күңелгә бигүк хуш килми.

Бу якларда Макайны танымаган кеше юк. Куркалар иде аңа сүз әйтергә, чөнки Макай – «Кужла» урман хуҗалыгы директоры Кугуй Осиповның бердәнбер малае. Балачакта ук аның асрамага алынган икәнлеген дә беләләр, әмма дәһшәтле директорның гаилә тормышында казынырга берәү дә батырчылык итми. Урман бу якларны ашата, җылыта, акча эшләргә мөмкинлек бирә, кыскасы, урман авылны яшәтә иде. Кугуй рөхсәтеннән башка урманнан сыңар ботак та алып кайта алмыйсың. Кугуйның бурзай-яраны – урман каравылчысы Хәлүш бик сизгер, җиләк һәм гөмбә җыярга гына рөхсәт итә.

Көтүчене көнгә ике мәртәбә ашату гадәте бар. Иртәнге ашны хуҗаның өенә кереп ашыйсы, төшкә, төенчек тотып, хуҗа хатын туплауга үзе килеп җитә. Денис иртәнге чәйгә бик иртә бара. Чөнки аның Туксабадагы яшьтәшләренең күзенә чалынасы килми – өстәвенә этисе Солтан атлы яшьтәшенең атасы Мирсәет агай белән белешләр дә, таң белән эшен бетереп, көтүне тизрәк авылдан алып чыгып китү ягын карый. Моның тагын икенче сәбәбе дә чыкты: ул иртәнге ашка кергәндә хуҗалардан башка өйдәге бала-чага әле йоклый, андый чакта кызлы йортларда аеруча кызык була. Хуҗа хатын, аңа өстәл әзерләп, үзе иртәнге савымын кибет янына килеп туктаган сөт машинасына илтә китә. Денис өйдә ялгыз башы кала. Шулай беркөнне ул олы якның ачык ишегеннән анда ике кызның йоклап ятканын

күрде. Хуҗа кеше күптән эшкә киткән, хуҗабикә сөт тапшыра, Денис ялгыз башы. Ул, кызыксынып, ачык ишектән түрдәге йокы бүлмәсенә күз салды. Караватта таралып ике кыз йоклап ята. Ул берсенең Мариҗан атлы кунак кызы икәнлеген белә. Кунак кыз Күлтәк күле буендагы таллыклар артындагы ачыклыкта кызынырга ярата. Анда аулак. Көтүчедән башка кеше йөрми. Мариҗан анадан тума диярлек сәгатьләр буе кызынып ята. Берсендә шулай Денис, таллыклар артына качып, бик озак күзәтте шәрә кызны. Мариҗан үзен сизмәгән дип уйлады. Тегесе, кайтышлый, чиркәү яныннан узды. Дениска: «Бесплатного кино больше не будет! Хочешь смотреть, приготовь бабки!» – дип көлде.

Әнә Мариҗанның мендәргә озын чәчләре таралган, өсте ачылган. Янәшәсендә Туксаба кызы ята. Мәликәне дә белә Денис. Менә Мариҗан Мәликә өстендәге одеалны үзенә тартты. Мәликәнең өсте бөтенләй ачылды, юрган читеннән шәрә матур ботлары күренеп тора. Малай, өнсез калып, мәче кебек эчкәрәк узды. Тәрәзәдән өй эченә үтеп кергән таң нурлары кызны кытыклый, ахрысы, ул кыймылдый, һәм бу юлы ябуы бөтенләй өстеннән идәнгә шуып төшә. Денис телсез кала, күзләре зур булып ачыла, сулышы ешая, күз алдындагы серле матурлык бу юлы сулышын тәмам кыса. Эчке күлмәкнең зур булып ерылган изүеннән ап-ак күкрәк, юка ситса эчке күлмәк аша тырпаеп торган канәфер төсендәге ими башлары шәйләнә.

Денис көтүчене ашату чираты әлеге кызлы йортка җитүен түземсезләнеп көтә башлады. Шулай итә торгач, ямьле җәйнең узганы һәм салкын, күңелсез кыш җиткәне сизелми дә калды. Нигә кыш көне көтү көтмиләр икән ул?! Кыш буе Мәликә белән төшләрендә саташты. Аны бер чишендерде, йә, туй күлмәгенә киендереп, үзе матур киемнәрдән аның янәшәсенә баскан килеш сурәткә төшкәнен күрде.

Киләсе җәйдә малай тагын бер яшькә зурайган иде. Ел кадәр ел узу гына түгел, бар эчке дөньясы белән үзгәрде яшүсмер. Аның хәзер үзе генә белгән яшерен сере бар, хәзер Денис атлы яшүсмер, бер яшькә генә түгел, кинәт биш, ун елга үсеп китте!..

Ни кызганыч, серле матурлыгын күз карашы аша күңеленә сеңдереп калган матур кыз кунак булган гаилә яздан сарыкларын бетергән, Оренбургтан мамык кәҗәләре алып кайтканнар, аларның мамыгыннан өрфиядәй шәл, башка хатын-кыз киемнәре бәйләргә исәплиләр. Шуларны Ханкала базарында сатып, көнне-көнгә ялгап барган тырыш хуҗабикә бәйләүгә утырган, бу аларның маллары көтүгә йөрми дигән сүз инде.

Хәер, ул сылу көтүчегә карамас бит инде!.. Ничек тә күп итеп акча табарга кирәк. «Приготовь бабло», – ди бит кунак кызы...

Денис ул җәйдә янә ташландык чиркәүгә ияләште. Хәзер ул яше белән дә, уйлары белән дә җитлеккән иде. Макайдан тамчы да курыкмады. Теге чакта кире ташлаган китапларда ниндидер сер бардыр сыман тоелды яшүсмергә. Җәйнең кызу көннәрендә сарыкларны көтәсе дә юк, алар комлыкта, бер-берсенең күләгесендә посып тик ятуларын беләләр.

Ни булса, шул булды, ул җәйне Денис атлы көтүче малай чиркәү нигезеннән бер чүлмәк алтын казып алды...

## Үле бала

Сәрвәр үле бала тапты. Бар гаепне киленнән күрде табиб. «Җыен юк-бар хорафатларга ышанып, күңеленә үзе үк тузга язмаган төрле вәсвәсәләр салып, тәмам эштән чыгарган Ходай ихтыяры белән йөрәк астына салынган җан иясен», – ди... Бала карында чакта ана организмы белән бергә яши, икесе бер була, җан иңгәнче бигрәк тә. Борчылу, стресслар турыдан-туры балага күчә. Дүрт айлык чакта җан керә балага; Сәрвәрнең инде табар алдыннан иләс-миләс килеп йөрүе, бала тудыру йортыннан качып кайту хәлләре – барысы да шуның нәтиҗәсе, ди. Соң, Алла бәндәсе, аңа кадәр үк зур профессорлар әйткән бит инде! Генетика дигәннәр! Кан катнашу дигәннәр!

– Сезнең мисалда кан катнаштыру очрагы түгел бит! – ди ул, күзләрен зур ачып. – Стресс, – ди. – Килен гаепле, – ди. – Дөньяви фәннәр алга киткән заманда нинди юк-бар төшләргә ышану ди ул! Юрап китерде бу афәтне Сәрвәрегез, – ди. Шул рәвешле аклана, болай да үзен кая куярга белмәгән каенатасының башын әйләндерә.

Әле яңа гына бала тудыру йортына куелган баш табиб аяусыз иде, бу исә аның куркаклыгыннан килә. Монда баш табиб итеп билгеләнү өчен күпме чапты ул! Кемнәрнең генә бусагаларын таптамады! Күпләп бирелгән ришвәтләрне әйтеп тә торасы юк. Ханкала партия комитетында медицина өчен җавап биргән Абтюков туя торган адәм түгел, бер хатын кәлимәсен тулы хезмәт хакына урнаштыруны да таләп итә, тик тегесе эшкә йөреп тормаячак. Зина өчен ире куып чыгарган ул Туксаба хатынын баш табибның үзенең дә эшкә йөртәсе килмәде, әлбәттә.

Тәки ышандырды Мирсәетне табиб. Тегесе гомер булмаганча дулады, чыгарыннан чыкты. Әгәр Сәрвәр килен беренче көннән үк кемнедер хәтерләтмәсә, ул кыз аның үткән хатирә-хәтере белән бәйле булмаса, кырыс Мирсәет кул күтәрергә дә күп сорап тормаячак иде. Үз гомерендә беренче мәртәбә шулай чыгарыннан чыкты күп еллар элек Төбәк партия комитетында җаваплы урыннарда эшләгән «тәмле телле» җитәкче.

Мирсәет киленне өйдән куып диярлек чыгарды. Җанында купкан буранны кешегә сиздермәскә тырышса да, Мәдинә, иренең капылт үзгәрүен күреп, яшерен уйларын сизәр кебек иде. Аларны кешегә белдерү түгел, ул уйлардан үзе дә курка иде Мирсәет. Әлеге хәерсез уйлар, хатирәләр кузгаткан ул уйлар Мирсәетнең җанын кимерергә кереште, чөнки Сәрбиназ белән бәйле иде алар...

Дөресрәге, Сәрвәр үзе түзә алмады, Миргали эштә чакта, качып, апаларына китте. Тик Зөләйха апасы өйдә түгел, аны ишектә җизни тиешле Чуракан каршы алды. Ул да белә иде әлеге хәлләрне, шуңа күрә борылып китәргә җыенган хатынны кочаклап диярлек өенә алып керде. Су бирде, апасының Оренбург шәленә урап кәнәфигә утыртты да тынычланырга кушты. Шулчак шатлыклы бер уй узды Чураканның башыннан: болай булуы яхшы булган түгелме соң? Тик нигә алай булган? Чуракан бу соравына үзе дә җавап бирә алмады ул вакытта. Сәрвәрнең туп-туры үзләренә килеп керүенә нигәдер сөенгәнен дә аңлап бетермәде химия-тарих укытучысы Миутын-Чуракан.

Ниһаять, тора-бара Мирсәет Хәйдәров катгый карарга килде: нәсел-

нәсәбенең тамырына төшәргә кирәк! Хәзердән үк башларга бу эшне!.. Якын буында булмаса, бишенче-алтынчы, җиденче буында туган булырга мөмкин кешеләр!.. Тик ничекләр итеп?! Кайдан табасың ди андый дәлилле документларны! Урыс патшалары татарның тарихын юкка чыгарган, шуның исәбенә монахлары ялган тарих язып гомер үткәргән. Ә ул гомерен үзе үк, Тукашка әйткәнчә, суга сәнәк белән язгандай, буш идеалларга хезмәттә уздырган! ВПШга укырга китәм дип, Сәрбиназдан баш тартылган. Хәзер ул аны бүгенге көнгә чаклы эзәрлекли. Сәрбиназ түгел, беренче ихлас мәхәббәтенә карата кылынган хыянәте эзәрлекли Мирсәетне. Авылдашы, кордашы Якуб гаепле моңа! Ул кире борган бит аны урман юлында!..

Мирсәет тагын Чуракан катына барды. Күңелендәгесен чиште, ярдәм итүен үтенде.

Партия җитәкчеләренең барысына да уртак бер сыйфатлары, гадәтләре бар иде, ул – чит кешене гаеплегә чыгарып калдыру. Холкына сеңгән гамәл-гадәте буенча Мирсәет тә гаеплене эзләде. Теге чакта милләтләрдән манкорт ясый язган партия гаепле түгел, аерым кешеләр гаепле! Галимнәр, милләтнең язучылары, журналист халкы гаепле иде ул чакта!

Ләкин «партократ» кешенең канына сеңгән, ул-бу була калса, сырт белән төшмәскә, ничек тә төшмәскә! Чын тарихны актара башласалар, Башкала моңа каршы киләчәк, дошман ясаячак. Әйтә бит Чуракан, Орхон-Енисей язмалары табылып, аларның төрки тарихына мөнәсәбәтле икәнлеген белгәч, Башкала шундук фәнни эзләнүләрне туктаткан ди!

Чуракан ушлы дидек, күп белә, чөнки туктаусыз эзләнә. Күптән түгел Якуб малае Тукаш гәҗитендә аның белән әңгәмә дә басылды. Украинаның Полтава шәһәре янында (Шәһәр исеме төрки сүздән килеп чыккан!) табылган алтын хәзинәләр дә төрки-татар-болгар белән бәйле. Башкала әлеге хәзинәне өйрәнүдән баш тарткач, аның белән немец галиме Вернер дигән кеше кызыксына башлый. Һәм ул аның Кубрат хан хәзинәсе икәнлеген дәлилләп тә чыга! Киевтан алып Идел Болгарына хәтле җирләрдә борын-борыннан бернинди славян, урыс-улакның дәһеле дә булмаган! Алары җиденче гасырларда Карпат яннарында күренә башлый. Аңа кадәр ул җирләрдә һәм хәзерге Россия җирләрендә славяннарның сыңар эзләре дә булмый! Болар төрки-татар-болгар җирләре булган дигән сүз дип яза атаклы немец галиме!

Шулай дип уйлады Мирсәет. Шикләнде. Шактый кыю документлар килеп чыгып, Башкала алдында уңайсыз хәлдә калырбыз дип курыкты...

Ләкин тора-бара үз гаиләсендә булган фаҗига карт коммунистның барлык курку-шикләнүләрен юкка чыгарды...

Теге чакта аның Солтаны, сыйныфташы Сәрдәр кебек, авылдан чыгып китте һәм Башкала шәһәре тарафына юл алды...

## Һәлакәт

### Сәрдәр

Егерме еллап кайтканы юк иде Сәрдәрнең туган ягына. Ул киткәннең икенче елында әтисе вафат булды, аның артыннан әнисе китеп барды. Сәрдәр йортны сатып җибәрде дә авылны «онытты». Хәзер менә хәзинә

турында хәбәр алуга, туган ягына ашыкты. Туган тиешлесе Мәрьям юкка чакыртмас, бик мәгънәле хатын ул. Җитмәсә, ул аның Гаврилов дигән зур түрәдә кияүдә икәнлеген дә ишеткән иде.

Әлбәттә, хәзинә өчен шулай тасырдамады йөрәге. Ике дистә ел эчендә Сарматта кылган гамәлләрен үлчәүгә салып карау теләге көчле иде. Бишек җырын тыңлап үскән туган ягың – иң дөрес Үлчәү тәлинкәсе...

Гөнаһ шомлыгына каршы, юлда һәлакәткә очрады һәм менә хәзер Сәрдәр юл кырыенда кара үлем белән көрәшеп ята иде.

Теге чакта әтисе Вәис агай, бәласеннән башаяк – авыл кызы белән ярәшә күрмәсен дигән уй белән малаен укып бетерүгә читкә җибәрсә дә, алар вафатыннан соң аяк басканы булмаса да, Сәрдәр гел авылны сагынып яшәде. Мәликәләре белән бергә сагынды ул аны...

Нишләсен, әтисе каты торды шул: китәсең моннан һәм бетте-китте!.. Баштарак Сәрдәр әтисе участок милиционеры Салихҗан аркасында шулай куша дип уйлаган иде. Монда барыбер безнең нәселгә көн бирмәсләр дип шикләнгәндер Вәис агай.

Үчле булып чыкты ул участковый. Теге чакта Хәйдәр абзыйга Сәрбиназны качырырга ярдәм иткәне өчен Вәис ягына һаман кырын карый, адым саен үч алырга тырыша. Югыйсә, әтисе Мирсәеткә атын гына биреп торган булган. Хәзер, әнә, арба төбендә аз гына печәне булса да, туктатып бәйләнә, урлагансың дип теңкәсенә тия, ниндидер кәгазьләр тутыра; беркөн Ләисовларның тулы оя казын борчак басуына кергәннәре өчен әвеннең караңгы бинасына яптырган.

Ләкин Сәрдәр генә шулай дип уйлый, сәбәп бөтенләй башкада иде. Дөресрәге, ул сәбәпне Вәис агай үзе дә тәгаен генә аңлап бетерми. Каргышлы авылдан малаен озатасы киләме, әллә отставкага чыккач, Туксаба мәчетендә мулла булырга кызыгып йөргән Салихҗанның имеш-мимешләре өркеттеме? Анысы әллә нәрсә уйлап чыгарган тагын... Туксабаның Әлли ягы зират өстендә утыра икән! Шуңа күрә алты бармаклы балалар туа икән, ди, имеш...

Ни булса шул булды, Сәрдәр читкә чыгып китте.

Авылга кайтуга, яшеренеп кенә Күлтәк буена барып, теге хатларны казып алырга дигән уй да күптән кайный башында; исәбе кеше серен белү түгел, ә бары андагы буш кәгазьгә «Сөмбел» дип язу гына. «Билгесез кыз Сөмбел!» дип язса, дөресрәк булыр. Сөмбел атлы сөяркәсенә күрсәтеп, тегенең ушын алыр, аны тәмам үзенә бәйләп куяр да, ул кыз мәгъшукадан хатынга, яраткан һәм гомерлек хатынына әйләнер...

Ләкин бу ният ничек тиз кабынган булса, шулай ук сүрелде. Сөмбел исемен язармы соң ул?.. Бәлки, язар. Чөнки Сөмбелнең нәсел тамыры алар ягы белән катышмаган. Ата-бабалары ул яктагы суны эчмәгән. Димәк, Сәрдәргә яшь хатын менә дигән сәламәт бәби дә алып кайтып бирер. Гайнаны да үз улы, югыйсә. Әмма Сәрдәр малайның дилбегәсен ычкындырган идеме, әллә башка сәбәпләр беләнме, тегесе начар юлга кереп китте. Милициядән башы чыкканы юк...

Ярый, хуш. Фани дөньяның асты-өскә киләсе бар иде бит әле. Чыннан да, Сәрдәр туган ягына таба юлга кузгалгач, дөньяның түбәсе купкан кебек булды. Тормыш – куласа, бер әйләнә, бер баса диләр бит. Менә

тагын басты. Сытылырлык, изеп ташларлык итеп басарга җыена бу юлы. Каршысына ике машина ажгырып килеп чыгар да юл кырыендагы сөрелгән басуга мәтәлер дип кем уйлаган?! Юл һәлакәтендә Сәрдәр башы белән бәрелде, әлегә аңын югалтыр-югалтмас хәлдә. Саташа да башлады бугай...

Сәрдәр бу саташулардан соң: «Хәерсез көнне юлга чыкканмын» дип уйлап өлгерүгә, өстенә ауган машина авырлыгына, басымга түзә алмыйча, саташуларның шул урынында аңын югалтты... Баш миендә кайнашкан фикер кырмыскаларының тәпи эзләре генә аерым сүз-җөмләләр рәвешендә калды. Һәр кырмыска үзенә бер хатирә сыман...

Кырмыскалар шулчаклы күп булган ки, эзләрен санап бетерерлек түгел, һәрберсендә нинди дә булса уйлаган уй, узган тормыш мизгелләре... Чынлап торып саташты Сәрдәр. Әнә хәтта Тәкъсирнең үзе белән сөйләшә:

– Ялгышып – яшь чагында җүләр баштан инде – марҗага өйләнгән мөселман татар, – тьфү, анасын корт чаккыры! Нинди татар булсын, алары монголлар бит аның! – мөселман болгар, никахын яңартып, үзе кебек мөселман кызын сөя башласа, бу гөнаһ эш саналырмы, Тәкъсир?

Тәкъсир дәшми, җүләр нәрсә кебек тик карап тора Сәрдәргә. Шулай тиештер дип, Сәрдәр сүзен дәвам иттерә:

– Никах яңартылмаган әле, шул максат белән кайтып барам Ханкаланың Морат якларына... Ике хатынны гына асрарга хәлемнән килә... Менә туган яктан өйләнәм дә, анда нинди хәзинә табылганын ачыклыйм да, Моратка кире әйләнеп кайтам. Тәкатем калмады, сагындым яшь бичәмне. Яратам, ди, бахыр... Авылда хәзинә табылганын ишеткәч кенә әйтми микән бу сүзне? Хәер, гаепләп тә булмый, кыз-хатын алтын, асылташ ярата инде ул...

Тегесе һаман җавап бирми, йә кире каксын, яки хуплап бер сүз әйтсен иде инде ичмаса! Ләкин үзе аның мәхәббәт монологын игътибар белән тыңлап торды, әмма авызына су капкан кебек. Бу Сәрдәрне пошаманга салды. Уйлары тулганды, бер чиктән икенчесенә сикерде. Тагын Сөмбелне исенә төшереп хафага калды. Әле үзе дә күрмәгән хәзинә хакында Сөмбелгә алданрак әйтеп ташламадымы икән соң ул? Морат аның туган авылы Туксабадан ерак түгел, аңа кадәр кайтып утырса, хәзинәне кулга эләктерү турында мәкерле планнар кора башлаган булса? Ышанып бетми Сәрдәр үз малае яшендәге кызның «яратам» дип муенына асылынуына... Хәер, ни кылмак кирәк, табылдык хәзинә дә әйбәт, яшь кызның кайнар куены да ымсындыра. Икесе бергә булса, тагы да яхшырак...

Хатыннар турындагы уй баягы саташуларны бөтенләй үзгәртеп ташлады. Әнә, оҗмах ишеге төбендә хатыннар тилмереп тора. Сыйныфташлары түгелме соң? Чиратка басканнар. Хатыннар арасында Сәрдәр дә күренә. Нишли ул берүзе хатыннар янында?! Хәер, Сәрдәр мүкләк сыер кебек бит ул, җитешмәгән җире юк аның!.. Хатыннар, Сәрдәрне читкә этәреп, алга ук килеп бастылар. Берсе аеруча кыю, сорау алучы каршысына килеп басты һәм:

– Ясминә мин, Гадел кызы Ясминә! – диде. Сәрдәр кызны шундук таныды: Ясминә шул, авылдаш кызы, аның сыйныфташы Ясминә! Сәрдәр сорау алучы белән сыйныфташ кызның сөйләшүләренә колак салды. Сорау алучы Ясминәгә:

– Хатын-кызның пароле иренең исеме булырга тиеш дип язылган монда! Күрмисеңмени?! – ди.

– Гафият атлы минем ирем.

– Бар андый. Уз, әйдә.

– Мин – Мәликә, Тукаш хатыны.

Аңлашылды! Мәликә Тукашка кияүгә чыккан икән! Тукаш шигырьләр яза иде бит, шуның белән әфсенләгәндер инде. Чү! Мәликәне өйдән куып чыгарган Тукаш дип сөйләштеләр түгелме соң?! Путанайның Паратовлар малае Денис белән тоткан булган хатынын! Ай Алла! Кем уйлаган җете зәңгәр күзле, тиз ышанучан беркатлы сыйныфташы Мәликә хыянәт юлына баса алыр дип?! Буй үстергәч тә, гел сабый күңелле, ихлас бер кыз иде бит ул!..

Сорау алучы Мәликәне уздырып җибәрде:

– Андый да бар, уз түргә.

Мәликә артыннан тагын сары башлы матур хатын килеп басты. Үзе белән таныштыра:

– Любовь Андреевна! Лаисова! Сәрдәр хатыны! Бармы исемлектә?

– Барын бар да... Әмма?..

– Нәрсә «әмма»?

– Мөһерләнмәгән, ханым, кем... Кертә алмыйбыз!

Сәрдәрнең марҗасын кертмәделәр. Ул, нәүмизләнеп, читкә китеп басты. Аның каравы, шуның артыннан ук икенче бер чая кыз-хатын чәчрәп чыкты да:

– Ә мин – Сөмбел! Сәрдәрнең, Гайнанның... мәгъшукасы... – диде.

– Гайнанныкымы, Сәрдәрнекеме?! Алар монда икесе дә Ләисовлар!

– Мин – ирекле мәхәббәт тарафдары! Телим – атасын, телим – малаен яратам!

– Ие, дөрестән дә... Ләисов Гайнан Сәрдәр углы яшендә икәнсең шул. Тик кертә алмыйбыз, мөһер юк монда! Аннан соң хур кызлары штатында да буш урын калмады, сеңлем! Бар, әнә, тәмуг ишеге сиңа...

– Ә ирекле мәхәббәт? Демократия, ирек, азатлык кайда?! Шәхес иреге кайда?! Беләсең килсә, шәхес иреге турында Төп канунда язылган безнең?

– Кайсысында, сеңлем? Монда күп алар, ләкин берсе дә мөһерле түгел!

– Алайса, европейский, американскиий свобода, азатлык, шәхес иреге! Кайда алары?

– Тәмугта...

Ә Солтанны капка янына бөтенләй якын җибәрмәде оҗмах сакчысы. Ирләр белән бергә килерсең, йөрмәле монда кычытмаган җирне кашып диделәр бугай. Сәрдәр моны күреп: «Шул кирәк сиңа!» – дип куйды.

...Колак төбендә зур тизлектә чапкан машина җиле сызгыра, һәм ул ни ара теге «кырмыскалар»ны куып тарата...

*(Дәвамы киләсе санда.)*



Рүзәл
Мөхәммәтшин

# ТАШ

ПОЭМА

## Каза

Дөньяның асты өскә килде.

Хәер, киресенчә: кызу-кызу атлаган шәпкә үзем ике канатымны кагып алдым да чалканлата җиргә барып төштем. Аңарчы маңгай турысында йодрык чаклы таш калыкты. Кайдан гына пәйда булды ул?

Урам чатындагы гарәп язулы сәгать тә берне сугып куйды.

Анысына сүгенмәдем.

Мин күк төсенең спектрдагы төгәл урынын хәтерләргә тырышып ятканда, элекке ГУМ тирәсеннән гөрелте йөгерде. Анда егерме-утыз кеше, кулларына ап-ак чәчәк бәйләмнәре тотып, космонавтларны каршыларга әзерләнә иде.

Нәкъ менә мондый тантаналарны өнәмәгәнгә күрә, йомран сыман җәһәт кенә метро чокырына чуммакчы идем дә бит!

Өлгермәдем. Юлым тупас сәбәп аркасында бүленде.

Күк, чынлыкта, спектрдагы һәммә төстәге нурларны үзе аша үткәрә. Әмма аларның таралыш дәрәҗәсе дулкын озынлыгының дүртенче дәрәҗәсенә кире пропорциональ. Ягъни, күз аерырлык диапазонда шәмәхә, куе зәңгәр һәм зәңгәрсу нурларның өлеше бермә-бер артык. Ми, кирәксезгә баш ватмыйча, бу палитраның барысын да бер төскә – күк төсенә әйләндереп, тулаем килеш кабул итә.

Мәктәптә физика укытучысы:

– Җиде төн уртасында уятып сорасалар да, сез моны белергә тиеш! – дип әйтә иде.

Менә нәрсәгә кирәк булган икән ул миңа.

Күк төсе – төркилек, татарлык төсе дә әле.

Хәер, килешәм: бусы – лирика.

---

Рүзәл МӨХӘММӘТШИН (1989) – *шагыйрь һәм прозаик; М.Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреаты. «Каралама», «Бүре мин», «Мин дә китәрмен әле» дигән китаплар авторы. Казанда яши.*

Мин, муенымны чак каерып, янымда яткан оятсыз ташка төбәлдем:

– Кайдан гына килеп чыктың син, хайван?

Беразга күз алларым караңгыланып китте. Карашымны таш өстеннән шудырып, юл аркылы торган бронза һәйкәлгә күчердем. Кай ягыдыр үзгә иде аның. Шул ук Олуг Мөхәммәт югыйсә. Аты да шул ук ат. Элек тә алгы аягын күтәреп торгандыр инде ул, арткысы булмагандыр? Моңарчы башы аскарак иелгән идеме соң? Әллә ханның чапаны алышынганмы?

Гөрелте кабатланды.

Космонавтлар күктән җиргә төшеп җиткән иде.

## Таш

Таш,
Таш
Тирә-юньдә –
Бөтенесе.
Калку булып тора,
Зәһәр дә:
Кыя-таулар,
Шоссе,
Җирне баскан
Йортлар чытырманы –
Шәһәрләр.

Күк йөзендә –
Биниһая йолдыз:
Онытылып баксаң –
Шашарлык...
Берәр кайчан,
Күз нурлары сүнеп,
Җиргә коелачак ташлар ул!

Тоташ
Таш,
Таш
Җирдә –
Бөтенесе:
Эре йә вак –
Кая карама.
Кәгъбәдә дә,
Гөнаһлардан янып,
Җәннәт кичкән якут карала.

Гомер буе
Ашкынуда, дауда,
Бертуктаусыз чаба эш белән –
Җыйнак кына мәрмәренә җиткәч
Тынычланып кала
Кеше дә.

Таш,
Таш
Тирә-юньдә –
Бөтенесе.
Тоташ,
Тоташ.
Шуңа иш бары:
Бөтерелеп, галәм киңлегендә
Мүкләнгән таш оча –
Җир шары.

## Өйлә

Башта ул күзлектәге тап кебек иде.

Әмма әкренләп борынга таба үрмәләвен күргәч инандым: кырмыска.

Аскы иренне өскесенә күтәреп, бар куәткә пошкырып җибәрдем. Бөҗәк төшеп китте. Тап кымшанмады да. Баксаң, күктәге болытны каплап торган икән. Анысы үзеннән олырак булып кабармакчы, бүртенмәкче.

Нәни чакта мин ядә ташы турында укыган идем. Борынгы... кем әле?.. мәҗүси муллалар шуның ярдәмендә һава торышын үзгәртә алган, имеш.

Әтәйнең чалбар балагына ябышып көтү көткәндә еш искә төшә иде ул. Табигатьнең кәефе кырылган саен. Валлаһи, муеннан сазга баткан көе таллык эчендә Сапура карчыкның кәҗәсе белән тарткалашу – иң рәхәт эш түгел.

Бу тылсымлы таш терлек-туарның тел астына яшерелгән була диләр. Берсендә аны табып җиткерүемә аздан гына калган иде. Әмма әтәй колак артына кундырганнан соң, исән кешегә тормышның ядә-мазардан башка да матур булуына ышандым.

Хәзер яңадан шул нәрсә хәтергә кайтты менә.

Беренчедән, торып китү димим, кымшанасы да килми иде.

Икенчедән, Кәҗә бистәсендә бүген Җәмигъ мәчете төзелә башлый. Шуңа нисбәтле истәлек билгесе (ягъни – таш) куелырга тиеш. Рәсми өлеш тәмамлануга, яңа нигезне котлап, бөтен өммәт белән җомга намазы уку да каралган. Урынында ук, ачык һавада. Яңгыр, һичшиксез, бәйрәмнең ямен җибәрәчәк иде...

Маңгаемның яңа танышыннан:

– Син ядә ташы түгелме? – дип кызыксындым.

Каушаудан гына дәшмәгәндер: аның кытыршы яңагы буйлап, сыртына алма төше салган килеш, баягы кырмыска үрмәләп маташа иде.

## Келәү

Карт иде кам.
Исәр иде.
Шуңамы,
Коты чәпчеп,
Йолык туенда[1] түгелгән
Сут сеңеп өлгергәнче,

Келәүлектә ялгыз калды.
Куера барды болыт.
Ул, нәрсәдер сизенгәндәй,
Үзгәртергә омтылып,

Давылга ачты кочагын,
Ялварды әрнеп,
Шашып;
Йөрәге –
Кызыл куз иде,
Кулында –
Ядә ташы:

– Тәңрем,
Сыгынам!
Күк, Җир!..
Нык сеңерле әүлад[2] бир,
Әүладыма дәүләт бир,
Җиргә Күк игез булсын,
Утка Су игез булсын,
Һәр дәвер симез булсын,
Һәр тараф тигез булсын! –
Җаныбызга маза[3] бир,
Тәнебезне таза бир,
Түземен бир, көчен бир,
Имин тормыш өчен бир!
Сыгынам,
Тәңрем,
Күк, Җир!..

Ялгап кына җибәрәсе
Теләгенең соңгысын:
– Илемдә
Һава торышы
Һәрвакыт аяз булсын!

Илемдә!
Һава торышы!
Һәрвакыт!
Аяз булсын!

Карт иде кам.
Өлгермәде.
Купты ядәсе, яше...
Таралды, каплап күк йөзен,
Җирнең тамыры –
Яшен.

[1] Йолык туе – борынгы төркиләрдә корбан чалу бәйрәме.
[2] Әүлад – нәсел-ыру, дәвам.
[3] Маза – тынычлык.

## Җәмигъ мәчете

Офыкта нәрсәдер балкып алды.

– Әгузү билләһи-минәш-шәйтанир-раҗим![4] – дип куйдым мин.

Тфү сәнә, йолдыз атылганда гына шулай диләр югыйсә.

Хәер, изге сүз дөньяга һәрвакыт тансык.

Сүгенмәдем бит.

Казанда Җәмигъ мәчетен торгызу нияте Татарстан Җөмһүриятенең бәйсезлеге турындагы Декларация кебек үк борынгы.

Башта илаһ йорты мәркәзгә сыймады. Явыз Иванга каршы көрәшкән Кузычак угланның ыстан җире, дип, Питрәч вилаятендә генә үгез тиресе чаклы кишәрлек бирделәр. Әмма Иҗтимагый үзәк йөз меңгә якын халыкны урамга чыгарып, Сабан туе уздырып алганнан соң, кирмәннең кыл уртасында да бик яхшы урын барлыгы ачыкланды.

Бу оешма белән сүзгә килмәсәң яхшы: татарның иң асыл, зыялы, кыю угыл-кызларын берләштергән чакма ташы ул! Матбугат, театрлар, телевидение – барысы да алар кулында. Димәк, җәмәгатьчелек фикере дә.

Шулай итеп, Кол Шәриф мәчете калыкты. Мәгълүм ки, имам сәет һәм аның мөритләре Казанның иң тугры, иң фидакарь яклаучыларыннан булган.

Олы түрә, тасманы кискән чакта, бераз тарихны капшап:

– Без моны онытырга тиеш түгел! – диде.

Икенче Җәмигъ мәчетенең барлыкка килүе беренчесенә турыдан-туры бәйле. Ничек анда җиткәннәрдер, белмим, әмма казу эшләре барышында Ару хәбәр чиркәвенең дә мөселман әхрамы нигезендә күтәрелгәнлеге ачыкланды. Ул көннәрдәге шаулашу-даулашу инде – буа ерылдымыни!

Җаен туры китереп, Иҗтимагый үзәк вәкилләре дә ил агаларыннан:

– Җә, нишлибез? – дип кызыксынмый кала алмады.

Нәтиҗәсе шул: башкалабызда хәзер Псков архитектурасы үрнәгендә корылган мәчет бар. Дөньяда бердәнбер экземпляр!

Әлеге дә баягы Питрәч вилаятендә туып үскән Атакай хәзрәтләре, бу үзгәрешләрне вакытлы, урынлы һәм саваплы санап, берсүзсез хәер-фатихасын бирде. Шуңа өстәп, изге эш хакына дип, күпмедер садака да кучергән бугай әле.

Хәзер, Идел Болгарстанында Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына багышлап, Казанда өченче Җәмигъ мәчетен җиткерү күз уңында тотыла. Аның нигезенә салыр өчен Алмыш илтәбәрне, Ибне Фадланны күреп калган Шәһри Болгар ташлары да кайтарылачак, имеш...

Миңа Кәҗә бистәсендә сайланган урын ошый. Су буе. Теплоходлар йөреп тора. Янәшә – атаклы Матбугат йорты, Татар яшьләре үзәге. Каршы ярда – тәмәке фабрикасы. Ап-ак кирмән. Анда, Нургали һәм Илбуга капкалары арасында, мәһабәт һәйкәл – Шәһитләр төрбәсе. Казанны җан бәрабәренә илбасарлардан яклаган бабаларыбыз рухына соңарып кылынган догабыз.

## Мәмләкәт

Тома үксез токым иде алар.
Тамырлары да юк, исеме дә.

Көнкүрешкә бәйле үзгәрештән
Актык өметләре киселүгә

[4] Әгузү билләһи-минәш-шәйтанир-раҗим! – Таш атып куылган шайтанның явызлыгыннан Аллаһка сыенам! (Гарәпчәдән)

Яңа кеше килде.
Җиң сызганды.
Кыя өйде ташны ташка яньчеп:
Сез, – диде ул, – дивар!
Сез – манара!
Бу сәгатьтән сезнең исем – мәчет!..

Яңа кеше,
Җир куеныннан йолкып,
Берәм-берәм күккә күтәргәндә
Ташлар меңәр еллык мәрттә иде.
Киләчәге иде – үткәннәрдә.

Сез, – диде ул, – мәктәп-мәдрәсәләр!
Сез, – диде ул, – мунча, йортлар – төмән[5]!
Сез – пайтәхет! – диде. –
Сеңдерегез:
Болгар –
Сезнең исем
Шушы көннән!

Төссез, төксе токым иде алар.
Сынауларның башын башка ватып,
Кеше кыя өйде:
Исемегез –
Биләр булыр,
Үкәк,
Сарай-Бату!..

Аның,
Илен коргач,
Соңгы тында
Әйткәннәре мең мәртәбә растыр:
Буйга басты ташлар,
Беркайчан да
Кире чүкмәс өчен буйга басты!

## Ызгыш

Нәни чакта мин Кара пулат турында риваять укып тетрәнгән идем. Аксак Тимер явы, би гаиләсенең хөкем йортына кереп бикләнүе, бинага ут төртелү... Янгыннан соң ак күлмәкле кызның гына исән калып, дошман кулына төшәргә теләмичә, үзен корбан итүе – сулуыңа кабарлык хәлләр, билгеле.

Бу риваять – Шәһри Болгардан битәр, тулаем Олуг Олыска эпитафия.

Аның берничә саллы-саллы җөмләсе – Идегәй мирзаныкы.

Гаҗәптер, бәлки, әмма шушы риваять мине тәкъдиргә ышанырга өйрәтте.

Сез Аксак Тимернең ни өчен аксак булуын хәтерлисезме?

Мәвараэннәһер хакименә күрәзәче карчык:

– Быел туасы балалардан берсе синең башыңа җитәчәк, – дип фал ача. Әмир, гадәттәгечә, мәсьәләне җиңел генә чишү ягын карый: көмән йөрткән һәрбарча хатын-кызның эчен таптап чыгарга боера. Отыры яшь аналар үле яралгы табып бушана. Ләкин, Аллаһ рәхмәте, бер сабый барыбер исән-сау туа. Дөрес, аякка гарип була ул – нык бәдәнле егетләрнең тырышлыгы бөтенләй юкка китми. Балага җисеменә күрә Тимер дип исем кушалар.

Калганы – табигый: иртәме-соңмы Аксак Тимер, үч кайтару хыялыннан исергән халәттә, әмирнең башын чабып төшерә. Иясен җуйган тәхетнең кемгә тиешлеге турында бәхәс купмый.

Һәрхәлдә, риваять тарихи вакыйгаларны шулай яктырта.

Хакимгә теге заманда:

– Олак, убыр! – дип, тилемсә карчыкны куып кына чыгарасы иде югыйсә.

Юк, алай итмәгән. Тәкъдир, димәк.

Аксак Тимер дә гап-гади урам шпанасы булып калмаган.

Бусы да тәкъдир, димәк.

Ил – сау, Шәһри Болгар – төзек, Кара пулат ап-ак килеш сакланмаган.

Тәкъдир! Тәкъдир!

Бүген, татар җирләре янә Казан канаты астына җыелган сәгатьтә, бу

[5] Төмән – монда: бик күп.

турыда пошыну, бәлки, урынлы да түгелдер. Яңа төбәкләр күрше-күләннән кубып, Олуг Олысның Болгар вилаяте чикләренә кайтып җиттек ләбаса.

Бердәм халкыбызның тавык тәпие таккан саргылт өлеше генә:

– Тигәнәк төсле ябышты, чукынчыклар! – дип сукранып алды.

Ләкин алар аз, тавышлары нәзек иде.

Бу чорны дөнья җәмәгатьчелеге «Татар язы» дип күккә чөйде.

Ил буйлап «Мәңге бергә!» шигаре белән митинг-концертлар узды.

Читкә салуламадым бит? Һич юк, әлбәттә.

Тәүге мәртәбә Кара пулатны һәм, гомумән, Шәһри Болгарны мин Милли университетта белем эстәгән чорымда күрдем. «Изге Болгар җыеннары»ның берсендә. Гомер буе сукыр яшәп, кинәт күзең ачылгандай, искиткеч халәт иде ул. Меңьеллык ташларга орынып, йөрәк тамырларым аша мәңгелеккә тоташтым гүя.

Шунда ук аксакаллар авызыннан гаҗәеп сүз ишеттем: үз вакытында Туктамыш, Тимер һәм Идегәй исемле егетләр, ызгышу урынына, киресенчә, берләшә калса, Европа бүген татарча сөйләшер иде...

Тарих шарт фигыльләрне өнәми.

Мин дә югыйсә Арча капкасыннан автобуста гына китсәм, әллә кайчан Кәҗә бистәсендә дисбе тартып утырыр идем инде. Ни пычагыма метрода барырга уйлап, Нугай урамына борылдым соң? Ул каһәр суккан ташы кайдан танып алды мине? Ник янәшәмнән исәнләшеп кенә үтмәде?

Тәкъдир.

## Идегәй

Тымызык Идел буе.
Идел яры –
Чуер таш.
Күк түшеннән агып төшкән
Шәфәкъ суны куерта.
Кич инде Идел-йортта.
Кич инде Идел-йортта.

Ялгыз ул.
Ният кора.
Уйлары аның ерак.
Күзләрен кысып төби дә
Учындагы бар ачуын
Каерылып томыра:

Су өстенә суга-суга,
Әлеге дә баягы,
Йомры дулкыннар калдырып,
Ашкына таш каядыр.

Идел-йортка юл урау.
Ялгыз ул.
Ният кора.

Аның дәгъвасы аша
Шомлы фал чынга ашар:
Ком җыелып таш булыр,
Кол җыелып баш булыр,
Тулаем язып һуштан
Күтәрелер орышка.
Һәм, тончыга-тончыга,
Зәңгәр керер, ал чыгар!
Далага күк убылыр,
Тояк асты ут булыр,
Көн тотылып чаң булыр,
Кара туфрак кан булыр,
Җан котырыр, тилерер,
Җәрәхәтле зинданыннан
Юл тапмыйча тилмерер.
Таш өстендә таш калмас,
Иң өстендә баш калмас...

Ялгыз ул.
Ният кора.
Хәтерен ера-ера,
Күзләрен кысып төби дә,
Куенымда калмасын дип,

Йодрык кадәр чуер ташны
Ташларга каерыла:

Дошманына атар ул,

Кашы-күзен ватар ул!
Дошманы кем?
Татары!..

Идел-йортта хәл мөшкел.
Идел-йортта хәл мөшкел.
Чытырдап янган учакның
Уты сүнде,
Көл төште.

Гасыр саен суга-суга,
Әлеге дә баягы,
Канлы дулкыннар калдырып,
Ашкына таш каядыр...

## Йорт

Колизейны урларга теләүче сәер кеше турында әкият бар.

Үзем дә укымадыммы икән әле? Күптән инде, нәни чакта ук.

Кыскасы, борынгы амфитеатрны ни өчендер үзләштерергә карар кыла бу. Һәм көн саен, букчасына салып, аны өлешләп-өлешләп өенә ташырга керешә. Отыры бөтен бүлмәләре, кухнясы, ваннасы, чардагы, ятак аслары таш белән тула, коридор траншеяга әйләнә... Һаман ташый, һаман ташый – бөтен гомерен шуңа сарыф итә! Ахыр чиктә, Аид хозурына барыбер авызын турсайтып китәргә мәҗбүр була: ул вакытка Колизей, юкка чыгу түгел, чак кына кечерәйми дә...

Самими рәвештә:

– Дивана! – дип хисләнгәнем истә. – Колизейны урлау мөмкинмени?

Ары таба әлеге сорау мине һәрдаим сагалап килде.

Казанның меңьеллыгына шаһит йортларны эзләгәндә дә, каршыма чыгып басты ул. Моңаеп, Болгардагы Успение чиркәвенең гарәп язулы нигезенә төбәлгәндә дә. Сарай-Бату җимерекләре өстендә селитра исе сеңгән җиллән чәчемне таратканда да...

Колизейны урлау мөмкин икән бит!

Башларны кыру гына җитмәгән, ташларны да җир йөзеннән кырып ташларга омтылучылар булган! Мәһабәт биналардан хәрабәләр өеме калган. Алары да хәкарәтләнгән! Үткән эшкә – салават, имеш. Юк, алай түгел!..

Без бүген татар йортының кыйтга буйлап таратылган ташларын җыябыз. Букча авыр. Куллар суелган. Иңнәр авырта. Әйе, эш күп әле. Әмма алда, һичшиксез, яшисе гомер дә күп.

Димәк, төп нигезебезне берәр кайчан барыбер торгызып бетерәчәкбез.

Һәм ул Колизейдан ким булмаячак.

## Чакма ташы

Бәрә,
Бәрә –
Маңгаема!
Кара янган йөзе.
Иблис, ана, изге рухны
Бер чылбырга тезеп,

Бәрә,
Бәрә кабат,
Бәрә!..
Түзәр чакта – түзәм!
Ике тамчы яшем гүя –
Очкын чәчри күздән.

Калтырана,
Бәрә,
Бәрә!..
Балчык –
Асты, өсте.
Ул тереләй каберенә
Кереп яткан төсле:

Өндә, һәр гамәле өчен
Җавап тоткан сыман,
Боргалана –
Кандай куе
Туфрак арасында...

Шәһит шәһәр изрәп йоклый.
Күләгәләр сафта.
Таң сызылып, миләшләргә
Бал төшәсе чакта

Изрәп йоклый
Кәләшләрнең
Бал төшкәне, хуры.
Ирен очларына җыеп
Бар дөньяның нурын,

Изрәп йоклый нарасыйлар –
Киләчәккә вәкил!
Арба күчәреннән алар
Чак озынрак, бәлки.

Йокылары гына түгел,
Рухы,
Иманы нык:
Изрәп йоклый мөритләре
Шәһәр имамының.

Һичнигә дә төшенмичә,
Һични сизенмичә,
Дөнья изрәп йоклый әле,
Төштән төшкә күчә.

Карынында Җирнең уйный
Яшенме?
Аҗаган? –
Дивар тамырларын капшап,
Берәү чакма чага.

Бәрә!
Бәрә кабат,
Бәрә! –
Җиле дә ят якта,
Ватаннарын ватам диеп,
Маңгаемны вата:

Бәрә,
Бәрә кабат,
Бәрә!..
Сер бирмичә, көтә
Күз яшемнең кайнар килеш
Тамачагын филтә...

Берәү
Бәрә һаман,
Бәрә! –
Йә, ни кылыйм каршы?
Мин бары тик чакма ташы,
Бары – чакма ташы.

Күз яшьләрем чәчри, оча –
Каршы, йә, ни кылыйм?
Кичерегез!
Түзәр хәл юк:
Елыйм,
Елыйм,
Елыйм!..

Кызган дары мичкәседәй,
Арча ягы – арттан –
Томырылып чыгар кояш...
Һәм шулвакыт –
Шартлар.

## Шәһитләр төрбәсе

Казанны яклаучылар монументы да һич матавыксыз корылмады.

Башта конкурс игълан ителде. Ике тапкыр. Өченчесендә генә җиңүче табылды. Нургали капкасы янында күтәрелергә тиешле төрбә проекты иде ул.

Аннары, туристлар күбрәк йөри дип, һәйкәлне Ташаяк мәйданына, цирк хозурына күчерергә булдылар. Тагын конкурс игълан ителде. Икенче омтылыштан ук йомгак ясалды.

Аңарчы биш кырлы Җимерек манара төбен яшел тимгелле кадерсез таш ватыгы каравыллап торды.

Соңрак аны фанерадан кагылган пирамидага алыштырдылар. Пирамида очына шар утырттылар. Халык арасында шомлы сүзләр таралды:

– Бәй, диварны ваткан ядрәгә мәдхия түгелме соң бу?

Ихтимал, шуны ишетеп килгәндер дә: Олы түрә хадимнәре белән бергә Яңа ел чыршысыдай монумент макетын җиде-сигез тапкыр әйләнгәннән соң:

– Нигезен биегәйтергә кирәк, – дигән.

Тагын конкурс игълан ителде.

Бу юлы җиңүче тәүге мәртәбәдән ачыкланды.

Яңа проект авторы, вакланып тормыйча, бакырдан коелган ядрә-шарны «Пирамида» милли-мәдәни үзәгенең түбәсенә генә утырту яклы иде.

Моның чын хәл булуын аңлауга мин:

– Ё-пэ-рэ-сэ-тэ, – дип иске алфавитны искә төшереп алдым.

Сүгенмәдем дә микән әле?

Изге сөякләр өстендә уйналган цирк, ахыр чиктә, Иҗтимагый үзәкнең үзәгенә үтте. Ил агаларын Ирек мәйданы уртасына чыгарып, йөз меңгә якын халык алкышлавында «Баламишкин» көенә биеткәч, монументның иң әүвәлге вариантына әйләнеп кайту фарыз табылды.

Шулай итеп Шәһитләр төрбәсе калыкты.

Уналтынчы йөз уртасында татар халкы кичергәннәрне уйласаң, йөрәгең өзелерлек: Казанны саклаучыларның барысы да кылычтан үткәрелгән, хатын-кызлар мәсхәрәләнгән, шәһәр таланган...

Сабыйларга, дөрес, тимәгәннәр. Буйлары арба көпчәгеннән артмаса.

Мәчет-мәдрәсәләр нигезенә кадәр җимерелгән. Меңьеллык китапларның көле күккә очкан. Саный китсәң, күп инде...

Олы түрә, тасма кисеп, Шәһитләр төрбәсен ачканда:

– Без моны онытырга тиеш түгел! – дигән иде.

Һичшиксез: Нугай урамында башны ярып ятканда да онытасыбыз юк!..

Куе болыт күләгәсендә калган ташка төбәлеп:

– Син ул вакыйгаларда катнаштыңмы? – дип сорарга баздым.

Җавап көткән арада игътибарым таныш бөҗәккә юнәлде: әле генә аска томырылуына карамастан, үҗәт кырмыска, алма төшен капшый-капшый, яңадан үз Олимпына күтәрелеп маташа иде.

– Сизиф, – дип елмайгандай иттем.

Тәкъдиренә төшкән өлешне урыныннан кузгатып, үргә тәгәрәтер өчен киерелгән таза гәүдә күз алдыма килде: яңагын, иңбашларын йөккә терәгән, йөзендә һәр күзәнәге тартыша, авырлыктан тез буыннары ычкыныпычкынып ала...

Сизифны түгел, кырмысканы сурәтләвем бу.

Минем соравыма җавап кайтаручы булмады.

## Түбә

Таш яңадан аска томырылды.
Шәрәләнде кинәт урыны.
Йөгебезме каһәрләнгән шулай,
Үзебезме әллә –
Ырумы?

Ничәнче кат Тарих өнсез кала,
Ага Вакыт,
Ага кирегә...
Җир-Ананың күкрәкләрен капшап
Өйрәнгәндәй тәпи йөрергә,

Һаман да бер:
Баш урында, шөкер,
Дүрт сан диеп, исән-сау гына,
Тәкъдиребез сыман авыр ташны
Күтәрәбез Ирек тавына...

Сыдырылсын иңнәр,
Билләр бетсен!
Кем терәтер Күккә – шуңа дан! –
Канатлары сынган хыял төсле
Таш ишелеп төшә яңадан,

Һәм яңадан Тарих артка чигә...
Башлар моны мең кат кичергән! –
Ярый Тәңре яраларны юып,
Таңда терек суын эчерә:
Төрки будун, ныгы,
Калык диеп!.. –

Тоныкланмас чакта шушы өн,
Ахыры гел күтәрелү булыр
Челпәрәмә килеп
Төшүнең!

Басылсак та, үкенечле түгел.
Торыннарны, Тәңре, ташлама! –
Ныгысыннар:
Бездән мирас булып,
Тау астында яткан таш кала.

## Тузан

Җил җиңелчә тузынып алды.
Көн ярыйсы ук бозылырга охшап тора иде.
Күземне уганда:
– Дөнья тузаннан яратылган, – дип уйладым.
Һичшиксез, кайчандыр аңардан янә тузан гына калачак.
Ихтимал, тузан – дөньяда иң кечкенә таш валчыгыдыр...

## Балбал

Изгеләрдән, ахры,
Мине яратучым:
Күз турыма тиеп
Үткәч бармак очы,
Дөнья төскә керде.
Йөзгә бәрде кояш.
Шулкадәрле назик,
Шулкадәрле юаш –
Сыпырынды җилләр.
Сырпаланды кыяк.
Һәм чык тәгәрәде
Таш яңагым буйлап...

Өстем – дөнья өсте,
Астым – дөнья асты,
Ныклы терәү булып,
Мин уртага бастым –
Имин торсын диеп,
Ыру, нәсел-нәсәп! –
Бер кулымда – кылыч,
Бер кулымда – кәсә:
Дошман каны аксын,
Йә күперсен буза –
Мин үз, торыннарым,
Тормыш туегызда!..

Күпме кояш сүнде.
Күпме сулар акты.
Юл өстендә торган
Дәүләтләрне ватып,
Томырылды еллар,
Тоттырмыйча ялын.
Дала уртасында
Тома ятим калдым:
Тубыгымнан – уба[6],
Иңнәремдә – күкләр,
Гөмбәз баскан саен
Чәрдәкләнә күкрәк,
Таралырдай булып
Буыннарым чатный.
Үткәннәрне кичтем,
Киләчәккә ят мин.

Арык тәнем тулы
Изге язу – яра! –
Күкләр баскан саен
Җиргә сеңә барам.

[6] Уба – монда: курган.

Җыерчыклы йөзе
Һәм кытыршы тыны –
Җилләр, тиле кортка,
Исә, һушы тонып;
Шам кылычы тапкан
Сабый төсле димме,
И каезлый билне,
И каезлый билне!..

Һәр тууның хакы –
Үлем, ахыр чиктә.
Булганына шөкер.
Яшәгәнем җитә.
Бер газабым калмас
Авып төшәрмен дә! –
Терәвеннән башка
Дөнья нишләр менә?

## Азак

Күзлек бөтенләй тапланып бетте.

Күк төсенең спектрдагы урынын чамаларлык түгел иде.

ГУМ тирәсендә гөрелте һаман куера барды.

Җил җәяүлеләр урамын буе-буена себереп төште. Почмак саен гүләде, ачы сызгырды. Түбәләр дөбердәште. Кайдадыр пыяла челпәрәмә килде. Илаһи симфониягә хатын-кыз чәрелдәве кушылды.

Метамериянең нәрсә булуын хәтерләргә тырышып ятканда өстемә ике космонавт иелде. Җилкәмнән генә йолкып күтәрделәр.

– Рәхмәт, – дидем. – Алайса, гәүдәмне тоймый башлаган идем инде.

Хәзер алар миңа, чыннан да, гарештән иңгән бәгъзеләр кебек тоелды.

– Тагын берәү, – диде уң яктагы фәрештә.

Сыегайган аякларыма баскач та, вазгыятьнең чак кына үзгәреш кичерүенә төшендем: халык кулындагы чәчәкләрнең күбесе, нинди сихер тәэсиредер, ак кәгазьгә, гап-гади ак кәгазьгә әйләнгән иде! Берничәсендә алты-җиде йолдызчык тамгасы да абайладым, ахры...

Космонавтлар кешеләрне (ир-атка, хатын-кызга, карт-корыга, үсмергә аермыйча) дию гайрәте күрсәтеп якынлашучы давылдан коткаруда иде.

Сул яктагы фәрештә маңгаемдагы кан куерыгына төртеп:

– О, монда безгә эш калмаган да, – дип куйды. Шаян кеше икән.

Мине, ике яктан култыклап, галәм корабына озаттылар. Ихлас күңелдән Чаллы заводының ассортименты арта баруына куандым. Кулны ипле генә каерып, ишеккә төрттеләр. Күзлегем төшеп китте. Шытырдатып өстенә бастым. Сынды, ахры... кул.

Элгәре мин башым күргәннәрне бәйнә-бәйнә сөйләргә, әлеге тантанага очраклы гына килеп керүемне аңлатырга да алгысынмадым түгел.

Әмма аннары:

– Ниемә хаҗәт? – дип кире уйладым. – Әллә бер дә гаебем юкмы? Һичьюгы, сүгенмимме, мәсәлән?

Дөнья үз урынына кайтып җиткән иде.

Кайдадыр бик тирәндә кечкенә очкын гөлт итеп ягулыкка капты. Техника җан бирмәкче диюдәй үкерде.

Кузгалдык.

Мин нигәдер Олуг Мөхәммәт һәйкәленә борылып карарга базмадым.

Нугай урамы чатында аунап калган ташка да.



Рафис Корбан

# ТАНКИСТЛАР

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

## Автордан кереш сүз

*2022 елның 24 февралендә, Донбасста Донецк һәм Луганск халык республикалары җитәкчеләренең, Украина тарафыннан үзләренә каршы алып барылган сәясәтенә риза булмыйча, Россиядән хәрби ярдәм сорауларыннан соң, Россия Украинада Махсус хәрби операция (СВО) башлап җибәрде. Киев шул көнне үк Россия белән дипломатик мөнәсәбәтләрен өзде. Ә инде Россия бу ике республиканы бәйсез дип таныганнан соң, Көнбатыш илләре, аеруча Америка Россиягә каршы сәяси һәм икътисади басым ясау юлына басты.*

*Россия махсус хәрби операцияне алып бару өчен илдә өлешчә мобилизация игълан итте.*

*Әлбәттә инде, илләр арасында ике елдан артыкка сузылган канлы бәрелешләрдә һәлак булучылар да күп, тиңдәшсез батырлык күрсәтүчеләр дә бар. Матбугатта, радио-телевидениедә, интернетта боларның барысы турында да яктыртып барыла. Мәскәү, Санкт-Петербург нәшриятлары инде операция каһарманнары турында дистәләрчә китаплар да чыгарырга өлгерде. СВОда катнашучылар арасында безнең Татарстаннан да 12 сугышчының Россия Герое исеменә лаек булганын беләбез. Әлбәттә, бу каһарманнарыбызның батырлыклары хакында да әсәрләр язылса, начар булмас иде. Кайсы турында язарга соң? Герой исеме алганнан соң туган ягына әйләнеп кайтып, иҗтимагый тормышта актив катнашып киткән, бигрәк тә яшь буында ватанпәрвәрлек рухы тәрбияләүгә зур игътибар бирүне кирәк дип табып, алар арасында актив эш башлап җибәргән Рәсим Баксиков исеме күңелгә килде.*

*Зур күләмле әсәр язу – әлбәттә, җитди эш. Аны иҗат итү өчен материалны яхшы белергә, өйрәнергә кирәк. Моның өчен операция барган җирләрне үз күзләрең белән күреп кайту да кирәктер бәлки. Аннан соң, язам дигәндә дә, мондый әсәрне кыска вакыт эчендә генә язып чыгып та булмас иде. Рәсим Баксиков белән очрашкач, ул миңа: «Анда ук барып йөрергә киңәш итмәс идем, Рафис абый. Сугыш булып узган җирләрдәге җимереклекләр турында язар өчен иҗади фантазияңне эшкә җигү дә җитә. Ә инде бәрелешләрне үз күзең белән күрергә телим дисәң, үзеңне үзең үлемгә илтеп тыгу белән бер булыр иде. Бүгенге сугыш ул моңа кадәр булган сугышлардан*

Рафис КОРБАН (1957) – *шагыйрь, прозаик; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе; Ш.Маннур, Ф.Хөсни, А.Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты, «Алмалы төн», «Бәхет телим», «Яра» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

*ның аерыла. Бүгенге сугышны, төгәл генә әйткәндә, һава сугышы дип атау дөрес булыр иде. Чөнки бу бәрелешләрнең уңышлы тәмамлануын баш өстендә әйләнеп йөрүче пилотсыз очкычлар хәл итә. Бөтен хәрби бәрелешләр дә дроннар аркылы алып барыла. Ә ул очкычлар һәр танк, һәр бронетранспортёр, һәр пушканы гына түгел, һәр солдатны да прицелда тота. Аз гына саксызлык күрсәтсәң дә, һәлак булуың бик мөмкин. Шуңа күрә әсәреңне Казанда торып кына язарга киңәш бирер идем», – диде. Һәм менә шул киңәшләрне тотып, Аллага тапшырып, шушы әсәрне язарга утырдым.*

## Беренче сынау

Украинада сугыш бара. Чын сугыш. Ләкин ул сугыш дип түгел, махсус хәрби операция (СВО) дип атала. Аның хәтта сугышчылары да юк. Анда катнашучыларга сигнал белән генә мөрәҗәгать итәләр. Ул сигнал позывной дип атала. Мәсәлән, «Алёша» – командиры Рәсим Баксиков булган экипажның позывное. Команда пунктыннан танк командиры белән элемтәгә керергә телиләр икән, аңа шулай: «Алёша» дип мөрәҗәгать итәләр. Рәсимнең үзен махсус хәрби операциягә алыныр алдыннан эшләгән оешма исеме белән «Монолит» дип кенә атыйлар. Механик-йөртүче Александр Леваковның позывное – «Ласка». Минада шартлаган үз танкы ремонтланып беткәнче Рәсим шул танкта сугышты. Аннары аның танкын «Кыш бабай» дип атап йөртә башладылар. Шул танк белән ул Яңа елга кергәндә, Луганскида чыршы бәйрәме үткәрүче бер мәктәп балалары өчен Кыш бабай бүләкләре алып килгән иде. Бүләкне Кыш бабай булып киенеп килгән Рәсим үзе өләште. Шуннан соң аңа «Кыш бабай» дигән позывной ябышып калды.

Беренче сугышчан чыныгуны Рәсим Татарстанда формалашкан Дамир Исламов исемендәге танк батальоны составында Луганск Халык Республикасын азат итү өчен барган операцияләрдә алды. Луганск азат ителгәннән соң сугышта күп батырлыклар күрсәткән танкистларга «Луганск Халык Республикасы Герое» дигән исем бирелде. Рәсим дә шул исемгә лаек булды.

Батальонга исеме бирелгән Дамир Исламов үзе дә – Рәсим шикелле үк Казан танк училищесын тәмамлаган егет. Алар ике Дамир – Дамир Исламов һәм Дамир Гыйлемханов, икесе бер танкта хезмәт иткәннәр, махсус хәрби операция игълан ителеп ике генә атна үткәндә, 7 мартта, Луганск Халык Республикасын азат итү өчен барган сугышта батырлык күрсәтеп һәлак булганнар.

Рәсим алардан күпкә алдан тәмамлады училищены. Дамир Исламов ул уку йортын Рәсим училищедан соң Ерак Көнчыгышта сигез ел контракт белән хезмәт итеп отставкага чыккан ике мең дә унсигезенче елда гына тәмамлаган әле. Ә Гыйлемханов, Армиядән соң тагын контракт төзеп, Ерак Көнчыгышта, Хабаровск шәһәрендә хезмәт иткән. Рәсим белән бер юллардан йөргәннәр булып чыга, кыскасы.

Украиннар Луганскида бик әшәке кыландылар ул вакытта. Ике Дамир да бер экипажда иде. Луганскиның Золотой Северодонецк районын азат итү өчен барган сугышта экипажга берьюлы биш танкка каршы торырга туры

килә. Исламов танкы дошманның көчле ныгытмасын һәм солдатларын юк итә. Дүрт танкын яндыра. Әмма бишенче танк аткан снаряд аның үзенә барып тия. Экипаж һәлак була.

Россия Президенты Указы белән Дамир Исламов һәм Дамир Гыйлемхановка Россия Герое дигән мактаулы исем бирелә.

Рәсимнең СВОга китәргә дигән теләге, шушы егетләрнең батырлыгы турында ишеткәч, тагын да ныгыды. Ул курку белмәс танкистлар өчен дошманнан үч алырга дигән максат белән яши башлады. Һәм нәкъ менә шушы вакытта Татарстанда СВОга җибәрер өчен танк батальоны оештырырга дип хәл иткәннәр иде. Рәсим үзен шушы батальонның бер солдаты булырга тиеш дип уйлады.

* * *

Бүгенге сугышта җиңүгә ирешүдә танклар хәлиткеч рольне уйный. Һичшиксез, пехота белән артиллериянең дә үз урыны бар. Башта артиллерия үзенең эшен башкара, авыр снарядлардан атып, һөҗүм ителергә тиешле дошман ныгытмаларын сафтан чыгара. Әлбәттә, аларның кайда урнашкан булуларын төгәл белергә кирәк. Аннары танклар һөҗүм итә. Танклар һөҗүмгә элекке кинофильмнарда күрсәтелгән шикелле сугыш кырын тутырып бармый хәзер. Күп дигәндә, өч-дүрт танк җибәрелергә мөмкин. Рәсим взводында ике танк, тугыз танкист. Ул, гадәттә, ике танк белән һөҗүм итүгә өстенлек бирә. Танк атакасы да кыска вакытта, утыз-кырык минут эчендә булып ала. Шул вакытта дошман тупланган урынга көчле удар ясап аласың да кире әйләнеп кайтасың. Аткан саен урыныңны алмаштырып, урыннан-урынга күчеп йөрүең хәерле. Чөнки дроннар синең кайдалыгыңны хәбәр итеп торалар, беренче снарядыңны җибәрергә өлгермисең, яныңа дошман снаряды килеп төшкәнен көт тә тор. Бер генә түгел, ул «кошчыклар» күчләре белән – бишәү-алтау оча, кайчагында унга хәтле җитәргә мөмкиннәр. Шуңа күрә тиз манёвр ясап өлгерергә кирәк. Әле танкка ул дрон үзе дә һөҗүм итәргә мөмкин. Шуннан саклану өчен безнекеләр танк өстенә челтәрле ятьмә кора башладылар.

Рәсим танк сугышының үзенчәлекләре хакында хәзер, инде күпмедер тәҗрибә туплагач, шактый гына бәрелешләрдә катнашканнан соң исенә төшереп утыра. Ул әнисенә кыска гына хат язды да үзенең беренче тапкыр сугышка керүен хәтергә төшерде.

Рәсим озын хатлар язарга яратмый. Телефоннан элемтәгә кергәндә дә, әнисенә үзенең хәлләре турында: «Бар да әйбәт. Исән-сау, ашадык-эчтек», – ди дә сүзен бетерә. Бу юлы да шулай: «Алга барабыз. Без җиңәргә тиеш! Башкача һич ярамый!» дип язды да, барысына да сәламнәрен юллагач, «Соңгы сугыштан соң командир мактады. Безне тиздән бүләкләрләр, ахры» дигән сүзләр белән хатын төгәлләп тә куйды.

Ә беренче тапкыр сугышка керүе, чынлап та, онытылмаслык булды аның.

Училищедан соң контракт буенча сигез ел танкта хезмәт итәргә туры килсә дә, сугыш сугыш инде, хәрби өйрәнүләрдәге уен гына түгел, монда пушканы чын снаряд белән корасың, дошманны юк итәргә дигән максат белән атасың. Отставкага чыкканнан соң узган дүрт ел, әлбәттә, шактый нәрсәләрне оныттырган да. Ләкин СВО игълан ителгәч, Рәсим үзен махсус хәрби

операциядә катнашырга тиеш дип тапты. Ни өчен малай чагында ук хәрби булырга дип хыялланган иде соң ул? Ни өчен танк училищесына укырга керде? Аны тәмамлагач, сигез ел буе контракт белән Ерак Көнчыгышта танк гаскәрләрендә хезмәт итте. Ә инде туган иле үз дошманнарына каршы чын хәрби операция башлагач, читтә торып калсынмы?

Мобилизация игълан ителгәч тә, комиссариатка барды ул. Аны пехотага рядовой солдат итеп җибәрәчәкләрен әйттеләр. Ничек инде рядовой солдат? Танкист та түгел хәтта. Ә бит ул инде гомеренең унөч елын – 2005 елдан тормышын танкистлыкка багышлаган хәрби офицер.

Әле җитмәсә, хәрби хезмәттән отставкага чыккан кешенең, яңадан солдатка алыныр өчен кулында элек хезмәт иткән частеннан белешмәсе булырга тиеш икән. Шундый белешмә булган очракта гына яшәгән урыныңдагы комиссариат сине хәрби опрерациягә җибәрергә мөмкин. Рәсим шул документны әзерләп җибәртер өчен Ерак Көнчыгышта үзе белән бергә артиллерия дивизионында хезмәт иткән дусты Михаил Яковенкога хат юллады. Ләкин Яковенко инде үз теләге белән СВОга артиллерист булып китеп тә барган булып чыкты. Ә ул әзерләп җибәргән белешмә Рәсимне артиллериядә хезмәт итүне күздә тота иде. Артиллерия? Ул бит танкист. Гади танкист кына да түгел әле, офицер – лейтенант. Юк, артиллерист буласы килми Рәсимнең. Ул бит Дамир Исламов исемендәге танк батальонында сугышырга дип ният корды.

Белешмә алыр өчен Рәсимгә Приморьега үзенә барырга туры килде. Бу вакытта ул Мәскәүдә белорус егетләренең «Монолит» дип аталган бер төзелеш фирмасында бетончы булып эшләп йөри иде. Хәрби хезмәттән киткәннән соң, ниһаять, әйбәт хезмәт хакы алып эшли генә башлаган иде. Белоруслар аның СВОга китәргә теләвен уңай кабул иттеләр. Ерак Көнчыгышка барып йөргән көннәре өчен дә хезмәт хакы түләп тордылар.

Хезмәт хакы дигәннән, отставкага чykканнан соң гаиләне тәэмин итү өчен канәгатьләнерлек акчалы эш таба алмыйча шактый интекте ул.

Казанга әйләнеп кайткач, кайларда гына эшләп карамады. «5 нче көпчәк» дип аталган шиномонтаж фирмасында бер ел бил бөкте. «Гаиләне тәэмин итә алмыйсың», – дип, хатыны күпме игәүләде. Фатирга кереп яшәделәр алар. Фатир хакын түләр вакыт җиткән саен өйдә гауга чыгармыйча калмый иде Анастасиясе. Хаклы да булгандыр инде. Акча бит ирләргә түгел, хатын-кызга җитми. Үзенә генә түгел, «Ике баланы да үстерәсе бар!» – дип тавыш чыгара. Андый чакларда Рәсим тавышланып тормый, хатыны тынычлансын өчен әнисе янына чыгып китә. Ул да акчага тиенеп кенә яшәми. Олы кызы Зарина гаиләсе белән коммуналкада көн күрә. Рәсимнең СВОга барырга ният кылуына яхшы хезмәт хакы вәгъдә ителүе дә этәргеч ясамыйча калмады, әлбәттә.

Шулай итеп февраль аенда игълан ителгән операциягә барып җитү өчен ноябрьнең бишесенә кадәр көтәргә туры килде.

Китәр алдыннан аларны берничә көн әзерләделәр. Танк йөртергә, снарядларны корып атарга өйрәттеләр.

– Барыгызда да телефоннар бармы? – дип сорады самолётка утырыр алдыннан аларны озатучы капитан.

– Бар, иптәш капитан!

– Телефоннарыгызны сүндерегез. Сим-карталарын чыгарыгыз. Дислокация урынына барып җиткәч, шундагы сим-карталарны алып куярсыз. Югыйсә Россия номерлары белән шалтыратуыгызны шундук беләчәкләр һәм өстегезгә бомба килеп төшкәнен сизми дә калырсыз.

Мондый очраклар баштагы чорда шактый булып торган икән. Озатучы беренче солдатлар арасында сугышка керергә дә өлгермичә һәлак булучылар турында әйтеп алды.

Рәсимне башта взвод командиры итеп билгеләгәннәр иде. Алар килер алдыннан гына рота командиры үз вазифасыннан баш тарткан булган. Батальон командиры аның урынын Рәсимгә тәкъдим итте:

– Нәрсә, Баксиков, рота белән җитәкчелек итәргә теләгең юкмы?

– Кая кушсагыз, шунда хезмәт итәргә риза, иптәш командир! – диде ул хәрбиләрчә ныклык белән.

– Молодец! Ротаны кабул итеп ал. Ләкин, бер «ләкин» бар. Башта үзең хезмәт итәргә тиешле танкны ремонтлап чыгарга кирәк булачак.

Рәсим хезмәт итәргә тиешле танкның командиры Александр Леваков взводы өчен өч танкны ремонтлап чыгарга кирәк икән. Һәм бу эшне оештыруны Рәсимгә йөкләделәр. Ул, рота командиры хәрби заданиеләргә шәхсән үзе катнашырга тиеш бит дип, танк белән операцияләргә чыгарга теләвен әйтсә дә, үз урынында калырга зампотехны әзерләгәнче, аңа ремонт белән шөгыльләнергә туры килде.

Һәм менә, ниһаять, Рәсим үзенең беренче заданиесенә чыгарга тиеш. Алар взводына бер-берсенә якын гына урнашкан ике дошман ныгытмасын алу бурычы куелды.

Һөҗүмне ике танк белән украиннар таң алды төшләрен күреп йоклаган чакта иртәнге биштә ясарга булдылар. Ике ныгытманы да берьюлы утка тоттылар. Бер-бер артлы фугаслы снарядлар белән туздырып ташлауга, артларыннан ук ике БМП белән десант төшерелде.

Бәрелеш тиз тәмамланды. Украиннар искә килеп, артиллериядән ата башлаганчы, тизрәк бу урыннан китәргә кирәк иде. Кузгалырга җыенганда гына, пехота командиры Рәсимгә туктарга сорап кул изәде.

– Нәрсә булды? – диде Рәсим, люктан башын чыгарып.

– «Монолит», мин – «Бөркет», – дип, десантник башта үзенең позывноен әйтте. Аннары: – Пленныйлар бар. Берсе яралы. Алып кайтып, лазаретка тапшырыгыз әле үзен, – диде.

Ул арада әсирләр чыккан окопның теге башыннан автоматтан ата башладылар. Әсирләр дә, десантчылар да, башларын тотып, җиргә аудылар. Рәсим тиз генә башын башня эченә алып, наводчикка атарга әмер бирде:

– Окоп башында амбразураны күрәсеңме? Фугаслы граната белән җиппәр әле шуңа берне! – диде.

Гранатомёттан бирелгән залп амбразураның көлен күккә очырды.

«Бөркет», сикереп торып, әсирләргә аякка басарга боерды:

– Торыгыз, кабахәтләр! Әле сезне лазаретка җибәрмәкче булам, теге дөньяга гына олактырасы икән! – диде дә, автоматын корып, аягына баса алмыйча, тезләнеп торган яралы әсиргә төбәде.

– Атма, командир, без монда деребез дә үз теләгебез белән түгел. Безне

сугышырга мәҗбүр итүчене юк иттегез инде, – дип, яралы украин егете ялына башлады.

Әсирләр, чынлап та, үз теләкләре белән сугышучыларга охшамаганнар иде. Гади халык арасыннан куып китерелгәнлекләре күренеп тора. Коралларын да окоп төбендә ташлап калдырганнар.

Лазаретка алып кайтырга дигән егетне танкка утыртып, кайту ягына борылдылар. Ләкин ерак китә алмадылар. Бәрелеш булган җирдән бер чакрым чамасы киттеләрме икән, өсләрендә ике дрон пәйда булды. Күп тә үтмәде, танк янында ук снарядлар төшеп ярыла башлады.

Танк эчендәгеләрнең бу әле беренче сугышчан задание үтәп кайтып килүләре. Снарядларның шулай яннарында ук ярылуын да әле беренче тапкыр күрүләре.

– Боларны атып төшерергә кирәк! – дип, наводчикка кул пулемётыннан дроннарга атарга команда бирде дә, Рәсим үзе танкның башнясын артка борып, алга арты белән бара башлады. Янәсе, тирә-якны күзәтергә уңайлырак булачак дип уйлады. Ләкин зур хата ясады. Артны күзәтеп барып, ул алда ни барын күрмичә калды һәм танк арты белән минага барып керде. Көчле шартлау яңгырады. Командир йөртүче-механик белән наводчикка, аннары яралы украинга люктан өскә чыгарга ярдәм итте. Яна башлаган танктан тиз генә чыгып, куркынычсыз зонага йөгерделәр. Аларның минага эләгүен күреп, артларыннан БМП килеп җитте, һәм аларны машинага күтәрделәр. Әнә шулай могҗиза белән генә исән калдылар.

Беренче операция вакытында ук танкны югалтуны Рәсим авыр кичерде. Бу уңышсызлыкта ул бары тик үзен гаепләде.

– Борчылма, командир, иң мөһиме – үзегез исән калгансыз. Бу сиңа беренче сугышчан сынау булды, – диде батальон командиры.

Танкка әллә ни зур зыян килмәгән иде. Соңыннан аны буксир белән алып кайтып ремонтлап, сафка бастырдылар.

## Батырлык

Җәй башында Украина хәрбиләре Запорожье юнәлешендә актив сугыш хәрәкәтләре башлап җибәрде. Менә бүген дә 127 нче дивизиянең бөтен подразделениеләренә дә дошманга каршы контрһөҗүмгә әзер булып торырга дигән әмер бирелде.

Ә Рәсим Баксиков командалык иткән танк ротасына Новодаровка бистәсен чистарту бурычы йөкләнде. Бу операция асылда сугыш белән үткәрелгән разведка дигән мәгънәне аңлата. Димәк, дошман белән капма-каршы бәрелешергә туры килүе дә бар. Шуңа күрә алдагы көндә ул территорияне артиллерия утына тотып, хәрбиләр телендә әйткәнчә, «артподготовка» үткәрелде.

Бөек Ватан сугышында һөҗүм вакытында хәлиткеч рольне артиллерия башкаруын әйтәләр. Ә хәзерге сугышта танкларга зур ышаныч күрсәтелә. Артиллерия туптан атканда, әле пехотага ышыклану урыннарында качып тору мөмкинлеге бар. Ә менә танклар һөҗүме башланса, алар инде бернинди каршылыкларны да исән калдырмый. Шуңа күрә: «Танклар өчен чикләр юк!» – дип әйтергә ярата Рәсим.

Леваков танкында экипаж дүрт солдаттан тора: рота командиры – өлкән

лейтенант Рәсим Баксиков үзе, танк командиры – сержант Александр Леваков, наводчик – ефрейтор Алексей Неустроев һәм механик-йөртүче Филипп Евсеев. Сугышта һәр танкның пилотсыз оча торган аппарат аша артиллериягә ут ачар өчен наводка биреп торучы үз операторы бар. Александр Леваков командасында бу эшне ефрейтор Илья Гаврилов башкара.

Экипаж заданиене үтәргә иртә таңнан кузгалды. Сугыш кирәк-яракларын җитәрлек итеп – танкка, бронетранспортёрларга, пехотага төбәп ата торган снарядларны тулы комплектта алдылар.

Җәйге матур тын иртә. Урман полосасын яңгыратып, сандугачлар сайрый. Шул тынлыкны бозып, полоса буен танк гөрелтесе күмеп китте. Ә бит 80 ел элек бу тирәләрдә Ватанны фашистлардан азат итәр өчен аяусыз сугышлар барган. Ул сугыш совет халкының зур җиңүе белән тәмамланган. Бөек Җиңү белән. Ул сугышта Рәсимнең әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да дәү әтиләре, бабайлары катнашкан. Кызганыч, немец нацистларын үз өннәренә барып дөмектерсәләр дә, Советлар Союзының үзендә, Украинада тамырларын корытып бетермәгәннәр шул ул кабахәтләрнең. Менә хәзер, сугыш бетеп, сиксән елга якын вакыт узганнан соң да, җиңүчеләрнең оныкларына шуларга каршы сугыш алып барырга, яңадан кан коярга туры килә.

Новодаровка юлы тыныч күренде. Бернинди дә хәрби техника да, кораллы кешеләр дә очрамады.

Бу тынычлыкка ышаныч юк, алдавыч тынлык булырга мөмкин дип уйлады Рәсим.

Леваков шунда урман полосасы буеннан үзләренә каршы килеп чыккан танкны күреп алды. Алар каршына туп-туры Т-72Б танкы килә иде.

– Танк! Командир! Каршыга танк килә!

Рәсим шул секундта ук наводчикка:

– Алексей, ут! – дип, атарга әмер бирде.

Неустроев машинаны фугаслы снаряд белән атарга корып куйган иде.

– Кумулятив снаряд белән ат! – дип кычкырды Рәсим. Чөнки фугас ул броняны җимерми, бары тик машинага ут кына каба һәм солдатларны снаряд кыйпылчыклары белән яралый. Ә кумулятив снаряд броняны тишеп, танк эчендәге һава басымын күтәрә. Шуның нәтиҗәсендә эчтә булган снарядларга детонация ясалып, шартлау барлыкка килә. Танк сафтан чыга. Экипаж басымга чыдый алмыйча шунда ук һәлак була.

– Дөмекте! – дип кычкырды Неустроев.

– Тагын күренмиләрме?! Тизрәк кор, кумулятив снаряд белән! – диде командир.

– БМПлар күренде. Алдан тагын бер танк килә. Монысы да – Т-72Б.

– Дөмектер тизрәк! Танкка ат. Исенә килергә өлгермәсен. БМПларны фугаслар белән яндырырбыз.

Минут та үтмәде, икенче танк та шартлап, күккә кара төтен баганасы күтәрелде. Бронетранспортёрлар киң фронт белән таралासы урында, берсе артыннан берсе укмашып киләләр иде. Йөртүчеләре тәҗрибәсезме, инструкторларының осталыгы шуның кадәрле генәме, боларны бер-бер артлы юкка чыгарырга җиңел булачак дип уйлап куйды Рәсим.

Шулай килеп чыкты да. Бер танк шушы хәтле машинага каршы тора

алмас, куркып качар дип уйладылар, ахры, БМПдагылар. Берәм-берәм үзләре утка тотыла башлагач бөтенләй югалып калдылар. Фугаслы гранаталар яңгыры ява башлагач, машинадан киемнәренә ут капкан солдатлар җиргә сикерергә тотынды. Ләкин аларның күбесе снаряд кыйпылчыкларыннан яраланган иде, сикереп төшкән җирләреннән аякка баса алмыйча ятып калдылар. Бәрелеш ничек тиз һәм көтмәгәндә башланса, шулай ук тиз бетте дә.

Көтелмәгән бәрелештән соң Рәсим үзен бастырылган төштән уянган кеше кебек хис итте. Ул шулкадәр йончыган, үзенең Мәскәүдә эшләгәндә бер цистерна бетонны кул белән бушаткан чагындагы кебек арган, тәмам хәлдән тайган иде. Рәсим генә түгел, аның экипажындагы наводчик Алексей Неустроев белән механик Александр Леваков та манма тиргә батып, суга төшкән чебешләргә охшап калганнар иде.

– Беттеләр бугай, бүтән техника күренми, – диде Рәсим, люктан башын чыгарып, тирә-якны күзәткәннән соң.

– Командир, без генә юк иттекме соң боларны?

– Кем булсын тагын?!

– Тулы бер взвод иде бит болар. Ике танк, алтымы, җидеме бронетранспортёр.

– Сигез, машина яна, – диде наводчик Неустроев.

– Берсе – американский М113.

– Кызу эшләп алдык. Снаряд куярга өлгереп булмый, мин сиңа әйтим. Ярты сәгатьтә бит.

– Ул бронемашиналарда күпме кеше булды икән? Һәрберсендә ун-унике дип исәпләсәң дә, йөзләп була түгелме?

– Сюрприз булды бу хәрбиләр өчен.

– Яңа һөҗүмгә килүләре булдымы икән?

Үзләре өчен дә көтелмәгән бу бәрелештән шок хәлендә калган егетләр, башкарган эшләреннән канәгать булып, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, көтмәгәндә килеп чыккан сугыш турында сөйләшә башладылар. Ул арада наушникта элемтәче оператор Илья Гавриловның тавышы ишетелде:

– «Алёша», «Алёша», ишетәсеңме? Шәп эшләдегез! Молодцы! Күчегез бу урыннан.

Егетләргә бу тирәдән тизрәк китү ягын карарга кирәк иде. Исләренә килеп, дошманның ярдәмгә ташланулары мөмкин. Ләкин Рәсим позицияне ныгытырга кирәк дип уйлап куйды. Элемтәчегә:

– Пехота кайда? Тизрәк булсыннар. Танклар, БМПлар яна. Солдатлары сугышырлык хәлдә түгел. Яралылар күп. Күбесе үлде бугай, – дип җавап бирде. Ул шулай диде дә танк йөртүчегә мөрәҗәгать итте: – Бор машинаны. Агачлар арасына посып торырга кирәк. Килеп чыга калсалар, көтмәгәндә һөҗүм итәргә уңайлы булыр, – диде. – Тиздән безнең мотострелоклар килеп җитәр. Аңа хәтле яшеренеп тору хәерле.

– Боеприпаслар бетте, командир. Безгә лагерьга кайтып килергә кирәк, – диде Неустроев.

– «Алёша», сезгә ярдәмгә тагын бер танк китте. Аның белән снарядлар алырга кайтып килерсез, – диде элемтәче.

Бераздан, чынлап та, ярдәмгә җибәрелгән танк күренде. Ул арада

мотоцикллы укчылар взводы килеп, яралы украин хәрбиләрен җыя башладылар.

– Мәетләрне дә калдырмагыз, – диде элемтәче тавышы.

Мәетләр дошман ягында һәлак булган безнең солдатларның мәетләренә алмашыр өчен кирәк иде.

Ярдәмгә килгән танкның үзенә ярдәм кирәк булып чыкты. Ул дошман артиллериясе атакасына туры килгән, сугыш алып барырга яраксыз иде.

– Буксирга алып, частька кайтарырга кирәк, – диде Рәсим.

Егетләргә аны буксирга алыр өчен машинадан чыгарга туры килде. Ул арада баш очында «кошчыклар» – дроннар күренде. Алар ике танкны да, өсләренә очып төшеп, юк итәргә мөмкиннәр. Дроннар хуҗаларына видео җибәреп торалар иде булса кирәк, дошман ягыннан артиллерия снарядлары төшеп ярыла башлады.

Егетләр, машиналарын агачлар арасына яшереп, үзләре дә агачлыкка йөгерделәр. Дроннардан качып, десантниклар да шул тирәгә җыйналганнар иде. Леваков үз янында яткан солдаттан кем булуын сорады:

– Мин – «Ласка», бу танкның командиры, ә син кем?

– «Колючий» мин, доброволец Сергей Солёнов.

Леваков шунда үзләренең өстендә жуылдап торган тавыш ишетте. Бу алар качкан агач башында зырылдаучы квадрокоптер-дрон тавышы иде. Ул арада янында яткан Солёнов көтмәгәндә, аның өстенә ташланды. Шул моментта ук граната шартлады, көчле шартлаудан Александр аңын җуеп тынсыз калды. Бераздан ул аңына килде һәм аның өстенә капланган Солёновның канга батып тынсыз ятуын күрде. Үзенең дә тәнендә граната ярчыгы барын тойды. Шунда «Колючий» да ыңгырашып, кымшанып куйды.

– «Колючий», син исәнме? – дип сорады Леваков.

Аның соравыннан айнып киткән Солёнов, аңына килеп:

– «Ласка», мин өч йөзенче, – диде.

– Нык бул. Син бит командирның гомерен саклап калдың. Сиңа Россия Герое бирәчәкләр.

– Шаярырлык түгел монда хәлләр, – диде «Колючий».

Леваков егетләрдән: «Табиб бармы?» – дип сорады.

Ефрейтор Алексей Неустроев тиз генә танктан аптечка алып килде. «Колючий»ның аяклары яраланган. Гранатаның бөтен ярчыгын ул үзенә алган булып чыкты. Ә Леваковка бары бер ярчык эләккән иде. Алексей, аның чалбар балакларын кисеп, йод белән яраларын сөртте. Ярчыкларның алып булганын алып, бинт белән урап бәйләделәр дә, плащ-палаткага яткырып, бронетранспортёрда кыр госпиталенә алып кайтып киттеләр.

Көн саен мондый бәрелешләр булып тормаса да, «Алёша» экипажы бүгенге сугышны гадәти кабул итте. Чөнки сугыш сугыш инде. Анда әллә нинди катлаулы операцияләргә юлыгуың мөмкин. Бу юлы да алар дошманның Запорожье юнәлешендә хәлиткеч һөҗүмгә күчәргә карар кылган чагына туры килделәр. Һәр як өчен дә көтелмәгән бәрелеш булды. Рәсимнәр экипажы вазгыятьне тиз ачыклады, югалып калган дошман колоннасын сафтан тиз чыгарды.

Егетләрне частьта тантаналы төстә каршы алдылар. Дивизия командиры үзе кабул итте танкистларның рапортын.

Урман полосасы буендагы дислокация урынына кайтып туктап,

машинадан төшкән җирләренә, яннарына полковник килеп басты. Рәсим егетләргә: «Смирно!» – дип команда бирде дә, аның каршына барып уң кулын чигәсенә куеп, «Иптәш полковник!» – дип сүзен башларга да өлгермәде, командир аны туктатып:

– Молодцы, егетләр! Булдырдыгыз! Бик яхшы күрсәттегез Россия солдатларының нәрсәгә сәләтле икәнен! – диде һәм – Кайсыгыз атты беренче танкны, синме? – дип сорады.

Рәсим үзен генә герой итеп күрсәтергә теләмичә, егетләргә борылып карады.

– Барыгыз да молодцы! Барыгызга да «Батырлык» ордены! Ә хәзер ял итегез.

Аларның вакытлыча яшәү урыны куе агачлар ышыгына эшләнгән блиндажда иде. Бераздан Новодаровка янындагы бәрелештән мотострелоклар подразделениесе дә кайтып җитте. Көннең уңышлы тәмамлануы уңаеннан командирлар егетләргә ял игълан итте. Каяндыр ризыклар табып, уңышлы көн хөрмәтенә табын да әзерләгәннәр иде. Луганскига Татарстаннан гуманитар ярдәм китергәннәр икән. Рәсимне шатландырганы – аңа әнисеннән хат бар!

Полковник «Батырлык» ордены белән бүләкләнәселәрен әйткәннән соң, Рәсим Казанга, әнисенә, гаиләсенә шалтыратып, шатлыгын уртаклашырга уйлаган иде. Ә монда менә – әнисеннән хат!

Ул шатлыктан кулына хат тоттырган егетне биленнән кысып кочаклап, җирдән үк күтәреп алды. Рәсимнең буе озын, ә хат ташучы ефрейтор аның муеныннан гына, ул җирдән шактый күтәрелеп, аякларын һавада болгата башлады:

– Булды, булды, касыкны кысасың, – диде ул. – Хат өчен биетергә иде дә сине, бүген ярый инде, батырлык кылдыгыз. Полковник мактады үзегезне.

Шулай дигәч, Рәсим аны җиргә бастырды да, хатны алып, бер читкә китеп басты. Ә егетләр Неустроев белән Леваковны сөйләндерүләрен дәвам иттеләр. Кайсыдыр Рәсимнәр танкының элекке механик-йөртүчесе, яраланып, хәзер лазаретка озатылган Николай Рудольфовичны искә алды:

– Николайны да бүләкләсеннәр иде. Ул да беренче көненнән бирле сугышта. Җитмәсә, тагын яраланды.

– Сорамадыгыз, кайчан бирәчәкләр икән орденнарны? Исән чакта герой булдыгыз. Югыйсә күбесе үлгәннән соң бүләкләнә егетләрнең, – дип куйды солдатларның берсе.

– Тфү диген, авызыңнан җил алсын. Дошман сүзе сөйлисең! – дип, Алёша Неустроев аны ачуланып алды.

– Мондый батырлык өчен Россия Героен бирсәләр дә, ярагaн булыр иде әле. Геройны алыр өчен һичшиксез үләргә димәгән. Сигез машина бит – ике танк, алты БМП!

– Әле күпме солдатны теге дөньяга олактыргансыз.

– Солдатлар кызганыч, әлбәттә.

– Нәрсәсе кызганыч булсын?! Сугыш бит инде бу, чын сугыш. Белгәннәрдер кая барганнарын.

– Араларында күбесе – наёмниклар.

– Шулай булгач, кызганып торасы юк...

Рәсим конвертны ачты да, таныш язуны күреп, күңеле нечкәреп китте.

Әнисеннән күптән хат килгәне юк иде инде. Телефоннан да бик сөйләшеп булмый. Командирлар рөхсәт бирми. Баштагырак вакытларда телефоннан хатыннарына, йөргән кызларына шалтыратабыз дип, кырга чыгып киткән егетләрнең күбесе һәлак булды. Һавада «кошчыклар» карап кына тора. Дроннарны җибәргән операторлар ориентирларын төгәл билгели. Снайпер винтовкасыннан гына түгел, артиллерия снаряды җибәрәләр өсләренә. Солдаттан мәет тә калмый, санын санга чәчеп туздыра. Әнә шулай күпме егет харап булды.

*«Исәнме, улым. Ничек хәлләрең? СВО барган җирләрдән көн саен куркыныч хәбәрләр килеп тора. Телевизордан гел шул хакта гына сөйлиләр. Сакланып кына йөр инде. Безнең хәлләргә килгәндә, элеккечә инде. Синнән килгән акчага Родина урамында ике бүлмәле фатир сатып алдык. Зарина «Джузеппе»да эшләвен дәвам итә. Анастасия эшли. Данил белән Софья каникулга чыктылар. Рәсим, үзеңне сакла. Син безгә кирәк. Сагынып, әниең Розия. Сау бул, дошманны җиңеп, тизрәк әйләнеп кайтыгыз».*

## Кем син, Рәсим Баксиков?

Әнисеннән гел шундый кыска гына язылган хатлар килә аңа. Озаклап хат язып утырырга вакыты да юк инде. Төзелештә эшли аның әнисе – штукатур-маляр. Көне буе эштә. Буш вакытында кызы Заринаның балаларын карый. Зарина – Рәсимнең апасы.

Анастасия – Рәсимнең хатыны, Данил белән Софья – балалары. Алар Розия белән яшәмиләр.

Розия – Таҗикстанда туган хатын. Әти-әниләре исән түгел инде. Әтисе Гашим Мазай улы Мәхмүтов – табасаран милләтеннән, Дагстаннан. Унҗиде яшеннән сугышка китеп, әсирлеккә төшкән булган. Җиңүдән соң, әти-әнисе янына әйләнеп кайтса да, үзе шикелле әсирлектә булган башка егетләр кебек үк, халык дошманы дип, Дагстаннан читкә – Таҗикстанга сөрелгән. Сталин үлгәннән соң азат ителеп, шунда ук – Ленинобад өлкәсенең Пролетарски бистәсендә яшәп калган. Чыгышы белән Татарстаннан, Аксубай районының Савгачево авылыннан булган Елена исемле чуваш кызы белән өйләнешеп, биш бала тудырганнар. Розия – шуларның өлкәне. Өченче һәм дүртенче булып туган Сөләйман белән Җомабикә бала чакларында ук авырып дөнья куйганнар. Урыннары җәннәттә булсын. Розиядән соң туган Гөлсәләм, үсеп украин егетенә кияүгә чыккач, Днепропетровск шәһәрендә яши башлаганнар; ике баласы белән бүгенге көндә шунда яшәп ята Розиянең сеңлесе. Хәзер Украинада сугышлар бара, Розия аларның хәлләре хакында берни дә белми.

Розия үсеп, җиткән кыз булгач, һөнәр училищесында укып йөргәндә, Рәшит исемле егет белән танышты. Рәшитнең әтисе Каир Баксиков – Казакъстаннан, әнисе Асия – татар кызы икән.

Илленче еллар ахырында романтика эзләп, Таҗикстанга килеп чыккан Рәшитне Розиянең әнисенең Татарстаннан булуы кызыксындырды бугай. Әле малай чакларында ук аның әнисе Асия туып үскән якларда, Татарстанда булганы бар иде.

– Карале, Розия, Розочка, минем әни дә Татарстаннан бит. Әти белән Казакъстанда чирәм җирләрне үзләштерү башланган елны танышканнар

алар. Казаннан бер төркем студент әтиләр яшәгән совхозга килеп эшли башлаганнар. Минем әтием – казакъ, Каир исемле, әнием – Асия, татар кызы. Татарстанның Нурлат-Октябрьский дигән районыннан. Малай чакта әнинең безне дә алып кайтканы бар ул Нурлатка.

– Шулаймыни? Алайса, минем әни туган Аксубай районы белән күрше булып чыга бит инде алар.

– Син дә татар кызымыни, алайса? Татарларда Роза исемле кызлар бар диләр шул.

– Роза түгел, Розия минем исемем. Татар да түгелмен. Әнием – чуваш, әтием – табасаран, Дагстаннан.

– Ә син нинди милләттән буласың инде?

– Әтием казакъ булгач, казакъ булып чыгам инде. Паспортыма шулай дип язылган. Ә сине кем дип белик?

Розия үзен нинди милләттән дип әйтергә дә белми иде. Алар биш бала, бишесенең исемен дә үз милләтендәге исемнәр белән әтисе куштырган.

– Әйттем бит, әтием Кавказдан, табасаран. Дагстанда туган. Биш баласына да мөселман исемнәре кушкан. Мине Розия дигәннәр. Сеңелләрем – Гөлсәләм белән Җомабикә, энеләрем – Сөләйман белән Рөстәм. Исемнәребез мөселманча булса да, без күбрәк әни тәрбиясендә үстек. Ул безне үзенчә атап йөртә иде. Миңа гел Валентина дип дәште, Гөлсәләмне – Галя, Сөләйманны – Серёжа, Җомабикәне Женя дип йөртте. Рөстәмне генә үз исеме белән атады.

Розия белән Рәшит шулай танышып, якынаеп киттеләр. Араларында мәхәббәт уты да кабынды. Бер көнне Рәшит Розиягә әти-әнисе белән танышырга, алардан кызларының кулын сорарга теләвен әйтте.

– Ни кызганыч, таныштыра алмыйм шул, – диде Розия. – Алар бергә тормыйлар. Әти Кавказына кайтып китте. Әни – Рөстәмне алып, Татарстанга, туган авылына.

– Минем дә хәлләр шулайрак – әтием дә, әнием дә бу дөньяда юклар инде. Казакъстанда Кентау каласында сеңлем генә яшәп ята. Әйдә, Розочка, өйләнешик тә Казакъстанга кайтып китәбез. Сеңлем күптән чакыра үз янына.

Шулай эшләделәр дә. Кентауга кайтып, фатирга кереп, икесе бер гаилә булып яши башладылар. Рәшит шофёр булып эшкә урнашты. Розия трансформаторлар җитештерү заводында электр үткәргечләрен кәтүкләргә чорнаучы булып эшли башлады. Озакламый беренче балалары – кызлары Зарина туды. Өч кенә айлык декрет ялыннан соң Розия заводта эшләвен дәвам иттерде. Икенче баласын табарга ашыкмады. Кызлары беренче класска укырга кергәч кенә, аңа бер энекәш алып кайтырга булдылар. Заринага сигез яшь тулган 1988 елда Рәшит өзелеп көткән малай дөньяга килде. Аңа Рәсим дип исем куштылар. Ләкин икенче бала тугач, гаиләдә өстәмә авырлыклар барлыкка килде. Иң авыры – торыр җир булмау. Алар Кентауга күчкәннән бирле фатир алулар авырлашты. Үз йортлары юк, фатирга кереп торалар иде. Кысан фатирда яшәүләре тагын да кыенлашты. Җитмәсә, дөньялар үзгәреп китте, акча алмашынды, бәяләр кинәт күтәрелде. Йорт сатып алырга дип җыйган акчаларының бәһасе төште. Эштә дә кыенлыклар туа башлады. Заводка чимал материалларын

Таҗикстаннан кайтарталар иде. Бер заман СССР дигән ил таралып төште. Завод ябылды. Розия квалификациясен күтәрергә өметләнеп, контролёр булып эшли башларга дигән ният белән Чирчик индустриаль техникумына укырга кергән иде. Болар барысы да буш хыял булып калды.

Тормышны алып бару юлын таба алмаган Рәшит, өметсезлеккә бирелеп, эчкечелеккә сабышты. Өйгә көн саен исерек кайта башлады. Ә көннәрнең берендә ул өйгә бөтенләй кайтмады.

Розия, ни булды икән дип кайгырып, тирән хафага төште. Эчеп йөри торгач, юлда бәрелеп үлдеме икән, әллә бергә эчеп йөрүче шешәдәшләре үтереп ташладылармы үзен дип кайгырды. Һәм бер көнне аңа иренең кулга алынуы һәм, кеше үтереп, төрмәгә ябылуы турында килеп әйттеләр.

Рәшит эшендә исерек килеш ачуын чыгарган бер чеченны пычак белән чәнчеп үтергән булып чыкты. Аны сигез елга ирегеннән мәхрүм иттеләр.

Ике бала белән утырып калды Розия. Нишләргә, кемгә барып ярдәм сорарга?

Шундый авыр уйлардан нишләргә белмичә йөргән көннәрнең берендә фатир хуҗасы килеп, аңа кисәтү ясады. Өч ай буе фатир хакын түләгәннәре юк иде шул.

– Йә бурычыгызны түлисез, йә фатирдан чыгып китәсез! – дип җикерде казакъ агае.

Нәрсә әйтергә дә белмичә зиһене чуалган Розиянең башында кинәт кенә бер уй яктырды:

– Бурычыбызны түләргә бер тәңкә дә акчабыз юк, Газим әкә. Әйдәгез, шундый килешү ясыйк: бурычыбызны фатирыгызга ремонт ясау юлы белән түлим. Теләсәгез, диварларын йә акшарлап бирәм, йә обойлыйм, – диде.

– Үзегез яшәп туздырган диварларны болай да акшарлап тапшырырга тиеш сез! – диде хуҗа.

СССР таркалганнан соң Казакъстанда совет власте елларында Россия республикаларыннан килеп урнашучыларны үз илләренә куу сәясәте башланган иде. Розия белән Рәшитнең дә ата-аналары төп казакълар булмавын Газим әкә белә. Фатир өчен акча сорап килгән саен ул аларга шул хакта әйткәли иде. Эшендә Валентина дигән исем белән атап йөртелгәнлектән, Розияне дә марҗадыр дип уйлый иде ул. Шуңа күрә китсен үз иленә дип йөри башлады.

Аптыраган Розия, ярдәм сорап, Рәшитнең сеңлесе Рәшидә янына барып гозерләнде. Алар вакытлыча Рәшидәләрдә яшәп торырга килештеләр. Ләкин аларның да гаиләсе ишле, озак яшәтергә чамалары юк иде. Розия ахыр чиктә балаларын алып Татарстанга, әнисе янына кайтып китәргә дигән карарга килде. Шулай итеп, ундүрт яшьлек кызы Зарина белән бер атна эчендә Газим әкәнең фатирын обойлап бетергәннән соң, алар җыенып, Татарстанга кайтып киттеләр.

Татарстанда да аларны беркем дә көтеп тормый иде. Әнисе Елена Фёдоровна улы Рөстәм гаиләсе белән яши. Рөстәм урман хуҗалыгында каравылчы булып эшли. Тормышлары начар түгел үзе. Ләкин авылда ике кулына бер чемодан белән, бернинди мал-мөлкәтсез, ике баласын ияртеп кайтып төшкән хатынга бернинди дә эш табылмады. Алар Рөстәм гаиләсе өчен дә артык кашык иде. Дөрес, караңгы чырай күрсәтүче булмады.

Киресенчә, ярдәм итәргә тырыштылар. Күршеләр дә хәлләреннән килгәнчә булышты. Кайсы кием кертте, кайсы – ризык белән...

Елена Фёдоровнаның бер туганы Людмила Алексеевск районының Биләр авылында яши иде. Туганының кызы ике бала белән Казакъстаннан кайтып төшүен ишеткәч, ул бер көнне аларның хәлләрен белешергә Савгачевога кайтып килде.

Күрешеп, Казакъстандагы хәлләр турында гәпләшеп утырганда, Розия аларга фатир өчен бурычын ничек түләве хакында сөйләде.

– Аллага шөкер, Заринам үсеп җитте. Фатир хуҗасына өч айлык бурычыбыз җыелган иде. Зарина белән икәүләп акшарлап, обойлап тапшырып киттек фатирны, – диде.

– Бәй, дивар акшарлый беләсеңмени? Төзелешкә эшкә урнашырга кирәк сиңа болай булгач. Әйдә, Биләргә кил. МСОга штукатур-маляр булып урнашырсың. Тулай торактан бүлмә бирерләр. Тора-бара фатирын да алырсың, – диде Людмила.

Шул чакта Елена Фёдоровна сорап куйды:

– Сатлык йортлар юкмы соң Биләрдә?

– Бар, нишләп булмасын. Хәзер күп кеше шәһәргә китә бит. Күбесенең йортлары авылда моңаеп торып кала. Шундый йортлар урам саен.

– Алай булгач, артык зур булмаган берәр йорт сатып алырбыз. Кара көнгә дип җыйган азмы-күпме акчам бар. Бәләкәйрәк бер йорт сатып алырга җитәргә тиеш, – диде әнисе, Розиянең борчулы йөрәген җылытып.

– Чынмы, әнкәй?! Риза, ике куллап риза мин штукатур-маляр булып эшләргә! – дип сөенде ул, әнисен кочып.

– Алайса, Людага ияреп барып кайт Биләргә. Үзеңә ошаган берәр йортны белеш.

Шулай итеп, алар әнисенең җиңел кулыннан Биләрдә яши башладылар. Бу 1993 ел иде. Рәсимгә ул елның беренче декабрендә биш яшь тулды.

## Танкистлар

Дамир Исламов исемендәге батальонда Рәсимнең танышлары, аның белән бер училищеда укыган егетләр күп. Алар арасында «Батырлык» орденына гына түгел, Россия Герое исеменә лаек булучылар да бар хәтта.

Россия Герое Раил Габдрахманов белән дә Рәсим бергә укыды. Училищены берүк вакытта тәмамлап, Рәсим – Ерак Көнчыгышка, ә Раил бераз якынгарак – Новосибирскида урнашкан хәрби частьларның берсенә китте. Танк взводы командиры дәрәҗәсенә хәтле күтәрелеп, ул Кемерово өлкәсендә һәм Алтай краенда хезмәт итте.

Рәсим Луганскига килгәндә, Раил Габдрахманов Россия Герое исеменә лаек булган иде инде. Луганскида ул СВОның беренче көннәреннән үк сугыша. Ә Герой исеме аңа Төньяк Дон елгасын кичкәндә күрсәткән батырлыклары өчен бирелә. Елга аша күпер төзелгәндә, ул үзенең взводы белән аны саклауда катнаша. Күпер төзелеп беткәч, беренче булып взводындагы ике танк белән шуның аша икенче ярга чыга. Икенче көнне дошман күперне җимерүгә ирешә, Раилләр икенче якта кала. Ләкин командир дошманның ике танкын, 20 сугышчысын юк итә.

2022 елның 10 августында, Раил Габдрахманов белән бер үк көндә Россия Герое исеме Казан танк училищесын тәмамлаган тагын бер танкистка – Иван Додосовка бирелә. Алар өч танк белән Украинаның икенче бер төбәгендә – Попасная шәһәре тирәсендә дошманның тулы бер танк ротасын юк итәләр. Додосов взводы дошман оборонасын урман аша турыдан өзеп чыгарга ниятли. Ләкин урман эчендә дошманның танк ротасы урнашкан урынга килеп чыга. Дошман контратакага ташлана. Ләкин Додосов взводы, аяусыз сугышып, җиде танкны юк итә, икесен трофей итеп алып чыга, тагын берсе шунда янып кала. Шулай итеп, безнең гаскәрләргә Лисичанск шәһәрен азат итәргә мөмкинлек туа.

Россия Герое исемен алган Казан танк училищесын тәмамлаган тагын бер каһарман – генерал-полковник Александр Лапин. Бу исем генералга Северодонецк һәм Лисичанск шәһәрләрен азат иткәндә, гаскәрләр белән дөрес җитәкчелек иткәне өчен, «хәрби бурычын үтәгәндә күрсәткән батырлык һәм героизм өчен» бирелә.

* * *

«Три танкиста» дигән җыр бар. Рәсимнең яраткан җыры. Ерак Көнчыгышта хезмәт иткәндә, алар батальонының гимны иде ул. Бөек Ватан сугышы елларында Ерак Көнчыгышта танкистларның батырлыгы турындагы җыр. Чик бозып, Советлар Союзына басып керергә батырчылык иткән япон самурайларына каршы көрәшкә баскан танк экипажы турында. Көе дә, сүзләре дә күңелдә ватанпәрвәрлек хисләре, туган илгә мәхәббәт, дошманга карата нәфрәт, үч уята торган җыр.

Ерак Көнчыгышта еш җырлыйлар иде алар ул җырны. Заманнар да башка иде. Отставкага чыкканнан соң аны бер тапкыр да ишеткәне булмады бугай. Әнисенә хат язганда, Рәсим әнә шул җырны исенә төшерде. Соңгы җөмләләрен язып бетереп, конвертка салганда, үзалдына гына көйләп тә алды әле хәтта.

На границе тучи ходят хмуро.
Край суровый тишиной объят.
У высоких берегов Амура
Часовые Родины стоят.

Амур дип түгел, Днепр дип җырларга кирәктер хәзер. Рус дәүләтенең башында торган илдә Россиягә каршы көчләр яшәп яткан бит.

2014 елда ук башларга кирәк иде бу операцияне дип уйлый Рәсим. Башында ук ныклы киртә куярга кирәк иде аларның эшчәнлегенә. Хәзер шактый көчәйделәр алар. Американың максаты – Россиянең бөтен байлыкларына хуҗа булу. Бу эшне нәкъ менә Россиянең борын төбендә яшәп ятучы шул фашист калдыклары кулы белән башкару. Украина армиясе баштанаяк Америка кораллары белән коралланган. Ләкин аңа карап, Америка коралларының Россиянекеннән әлләни өстенлеге юк. Танклары да безнең җирдә йөрер өчен уңайсыз, гусеницалары сазлы урыннарда танкны төпкә өстери. Манёврлылыклары начар.

– Әйбәт җыр! – диде Леваков, Рәсимнең үзалдына гына җырлавын ишетеп. – Кычкырыбрак җырла. Экипаж өчен гимн итеп алсак та буладыр

аны. «Өч танкист» дигән җыр бугай бит. Без дүртәү. Булсын, хәзерге танкларга дүрт солдат хезмәт күрсәтү дә аз әле.

Рәсим тавышын күтәребрәк җырлый башлады:

– Там врагу заслон поставлен прочный,
Там стоит, отважен и силён,
Вдоль границ земли дальневосточной
Боевой ударный батальон.

Җырга Александр да кушылды:

– Там живут – и песня в том порука –
Нерушимой, крепкою семьёй
Три танкиста – три весёлых друга –
Экипаж машины боевой.

Җырны башка егетләр дә белә икән. Александр артыннан калганнар да күтәреп алдылар.

– На траву легла роса густая,
Полегли туманы широки.
В эту ночь решила вражья стая
Перейти границу у реки.
Но разведка доложила точно –
И пошёл, командою взметён,
По родной земле дальневосточной
Броневой ударный батальон.

Мчались танки, ветер подымая,
Наступала грозная броня.
И летела наземь вражья стая
Под напором стали и огня.
И добили – песня в том порука –
Всех врагов в атаке огневой
Три танкиста – три весёлых друга –
Экипаж машины боевой.

Җыр тавышын ишетеп, блиндажга башка экипаж егетләре җыйналды.

– Нинди бәйрәм сезнең монда?

– Нинди бәйрәм булсын, танкистлар маршын җырлыйбыз. Командага «Батырлык» ордены биреләчәк диде бит полковник.

– Ерак Көнчыгышта хезмәт иткәндә, безнең ротаның гимны иде ул, – диде Рәсим. – Бөек Ватан сугышы елларында чыккан җыр.

– Әллә мин тагын концерт башланганмы, монда гына куярга булганнармы концертны дип торам, – диде икенче взвод командиры «Буран».

– Нинди концерт? «Алёша» егетләре генә җырлый бит.

– Казаннан гуманитар ярдәм, филармония артистлары килгән, ди, анда. Бүген Молодогвардейск мәдәният сараенда чын концерт куячаклар, ди. Тәк што, татарча белгәннәр, концертка җыеныгыз.

127 нче мотоукчы дивизиянең яртысы Татарстаннан килгән егетләр иде. Пехотачылар, БМП йөртүчеләр, танкистлар, артиллеристлар арасында да татар егетләре күп. Менә бит нинди бәйрәм ясаганнар филармония артистлары аларга!

– Татарлар, руслар дигән бүленеш юк СВОда. Хәзер артистлар татарча гына түгел, русча да әйбәт сиптерә. Тәк што яраткан җырларыгызны сорамыйча калмагыз, җырларлар, – диде «Буран».

– Шул хәбәргә өстәп, тагын бер яңалык: Казаннан Зиннур Әхмәтгалиев атлы бер абзый мотоцикл җибәргән СВО сугышчыларына бүләк итеп.

– Командир, алайса, бүгенге батырлыгың өчен сиңа инде бу бүләк.

– Узган юлы якташлар квадроцикл да җибәргәннәр иде бит. Яу кырына танклар өчен снаряд ташырга бер дигән транспорт булды. Ә бу матайны миңа түгел, минем урыным – танкта, экипаж белән бергә, аны батальон табибына бирергә кирәк, – диде Рәсим. – Яралanучылар булса, аның тизрәк килеп җитүе, ярдәм күрсәтүе кирәк.

* * *

Луганск республикасына Татарстаннан фольклор ансамбле килгән булып чыкты. Рәсимнең ул ансамбль концертында булганы бар. Казанда төзелештә эшләп йөргәндә, ансамбльнең администраторы Хәйдәр Сафин атлы бер абзый ниндидер бер бәйрәм уңаеннан аларның бригадасына билетлар калдырып китте. Бушка түгел, әлбәттә. Түләүле. Концертлары ошады. Хәзер дә шул составта диярлек килгәннәр. Ничек куркып тормаганнар. Монда бит, уяу тормасаң, дроннар килеп, шартлатып та китәргә мөмкиннәр. Юлда алай-болай төрле хәл килеп чыгарга мөмкин. Ә бүгенге концертта яшь кенә бер кыз Рәсим өчен махсус җыр башкарды. Сәхнәгә чыгып, берничә җыр җырлаганнан соң:

– Ә бу җырымны Казан егете, бүген генә күрсәткән батырлыгы өчен «Батырлык» орденына лаек булган Рәсим Баксиковка багышлыйм, – диде.

Дивизия командирлары сораганнардыр инде. Үзләренчә бер бүләк ясарга уйлаганнардыр. Ләкин Рәсимнең моменттан файдаланып каласы килде, үзе яраткан җырны ишетәсе килүен әйтте.

– Ә мин теләгән җырны башкара аласызмы соң? – диде.

– Ә нинди җыр ишетергә телисез? – диде кыз.

– «Әниемә» дигән җырны яратам мин. Казакъ җырын. Аны татарлар да белә.

– Белә генә түгел, яратабыз да! – дип кычкырды кайсыдыр солдатлар арасыннан.

– Була ул, – диде дә җырчы, янында торган баянчыга борылып: – Әйдә, Азат, башла. Ишетсеннәр егетләр үзләренең яраткан җырларын, – дип, баянчыга кушылып җырларга да кереште:

Кадерләп үстергән
Мин – синең җимешең.
Куеның гөлбакча,
Назлы җил сулышың...

Әнисенең яраткан җыры ул. Таҗикстанда туса да, үзе чуваш булса да, яшьлеге Казакъстанда, казакълар арасында үткәнгәме, ярата аның әнисе бу җырны. Аның яшьлек елларында чыккан җыр бит ул. Җитмәсә, татарларның да яраткан җыры.

Җыр тәмамлануга солдатлар гөрләтеп кул чаптылар. Татары да, русы да, башка милләт егетләре дә. Алексей Неустроев белән Филипп Евсеев та, җырны аңлагандай, алкышлаулар туктагач та, һаман кул чабалар иде.

– Әллә сез дә аңладыгызмы җырның нәрсә турында икәнен? – дип сорады шунда алардан разведтөркемдә дроннар белән эшләүче элемтә операторы Фирданис Абдуллин атлы егет.

– Беләбез без бу җырны. Әниләр турында бит ул. Казакъ-татар җыры.

Без бит якутлар, татарлар белән кардәшләр – төркиләр, – диде Алексей Фирданиска. – Үзең дә әниеңне сагынгансың бугай. Күзләрең дымланган әнә.

Тамашачылар арасында шахтёрлар да бар иде бугай. Шунда бер хатын торып басып артистлардан «Шахта» җырын башкаруларын сорады.

– Заманында Донбасска шахтага эшкә килүчеләр дә утыра монда сезне карап, – диде ул ансамбльнең җитәкчесе Айдар Фәйзрахмановка. – Татарстанның Казан арты дигән төбәгеннән, Дөбьяз, Әтнә якларыннан без. Казаннан артистлар сирәк килә. Туган якларны бик сагынабыз. Безнең өчен «Шахта» җырын җырласагыз иде.

– Бик теләп, – диде Фәйзрахманов. – Бу җырны сорарлар әле дип, алдан ук программага керттек. Мин аны үзем башкарырга телим. Ләкин башта сезнең игътибарга бер шагыйребезнең «Терәү» дигән шигырен сөйләп китмәкче булам. – Айдар җырны баянда да үзе уйнап башкарырга җыенган иде. Шигырь дә сөйләргә булгач, баянын концертны алып баручыга тоттырды.

## Терәү

Украина. Донбасс шахталары.
Кан коела кабат бу якта.
Ник бу хәтер шулай кыска икән?
Уйга сыймый күпме уйлап та.

Донбасс, Донбасс, сәйяр татарның да
Бәгыренә төшкән җир ласа!
Бәгырькәйләр өзелеп китмимени,
«Шахта» көен берсе җырласа?!

Бәхет эзләп киткән күпме татар
Аерылган туган иленнән.
Таш баскандыр анда күпме ирне!
Ә күпмесе язган теленнән!

Күбрәктер телен онытканнар!
Шундыйлары күбрәк уйлата!
Украина. Донбасс шахталары.
Кан коела кабат бу якта.

Кан коела. Мин сәбәбен эзлим.
Сәбәбе бер: сәбәп – терәүдә!
Терәү тузса, шахта җимерелә,
Исән кала алмый берәү дә!

Шахтамыни?.. Украина үзе
Калган бүген торып терәүсез.
Мин сәбәбен эзлим, серен... Шуңа
Кем табала тәңгәл төгәл сүз?!

Күңелемә килә шахта баскан,
Телен җуйган мәхлук татарым.
Украина, монда сугыш бара...
Канга баткан Донбасс яклары...

Айдар шигырен сөйләп бетерүен белдереп башын иде дә, алып баручы ягына борылып, баянын сорап ым какты. Халык гөрләтеп кул чапты. Шуннан соң ул, баян каешларын иңенә салып, салмак кына аккордларын алып, «Шахта»ны җырлый башлады.

– Китә җаныем, китә җаныем,
Китә җаныем Донбасска.
Ул китә инде Донбасска,
Сүз бирдек ташлашмаска.

Шахталарга син төшәрсең,
Җырлап күмер кисәрсең.
Әмма мине бик сагынсаң,
Бик саргайсаң, нишләрсең?..

Тагын гөрләтеп кул чаптылар.

– Рәхмәт! Татарлыгыгызны онытмагансыз икән. Җыр-моңнарыбызны сагынып яшәп ятасыз. Безнең монда килүебезнең максаты – сезнең сугышчан рухны күтәрү. Бу махсус хәрби операциядә Татарстаннан зур ярдәм күрсәтелүен

әйтеп үтәргә телибез. Дамир Исламов исемендәге танк батальоны, «Алга», «Тимер», «Батыр» – барысы да Татарстанда оештырылган батальоннар. Алар Луганск, Донецк халык республикаларын азат итү өчен көрәшәләр.

Айдар сүзен бетерергә өлгермәде, «Әниемә» җырыннан соң якут егетләреннән шул җыр турында сораган Фирданис Абдуллин кулын күтәреп:

– Абый, миңа да сүз бирегез әле, – дип, аңа мөрәҗәгать итте: – Мин – Фирданис Абдуллин, Татарстан егете. Минем әнием – Фирая Абдуллина, укытучы. Шигырьләр яза. Минем сәхнәдән әниемнең миңа багышлап язган шигырен укыйсым килә.

– Рәхим ит, Фирданис. Тыңлыйк әниеңнең шигъри сәламен.

Егет, рәхмәт әйтеп сәхнәгә күтәрелде дә, кесәсеннән блокнот чыгарып, битен ачты һәм укый башлады:

### Улыма

Синең һәрбер хәбәреңне
Зарыгып көтеп алам.
Бүген көнем озын булды –
Шалтыратмадың, балам.

Болай ук көтмәс идем дә,
Дөньялар тыныч түгел.
Җан тынычлыгына бигрәк
Сусады боек күңел.

Бер Аллаһка өмет белән
Сәҗдә кылып ялварам.
Фәрештәләр саклап йөртсен
Сине, и газиз балам!..

– Молодец, Фирданис! Әйбәт шагыйрә икән әниең. Кая, бир әле миңа аның бу шигырен. Казанга кайткач, берәр гәзиттә бастырып чыгарып булыр, бәлки, – дип, Айдар егеттән шигырен сорап алды.

– Бу гына түгел, аның шигырьләре әле тагын бар. Мин сезгә аның адресын бирермен, абый, үзеннән тагын шигырьләрен сорап алырсыз, – диде Фирданис.

Концерт шулай артистлар һәм тамашачылар белән үзара әңгәмә рәвешендә шактый озак дәвам итте. Тамашачылар бар да канәгать калды. Мондый очрашуны аларның моңа хәтле әле күргәне юк иде бугай.

Рәсимгә дә ошады концерт. Казан сагындырган. Әле СВОга киткәненә күпме генә, сагынырга да өлгергән икән. Отставкага чыкканнан соң Казанда өч ел яшәп, өч тапкыр барганы булдымы икән аның концертларга?! Их, бу бандерачыларны дөмектереп, Казанга исән-сау әйләнеп кайта алса, ешрак йөрер иде ул концерт-спектакльләргә. Шундый тамашалар, җырлар күтәрә бит инде кешенең рухын. Тормышны ямьли, яшәүгә дәрт уята. Ә монда дошманга нәфрәтне көчәйтә.

Әнә шулай, Рәсим Баксиков, Александр Леваков, Филип Евсеев һәм Алексей Неустроев составындагы экипажның батырлыгы дивизия һәм Молодогвардейск бистәсе халкы бәйрәменә әверелде.

### Кискен борылыш

Новодаровка бистәсе янында булган бәрелеш Рәсимнәр экипажы өчен тормышларында кискен борылыш ясады. Егетләр үзләре дә мондый борылыш булыр дип башларына да китермәгәннәр иде. 6 июньдә булган

бу вакыйга турында алар инде оныта да башлаганнар иде. Нәрсә инде, гадәттәге бер бәрелеш. Дошман белән ике көннең берендә булып тора торган очрашу. Ул орыш өчен аларга «Батырлык» ордены тапшырдылар. Луганск Халык Республикасы Герое дигән исем бирделәр. Гәзитләрдә мактап яздылар. Бәрелешнең дроннар төшереп алган видеоларын телевидениедән күрсәттеләр. Инде ул вакыйгага ике ай вакыт үтеп китте. Тик бу батырлык турында матбугатта, радио-телевидениедә язып, сөйләп, күрсәтеп, егетләрнең даны бу орден белән генә бәяләнергә тиеш түгел дигән нәтиҗәгә килгәннәр булып чыкты.

Июль ахырында интернетта Рәсим Баксиков, Александр Леваков, Филипп Евсеев белән Алексей Неустроев составындагы «Алёша» экипажының 6 июньдәге батырлыгы турында видео таралды. Август башында бу егетләрне үзләренә дә нәрсә икәнен әйтмичә, нindидер чарага әзерли башладылар. Иң кызыгы – 7 июньдә алган «Батырлык» орденнарын кире алырга мөмкиннәр дигән хәбәр булды. Һәм менә, ниһаять, аларны аэродромга алып килделәр дә вертолётка утырттылар. Шунда гына аларга 6 июньдә ясаган батырлыклары өчен Россия Герое исеме бирелүе хакында һәм Бөек Ватан сугышы вакытында Курск Дугасы бәрелешендә җиңүнең 80 еллыгы уңаеннан үткәрелә торган тантаналарда катнашырга алып баруларын, шунда Президент Владимир Владимирович Путинның аларга Россия Герое билгесе булган «Алтын Йолдыз» медален тапшырачагын әйттеләр.

Юбилей тантанасы Курск шәһәре янындагы Поныри бистәсендә үтәчәк икән. Бистәнең үзәк бер урынында бик зур, монументаль мемориал эшләгәннәр. Мәйдан алдындагы сәхнәдә зур оркестр. Мәйданда тантанада катнашучы хәрбиләр һәм җәмәгатьчелек вәкилләре. Искиткеч тетрәндерә торган күренеш. Ул Рәсимгә хәтта Волгоградтагы Ватан Ана мемориалыннан да колачлырак булып күренде. Аларны – биш геройны сәхнәгә чыгарып бастырдылар. Бишенче каһарман дроннар белән элемтә операторы ефрейтор Илья Гаврилов булып чыкты.

Мәйдан алдына чыгып баскач, Рәсимне җиңелчә генә дулкынлану хисе биләп алды. Хәтта аяклары дерелдәде. Дулкынланмаслык та түгел, телевидение камералары сиңа төбәлгән. Президентның үзе белән очрашачаклар бит. Аның белән кул биреп күрешәчәкләр. Котлап кына калмас, әле нинди дә булса сорау да биреп куярга мөмкин. Югалып калмаска, кыска һәм ачык җаваплар бирергә кирәк.

Менә тантаналы мизгелләр җитте. Сәхнәгә Президент чыгып басты һәм телевидение дикторының йомшак, мөлаем, шул ук вакытта тантаналы һәм җитди тавышы яңгырады:

– Махсус хәрби операция барышында хәрби бурычын үтәп, батырлык, кыюлык, тәвәккәллек һәм фидакарьлек күрсәткәне өчен Россия Президенты Указы белән бишенче армиянең 127 нче мотоукчылар дивизиясе икенче танк ротасы командиры Баксиков Рәсим Рәшит улына Россия Герое исеме бирелә!

Оркестр башкаруында тантаналы фанфаралар яңгырады. Подноска салып бүләкләнүчегә бирелəсе медальне китерделәр. Рәсим Президент каршына килеп басты. В.В.Путин аның кулын кысты һәм, медальне алып

геройның күкрәгенә такты. Тагын бер мәртәбә кулларын кысышканнан соң, алар тамашачыларга карап, фотога төштеләр. Рәсим икенче бүләкләнүчене көтеп сәхнә алдына барып басты. Президентның тыныч һәм салмак тавыш белән котлавы аның күңелендәге киеренкелекне җиңеләйтеп җибәргән иде.

Медальләр тапшырылды. Бу тантананы телевидение аша бөтен Россия халкы карады. Геройлар инде шуның белән эш бетте, яңадан вертолётка утыртырлар да хәрби бурычларын үтәүне дәвам итәргә алып кайтып китәрләр дип көттеләр. Ләкин аларга иртәгесен кабат Президент белән очрашачакларын әйттеләр. Монысы инде Курскида да, Донбасста да түгел, Мәскәүдә, Президент резиденциясендә булачак диделәр.

Икенче көнне аларны Кремльдә зур гына бер бүлмәгә алып килделәр. Әлбәттә, башта бик җентекләп тикшерделәр. Бүлмәнең уртасындагы зур гына түгәрәк ак өстәл тирәли кара-каршы өчәр урындык куелган иде. Леваков, Неустроев һәм Евсеевны бер якка, Баксиков белән Илья Гавриловны, араларында бер урындык калдырып, икенче якка утырттылар.

Бераздан Президент килеп керде һәм Рәсим белән Илья арасындагы буш урындыкка килеп утырды.

Ул очрашуны геройларны котлау белән башлап җибәрде:

– Хәерле көн! Мин сезне Россия Герое булуыгыз белән тагын бер тапкыр котларга телим, – диде ул. – Кичә барыгыз да нык дулкынланган идегез. Сугыш кырындагыдан да ныграк дулкынландыгыз бугай. Әлбәттә, дулкынланмаслык та түгел. Беренчедән, кеше күп иде. Урыны үзе үк бик истәлекле. Миңа калса, нәкъ менә шушы урында, безнең бабайлар, әтиләр сугышкан һәм дошманны җиңгән урында бүләкләнүегез үзе символик мәгънәгә ия. Бүген – истәлекле көн, моннан 80 ел элек совет гаскәрләренең Курск Дугасындагы сугышта немец-фашист илбасарларын тар-мар иткән көне.

Шунда танк командиры Александр Леваков, аны бүлдереп:

– Безнең бер көрәштәшебез Филипп Евсеевның бабасы да ул бәрелештә катнашкан, – диде.

– Чынлапмы? Сезнең бабагыз шул сугышта катнашканмы? Менә бу – безнең буыннар элемтәсе, бу инде безнең Ватанны саклау буенча генетик кодыбыз, – диде Президент.

Филипп Евсеев 1984 елда Якутия (Саха) Республикасының Сунтар районында, Кюндяй авылында туган. Аның әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да бабайлары Бөек Ватан сугышында катнашкан. Үзе ул ишле гаиләдә – өченче бала, малайлар арасында өлкәне булып дөньяга килгән. Малай чагыннан спорт белән шөгыльләнгән. Армиядә хезмәт итеп кайткан, өйләнгән. Хәзер инде үзенең ике кызы һәм улы үсә икән.

Филипп СВОда 2022 елның сентябреннән. Октябрь аенда махсус курсларда укыганнан соң ул 127 нче мотоукчылар дивизиясенә танк йөртүче-механик итеп җибәрелә. Анда үзенең якташы, якут егете Алексей Неустроевны очрата һәм, аның үтенечен тыңлап, «Алёша» танкында, бәрелештә яраланып госпитальгә озатылган йөртүче-механик Николай Рудольфович урынында хезмәт итә башлый.

Алексей Неустроев та Якутиянең Усть-Алдан районы Танда авылында биш баланың өлкәне булып дөньяга килә. 2004 елда мәктәп тәмамлый. Мәктәптә укыганда, милли спорт төрләре – мас-рестлинг һәм ирекле көрәш

белән шөгыльләнә. Армиядә танкист булып хезмәт итә. Россия Герое исеме белән бәяләнгән батырлык нәкъ менә аның наводчик буларак төз атуы нәтиҗәсендә мөмкин булды дип исәплиләр иптәшләре.

Президент, танкистларны герой исеме алулары белән тагын бер тапкыр котлаганнан соң, алар эшләгән батырлыкның ничек килеп чыгуы турында кызыксынды.

– Кыска гына вакытта бер танк белән сигез бронемашинаны юк итә алуыгызны күз алдына китерәсе килә. Нәкъ менә шул вакытта, шул урынга ничек килеп чыктыгыз соң сез?

– Безгә алдагы көндә дошман белән бәрелешкән Новодаровка бистәсен чистартып кайту бурычы йөкләнде, – диде танк командиры Александр Леваков.

– Димәк, сез анда дошман барын белмәдегез?

– Дөресен әйткәндә, без һәркөнне ниндидер бәрелеш булырга мөмкин дигән уй белән утырабыз танкка. Бу көнне дә 127 нче дивизия командирыннан әнә шундый приказ алдык. Иң куркыныч участокларга дивизия командиры безне җибәрә. Чөнки без инде яшьләр түгел, тәҗрибәбез бар.

– Безнең подразделение дивизиядә һәрвакыт катлаулы участокларга җибәрелә, – дип, сүзгә Рәсим Баксиков кушылды. – Бездән башка Новодаровкага беркемнең дә җибәрелгәне булмады.

– Мөмкинме, сезгә бер сорау бирәсем килә. Бу бәрелеш алдыннан минем белән бәләкәй генә бер проблема килеп чыкты, – диде Леваков, Рәсимне бүлдереп. – Дүртенче числода без үзебезнең механик-йөртүчебезне югалттык. Ул яраланды. Машинаны ташламады, безне кайтарып куйды. Аннары аны госпитальгә алып киттеләр. Шуннан соң аның урынына танк йөртүче булып Рәсим утырды. Ә икенче көнне дроннар атакасы вакытында «Колючий» кушаматлы доброволец мине үлемнән саклап калды, үзе нык яраланды. Ул коткармаган булса, танк механиксыз каласы иде. Гел бергә сугыштык-сугыштык та, ул бүләксез калган булып чыкты. Кызганыч, әлбәттә, үзе исән калгандырмы, нык яраланган иде. Шул «Колючий» дигән позывное белән исем-фамилиясеннән башка берни дә белмим. Телефонын да сорамаганмын.

Леваковның ни әйтергә теләгәнен Президент аңлады:

– Александр Сергеевич, борчылмагыз, барысын да эшләрбез. Барысы да сез теләгәнчә булыр. Борчылмагыз. Әйтегез әле, йөртүчегез сафтан чыккач, ник тагын шул ук урынга кайттыгыз?

– Команда булды бит, без аны үтәргә тиеш. Кабат шул урынга борылдык.

– Безне бит икенче танк килеп буксирга алды. Монда инде икебезгә дә куркыныч яный башлады, ике танкны да утка тотарга мөмкиннәр, – дип Рәсим аңлата башлады.

– Яхшы. Рәсим Рәшидович, белүемчә, сез идарә рычагына, механик-йөртүче урынына берничә тапкыр үзегез утыргансыз. Сезнең кул астында ничә танкист?

– Хәзерге вакытта тугыз.

– Тугыз?

– Әйе.

– Шуңа карамастан, рядовой танкист урынына үзегез утыргансыз. Нишләп?

– Ы-ы... Ничек аңлатырга... Әлбәттә. Бу куркыныч. Ләкин буйсынучыларыңа, үзең курыккан очракта да, ул куркуны җиңәргә кирәклеген күрсәтергә кирәк.

– Шәхси үрнәк күрсәтергә кирәк дисең?

– Әйе.

– Бу... Бу инде Россия офицерларының яхшы традициясе үрнәге.

– Кулда кылыч булсамы әле?!. Тик безгә кылыч бирмиләр.

Рәсимнең бу сүзләреннән соң барысы да көлешеп алдылар.

– Александр Сергеевич башнядан чыгып, һичшиксез кылыч айкана башлар иде, – дип көлүен дәвам итте Рәсим.

– Ул, чынлап та, казакка охшаган... – дип куйды Президент, чыраен сакал баскан Леваковка карап.

– Әйе, ул бит чын казак.

Көлешеп алганнан соң Президент икенче ягында утырган Илья Гавриловка борылып:

– Илья Владимирович, сез – талантлы кеше. Техника буенча гына түгел, әдәби яктан да дип беләм? Хәрби хезмәттән соң сез зур халыкара... Россия күләмендәгесен әйтмим дә инде, бәйгеләрдә катнаша алган булыр идегез.

– СВОдан китеп дисезме? – дип куйды Леваков.

– Әгәр дә сез кушсагыз, ул һичшиксез катнашыр иде. Сезнең боеруыгыз гына кирәк, – дип кушылды Рәсим. – Без барыбыз да... Бары тик команда гына булсын.

– Күпме танкны юкка чыгардыгыз ул вакытта?

– Икене.

– Ике танк һәм алты бронемашинаны?

– Сигезне. Колонна белән алтау килә иде. Ныгытмада тагын икәү бар иде.

– Молодцы. Бу читтән дә яхшы күренә иде. Бик әйбәт эшләдегез... Артиллерия ничек эшләде? – дип, Президент башка подразделениеләрнең бәрелештә ничегрәк катнашуы турында кызыксынды.

– Артиллерия дә яхшы эшләде. Барысы да молодцы.

– Артиллериягә килгәндә, ул бик яхшы эшләде, – дип, Рәсим Левакoвның сүзләрен хуплады. – Төз аттылар, снарядлар барысы да төзәгән урынга тиеп барды. Артиллериясез бөтенләй башка ситуация килеп туган булыр иде.

– Яхшы, аңлашылды.

Президент белән очрашу озак бармады. Ләкин ул геройлардан СВО хакында үзен кызыксындырган сорауларга тулы җаваплар ишетте шикелле. Аларның хезмәтеннән канәгать калган иде күрәсең, очрашу тәмамланганнан соң, егетләрнең моннан соң СВОга китмәячәкләре, ялга җибәреләчәкләре турында әйттеләр. Ләкин ялга гына да булып чыкмады. Аларга киләчәктә югарырак чиндагы офицерлар булырга, Мәскәүдәге берәр хәрби уку йортында укып, белемнәрен тирәнәйтергә дип тәкъдим ясадылар.

Туган якларга таралышыр алдыннан Александр Леваковка аны үлемнән коткарып калган «Колючий»ның телефон номерын һәм исем-фамилиясен шалтыратып әйттеләр. Александр шунда ук аңа шалтыратып, хәлен белешергә булды. Ул телефон номерын җыйды:

– Сәлам, таныдыңмы кем шалтыратканын? – диде.

– Миңа шалтыратучылар күп. Танып бетермәдем. Кем әле?

– «Ласка» мин!

– «Ласка»?! Сәлам, дускай! Исәнме?! Ничек синең хәлләр? Каян таптың минем телефонны?

– Үзең ничек? Исемеңне дә сорамаганмын. Югалттым мин сине. Барыгыз да исән-саулармы?

– Исәннәр, Аллага шөкер. Бәлки ишеткәнсеңдер безнең турыда. Геройлар бит без хәзер. Россия геройлары.

– Туганкай, миңа да «Батырлык» ордены бирделәр бит! Шул сине коткарган өчен бугай. Кичә генә Мәскәүгә кайтардылар. Преображенский районы хәрби комиссариатына чакырып, военком үзе тапшырды. «Бер танкистны үлемнән коткаргансың», – диде. Шул сине коткарган өчендер инде. Айдан артык госпитальдә ятып чыктым. Хәзер ярый инде, аякка бастым.

– Әйбәт булган. Элемтәдә торыйк. Югалтма минем телефонны.

* * *

Рәсимнең Казанга кайтып төшүе журналистлар өчен зур сенсация булды. Телефоннан шалтыраулар өзелмәде. Аның белән очрашырга, әңгәмә үткәрергә, интервью алырга ашыктылар. Барысын да «Алёша» экипажының Запорожье юнәлешендәге Новодаровка бистәсе янындагы бәрелеш кызыксындыра.

Бүген Рәсим үзенең вазифасын балаларда ватанпәрвәрлек рухын тәрбияләүдә күрә. Ул үзе эшли башлаган Танк училищесында укучыларга тәрбия дәресләре алып бара. Шәһәр һәм авыл мәктәпләрендә укучылар белән очрашуларга йөри. Республикада үткәрелгән чараларда катнаша.

Нәрсә соң ул ватанпәрвәрлек? Аны ничек тәрбияләп була? Ул мәктәп дәреслекләре аша тәрбияләнергә тиешме? Ул Рәсимнең балалар белән очрашулар вакытында сөйләгәннәре белән генә тәрбияләнәме?

Ватан – ул зур төшенчә. Ул дәүләт дигән сүз түгел. Ул туган җир, туган як, туган халкың, ата-бабаң гореф-гадәтләре, туган тел дигән мәгънәләрне берләштерә. Ә күпмилләтле илдә туган ягың тарихын өйрәтмәсәләр, туган телеңдә теләсәң – укы, теләмәсәң, укымаска да була дип белдерсәләр, югары уку йортларына кергәндә, туган телеңдә имтихан бирүдән мәхрүм ителсәң, Ватаныңның патриоты булып үсеп буламы? Рәсим әнә шул сорауларга җавап эзли. Беренче чиратта, ул бу сорауларга җавапны үзе өчен эзли. Шуңа күрә үзенең белемнәрен тирәнәйтү, дөньяга карашын киңәйтү, һәм, әлбәттә инде, хәрби белемнәрен ныгыту өчен, Россия Оборона министрлыгының Мәскәүдәге Хәрби университетына имтиханнар тапшырды. Татарстан Дәүләт Советына депутат булып сайланды. Ул шулар аша илебезнең киләчәк хуҗалары булачак балаларны ватанпәрвәрләр итеп тәрбияләү эшенә үз өлешен кертү максаты белән яши.



Гөлзадә
Әхтәмова

# ӨМЕТЛӘР ҺӘРВАКЫТ БУЛА АК...

## Алабуга

Һәр каланың җирдә үз язмышы:
Ни кадәрле озак яшәсә,
Шул кадәрле сергә күмелә ул,
Гаҗәеп бер якты нур чәчә.
Алабуга!
Гасырларны кичте, җиңеп чыкты,
Калкып чыкты хәрабәләрдән.
Саклап калды ул данлы исемен,
Тарих чүбен җилгәрүләрдән.
Яңгырашы аның үзебезчә,
Алабуга – дәртле, шат аваз!
Ул – ягымлы, җиңел, гади исем,
Гасырларны җиңгән кайтаваз.
Чулман суның дулкыннары кага,
Иркәләнеп текә ярына.
Таш корылма, аны моңга салып,
Ялгый гасырларның җырына.
Моң тарала елга буйларына,
Шаулата ул кара урманны.
Аһәңнәре – назлы борынгылык,
Агымсудай борма-бормалы.
Чал каланың капкалары ачык –
Чакыра ул, дәшә һәркемне.
Алабуга калка, үсә, яши!
Хыяллары ап-ак җилкәнле.

---

Гөлзадә ӘХТӘМОВА (1941) – *шагыйрә, С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Алабугам минем», «Йөрәгемдә яшен», «Күңел ашкынуы» һ.б. китаплар авторы. Алабугада яши.*

## Күңелләрдә якты өметләр

*Һәм уята мине кискен тавыш.*
*Кайда атым? Кайда кылычым?*
Муса Чахоровский,
Польша татары.

Бу дөньяда нинди мирас калган
Татар булып туган егеткә? –
Югалтулар арты югалтулар...
Тик өметләр генә йөрәктә.

«Кайда атым? Кайда кылычым?» – дип,
Ул төшеннән әрнеп уяна.
Бүген дә бит, әнә, дала яна,
Гөжләп аккан канга буяла.
Ут чәчрәтеп, корыч атлар чаба,
Яңа корал яный далада.
Гасыр арты гасыр үтә тора,
Тик тынычлык һаман юк анда.
Буыннардан-буыннарга күчә,
Җилкәләрдән төшми авырлык.
Ачы хакыйкатьләр әрнеткәндә,
Сорала нык түзем-сабырлык.
Чал тарихта тирән эзләр ята,
Үткәннәрдән сабак алырга.
Бар зур теләк, бар әле көч-куәт,
Татар булып яшәп калырга.
Без – мәңгелек халык! Күңелләрдә
Киләчәккә якты өметләр.
Җир шарының төрле почмагында
Татар исемен, данлы казанышын,
Горурланып,
Хәтерләрдә саклый егетләр!

## Күктә тулган ай

Таңнарны көтәм. Юк, атмый әле.
Күктә тулган ай һич батмый әле.
Ул әле һаман яктырта өйне.
Ничек үткәрим бу озын төнне?
Борчый киләчәк. Үткәннәр түгел.
Ни көтә диеп уйлана күңел.
Сизенә күңел, сызлана күңел,
Аңа тулган ай гаепле түгел.

Ничек табарга гомерлек дәва?
Сораулар арты сораулар ява.
Тетрәнә күңел, күкрәнә күңел,
Уйланмый тору һич мөмкин түгел.
Борма-бормалы җырлар агыла,
Иркәләп-назлап җанга кагыла.
Әйтә тулган ай: «Юаныч янда,
Тоярсың аны саф милли моңда».

## Уйлану

Җирдә күпме авыр сорауларга
Җавап таба алмыйм кирәктә.
Йә эсселим, йә бик туңам аннан –
Җиңел түгел тибү йөрәккә.
Кайгылардан айнып йөргән чакта,

Тормыш матур диеп, бер көлсәм,
Аяз көндә яшен яшьнәп ала,
Һич ярамый, юкка сөенсәм.
Дөньялары тыныч түгел чакта
Ничек сикереп-төшеп биергә?

Берни күрми, берни ишетмичә,
Эшләпәне күккә чөяргә?
Тетрәндерә һәрбер кара хәбәр –
Югалтулар арты югалту.
Газиз кешеләрен җуйганнарга
Ярдәм итми һичбер юату.
Күкләр аяз, җирләр тыныч булсын
Дигән теләк җанга уелган.
Җиңү хакы – күпме гомер хакы?!
Бәяләре күктә куелган...

## Төшенү

«Җирдә оҗмах юк һәм булмаячак!» –
Диләр. Ышану авыр аңарга.
Өмет итеп күпме яшәленде,
Тырышылды көн дә табарга.
Хыялларның ап-ак канатында
Очып килер кебек тоелды.
Киләчәктә рәхәт яшәр өчен
Зур максатлар алга куелды.
Каршылыклар арты каршылыклар
Очрый тора халкым алдында.
Җир әйләнгән саен кимеми ул,
Яшәү – көрәш бит ул чынында.
Яшәр өчен күпме уңайлыклар
Җир йөзендә уйлап табыла.
Бер-береңнең хәлен белер өчен
Җайлы элемтәләр салына.
Тик кабына кинәт сугыш уты,
Бәрелешләр булып торалар.
Бер-береңне җирдә юк итәргә
Ясала өр-яңа кораллар.
Саклый да һәм сагалый да алар
Күк йөзендә, җирдә, суларда.
Яшәү – көрәш булып кала бирә,
Җаннар тыныч түгел шуңарга.
Туры килде авырлыкка түзеп,
Алданылып гомер итәргә –
Рәхәт яшәтәчәк коммунизм
Таңы атар диеп иртәгә!
Күчәрендә Җир әйләнә тора.
Кая бара бүген кешелек?
Оҗмах Җирдә юк һәм булмаячак
Икәненә бик соң төшендек.

## Өметләр була ак

Юк аның карасы, сорысы –
Өметләр һәрвакыт була ак.
Яши ул күңелең түрендә,
Ә кайчак үзеңнән бик ерак.
Тормышны син ничек җайлама –
Өметнең өзелгән чагы бар.
Дөньялар киң диеп йөрсәң дә,
Атлыйсы сукмагың чыга тар.
Өметне ялгавы бик авыр,
Җепләре күренми күзеңә.
Җәйләрдә каласың килсә дә,
Борыласың гомер көзенә.
Һәм өмет кечерәя. Кечкенә.
Инде ул зураймый һич кенә.
Шулай да ул сине яшәртә,
Ышаныч сугарып яшәтә.
Җиңелрәк өметең булганда,
Күңелең шатлыктан тулганда.

## Тугай

И безнең бакча артында
Борылып киткән тугай!
Син минем күңел түрендә
Мәңге яшәрсең бугай.
Үлән басты комнарыңны,
Тарайды сукмакларың,
Син барыбер балачакның
Эзләрен саклап калдың.
Әрәмәләрең белән син
Беркая да китмәдең.
Ник син миңа да монда кал,
Китмә диеп әйтмәдең?
Ташысаң да, кайталасың
Ярларыңа син генә.
Гафу ит, тугай, читләрдә
Яшәп калынды менә...
Бакча артындагы тугай,
Син дә уйлыйсың кебек –
Көтмәгәндә шигъри юлга,
Кинәт китәсең кереп.
Ачыла хәтер ишеге,
Анда матур тамаша –
Кызыл канатлы балыклар,
Каз-үрдәкләр кайнаша!

Борылып аккан суларга
Буй салып үскән чаклар,
Дулкынланып җырга күчә,
Җанлана туган яклар!
И тугай, ямьле тугай!
Сагынам сине шулай!

## Кыш чыгу

Тәрәз төбендәге яраннарны
Әнкәм куйды базга төшереп.
Ул гөлләрне шулай саклап калды,
Кышкы салкыннардан яшереп.

Безне дә ул саклап торды кыштан –
«Усал җилләр өйгә кермәсен!»
Куа иде тәрәз төпләреннән –
«Берүк салкын тия күрмәсен!»

Ә без исә көн дә кызык таптык
Тәрәзәгә каткан бозлардан.
Эретеп тын белән хәбәр көттек
Җылы китерәчәк язлардан.

Түземсезлек белән көтелде яз –
Авыр да соң инде кыш чыгу!
Суык бабай сынауларын үтү –
Безгә булган икән чыныгу.

Базда язны көткән сабыр гөлләр
Тамырлардан кабат үсәрләр.
Томау төшүләрдән, ютәлләрдән
Без дә менә, шөкер, исәннәр!

Түбәләрдән тамчы тама башлый –
Бу шатлыктан күңел җилкенә!
...Балачакның озын-озак кышы
Истә калды булып төш кенә.

## Яз тантана итә

Яз – гаҗәеп көч-куәтле фасыл,
Исе китми кышкы карларга –
Әйләндерә аны салкын яшькә,
Ташкыннарга, шаулы җырларга.
Уята ул, тылсымлы көй уйнап,
Тигез күреп җирдә һәрберсен.
Сыйпап уза назлы кулы белән
Агачларның нәни бөресен.
Яз киләсен алдан һәркем белә,
Күнегелгән аңа күптәннән.
Язны көтеп, язга өметләнеп,
Азмы җаннар кышны үткәргән?
Яз тантана итә! Нуры белән
Моңсу күңелләргә дәрт биреп.
Алда ямьле көннәр, яшеллекләр,
Яз гөлләре үсәр үрелеп.
Алда өмет – йомшак оя ясап,
Кошлар тиздән бала чыгарыр:
«Тс-с-с! Шаулама, кеше!»
Аны тыңлап,
Туплар атмас, Җир тынычланыр!



Нәзифә Кәримова

# ОЗЫН-ОЗАК ЯЗМЫШЛАР

ПОВЕСТЬ-ИСТӘЛЕК

## Казан

Нишләп әле шулай килеп чыкты?
Үзем дә һич аңламаем, Казан.
Газиз исемеңне тәүге тапкыр
Шигырь итеп ак кәгазьгә язам.

Ә бит сиңа хәйран калганнан соң
Ярты гасыр нинди гомер акты!
Килгән саен урыным – түр башында,
Җаным, тәнем сый-хөрмәткә батты.

Төннәреңдә йолдызларың, Казан,
Җемелдәшеп күзләремә бага,
Идел дулкыннары иркә итеп,
Ярны түгел, күкрәгемне кага.

Булды еллар: шигырьләрем синдә
Канатланды һаваларга ашып,
Рухым исә Камал сәхнәсендә
Үкседе дә, шатланды да шашып.

Урамыңны күп таптадым, Казан,
Кызмача һәм... хәтта аек баштан,
Берчак капыл күз чагылып китте
Тимбикова затлы яшь Кояштан.

Туфрагыңа баскан саен, Казан,
Яна... туңа... минем бәгырьләрем.
Бәгыремдә яши исән дуслар,
Бәгыремдә – дуслар каберләре.

Туфан, Фәйзи, Хәким, Ахун, Риза –
Уннар, йөзләр күз алдымнан уза...
...Җирдә һаман ак бураннар туза,
Күкләр һаман күкрәп, яшен сыза.

Таушалмаган сөюемне, Казан,
Пышылдарга сиңа бүген базам.
Данлы исемеңне мәңгелеккә
Дога итеп язам: Казан, Казан...

Бу шигыре белән Мостай Кәрим, Казанга, аның урамнарына, күктәге йолдызларына, дусларына мәхәббәтен белдереп, шушы гүзәл төбәкне никадәр яратуын әйтергә омтылган. Юкка гына язмамны әлеге шигырь белән башламадым. Минем каенатам Мостай Кәримнең сөюләрен, милләтләребез турында борчылуларын, заман, киләчәк өчен кайгыруларын, барысына да түзгән, чыдаган көчле рухын Казанга алып кайтасым килде. Мостай Кәрим Казанга булган мәхәббәтен балаларына да калдырып китте. Күп вакыт, бигрәк тә соңгы елларда, ул Казанга үзе генә түгел, кызы Әлфия, онычы

Нәзифә КӘРИМОВА (1947) – *язучы, драматург, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре; «Җәнлекләр кайта», «Карурманнан чыккан юлчылар», «Сагынасыңмы дип сорыйлар» һ.б. китаплар авторы. Мәскәүдә яши.*

Тимербулат белән килә иде. Алар да Казанны чын ярату белән ярата, анда туганнарга тиңдәш дуслары да бар. Әткәйнең Казан белән үзара мәхәббәт иде! Казан да Мостай Кәримне яратты, хәзер дә ярата. Шулай булмаса, ул урамнарының берсенә Мостай Кәрим исемен биреп, аның мәһабәт һәйкәлен гүзәл бер почмагына кайтарып утыртыр идемени?!

## Гомер агышлары

Гомер тиз уза. Гомер ул үткән көннәр түгел, гомер ул истә калган көннәр дип әйтәләр. Минем истә калган көннәрем күп икән. Шуларны барлый башлагач, кара әле, мин бит бик кызыклы тормыш юлы үткәнмен икән дип куйдым. Нәрсәсе белән кызыклы дигәндә, тормышымда гаҗәеп кешеләр белән очраштым, алар әле һаман да очрап тора. Ачышлар гаҗәпләнүдән башлана диләр. Яңа кешеләрне табу, танышу, тормышның могҗизаларын күреп гаҗәпләнү – болар ачыш түгелмени? Ул шәхесләр, күңелемдә үз урыннарын алып, соңгы көннәремә кадәр минем белән булырлар. Язмамны каенатам Мостай Кәрим турындагы истәлекләргә багышларга теләсәм дә, туган йортым, әти-әнием, балачак, үсмер чагымның онытылмас хатирәләре дә бу китап битләренә үзләре керергә тора. Алардан башка мин үзем түгеллекне аңлыйм. Шуңа күрә, укучым, истәлекләремдә мәңге яшәячәк каенатам, каенанам, Илгизем, балаларым, аның туганнары белән бергә минем белән дә, әти-әнием белән дә, тормышыма йогынтысы булган дусларым һәм тагы бик күпләр белән танышырсың. Әйтергә генә ансат, әлбәттә, күңел шикләнеп тора, башкарып чыга алырмынмы? Мостай Кәрим иҗаты белән бер рәттә торырлык сүзләр таба алырмынмы? Шуңа күрә ничә еллар инде бу эшкә алынырга куркып йөрдем. Мостай Кәрим турында, аның иҗатына, шәхесенә багышланган китаплар бар. Алар чыгып тора. Димәк, Мостай Кәрим иҗатына ихтыяҗ бар. Миңа бу эшкә тотынырга хәер-фатиха биргән кеше – каенатам үзе. Әле аның улы Илгиз белән өйләнешкәндә, туй табынында ук каенатам: «Минем турыда соңгы китапны Нәзифә язачак!» – дип әйтмәгән булса, бу эшкә алынмас идем, батырлыгым җитмәс иде. Ә бит ул миңа ышанган. Шагыйрьләрдә әүлиялык бар ул! Әткәйдә ул, һичшиксез, бар иде. Димәк, бу язмалар каенатамның васыяте нәтиҗәсендә туган дип укыгыз. Ниятләдем дә тәвәккәлләдем!

Шул ук вакытта әле хәтердә калган истәлекләрне берәм-берәм якты дөньяга чыгара башласаң... Истәлекләрнең башы бу гаиләдәге тормышымның беренче көненнән генә түгел, ә инде булачак ирем Илгиз белән танышкан көннән башланган икән дисәм дә... Алай гына да түгел икән әле... Үземне кайчан белә башланганмын – шуннан ук икән... Нигә мине язмыш Мостай Кәримнең улы Илгиз белән очраштырды да, аның гаиләсе минем дә гаиләм булып китте, безне озак еллар иңгә-иң бергә яшәтте соң? Менә шушы сорауларга җавап бирергә тырышырмын...

Без Илгиз белән Мәскәүдә таныштык... Шулай дигәч, Мәскәүгә ничек килеп эләктең дип сораучылар да булыр. Инде ул хакта соңгы елларда гына сорамый башладылар, белеп бетерделәр бугай. Мин ул вакытта «Бөтенроссия эстрада сәнгатенең иҗат остаханәсе» (ВТМЭИ) дигән уку йортында артист булырга укып йөри идем. Студия турында да язмыйча

булмас, әткәй азрак көтәр, сабыр ул безнең, аңлар. Чөнки ул бит минем белән бергә белем эстәгәннәрнең барысын да белә, барысы белән дә таныш!

Эстрада студиясе дигәннән, без анда 14ләп яшь артист, филармониядә зур конкурста җиңеп чыгып, Мәскәүгә чын артист булырга дип, белем алырга килгәнбез. Җырчылар – Клара Хәйретдинова, Римма Ибраһимова, Зиннур Нурмөхәммәтов, Рабига Сибгатуллина. Мин җырчы да түгел, биюче дә түгел – сүз осталары арасында идем. Без бишәү идек! Виктор Шәрәфетдинов, Зәйтүнә Яруллина, Надия Низамиева, Мәрзия Вәлиева. Биючеләребез дә бар иде. Эльба Закирова, Мөнир Мөхәммәтдинов, Галина Васильева, Рөстәм Юнысов. Оригиналь жанр буенча Татьяна Романова да укыды безнең белән. Бу хөкүмәт программасы иде. Татарстанның 50 еллыгына багышлап, Россия Мәдәният министрлыгы махсус акча биргән диделәр. Ул вакытта безнең сәнгать җитәкчесе бик кырыс, туры сүзле, бик мәгълүматлы музыка белгече, филармониянең сәнгать җитәкчесе Мәхмүт Нигъмәтҗанов иде. Мәхмүт абый гомер буе безнең эшләр белән кызыксынып торды. Алып мактамаса да, салып таптамады дигән кебек, кырыс Мәхмүт абый безнең белән горурланды... Хәтта мин Казанга кайтмыйча, Мәскәүдә калсам да...

...Казанда бу студиягә укучылар җыйган конкурслар барган вакытта, мин Минзәлә Мәдәният йортында директор булып эшли идем. Үземә нибары 21 яшь. Конкурс турында очраклы гына ишеттем. Минзәләдә агитбригада белән йөргән төркемдә яңа гына педучилище тәмамлаган Галия исемле бик яхшы җырчыбыз бар иде. Тавышы сандугач тавышы иде аның. Галия Казанга барган да шул конкурс турында ишетеп кайткан. Миңа:

– Киттек, дустым, Мәскәүгә укырга! – ди. – Мин барысын да белешеп кайттым. Син сүз остасы булып үтәсең дә үтәсең инде! Ә мин – җыр! Их, филармония концертларында бергә йөрер идек. Мин җырлар идем, син сөйләр идең!

Минзәләдән Казанга кукурузник дигән очкычларда гына барып була. Юллар да юк, автобуслар да йөрми. Ул вакытта әле КамАЗ төзелеше дә башланмаган. Бүгенге кебек исемдә икән. Мин нишләргә дип күп уйланып тормадым, конкурстан үтсәм, әлбәттә, укырга барачакмын дип хәл иттем. Ләкин андый чакта киңәш бирүчеләр дә күп була икән. Казанга конкурска җыенганымны белгәч, миңа бер акыллы кеше: «Кискен борылышлар ясаудан курыкма. Ул һәрвакыт уңышка китерә. Бар!» – диде.

Ә инде конкурстан үтеп җиңеп кайткач, икенче берәү – анысын да акылсыз дип әйтеп булмый, хөрмәткә лаек, галим кеше: «Мин сиңа киңәш итмәс идем. Конкурстан үткәнсең, бик хуп, доказала! Ләкин синең эшең әйбәт, директор булып эшлисең, партиягә керерсең, фатир алырсың... Нәрсә калган сиңа ул Мәскәүдә!» – диде.

Мин беренчесен тыңладым. Акыллы фикерләрне аңларга да акыл кирәктер бәлки... Ул вакытта акыллы фикергә караганда, урын алыштырасы, дөнья күрәсе килү теләге, яңалыкка ашкыну өстенлек иткәндер. Кыскасы, киткәнемә бер тапкыр да үкенмәдем. Ләкин шунысы кызганыч булды: дустым Галия генә конкурстан үтә алмады. Ул калды, мин киттем. Ләкин Галия дә Минзәләдә торып калмады, Сәнгать институтына укырга керде, режиссёр һөнәрен үзләштерде, профессиясе буенча эшләде.

Казанга, соңгы турда безне тәгаен сайлап алырга ВТМЭИның директоры,

РСФСРның халык артисты Леонид Маслюков белән Татарстанның атказанган артисты, танылган тенор Георгий Виноградов та килгән иде. Заманында Георгий Виноградов Казанда эшләгән булган. Алар сайлап алды: без – җиңүчеләр исемлегендә!

1969 елның февралендә (кайсы көн икәне хәтердә калмаган) без Мәскәүнең Казан вокзалына килеп төштек. Барыбыз да дип әйтерлек Мәскәүдә беренче тапкыр! Мәхмүт абый безнең белән. Ә без аның янында тавык янына елышкан чебешләр кебек. Безне каршы алучы юк. Байтак таптандык перронда. «Каршы алырга тиешләр», – ди Мәхмүт абый. Тик без дә ул кешене белмибез, ул да безне танымый. Ниһаять, бер озын буйлы, матур киенгән зыялылыгы йөзенә чыккан бер ир-ат минем янга килеп: «Казаннан килүче артистлар сез түгелме?» – дип сорады. Бөтен төркем арасында артисткага охшаганы мин генә булдым микәнни дип уйлыйм хәзер. Соңыннан белдек: ул кеше без укырга тиешле ВТМЭИның директор урынбасары, атказанган артист Новицкий булып чыкты. Хәзер инде сәхнәдән киткән, яшь артистлар үстерү белән мәшгуль икән. Аның үз-үзен тотышы, сөйләшүе, безгә булган мөгамәләсе, тәртибе – аңлаган кешегә үзе дәрес, үрнәк иде...

Студия турында сүз чыккач, укытучылар турында да әйтми һич мөмкин түгел. Гаҗәеп кешеләр, Россия эстрадасында үзләренең данлыклы урыннарын алган легендалар укытты безне. Студия директоры, РСФСРның халык артисты Леонид Маслюков – ВТМЭИны оештыручы, эстрадада акробатик номерлар белән чыгыш ясаучы данлыклы артист. Башта үзебез – сүз осталары турында әйтеп үтим әле: безнең укытучыбыз – Харламова Александра Алексеевна Совет Армиясе театрында хезмәт иткән, лаеклы ялга чыккан артистка иде. Александра Алексеевна укучылары арасында танылган Любовь Полищук, Евгений Петросян, Сергей Дитятев һәм башкалар бар. Студиядә безнең вакытта укыган җырчылар – игезәк кызлар Лена һәм Таня Зайцевалар, Валерий Леонтьев... Саный китсәң, бөтен Россия эстрадасында чыгыш ясаучыларны атап китәргә кирәк.

Җырчылардан Рабига Сибгатуллина гына аерым укытучы – Ирма Яунземдә укыды. Ул укытучы да заманында бик талантлы халыкчан җырларны башкаручы артистка булган. Ә инде Клара Хәйретдинова, Римма Ибраһимова, Зиннур Нурмөхәммәтовлар лирик тенор тавышлы Георгий Виноградовта укыдылар.

Балет классы да бар иде. Гомумән, дәресләр иртән станок янында балет классыннан башлана иде. Сүз остасымы син, җырчымы – мөһим түгел. Балет укытучылары – Анна Редель белән Михаил Хрусталёв. Алар да эстрадада әле узган гасырның 30 нчы елларыннан ук билгеле булган атказанган артистлар иде.

Пантомимадан безне Анатолий Бойко укытты. Сүз остасы булган Виктор Шәрәфетдинов аны эстрадада чыгыш ясарлык итеп үзләштерде. Шуның өстенә оста биюче булып та китте. Алар соңыннан биюче Эльба Закирова белән өйләнештеләр, татар сәхнәсендә биюче пар барлыкка килде. Сүз осталары сәхнә сөйләме техникасын үзләштерде, укытучы белән эстрада монологларын өйрәнде. Репертуар өстендә эшләде. Минем белән бергә укыган бу дусларым хәзер инде барысы да атказанган, халык артистлары

дигән исемнәргә лаек булдылар. Укытучыларны да, шулай ук аларның укучыларын да «галиҗәнап артистлар» дип атар идем. Барысы да диярлек үз эшенә тугры булып калдылар. Мин генә артист булып китмәдем. Ләкин бу юлларны язарлык кеше булгач, язмышыма үпкәләмим. Эстрада студиясендә алган тәҗрибәм миңа Щепкин исемендәге югары театр училищесында татар студиясендә укытканда да, радиода эшләгәндә дә, «Зыялылар клубы»н алып барганда да, Мәскәү Сабантуйларын оештырганда да бик кирәк булды.

1959 елдан эшли башласа да, рәсми оешма булып 1961 елда танылган, күпме хезмәт күрсәткән ВТМЭИ 2014 елда ябылды. Леонид Маслюковның 86 яшьлек тол хатыны Ирина Осинцова гына елга бер мәртәбә, студиядә укыган артистларны җыеп, шанлы елларны искә төшерерлек көч таба. Без укырга килгәндә, студиягә нибары 10 ел гына булган икән.

Без укыганда, Омск артистлары килде. Алар арасыннан берсе – Равил Таишев безнекеләр белән Казанга кайтты. Соңыннан Равил белән Римма Ибраһимова гаилә корып җибәрделәр.

Бу тарафтан сүзем озынга китәргә мөмкин, чөнки барысы да әле бүген генә булган кебек. Ләкин максатыма якынрак булыр өчен Илгиз белән танышуымны аерым искә аласым килә. Ул да бик кызыклы, үзенчәлекле булды. Чынлап әйткәндә, онытылмаслык. Язмышның, күрәсең, үз билгеләре бар... Бу очрашуга язмыш мине дә күпме еллар әзерләп килгән...

Очрашулар очраклы булмый икән... Без Илгиз белән 1969 елның 19 июлендә таныштык. Минем әле ел ярым укыйсым бар, аннан соң Казанга, филармониягә эшкә кайтачакбыз. Мәскәүдә вакытлы икәнлегебезне беләбез. Шуның өчен театрларга йөрибез, концертлар карыйбыз, хәтта Зур театрга да барганыбыз булды. Без, эстрада бүлегендә укыгач, күп концертларга бушка йөри идек. Шулай итеп, Мәскәү мәдәнияте белән танышып кына калырга түгел, эчендә кайнарга тырыштык. Һәм туган көннәрне Мәскәүнең кайсы булса да ресторанында үткәрүне дә гадәткә керттек. Безнең хезмәт хакы яки стипендия дип әйтсәм инде – заманы өчен ярыйсы гына иде: аена 66 сум алып укыдык. Әлбәттә, Мәскәүдә мөмкинлекләр бар, кибетләрдә кием дә күп. Ул вакытта ни телисең, шуны алырга була иде. Күрәсең, теләкләр дә тыйнак булгандыр инде: 66 сумның Мәскәүдә күп акча түгеллеген без шунда ук аңладык. Безне башта ВДНХдагы бер кунакханәгә урнаштырдылар. «Колхозчы йорты» дип атала иде ул. ВДНХга күргәзмәгә килгән авыл алдынгыларын да шунда урнаштыра торган булганнар. Аннары, тагы бер айга дип, икенче корпуска күчерделәр. Кунакханәләрнең үз законы. Анда бер айдан артык тотмыйлар, айдан артса, түләү икенче төрлерәк, ягъни ике тапкыр кыйбатрак була икән. Без дәүләт акчасын бушка туздырырга тиеш түгел. Шулай итеп, Татарстан филармониясенең ике еллык укуларга килгән яшь артистларын берничә ай күчереп йөртә торгач, калган ел ярымга Мәскәүнең «Марьина роща» дип аталган районындагы «Северная» дигән кунакханәсенә урнаштырдылар. Әле Казанда ук Мәхмүт абый мине төркемебезнең старостасы итеп билгеләгән иде. «Бу абыстай сезнең староста булыр, аның тәҗрибәсе бар!» – диде ул (Мәхмүт абый миңа гына түгел, күпләребезгә «абыстай» дип дәшә иде). Мин Минзәләдә мәдәният йорты директоры булып эшләгәнгә, биредә дә оештыра белер дигәндер

инде. Казаннан безнең стипендияләр минем исемгә килә, кирәк чакта кунакханәләрнең директорлары белән сөйләшергә дә мин йөгерәм.

Без ВДНХ эчендә урнашкан җәйге «Яшел театр» бинасында укыдык.

Шулай итеп, 1969 елның 19 июле дә килеп җитте. Минем өчен бу гадәти генә дата булып чыкмады. Ул көнне безнең биюче артистыбыз Мөнир Мөхәммәтдиновның туган көне иде. Төркем старостасы буларак, төрле чараларны оештыру да минем өстә, шуңа Мөнир белән уйлаша торгач, күп кенә ресторан-кафеларны йөреп чыкканнан соң, Кызыл мәйдан каршындагы «Москва» кунакханәсенең 7 катында урнашкан ресторанга тукталдык. Ул «Седьмое небо» дип атала иде.

Руслар «никахлар күкләрдә укыла» диләрме әле? Шулай итеп, без туган көн генә үткәреп калмадык, «Күкнең җиденче каты»нда мин булачак ирем Илгиз белән таныштым. «Москва» кунакханәсенең җиденче катында урнашкан бу ресторанның балконына чыгып, кулыңны сузсаң – менә ул, менә ул Кызыл мәйдан! Шундый символик урында очраштык без.

...Без көндез килеп, ресторанда администратор белән сөйләшеп, күпмедер акчасын алдан түләп куйганга гына булды ул урын. Чөнки ул вакытларда ресторан-кафеларда буш урын булмый торган иде. Кешеләр ишек төбендә чират көтәләр иде. Без – 16-17 кеше. Безнең төркемгә Татарстаннан килгән кунаклар да кушылды. Әле шунысын да бик яхшы хәтерлим: безнең төркем утырган урын ике яклап шалтыр-шолтыр килеп торган бамбук пәрдәләр белән бүленгән иде. Аулаграк урын дип әйтәсем килә. Ресторан оркестры уйный, ә без яшь, чая! Ни дисәң дә, булачак артистлар бит. Авылдан килгән онытылды инде. Без Мәскәүдә! Без Кызыл мәйдан каршында! Без барысын да булдырабыз! Безнең кызларга 18-22 яшьләр тирәсе. Римма Ибраһимова, Надия Низамиева, Мәрзия Вәлиева мәктәпне яңа гына тәмамлаганнар. Ә инде Виктор Шәрәфетдинов соңгы классны, гомумән, Мәскәүдә укыды, шул ук вакытта студиягә дә йөрде! Клара Хәйретдинова бер курс педогогик институтта укыган, ләкин аны ташлап, Мәскәүгә артист булырга килгән. Олырак яшьтәгеләрдән берәү генә иде, ул да булса – җырчы Зиннур Нурмөхәммәтов. Олы яшьтә дигәч тә, аңа 28 яшь тирәсе иде бугай (Сүз уңаеннан, шунысын да әйтеп китим әле: Казанга кайткач, Зиннур белән безнең оригиналь җанрда эшләүче артисткабыз Татьяна Романова да өйләнештеләр).

Безнең төркемдә җырчылар да, биючеләр дә бар, сүз осталары да җитәрлек. Менә бүген Мәскәүнең иң шәп ресторанында Мөнирне туган көне белән котлыйбыз. Бервакыт безнең төркемнең җырчылары Клара Хәйретдинова белән Римма Ибраһимова, ресторан оркестрының тавышын күмеп, берсе артыннан икенчесе Мәскәү укытучылары белән өйрәнгән репертуарларын башкарырга тотындылар. Официантлар безгә җырламаска куша. Ә безнекеләр татарча җырларны теттерәләр генә. Шулвакыт ресторан залының иң уртасында бер төркем егетләр утырган өстәлдән: «Җырласыннар, без каршы түгел, браво!» дигән тавышлар ишетелде. Һәм шул өстәлдән безгә бүләккә бер шешә шәраб та килеп төшмәсенме! Без моны аңлап бетермәдек. Бу нәрсә дигән сүз инде? Бер-беребезгә карашабыз. Ничек рәхмәт әйтергә боларга? Безнең арада тәҗрибәле артистлар да юк түгел иде. Хәзер инде мәрхүм Зиннур: «Әлбәттә, без җавап итеп аларга да ни

булса да җибәрергә тиеш, ләкин безнең акча инде түләнгән, кесәдә артыгы юк, әйдә, барыбыз да басабыз да баш иябез, рәхмәт әйткәнне аңларлар», – диде. Шушы хәлдән соң, безгә күчтәнәч җибәргән өстәл артында утырган бер егет, безнең өстәл янына килде дә, миңа карап, татарчалатып: «Сезне мөмкинме?» – дип, биюгә чакырды. Өстәлнең иң түрендә утырган мин: «Рәхим итеп!» – дидем дә Мәскәүнең нәкъ уртасында Кызыл мәйдан каршындагы ресторанда мине татар телендә биергә чакырган татар егете янына ашыктым. Ә ул егет Илгиз булып чыкты. Ул, еллар узгач, безнең аларга карап баш июне: «Безгә бик уңайсыз булды, кайсыгыз уйлап тапты аны?» – дигән иде. Ә мин: «Бик тәҗрибәле кеше уйлап тапты. Игътибарсыз калдырсак, безгә уңайсыз булыр иде. Мин үзем безнең рәхмәт бик урынлы булды дип саныйм», – дидем. Ул минем белән ризалашты. Үзенең тыйнаклыгыннан гына шулай дию иде.

Танышып, байтак вакыт узгач, Илгиз дуслары белән бу ресторанга бик катлаулы юллар үтеп килгәнен сөйләде. «...Кич җитсә, Мәскәүдә ресторан-кафеларда урын калмый. Уфадан бер дустым да килгән иде, редакциядән дә безгә иярүчеләр табылды. Җитмәсә, мин үзем белән бергә эшләүче бер кызны да чакырган идем. Без бер төркем булдык. Кая барырга? Тегендә сугылдык, монда килдек дигәндәй. Бер җирдә дә урын юк. Ишек төбендә торалар – кертмиләр. Минем иң таныш кунакханә – «Москва» (Әтисе анда еш тукталганга, Илгиз бу кунакханәне бик яхшы белә, Казан, Уфадан килгән язучылар да шунда тукталалар. Ресторанга урамнан да керергә була икән, ләкин урамда чират, кунакханәдә торучылар өчен лифтта гына күтәреләсе. Хәйләсен белгән Илгиз кунакларын шулай алып кергән). Ишек төбендә швейцарга бер сум бирдем, ә инде лифтка кергәндә, 50 тиенгә дә риза булдылар», – дип көлдереп сөйләгән иде.

Без бу урынны көне буе эзләп, алдан табып куйган булсак, Илгизләр җиденче каттагы күккә акча бирә-бирә менгәннәр! «Белгән булсам, ишек төбеннән үк борылган булыр идем», – дия иде Илгиз, кайчакларда шаяртып... «Мин – синең язмышың! Син моңа фәлсәфи яктан кара! Харап икән, җәмгысе бер сум илле тиен түләгәнсең ишек бавына!» – дип көлә идем аннан! Хәзер бу тиеннәр турында сөйләү үзе бер көлке. Менә бит бәяләр нинди булган ул вакытта.

Таныштык, ләкин Илгизнең кем улы икәнлеген белмим әле. Беткәнмени Мәскәүдә татарча сөйләшә белгән егетләр! Ул миңа гаилә серен тиз генә чишмәде әле. Журналист, журналист! Мин аның гаиләсе хакында бары тик берничә айдан соң гына белдем. Анысын да Илгиздән түгел, танышы Уфа кызы әйтте. Мин ул хакта уйлаган булсам, бәлки үзем дә сизенгән булыр идем, ләкин минем башыма да килмәде! Мостай Кәримнең иҗатын белми идем дисәм, бик үк дөрес булмас...

***

...Алабугада дүрт ел мәдәни-агарту училищесында укыганнан соң, мине юллама белән Минзәләгә эшкә җибәрделәр. Миңа ул вакытта 19 яшь. Татар әдәбияты белән яхшы гына таныш булсам да, Татарстаннан башка төбәкләрдә яшәгән язучыларны белми идем дип әйтергә була. Без үскәндә, авылда аерым китапханә дә юк иде әле. Бары тик клубның кызыл

почмагындагы китаплар белән шыгрым тулы 4 шкаф истә калган. Укырга өйрәнгән беренче көннәрдән башлап, мин ул шкафтагы китапларның барысын да укып чыкканмындыр дип уйлыйм. Хәтта Лев Толстойның «Яңадан туу» («Воскресение») дигән китабы белән дә дүртенче класста укыганда ук таныштым. Гариф Ахунов тәрҗемәсе иде бугай. Вак хәрефләр белән сары газета кәгазенә басылган, кирпеч кенә түгел, ике кирпеч калынлыгындагы бу китапны мин ахырына кадәр укып чыкмадым, әлбәттә. Без аны классташым белән бергә укыдык, фикер алыша идек. Катерина Маслованың нәрсә белән шөгыльләнгәнен белгәч (кемдер безгә «фахишә» сүзенең нәрсә икәнен дә аңлатты), без аны бик каты гаепләп, ул китапны укудан туктадык. «Оятсыз кыз икән бу!» дигән нәтиҗә чыгардык. «Яңадан туу» китабы безгә шуннан ары мәгълүмат бирмәде. Клуб мөдире Сания апа, китапларны алыштырырга төшкәндә, алдан алган китапның эчтәлеген сорый торган иде. Бу юлы сорамады. «Мин биргән идемме сиңа бу китапны?» – дип кенә куйды. Чөнки кайчагында китапларны аның энесе дә бирә торган иде. Шул туры килгәндер, мөгаен. Бик күп укый идем. Миңа ул вакытта безнең клубтагы шкафларга дөньядагы барлык китаплар җыелган кебек тоела иде. Ә инде яңа әсәрләрне «Совет әдәбияты», соңыннан «Казан утлары» журналыннан чират торып укысак, яңа чыккан татарча китаплар гел кайтып тора иде. Бервакыт, башлангычта укыганда, клуб китапханәсенә керсәм, яңа китаплар кайткан. Балалар өчен дә бар. Каты тышлы. Тышында солдат киемендәге абыйның бер кызны күтәреп торган рәсеме дә бар. Авторына бик ис китмәгәндер инде, китапның исеме «Безнең өйнең яме» дип аталган иде. Күрәсең, Мостай Кәрим белән танышу шул вакыттан башланган икән...

...Ә инде мин эшкә килгән мәдәният йортының икенче катында Минзәләнең данлыклы театры урнашкан иде. Пьесалар яратканга, Минзәлә театрының репетицияләрен калдырмаска тырышам, спектакльләрне ятлап бетерә торган идем. Мин килгәндә, баш режиссёр булып, Сабир абый Өметбаев эшли иде. Хәзер театр аның исемен йөртә. Аннан соң инде Мулланур Мостафинны билгеләделәр. Мулланур Мостафин Мостай Кәримнең «Айгөл иле» спектаклен куя башлады. «Мостай Кәрим, Уфа» дигән сүзләр еш яңгырый иде репетиция вакытында. «Уфалар куйган инде, барып карыйсы иде аларныкын», «Әле баш режиссёр Уфага музыкасын алырга китте» дигән сүзләр бүген генә әйтелгән кебек хәтердә. Бу спектакль миңа бик тәэсир иткән иде. Мостай Кәримнең фоторәсемен дә шул вакытта күрдем. Язучы язучы инде. Ул премьерага килмәде, әлбәттә. Чөнки аның пьесалары бөтен СССР буйлап куелган вакыт ул...

***

Ресторанда танышканнан соң, Илгиз без яшәгән кунакханәгә безнең янга килгәләп йөри башлады. Мин аның Мәскәү дәүләт университетын тәмамлап, «Литературная Россия» дигән газетада милли бүлектә эшләгәнен белдем. Без Илгиз белән очраша башладык. Кино, театрларга, күргәзмәләргә йөрибез. Еш кына ЦДЛга – язучыларның үзәк йортындагы кафега бара идек. Ул кафеда нинди генә язучыларны очратмыйсың! Давид Самойлов, Евгений Евтушенко, Рәсүл Гамзатовның яшь чаклары! Равил Бохараев

белән дә без шул әдәби кафеда танышкан идек. Ул Мәскәү университетының математика факультетында аспирант иде. Күп вакыт ул кафега милли республикалардан килгән шагыйрьләр Илгиз эшләгән газетада беренче шигырьләрен бастыргач чакыра иде. Рәсүл Гамзатов әйтмешли, «кечкенә даһилар», өч куплетлы ике шигыре басылса, бөтен редакцияне чакырып, банкет ясыйлар иде. Шигырь укулар, шигырьнең фәлсәфи яклары турында сөйләшеп, сәнгать сәнгать өчен дигән бәхәсләр дә шул язучылар кафесында гөрли, кайчагында Илгизнең фатирына да күчә иде.

***

Бервакытны Илгиз мине вакытлыча яши торган фатирына чакырды. Ни өчен вакытлыча дип әйтәм, чөнки ул миңа Курский метросы янындагы зур гына бер йортка күрсәтеп: «Менә бу йорттан миңа фатир бирергә тиешләр», – дигән иде. Аның яңа гына Кырымнан Күктүбәдән ял итеп кайткан вакыты. «Күп итеп виноград алып кайттым, Кырым винограды белән сыйлыйм үзеңне», – диде ул. Илгиз өч бүлмәле коммуналь фатирның бер бүлмәсендә яши иде. Шунда беренче тапкыр коммуналь фатирның нәрсә икәнен күрдем. Шул фатирда яшәгән кешеләрнең үзара мөгамәләсен күзәтү кызык иде.

Беренче бүлмәдә Илгиз тора, икенчесендә хәмер яратучы, һәрвакыт сәрхуш ирле-хатынлы гаилә торса, өченче бүлмәдә бик зыялы, укымышлы, ике игезәк балалары белән яһүд гаиләсе яши иде. Бүлмәләрнең ишекләре беркайчан да бикле булмавы хәтердә калган. Хәтта һәрвакыт сәрхуш булган, итек төзәтүче булып эшләүче Виктор да «культуралы» итеп, сөйләшкәндә «сез» дип кенә дәшеп, салмышлыгын белдертмәс өчен гәүдәсен туры тотарга тырышып йөри иде. Кычкырыш, сүгенүләр юк иде ул коммуналь фатирда. Ә инде Илгиз торган бүлмәдә шагыйрь, тәрҗемәче Яков Козловскийның хатынының әнисе, ягъни әбисе яшәгән булган. Минемчә, Илгиз ул фатир өчен акча да түләми иде шикелле. Козловский әткәйнең дә байтак кына әсәрләрен рус теленә тәрҗемә иткән, билгеле шагыйрь генә түгел, дусты да иде.

Шул, беренче тапкыр фатиры, күршеләре белән таныштырырга, шул ук вакытта виноград белән сыйларга чакырган Илгиз кулыма фотоальбом тоттырды да кухняга чәй куярга чыгып китте. Таныш булмаган кешеләр фотосын карап утыру кызык түгел инде ул. Илгиз бер фотоны күрсәтеп, менә без монда әткәй белән диде. Карыйм: таза гына, матур кеше икән этисе. Тик костюм якасындагы значогы мине шаккатырды. Эчемнән генә «кара әле, үзе олы кеше, бала-чага кебек значок таккан» дип уйлап куйдым. Шулай да бу кешене кайдадыр күргәнем бар кебек. Ләкин фоторәсемдәге ул кешене түгел, аңа охшаган кешене күргәнмендер кебек тоелды миңа. Ә инде Илгизгә:

– Синең этиең Мостай Кәримгә охшаган икән, – дидем. Илгиз шунда, бер сүз дә әйтмичә, кулымнан альбомны алды да шкафка куйды.

– Әйдә, чәй эчәбез, – диде ул. – Виноград белән, – дип тә өстәде.

Ул вакытта Илгиз миңа үзенең Мостай Кәрим улы икәнлеген әйтмәде. Ә инде этисенең костюмындагы значокның депутат значогы булганын мин соңыннан гына аңладым. Бер дустыбыз әйтмешли – сельпо! Нәрсә күргән, нәрсә белгән кеше инде мин! Менә шулай әкрен генә үзем белмәгән, күрмәгән, хәтта аңламаган дөньяның серләренә төшенә барам. «Аң бул,

Нәзифә, Мәскәү бу, үзеңнең кем икәнлегеңне күрсәтмә!» – дияр иде әни. «Акыллы бул!» – дигән сүзе инде ул аның.

Илгиз белән очрашабыз, киноларга барабыз, Мәскәүнең кызыклы, тарихи урыннарында йөрибез. Ләкин Илгизнең гаиләсе белән мин әле һаман да таныш түгел. Чөнки өч ай тирәсе узганнан соң гына, бер дусларына кунакка баргач, аның Мостай Кәрим улы булуын ишеттем. Ләкин безнең мөнәсәбәтләрдә бернәрсә дә үзгәрмәде. Без элеккечә очрашып йөрдек. Илгиз яттан бик күп шигырьләр белә: Сергей Есенин, Валерий Брюсов, Роберт Бёрнс, Александр Блок шигырьләрен сөйли иде. Ул минем күңелемне биләп алды. Үзенең тәртибе, зыялылыгы, акылы белән җәлеп итте. Бик күп укый, күп авторларны белә иде. Бигрәк тә чит ил язучыларын. Ә мин рус язучыларын мәктәп программасыннан гына беләм ул вакытта. Татар язучыларын, әлбәттә, бик яхшы белә идем дип уйлыйм. Илгизнең дә әдәбиятка мөкиббән кеше булуы – үз мохитемә, үз кешемә очрадым дигән уйны күңелемә кертте, сөендерде... «Яттан шигырь сөйләгән кеше начар кеше түгелдер әле» дигән нәтиҗә ясады авыл кызы Нәзифә. Ике арада күңел якынлыгы барлыгын икебез дә аңлый идек. Бу язмаларга карап, болар рестораннарда гына йөргәннәр икән дип аңлый күрмә, укучым. Без көне буе укуда. Үзебезнең сүз осталыгы дәресләре янына без әле акробатика, пантомима, балет белән дә шөгыльләнәбез. Төрле яктан артист булырга әзерләнәбез. Ябыктык, нәфисләндек. Авылдан килгән түгәрәк битле, тупырдап торган кызларга Мәскәү төсе керә башлады. Шушы нәфисләнүебез янына диета тотабыз, бигрәк тә биючеләр. Шулай шөгыльләнә торгач, киемнәрне дә «Детский мир» кибетеннән ала башладык. Бәяләр ике тапкыр арзан, ләкин аңа карап, балалар киеме түгел, яшүсмерләрнеке. Ул вакытта модада булган водолазка, джинса кебек итеп тегелгән чалбарлар. Биек үкчәле туфлиләр алып җибәрдек. Без – артистлар! Шту син!

Шунысын да әйтеп китим: җырчыларга, биючеләргә репертуар эзләп торасы юк, ә менә сүз осталарына эстрада монологлары юк дәрәҗәсендә. Рус телендә байтак кына булды, өйрәндек, ә бит безгә татарча кирәк. Минзәләдә агитбригадада белән йөргәндә, мин, Газиз Мөхәммәтшинның хикәяләрен кыскартып, сәхнә өчен монологлар әзерләгән идем. Без, кызлар белән сөйләшеп, бу язучыга хат язарга булдык. Аңлаттык барысын да! Ул безгә, рәхмәт яугыры, почта белән үзенең хикәяләр китабын җибәрде. Кинәндек репертуарга! Хәтта бер хикәясен Виктор Шәрәфетдинов белән бергәләшеп әзерләп, ниндидер бер оешма кичәсендә (Мәскәүдә!) чыгыш та ясаган идек. Хат аша рәхмәтләр әйтсәк тә, ни кызганыч, ул язучы бик иртә вафат булды, үзен күреп рәхмәт әйтә алмадык.

### Барып чыкмаган «танышу»

Беркөнне без Илгизнең дуслары белән озак кына ЦДЛның данлыклы кафесында утырдык. Инде соң иде. Өйләргә таралышырга вакыт. Илгиз шунда әтисенең Мәскәүгә килүен әйтте: «Әткәй – Россия Язучылар берлеге секретаре, ул Мәскәүгә эш белән бик еш килә, – диде. – Аның Язучылар берлегеннән бирелгән фатиры да бар. Ленин проспектында. Мин сине әткәй белән таныштырырга телим, әйдә, киттек!»

Дуслар белән табын бүлешкән салмыш Илгиз минем: «Соң инде, кешене

борчымыйк, оялам!» – дип әйтүемә карамастан, такси алды да: «Мин сезне бүген таныштырам», – дип, әтисе Мостай Кәрим янына алып китте.

Мостай Кәримнең вакытлы фатиры Ленин проспектындагы иң соңгы, кирпеч йортларның берсендә урнашкан иде. Ул йорт янынннан гына басу башлана, бушлык, башка йортлар юк иде. Ә хәзер исә ул Мәскәү уртасында дип әйтерлек...

Ничәнче кат икәнен хәтерләмим инде. Ул вакытта ишекләр ачык, консьержлар юк. Менә без фатир каршында. Кыңгырау төймәсенә басабыз – җавап юк. Тагы баса Илгиз... Көтәбез... Тик әтисе ишекне ачмый әле. Илгизнең дә китәсе килми. Ул вакытта телефоннар да юк бит. Әтисе безнең киләсен дә белми.

– Әйдә, киттек, йоклый торгандыр йә эшләп утырадыр, борчымыйк кешене! – дим.

Илгиз, үҗәтләнеп, кыңгырау төймәсенә баса да баса. Беркавымнан соң, дөбер-шатыр килеп, ишек ачылып китмәсенме! Тубалдай бөдрә башын чайкап, Илгизнең әтисе килеп чыкты. Авыз ачарга да ирек бирми:

– Сез нәрсә?! – диде ул бик ачулы тавыш белән. Сүз башка кеше турында барса, шартларга җитешеп дип әйтер идем. Алга китеп, шунысын гына әйтим: кабат беркайчан да аның шундый ачулы чагын күргәнем булмады. – Бу вакытта кешегә килеп йөриләрмени? – Шуннан соң миңа карап алды да: – Ә син кыз башың белән төн уртасында нигә исерек егетләргә ияреп йөрисең? – дип, мине гел бетереп ташлады.

Шулай итеп, танышу түгел, ул безне ишегеннән дә кертмәде. Ул вакытта әткәйнең сүзләрен җир ярылса, җир тишегенә кереп китәрдәй булып тыңладык та шым гына баскычтан төшеп киттек. Менә сиңа Мостай Кәрим! Менә сиңа танышу! Менә сиңа данлыклы язучы! Белмим, Илгиз нәрсә уйлагандыр, миңа бик-бик уңайсыз, оят булды. Әйттем бит Илгизгә, тыңламады! Беренче очрашуда ук үзең турында шундый фикер калдыр әле. Мине кем дип уйлады инде ул...

Минем өчен Мостай Кәрим биргән беренче дәрес шушы иде.

Менә хәзер уйлап куйдым әле: чынлап та, әткәйнең әйткән сүзләрен, фикерләрен мин һәрвакыт иң асыл, иң дөресе дип кабул иттем. Аның әйткән сүзләренә һичбер шик-шөбһә кертмәдем. Тормыш юлында аның дәресләре байтак булды. Мостай Кәрим университетлары алда иде әле...

Аңынчы – Илгиз белән туебызга кадәр байтак вакыт узасы бар. Барысы да менә болай башланды...

### Чын танышу

Бу хәлләр 1969 елда булды. 20 октябрьдә Мостай Кәримгә 50 яшь тулган ел. Нибары 50 яшь! Аның беренче зур юбилеен Мәскәүдә ЦДЛның зур залында уздырдылар. Анда минем булачак каенанам Рауза Суфияновна да килгән иде. Тантаналы җыелыштан соң, бәйрәм ЦДЛның ресторанында дәвам итте. Илгиз миңа тагы: «Әйдә, ресторанга керәбез, хәзер мин сине алар белән һичшиксез таныштырам!» – дип, өстерәп диярлек ресторанга алып китте. Бер тапкыр авызы пешкән Нәзифә бу юлы инде үзен ничек тотарга белә иде. Кердек ресторанга. Аралашалар, көлешәләр, бәйрәмнең

иң рәхәт чагы. Әле дә хәтерлим, Илгиз мине әткәй белән әнкәй янына алып килеп: «Таныш булыгыз, бу – Нәзифә», – диде. Күрешкәнне дә хәтерләмим, аларның сүзләрен дә ишетмәдем кебек. Бер-ике кәлимә сүз әйтешкәч, Илгизнең колагына: «Киттек моннан», – дидем.

Бу очрашудан соң әткәй Илгизгә минем турында: «Тәртипле, тыйнак кыз икән, әрсезләнеп табын артына кереп утырмады», – дигән.

Бәлки мин беренче очрашудагы ялгышны төзәткәнмендер.

### «Девушка без адреса»

Илгизнең әтисе Мәскәүгә еш килә, кайчагында очраша да торган идек. Язучылар эше белән генә түгел, партия съездлары, үзе депутат булган Югары Шура сессияләре... Ул вакытларда Уфага караганда, Мәскәүдә күбрәк тә булгандыр әле. Әткәй байтак еллар РСФСР Югары Шурасы Рәисе урынбасары да булып эшләде. РСФСР Язучылар союзы секретаре эшен дә алып барды.

...Тагын бер очрашуны искә аласым килә. Бу очрашу аның белән соңгы ярты ел эчендә өченчесе иде кебек хәтерлим. Без аның янына кунакханәгә килгән идек. Булачак каенатам миннән нинди татар рәссамнарын беләм, нинди татар язучыларын укуым белән кызыксынды. Мин эчемнән генә «әһә, бу минем кругозорны тикшерә инде» дип уйлап куйдым. Нинди рәссамнарны атаганмындыр, хәтерләмим, ләкин язучыларны, аларның әсәрләрен бик яхшы белә идем. Ул минем белән аралашудан канәгать калган сыман тоелды.

Ул көнне әткәй безне каядыр алып барырга тиеш иде. Илгизнең әтисе депутат корпусыннан машина чакыртты. Утырып киттек. Бер сүз әйтмичә, авыз ачарга уңайсызланып, тып-тын утырам. Илгиз дә нигәдер дәшми. Кайсыдыр бер кинотеатр яныннан узганда, «Девушка без адреса» дигән бер афиша күзгә чалынды. Тынлыкны бозарга теләптер инде, шунда минем булачак каенатай:

– «Девушка» сүзе кергән тагы нинди киноларны беләсез? – дип, Илгиз белән икебезгә сорау бирде. Илгиз:

– «Девушка с гитарой» – диде.

Мин дә уйлый торгач таптым бит!

– «Матрос с кометы»! – дидем мин, шатланып. Тегеләр дәшми. Беркавымнан соң гына көлеп җибәрдем дә:

– Менә, Нәзифә дә әйтеп куйды! – дидем. Без өчәүләшеп көләргә тотындык. Татарча бернәрсә дә аңламаган шофёр безгә сәерсенеп, шаккатып карап ала. Чынлап та, нигә ул киноны атадым соң әле? Тиле түгелмен бит инде! Көлеп туктагач, мин аларга аның серен аңлаттым.

Сер дигәч тә инде, сер үк түгел, тик шулай да... Безнең авылда без бәләкәй чакта киноны движок мотор белән читтән килгән киномеханиклар күрсәтә иде. Бер килгәндә, берничә фильм алып киләләр дә, ике-өч көн рәттән клубта кино! Без инде киноны калдырмыйбыз. Ул вакытта да шул илле тиен иде аның бәясе. Акча булмау куркытмый, без качып булса да керәбез! Бүгенгедәй хәтердә: «Девушка без адреса» дигән киноны күрсәткәннән соң, икенче көнне «Матрос с кометы» дигәнен караган идек. Менә шул балачакта

караган фильм табышмак булып килде дә чыкты. Бик кызык булды ул. Әткәй рәхәтләнеп көлде. Минем ялгышканнан түгел, «менә, Нәзифә дә әйтеп куйды!» диюем бик ошаган булып чыкты аңа. «Синең үзеңнән көлеп, шаяртып сөйләвең синең самимилекне күрсәтә. Афәрин!» – диде әткәй ул вакытта. Әйе, беркатлылык – минем икенче исемем инде ул.

### «Эстрадница!»

Шул ук 1969 елны Мәскәүнең Пушкин исемендәге театры Мостай Кәримнең «Айгөл иле» пьесасын сәхнәләштерде. Премьерага мин дә чакырулы идем. Уфадан Илгизнең әнисе дә килгән иде. Бу юлы мин аны инде исемдә калдырдым. Читтән дә карап тордым. Бәләкәй генә гәүдәле, бик зәвыклы киенгән бу ханым бик мөлаем тоелды. Аның янында тагы олы яшьләрдәге зыялылыгы йөзенә чыккан искиткеч матур бер ханымны һич онытасым юк. Илгиз мине аның янына алып килеп: «Разия ханым Фаизева, гаиләбезнең якын дусты», – дип таныштырды. Разия ханым мине шунда ук күптән белгән кеше кебек кочаклап алды. Исемемне кабатлады. Аның бу гамәле минем булачак каенанам белән очрашудан килеп туган киеренкелекне бераз йомшартты. Үземне ничек тотарга да белмичә тора идем. Шушы очрашудан соң бик якын булып, алга таба да аралашып яшәдек. Разия ханымның әткәй язмышында ярдәмнәре белән зур роль уйнаган кеше икәнен дә белдем. Ул Язучылар берлегендә консультант булып эшләгән булган. Сугыштан соң әткәй авырган чакларда аңар ярдәм итүчеләрнең берсе. Разия ханым бик бай гаиләдә үскән, ул үз гаиләсе турында сөйләгәндә: «Мәскәүнең нәкъ үзәгендә «Старая площадь»тагы ЦК биналары минем әтиемнең кибетләре иде, шуннан аңла инде минем кем икәнлекне», – дигән иде.

Премьерада Әхияр Хәкимов дигән башкорт язучысы да бар иде. Алга китеп әйтим: Илгиз аның байтак кына романнарын рус теленә тәрҗемә итте. Хәкимов ул вакытта «Литературная газета»ның милли әдәбият бүлеген җитәкли иде. Алар хатыны Лидия ханым белән үзләрен бик һавалы тоттылар. Башкортча гына сөйләшәләр. Миңа сүз кушып, үзләренең «дәрәҗәләрен» төшермәделәр. Шушы очрашудан соң аның минем турында әйткән фикерләрен берничә елдан соң гына белдем. Ул әткәй белән әнкәйгә миңа кагылышлы «яхшы киңәш» биреп, «күзләрен ачкан»:

– Сез нәрсә? Ул бит эстрадница! Аны улыгызга якын да китермәгез! – дигән.

Илгизнең эти-әнисе бу фикергә колак салмаганнармы, белмим, ләкин алар ягыннан безнең араны бозарга тырышулар булмады. Байтак еллардан соң, Әхияр Хәкимовның ул сүзләре хакында миңа Разия ханым Фаизева сөйләгән иде. «Кемнең кем икәнлеген белеп тор, син алар тирәсендә булачаксың», – дигән иде ул.

Кабат бу темага кайтып тормас өчен Әхияр Хәкимов турында әйтәсе килгән сүземне шушы урында тәмамларга уйлыйм. Тормыш юлында миңа аның белән күп тапкырлар очрашырга туры килде. Хәтта бер романын русчага сүзгә-сүз тәрҗемә дә ясаганым булды. (Аның минем турыда Илгизнең эти-әнисенә әйткән киңәш-фикерен ишетмәгән идем. Ишеткән

булсам, бәлки алынмаган да булыр идем.) Тәрҗемәне миңа тәкъдим иттеләр, мин ризалаштым. Эш бит ул. Бер биткә бер сум түлиләр. Илгиз дә «на вольных хлебах», үзе әйтмешли, «вольно да не хлебно».

«Думра чыңы» дип аталган башкортча язылган ул романда 12 нче гасыр вакыйгалары бәян ителә. Борынгы, хәтта сүзлекләрдә дә юк сүзләр, авыр текст. Ләкин ике айда җиңеп чыктым мин аны. 400 битлек романга 400 сум акча алдым нәшрияттан. Ул вакытта машинисткаларга әзер текстны баскан өчен 2 сум түлиләр иде. Ә инде сүзгә-сүз тәрҗемәгә – бер сум! Менә байлык, әйеме! Әле эшкә йөрим бит! Каенанам әйтмешли, «йокы чутыннан» инде барысы да. Мондый эш минем тормышымда беренче һәм соңгы тәҗрибә булды. Монысы сүз уңаенда гына әйтелде. Күпкә алга киткәнмен икән. Бу теманы төгәлләп, шуны гына әйтәсем килә: инде «Зыялылар Клубы» оештырганнан соң, мин Хәкимовны гаиләсе белән Клубка Башкортстан язучыларына багышланган очрашуга чакырдым. Анда Мостай Кәрим, Муса Гали дә бар иде. Гаҗәеп эчтәлекле, күңелле очрашу килеп чыкты. Шул вакытта күр, кара, Әхияр абый, эстрадницаны!» – дип әйтәсем килде. Әйтмәсәм дә, аңлады дип уйлыйм...

Шулай итеп, хәзер генә түгел, инде күптән аңлаган нәрсәм – мин гомер буе үземнең кем икәнлегемне исбатлап яшәргә мәҗбүр булганмын, ахры.

## Без өйләнешәбез!

...Илгиз миңа тәкъдим ясаган көнне үк без, ЗАГСка барып, гариза бирдек. Безнең белән Кайсын Кулиевның улы Элдар да бар иде. (Кайсын Кулиев турында истәлекләр әле булачак. Ул – балкар халык шагыйре, әткәйнең бик якын дусты иде. Аларның дуслыгы гомер буе дәвам итте. Без дә балалары белән аралашып яшәдек.) Ул ВГИКка керү имтиханнарын биреп йөри, вакытлыча Илгиз фатирында тора иде. Ул гына түгел, байтак дусларыбыз җыелды ул көнне. Без дә инде, беркемнән дә хәер-фатиха да алмаган көе! Минем як та, Илгиз ягы да әле бернәрсә белми. Ә безнең инде язылышу көне билгеләнгән. Чөнки элемтәгә керү хәзерге кебек тиз генә түгел, телефоннар кесәдә түгел шул. Безнекеләргә бары тик хат кына язарга була, ә Илгизнең әти-әнисенә бу хәбәрне ишеттерер өчен кичке якта почтамтка сөйләшүләр пунктына киттек. Телефонны әткәй алды. Илгиз генә сөйләште. Соңыннан әткәй бу сөйләшүне искә алганда: «Мин бит төне буе йокламадым. Сезнең бу карарга сөендем. Хәтта өйдә дә кала алмадым. Төне буе Уфа урамнарын әйләндем», – дигән иде. Сөенеч кенә булмагандыр инде, борчылулары күбрәк булгандыр дип уйлыйм хәзер. Килен – бер авыл баласы, югары белеме дә юк... Ләкин минем авыл баласы булуым турында да, югары белемем булмавы хакында да Илгизләр гаиләсеннән бер генә кеше дә йөземә бәреп әйтмәде. Мин ул вакытта алардан бары тик хөрмәт белән ярату гына күрдем. Авылда кырыс тәрбия алган, ягымлы сүзләр сирәк ишетергә туры килгәнгә, Илгизнең гаиләсе күрсәткән мөнәсәбәттән мин бик бәхетле идем. Күз алдына китерегез: менә дигән партия (шулай дип әйтәләр бит) ясардай улы бер авыл кызына, җитмәсә, артисткага өйләнсен әле! Юк, безгә каршы чыгучы булмады! Бәлки, ниһаять, бу малай да акылга утырды бугай, безнең кулдан китте, теләсә нәрсә эшләсеннәр дип уйлаганнардыр?

Ул көнгә кадәр мин бит инде алар белән әзме-күпме таныш идем. Минем турыда аларда төпләнгән фикер булгандыр инде. Илгиз белән елдан артык очрашып йөргән вакыт эчендә булачак каенатай, каенанай белән күрешергә туры килгәләде бит.

ЗАГСка гариза биргәннән соң, мин Илгиз фатирына күченеп килдем. Гариза бирү уйламаганчарак килеп чыкты. Илгиз көтмәгәндә тәкъдим ясады, мин риза булдым. Аның Кырымга Күктүбәгә ял итәргә юлламасы бар, ул дусты белән берничә көннән китәргә тиеш иде. Әткәй, безнең гариза биргәнне белгәч, Илгиз ялының соңгы ике атнасына миңа да юллама алып бирде. Мин әле һаман студиядә укып йөрим. Җәй. Укытучыларның күбесе ялда. Ләкин без барыбер студиягә килергә, үзлегебездән өйрәнергә тиеш. Мин сорап-нитеп тормыйча тоттым да Кырымга Илгиз янына киттем. Менә ваемсызлык! Барыбер Казанга кайтмыйм дип уйлаганмындыр инде... Кырымнан ял итеп, кояшта янып, бәлки матурланыптыр да кайттым! Кайтсам, киткәнемне җитәкчеләргә җиткергәннәр. Безнең арада шундый берәү бар иде. Аның үзенең староста буласы килгән икән, ә мин сизмәдем дә. Интригалар шулай корыла икән... Мин «Күк түбә иле»ннән кайтуга, студиянең директоры барыбызны да кабинетына чакырып алды. Минем өстә яшел төстәге кыска итәкле костюм, аякта биек үкчәле туфлиләр, шомартып, артка җыелган сары чәч. Үзем кояшта матур итеп каралганмын. Җыелышып кереп утырдык. Леонид Маслюков миңа: «Без бит – синең дусларың, әйтергә иде, болай да җибәргән булыр идек», – диде, ләкин ачуланып, бер сүз дә әйтмәде. Җыелышны оештыручының ачуын китереп, болай дип тә өстәде: «Менә карагыз әле Нәзифәгә, ул бит балерина түгел, ә нинди нәфис». Аннан соң инде телдән төшми торган бер үк сүзләрне кабатлады: биюче кызларны ачуланырга тотынды. Галя Васильевага ике атна вакыт бирде. «Өч килога ябыкмасаң, студиядән чыгарабыз, сине биюче егетләр күтәрә алмый», – диде. Шулай итеп, кемнеңдер кара планы тормышка ашмый калды. Киресенчә, мактадылар гына.

Гариза биреп, ике ай вакыт узгач, без Илгиз белән 1970 елның 19 августында языльштык. Мин һаман эстрада студиясендә укып йөрим. Бергә укыган кызлар Илгизнең бер бүлмәле яңа фатирында туй өстәле кордылар. Безне, татарча туй йоласына туры китереп, ишек төбендә аяк астына мендәр салып, бал-май белән каршы алдылар. Хәтта күрше фатирда яшәүче генерал Дмитрий Сухоруков белән аның хатыны Надежда Николаевна да булды безнең туйда. Шулай итеп, генераллы туй уздырдык. Уфадан әткәй белән Илгизнең сеңлесе Әлфия килгән иде. Әткәй ЗАГСка барырга ул вакыттагы иң кәттә саналган «Чайка» машинасы да тапты. Тагы бер горурлыгымны әйтим: язылышканда, Илгиз ягыннан Илдар Ханов шаһит булды. Талантлы рәссам, скульптор Илдар безнең бик якын дустыбыз иде.

Икенче көнне үк без самолёт белән Уфага очтык. Чөнки туйның чыны Уфада узды. Алары инде төштә кебек кенә истә калган.

Туйдан өйгә кайттык. Мин Илгизнең әти-әнисенә кем дип эндәшергә дә белмим. Бер тапкыр Рауза апа дип дәшкәч, каенанам: «Уфалар ишетмәсен тагы, көләрләр, нигә миңа апа дип дәшәсең?» – диде. Әнкәйдә генераллар тавышы бар иде. Шуннан соң әткәй мине кабинетына чакырып алды да:

«Минем синең урында калганым юк, ләкин мин сине бик яхшы аңлыйм. Ят кешеләргә әткәй, әнкәй дип әйтү читендер, ләкин син дә безне Илгиз кебек «әткәй, әнкәй» дип ата инде, менә хәзер үк миңа «әткәй» дип әйт әле», – диде. Мин аңар «әткәй» дип әйттем дә елап җибәрдем. Ул мине, иңемнән кочаклап алып, аркамнан сөеп юатты. Шул ук кичне Илгизнең әнисенә дә әнкәй дип дәшә башладым.

Уфада туйның икенче көнендә кунакларның иң якыннары, туганнар әткәйләр фатирына җыелды. Шунда табын артында әле мине белер-белмәс Мостай Кәрим: «Минем турыда соңгы китапны Нәзифә язачак!» – дип әйтте. Бу сүзләр минем аңыма да, күңелемә дә уелып калды. Бәлки бу китап минем өчен соңгысы булыр, ләкин аның турында язарлар әле дип уйлыйм. Бәлки ул табында булганнар бу сүзләрне хәтерләми дә торганнардыр. Кемнәр булганын мин дә хәтерләмим бит... Ә менә ул сүзләр минем өчен васыять булып калды. Күрәсең, бу хакта язарга чират җиткәндер. Хәзер дә гаҗәпләнәм, нигә шулай дип әйтте икән ул? Мин әле ул вакытта каләм тотып карамаган, бары тик артист булырга хыялланган бер авыл баласы гына бит!

## Эш рәтен кем өйрәтте?

Без Илгиз белән өйләнешкәндә, Мостай Кәримгә нибары 50 яшь иде. Әле «Озын-озак балачак» та язылмаган, «Җәяүле Мәхмүт» тә планда гына, «Прометей» да, «Ат бирегез диктаторга» дигән фарс та юк. «Гомер мизгелләре» бәлки планда да булмагандыр... «Ярлыкау» һәм башка әсәрләр... Күпме шигырьләр... Болар барысы да һәм аның башка бик күп әсәрләре 1970 елдан соң, мин инде бу гаиләдә яшәгәндә, күз алдында язылды. Шуңа күрә аның турында җылы хатирәләрем белән бүлешергә минем дә хакым бардыр дип уйлыйм. Безнең әткәй белән җаннар, күңелләр туры килә иде. Якынлык бит ул рәттән утыру гына түгел, ул бит – күңел якынлыгы. Мин каенатаем Мостай Кәрим фани дөньяда булганда, бер гаиләдә 35 ел гомер иткән килен дә бит әле.

Илгизләр гаиләсе өйдә татарча сөйләшә. Әле татарчаның да татарчасы. Безнең урта диалектта, безнең авыллар кебек сөйләшәләр. Әле бездә тагы бер кызыгы бар – бездә Минзәлә сөйләше. «Кыдыл бодаулар» без. Шәһәрдән кайтып, «з» белән сөйләшә башласалар: «Ай-һай, харап икән! Бер кеше ике көндә шәһәр кешесе булган икән! Шул арада телен бодып кайткан!» – дип көләләр иде. Әлбәттә, уфаларның теле бераз аерыла, безнең авылча ук түгел. Кызык өчен языйм әле. Без «чүмеч» дибез, алар – «уҗау», бездә – «чиләк», аларда – «бидрә», без «пәрәмәч» дибез, алар – «чокырча», бездә – «почмак», аларда – «мөеш», бездә – «гөмбә», аларда – «мәшкәк».

Мин үзебезчә әйткәндә, төзәтүче булмады, ләкин күп нәрсәгә каенанайдан өйрәндем. Пешеренүгә бары тик аннан! Өйдән 15 яшемдә чыгып киткәнемне беләсез инде. Үсмер чакта, олы бала булгач, мин күбрәк әтигә ярдәм итә идем. Утын кискәндә пычкы башы тоту, печән вакытында печән чабу, уфалла арбасы тарту. Аш-су тирәсендә бик йөрергә туры килмәсә дә, башлангычта укыганда ук, әниләр эштән кайтуга токмач кисеп, аш пешереп куя идем. Аннан соң без үскәндә авыл кешесендә нинди тәмлүшкәләр булсын инде!

Иң затлысы, әти яратканы – кыстыбый. Минем әти әнигә: «Берәр ару нәрсә пешерәсеңме?.. Кыстыбыймы шунда...» – дигәне һаман исемдә. Бәлешләр инде кунак килгәндә генә. Коймак – бәйрәмнәрдә. Болар без үскән чакта, әлбәттә! Ә соңыннан тормыш бөтенәя башлагач, әни ул коры-сары тәмлүшкәләрне көн дә пешерә иде, чөнки әти әнинең мич ашларын ярата иде.

Бервакытны каенанай миннән:

– Син әниең яныннан яшьли чыгып киткәнсең, тулай торакларда торгансың, оста пешеренәсең, эш рәтен каян беләсең? – дип сорады да – Мин улым өчен тыныч, ул ач булмаячак, Нәзифә пешеренүгә оста, – диде.

Беренче чиратта, әнидән, әлбәттә. Токмач кисәргә, юка итеп бәрәңге әрчергә, савыт-сабаларны өчәр кат юарга, хәтта идән юарга да үз әнием өйрәтте. Күзәтүчәнлек тә көчле, укытучылар әйбәт булгандыр инде.

Авылда бит тәрбия бирү, эшкә өйрәтү бик үзенчәлекле. «Идәнеңне юганда, идән башлары чиста булса да, су тидерми китмә – сукыр каенана белән гомер итәрсең, интегерсең!» «Идән юганда, мич казнасын да сыпырып үтсәң, кызың матур булыр!» – Менә болар инде кызыксындырып, хәтта куркытып эшкә өйрәтү. «Чишмәдән кайтканда, чиләкләреңне чайкалдырма, суын түкмә, түгелсә, исерек ир белән гомер итәрсең!», «Баскыч башларын матур, чиста итеп ю – фәрештәләр борылып китмәсен!»

Тормыш итәргә өйрәтә торган мондый киңәш-тәрбияләр, әлбәттә, күңелгә уелып калган. Аннан соң әнинең әле балачактан әйтелгән тагы бер киңәше гомер буе озата килә. Әле һаман да! «Сабыр бул, усалланма, яхшылык белән ярарга тырыш...» Бәлки алай ук кирәк тә булмагандыр. Ярарга тырышуны әйтәм. Кайчагында үз акылымны да эшкә җиккәнмендер инде. Тик әни киңәшләре онытылмый гына түгел, ул һәрбер күзәнәккә сеңгән, аңга кереп утырган. Бу инде кыз баланы гаиләдә тормыш итәргә, дөнья көтәргә өйрәтүнең беренче адымнары булгандыр. Безнең әни андыйга бик оста иде. Аның тәрбия методларына данлыклы педогогларның исе китәр иде. Хәзер уйлап куям да тормыш итүгә, гаиләдәге мөнәсәбәтләргә, әлбәттә, мин әти-әни янында, үзем туган гаиләдә өйрәнгәнмен дим. Әти безнең өйдә баш кеше иде. Бар нәрсә дә ул планлаштырганча бара. (Өйдәге ир-атка хөрмәт шуннан килә.) Икмәген дә таба, утынын да хәстәрли, малны да әти карый иде. Аның каралты-курасы да ал да гөл! Утыны биш еллык, икмәге дә берничә елга җитәрлек. Әти коры, кырыс кеше иде. Ул – малны хезмәте, кул көче белән эшләп тапкан кеше, бездән дә шуны таләп итә иде. Ә менә бервакытны, һич онытасым юк, җәй көне иде, әти сеңлем белән икебезне ишегалдына чакырып чыгарды. Гомер булмаганны йөзендә елмаю!

– Менә сезгә нәрсә эшләтеп алдым. Олырагы сиңа, – диде ул миңа карап, – бәләкәйрәге Әлфиягә! (Сеңлем Әлфия исемле. Безнең ара ике яшь тә 4 ай.)

Карасак! Ишегалдында үрәчәләрен тырпайтып, өр-яңа ике уфалла арбасы тора. Әти шул хәтле шат, әйтерсең ике кызына ике «Мерседес» машинасы алып кайтып куйган!

– Ә менә сиңа дигәненең тәгәрмәче, – диде ул, миңа таба борылып, – калхуз персидәтеле тарантасы тәгәрмәче белән бер үлчәмдә! Сибгат абый шулай диде. (Ул безнең авылның тимерчесе.)

12 яшьлекябык, какча кызында ничә ат көче бар дип уйлады икән әти ул вакытта? Зур иде ул арба. Мин өстерәрлек булмады ул. Буш көе дә авыр

иде аны тарту. Шулай да, җәйге эшләрдә дә безгә катнашмый булмый. Җелекләргә төшә иде ул уфалла тартулар! Әти белән әни көне буе колхоз эшендә! Әле безгә өйдә дә эш күп бит. Суга да чишмәгә йөрисе. Маллар өчен дә, бакчага сибәр өчен дә! Өйдәге кисмәкне әйтеп тә торасы юк! Җитмәсә, бала карау да, ашарга пешерү дә безнең өстә. Урамга чыгып уйныйсы да килә. Әти бер дә тик торганны яратмый, безне эшсез тотмый иде. Әтинең миңа иң ошамаган бер ягы бар: ул китап укудан тыя торган иде. «Мичкә атам китапларыңны!» – дигән чаклары да булды. Тик атканы булмады. Китапханә китабын дәреслек эченә куеп укый идем. Дәрес әзерләгәнгә сүз юк иде, әлбәттә. Китапханәдәге китапларга бик кызыга идем. Киштәләр ясап, шунда китаплар тезәсем килә иде. Бервакытны кемнәндер безгә посылка килде. Шул фанер посылка тартмасының уртасыннан кадак белән стенага кагып, мин дә китап киштәсе ясадым. Үзем. Тик анда куярга китапларым гына юк. Менә шуннан соң инде китапларны үзем язарга тотындым. Дәфтәрдән энә белән тегеп, кечкенә китаплар ясадым да аларга хикәяләр, шигырьләр язарга тотындым! Тик менә беренче китапларымда нәрсәләр булганын хәтерләмим. Сакланмаган. Китапларны күп укыганым өчен миңа әти кушамат та такты. Хәзер сөйлим тиз генә: безнең әни күп йөргән, күп күргән кеше буларак, аның сөйли торган кызыклы, куркыныч, бигрәк тә җеннәр турындагы хикәяләре бик күп иде! Ул сугыш вакытында керәшен кызлары белән бергә совхозда тракторда эшләгән. Әни хикәяләренең күпмеседер безнең авыллар ишетмәгән, сөйләнмәгән, шул кызлардан ишеткәннәр иде. Безгә кич утырырга башка урамнардан да киләләр. Әни барысын да авызына каратып тора иде: «Бервакытны бер авылда бер хатын бәбигә авырган, ди. Өйдәге ир-атларны мунчага чыгарганнар. «Торып торыгыз шунда, бәби тугач әйтербез», – дигәннәр. Өйдә бәби табучы белән кендек әби генә калган. Әтисе белән малае бик җылы булмаган, суына барган мунчада утыралар икән. Үзләре шикләнәләр дә икән. Мунча бит, вакыт соң, төнге сәгать уникеләр тирәсе! Җеннәрнең кайнаган вакыты. Бервакытны мунча ишеге ачылып китмәсенме! Кочагына бик күп китаплар күтәргән, мунча түшәменә башы тияр-тимәс озынлыктагы берәү ла-ла-ла дип китап укый-укый килеп тә кергән, ди. Ләүкәдә утырган әтисе белән улы куркудан бер-берсенә чытырдап ябышканнар. Тәрәзә төбендә сукыр лампа булган, Ходай рәхмәте! Шунда мунча тәрәзәсен шакып, кендек әбинең: «Кайтыгыз, малаең туды!» дигән тавышы ишетелгән. Шул арада теге китап укучы ла-ла юкка да чыккан».

Кич утырганда, әнинең әкиятләрен тыңлап утырган әти, мин китапханәдән китаплар күтәреп кайтсам: «Әнә, Ла-ла кайтты!» – дия торган иде. Без әтинең күз карашыннан курка идек. Аның зәп-зәңгәр күзе миңа үтәкүренмәле кебек тоела иде. Яшь чакта матур кеше булгандыр дип уйлыйм. Кап-кара чәчле, зәп-зәңгәр күзле, туры борынлы кара-кучкыл йөзле кеше иде. Менә шул зәңгәр күзле карашы куркыта иде безне. Әти безгә кул күтәрмәде, матчада тәрбия чарасы булып, сыек чыбык эленеп торса да. Ләкин алты бала үскән гаиләдә без аның беркайчан да исерек чагын күрмәдек. Беркайчан да әни белән сүзгә килеп, безнең күз алдында әйткәләшкәннәре дә булмады. Андый хәлләр безнең гаиләгә хас нәрсә түгел иде. Әти белән әни бер-берсен хөрмәт итеп, яратып яшәделәр. Без алты

бала әле барыбыз да якты дөньядабыз. Иң олылары – мин. Туганнарым әйбәт яши. Әни әйтә торган иде: «Кешеләр миннән балаларыңа нинди хәер-дога кыласың син, синең балалар барысы да бик тәүфыйклы, игелекле, диләр». Ул шулай дип, бездән риза-бәхил булганын сиздереп куя иде. Менә хәзер инде оясында ни булса, очканында шул булыр дигән мәкальне искә төшерергә була.

Шунысын да искә алып китим әле: безнең әти белән әни иркәләүгә, мактауга бик саран иде. Ул авыл кешесенең баласына артык нечкә күңелле булуын күрсәтергә оялуыннан килә торгандыр дигән нәтиҗә чыгардым әле. Тормышта шундый булса да, әни хатларында ул сүзләргә иркенлек бирә иде. «Кызым, балакаем, бала җимешем» дигән сүзләрен үземә әйтмәсә дә, хатларында укып елый идем.

Мин бит – авыл баласы. Бәләкәй чакта бик тиз үсәсе килү миндә дә бар иде. Үсеп җитәргә дә дөнья күрергә! Бер дә таныш булмаган, бераз куркыткан дөньяга чумасы килү теләге күпләрдә булгандыр. Ә менә кай тарафка китәргә? Кая... Юл күрсәтүчеләр бармы?..

## Укырга, укырга, укырга!

Сөйлиләр иде... Безнең авылдан бер абый, авылга беркайчан да кайтмаячакмын дип, тау башына менеп, ыштанын төшереп, авылга артын күрсәтеп киткән. Ничек кенә китүенә карамастан кайткан, зур урындагы кеше булып кайткан. Урыны зур иде, ә үзе кеше буларак зур булмагандыр дип уйлыйм... Шунысы кызык: ул абый белән миңа да очрашырга туры килгәне булды...

...Без авылдан китәргә ашкынсак да, читтә йөри торгач белдек: безнең ниндидер бик мөһим нәрсә авылда калган булып чыкты. Шул безне гомер буе авылга тартып торды, үзен генә түгел, безнең кем булуыбызны да оныттырмады... Һәркемдә дә авылдан китүнең дә, кайтуның да үз сәбәбе бар. Авылдан ничаклы гына теләп китсә дә, ул кеше авылын сагынмый дигән сүз түгел әле. Сагынып яши кеше. Туган җирне сагыну гел икенче төрле. Гомерләрем шәһәрдә узса да, шушы көннәрдә авылга кайтып төпләнүемнең сәбәбе сагыну гына түгел, әлбәттә... Аны аңлап булмый... булмый. Бәлки ул күңелнең ачылып бетмәгән бер середер. Менә карыйк әле, бәлки истәлекләрне сүтә торгач, асылына кайтырбыз... Әнә балачакның иң ерак ноктасыннан бер тавыш ишетелә. Укытучы абый тавышы:

– Үскәч кем буласыз? Йә, кайсыгыз әйтә?

Өченче класста укыган чак булгандыр инде! И-и, әле үскәнче! Әй, көлешәбез! Ике классташыбыз – Зима белән Мәймүнә, ояла-ояла гына, врач булабыз дип әйттеләр. (Зиманың исеме Зима иде, үзгәртми бирәм.) Өйләре дә рәттән – күршеләр, бергә утыралар. Кем булырга теләгәнемне ул вакытта белмәсәм дә, врач булмаячагымны яхшы белә идем. Шулай да кем булырга соң? Без укытучыга шул турыда язып бирергә тиеш идек. Беребез дә мин колхозчы булам дип әйтмәде дисәм дә... Юк, юк, әйтте... Кемдер үзенчә шаяртып: «Колхозчы булам!» – дип кычкырды. Әй, көлдек аннан. Чөнки киләчәктә кем булса да буласы килү ул хыял иде. Хыял! Бәлки тормышка ашмаслыктыр. Ләкин ул булырга тиеш! Шулай булгач, нигә бүген күз алдында булганга кызыгырга! Колхозчы булырга? Анысы

хыялсыз да була бит! Малайлар тракторчы, шофёр булам диделәр, кемдер укытучы булам диде. Без әле дөнья күрмәгән, бөтен олы дөньябыз шушы туган авылыбыз белән чикләнгән балалар... Тагы кем булырга инде? Башка профессия юктыр да ул! Без шулай дип уйлаган идек. Бар икән!

Менә сигезенче классны да тәмамладык. Без күбәү идек. Авылда башлангычта бер класста 18 бала укыдык. Сугыштан соң туган балалар. Ә инде бишенче класска күрше авылга йөреп укыганда (ике авыл арасы 5 чакрым, көн дә кайтып йөрибез!), бер класста 41 бала булдык! Безнең бәхеткә, ул елны мәктәпкә яшь укытучылар килде. Алар, чынлап та, безнең бәхет булган. Чөнки алар чын укытучылар булган! Әнисә Касыймовна белән Гөлфәридә Минһаҗевна! Рус әдәбияты белән математикадан без бик төпле белем алдык. Гомумән, ул фәннәр генә түгел, башка фәннәр дә бик яхшы укытылган дип әйтә алам хәзер. Барысы да татар телендә булса да, русчага да шәп кенә өйрәнеп алдык. Чөнки бишенче класска шәһәрдән тамчы да татарча белмәгән бер кыз кайтты. Алар шәһәрдән бөтенләйгә күченеп кайттылар. Әтисе, балаларым рус булып үсәләр дип куркып, ике кызы, бер малае белән Магнитогорскидан кайтып, авылда өй салды. Бер кызы безнең класска эләкте. Русча сөйләшергә өйрәнүнең башы иде ул.

Менә сигезенче класс та артта калды. Бездә тугызынчы класс юк иде ул чакта. Балачак артта калды. Миңа да 15 яшь тулды. Башлангычта укытучы булырга хыяллансак та, кая барып укытучы булырга? Һаман да үзебезнең кем булачагыбызны белмибез. Үзеннән-үзе кемдер килеп чыгар да җитәкләп алып барыр, укырга урнаштырыр кебек тоела иде. Тугызынчы класска тагы даераграк күрше авылга йөреп укыйсы икән. Әле түләүле дә, ди. Кая инде ул миңа?

Сигезенчене бетереп, өлгергәнлек аттестаты алуга, колхоз безне шунда ук эләктереп алды. Бер көн дә калдырмый колхоз эшенә куша башладылар.

Без шулай йөри торгач, август та җиткән. Күрми дә, сизми дә калдык! Чөгендер утаулардан соң бәрәңге күмү, инде урак өсте дә җиткән. Безне амбар янына икмәк ташу эшенә җиктеләр. Әкренләп укырга барырга кирәклеге дә онытыла башлады. Кинәт безне шаккатырып, бер хәбәр ишетелде! Башлангычта ук врач булырга хыялланган Зима белән Мәймүнә Алабугада фельдшерлар әзерли торган училищега укырга кергәннәр! Әйтәм аны, безнең белән эшкә йөрмәделәр. Болай да хәлле кешеләр, берәр җиргә кунакка киткәннәрдер дип уйлаган идем. Классташлар булса да, әйтеп тә тормаганнар. Алар белән бергә авылга шәһәрдән кайтып, безгә бишенче класста килеп кушылган, һаман да татарча сөйләшергә өйрәнә алмаган Зина да барган булган. Үзе Зина дигәч, без дә Зина дидек инде. Аның исеме Язилә булган икән. Яши башлагач белдек анысын. Шунысы да шаккатырды, Мәймүнә белән Зима кергәннәр укырга, ә менә Язилә врачлыкка керәлмәгән булып чыкты. Имтиханнар анда гел русча гына дигәннәр иде. Рус теле генә ярдәм итмәгәндер шул.

Ә без һаман авылда! Кызлар укырга кереп кайтканнан соң гына, безнең дә башыбызга сукты. Сентябрь җитә, ә без шулай укырга керми калдыкмыни?! Безнең бәхеткә, Мамадышка элеваторга илтергә икмәк төягән вакытта амбар янына Мәймүнәнең әтисе Садретдин абый килеп чыкты. Безнең арыш тутырылган кычыткан капчыкларын шалт-шолт үлчәүгә салганны күрде дә:

– Кызлар, нишлисез?! Сез, нәрсә, монда грузчикլармыни?! Тапканнар лашман бияләрен! Балалар бит алар, капчык белән икмәк күтәртәсез! – дип, бригадирга кычкырды.

– Хе! – дип көлде бригадир абый. – Бүрек белән бәргәч егылмаса, аларны кияүгә бирергә була! Болар, әнә, кычыткан капчык белән икмәк төйи!

Без Садретдин абыйны уратып алдык.

– Мәймүнә кайттымы? Нигә күренми? Эшкә дә йөрми, – диештек.

– Нишләп йөрсен ул монда! Аның азабы көчәймәгән, Мәймүнә укырга керде, врач булачак. Кызлар! Әле хәзер дә укырга керергә соң түгел. Таегыз моннан! – диде Садретдин абый, пышылдауга күчеп. – Алабугада укырга керә торган җирләр күп икән. Культпросвет дигәнне ишеткәнегез бармы? – Без бер-беребезгә караштык. Ничек? Ничек! Садретдин абый каян инде сезгә аны белү дигән кебек итеп кулын селкеде... – Белмисез! Кызлар, – диде ул, – менә шул училищеда әле һаман да укырга алалар икән, укучылар җитми, ди.

– Анда укыгач, кем булабыз инде без? Мәймүнә дә шунда кердеме?

– Юк ла! Нишләп Мәймүнә анда керсен инде? Ул бит врач була. Сез керәсе училище клуб мөдирләре чыгара, ди.

Без көлеп җибәрдек.

– Безнең авылда клуб мөдире бар бит! Тагы без дә өстәлсәк, клуб мөдирләренең бәясе төшмәсме соң?

– Укырга барасыгыз киләме, әллә колхозда каласызмы? Монда капчыкларны күтәрәсе дә күтәрәсе әле! – дип кычкырды Садретдин абый, таулар кебек өелгән икмәк көшеләнә күрсәтеп.

Без ул көнне амбар янында эштә әле генә 8 класс бетергән, укырга теләкләре бик нык булган җиде-сигез кыз идек. Садретдин абый училищеның адресын бирде. Кирәк булса, анда танышым да бар дип, бер укытучының исемен дә әйтте. Кибетче Садретдин абыйның танышлары бөтен җирдә. Абруе да бар. Әнә Мәймүнә укырга кереп кайткач, тагы да күтәрелде.

Нәрсә эшләргә? Кызлар белән болай сөйләштек. Иртәгә икмәк төягән машинага утырып, Мамадышка чаклы барабыз да авылга кайтмыйбыз, туп-туры Алабугага укырга китәбез!

Икенче көнне эшкә барыр алдыннан әнигә:

– Әни! Мин укырга китәм! – дидем.

Әйтерсең минем теләк белән барысы да барып чыгачак. Иң мөһиме: машина бар, сорап йөрисе түгел. Бу инде – ярты уңыш! Юлга акча кирәк булачак бит әле! Акча белән эш иткән булмагач, анысын гел онытканмын. (Шул вакытта ике айга якын колхоз эшендә эшләгәч, аның өчен хезмәт хакы тиешлеге башка да килмәгән! Ияләнгән без колхозга бушка эшләргә!)

– Әни! Мин укырга китәм, мин генә түгел, бөтен урам кызлары бара. Акча кирәк булачак инде юлга булса да, – дидем әнигә.

– Барырсың абзар артына, каян килгән акча булсын! – диде әни, миңа борылып та карамыйча.

Мин инде этигә әйтеп тә тормадым. Белсә, кая ул риза булу! Әни ни булса да хәстәрләр дигән идем. Исе китмәде.

Нишләргә? Кызлар барысы да бара, әзерләнгәннәр. Мин үзем генә калырмын микәнни? Юк, мин колхоз эшенә бармаячакмын! Мин йөк төяүче түгел, ул капчыкларны башка күтәрмәячәкмен! Минем акча сорар кешем

бар. Мин шунда ук әнинең ахирәт дусты Хәерниса апаларга йөгердем. «Хәерниса апа! Кызлар белән укырга китәбез, акча юк, биреп тор әле, баегач түләрмен», – дидем. Хәерниса апа уйлап та тормыйча таслап төрелгән өч тәңкә акчаны уч төбемә салды да: «Бар, укы, кире бирмәсәң дә ярый», – диде, аркамнан сөеп. Мин ул өч тәңкә акчага гомерләрем буе рәхмәтле булдым Хәерниса апага. Авылга кайткан чакларымда күчтәнәчләр белән аңа керми калмый идем. Хәзер дә догамнан калдырмыйм.

Ур-ра! Без, әрҗәсе арыш белән тулы йөк машинасы өстенә кырын-ярын ятып, Мамадышка юл тоттык, аннан – Алабугага! Сау бул, авыл! Хуш, балачак! Балачакның капкасын зур йозак белән бикләп, ачкычын юл өстендәге каенлыкка атып калдырдык. Юллар калтыр-колтыр булса да, Мамадышка выжлап юл алган машинадан күренеп калган авыл манзарасының соңгы бизәкләре иде ул каенлык. Без кайтмаска китәбез, белеп тор! Син безне сагынырсың, без сине – беркайчан да! Шулай дип уйладык. Башкалар ничектер, мин нәкъ шулай уйладым ул чакта! Мине инде иртәгесен амбар янында сигез йөк төяүче булмавы да тамчы да борчымый иде!

Менә бу тәвәккәллек, менә бу карар язмышымның беренче адымы булган. Үз язмышымның. Без сигез кыз булсак та, бер йөк машинасы өстендә барсак та, язмышлар сигезебездә сигез төрле булды безнең...

Мамадыштан Алабугага барыр өчен, Нократның теге ягына чыгып, автобуска утырасы икән. Елга ярына җиттек. Яр буена машиналар җыелган, җигүле атлар да бар. Алабугада врачлыкка имтихан биреп тә, укырга керә алмый кайткан классташыбыз Язилә да безгә иярде. «Анда керәлмәсәм дә, монда барыбер керәм», – диде ул. Башта Алабугада кызлар белән медучилищега имтиханын бирә алмаганга уңайсызланып торса да, юлга чыккач батырайды бу. Чөнки ул бу юллардан бер йөреп кайткан, белеп йөри. Шуның өстенә русчаны да су кебек эчә!

Паромга утырдык, анда билет аласы икән. Паромны чух-чух килеп, кечкенә генә катер өстери. Хәерниса ападан алган өч тәңкә акчаны вакларга туры килде. Билет сатучы белән сатулаштык әле башта. Унбиш тиен түләгез дип ята! «Ә менә монда укучыларга җиде тиен дип язылган», – дигәч, хәзер кияүгә чыкканнар да укый дип тартышса да, мырлый-мырлый, акчаны ватты билет сатучы. Без кияүгә чыкканнарга охшамаганны үзе дә аңлады бугай. Ура! Сигез тиен янга калды. Менә шулай шомара башладык. Башыбызга тагы бер якты уй килде. Автобус бәясе 73 тиен икән, ә инде йөк машинасы тартмасында барсаң, Алабугага чаклы 50 тиен генә түлисе! Паромда Алабугага бара торган машиналарны белешә торгач, анысы да табылды. Тартмасы тулы салам! Йомшак, барыбыз бергә, бәясе дә шәп! (Һай, бу илле тиен! Булачак ирем Илгиз дә әле мине белмәгән, күрмәгән вакытта язмыш әзерләп куйган очрашуга барганда, ишек төбендә утыручыга 50 тиен түләгән иде бит.)

Мин паромда акчаны ваклагач, кая куярга да белмәдем. Учлап тоткан акчадан аерыласы килмәдеме шунда... Акча янчыгы юк та юк, кесәсе дә юк икән. Акчаны әйберләремне салган кирзовый сумка төбенә салдым. Инде машинага түләргә дип, вак акчалар чутлый башлагач, 20 тиен акчам тартмадагы саламга төште дә китте. Салам калын, кармаклап акча эзләргә тотындык. Ләкин акча табылмады. Саламны аралап, машина тартмасының

төбенә төшсәк – анда тишек тә, ярык икән! Менә нәрсә өчен салган ул саламны шофёр! Акчам да бәлки, шул тишектән тайгандыр... Минем өчен бик зур югалту иде ул 20 тиен. Кызлардан да эләкте. Бигрәк тә инде бу юлларны буш булса да, бер әйләнеп кайткан дустыбыз:

– Тормыш юлыңны зур югалтулардан башладың, ничек яшәргә уйлыйсың? – диде.

Кайбер кешеләр шулай инде. Үзләрен белмиләр, кеше өйрәтәләр дип уйладым мин. Эчем бик сызса да, югалган акча өчен кайгырмаска булдым. Юл хәере булыр, алдагысы бәрәкәтле булсын...

Тормыш югалтуларсыз булмый торгандыр. Шул вакыттан бирле югалган, төшеп калган акча, әйберләр өчен кайгырмаска үземә сүз бирдем. Бу юл хәере миңа гомер буе уңыш биреп торды...

Алабуга! Монда килергә күптәннән хыялланган идем. Кызлар алтынчы классны бетергәч, бирегә экскурсиягә дә килгәннәр иде. Мин бара алмаган идем ул вакытта. Авырып калдым. Алар барысы да белгән булып йөриләр. Мин иярәм. Авыз ачып, артта калам. Тагы йөгереп, кызларны куып җитәм. Без – сигез кыз! Бер төркем. Барыбыз да культпросветка! Культура, сиңа яңа көч килә! Тик нәрсә ул, ничек укыталар, нинди фәннәр – ул хакта бернәрсә дә белмибез, ләкин культпросвет дигән исемне отып алдык. Ишеткән нәрсәбез булмаса да. Документлар кулыбызда. Сигез классны бетергәнгә өлгергәнлек аттестаты, туу турында таныклык, мәктәптән характеристика. Документлар кабул итеп утыра торган кыз янына килеп теркәлдек, документларны тапшырдык. Аның белән генә бетми икән әле. Укучылар җитмәсә дә, имтиханы бар икән. Башта безне таза гына, сап-сары чәчле, кып-кызыл иренле бер укытучы музыкага һәвәслекне тикшерде. «Җырлагыз!» – ди. Һи, без – җырчылар! Беренче класстан бирле авыл клубында концерт куючылар без! Ул, әзерләнергә кушып, гармунда уйнаучы эзләп китте. Укытучы килгәнче, без белгән җырларны барлый башладык. Русча бер җыр да белмибез, укытучы – рус кешесе. Татарча булса да, ярый дигәч, җиңел сулап куйдык. Ул вакытта яңа гына чыккан бер җырны сайладым.

«Тау башында тора бер кала
Ул кала Өфө дип атала...»

(Башка җыр юкмыни, нигә Уфа турындагы җыр телемә кергән? Бу бер билге булган инде дип уйлыйм хәзер. Уфа турында күп җырлар ишеткәнем бар иде. Орынып торган күршеләребезнең патефоны бар иде без үскәндә. Рәшит Ваһапов, Зифа Басыйрова җырларын тыңлый идек. «Уфа юллары пыяла, таш булса, таймас иде...» Уфа минем өчен бер әкият илендәге тау башында тора торган пыяла шәһәр булып тоелган иде ул чакта. Миндәге фантазия!)

Шуннан соң безне фортепьяно янына чакырдылар. Аны беренче мәртәбә күрәбез! Укытучы клавишаларга басып, анда яңгыраган музыканы – ул ноталар дип атала икән – тавыш белән җырлап бирүне сорады. Кызык! Анысын да башкардык! Мактаганнардырмы, көлгәннәрдерме – хәтерләмим. Музыка ягыннан беребез генә төшеп калды. Ул да булса – Асия! Ул башта җырламыйча ялындырды. Нәрсәгә дип ияргәндер безгә! Клубта концерт

куйган вакытларда хорда җырларга да ялындыра иде. Монда оялды бугай. Аннары ручка белән шакылдатып, ритмны кабатларга сорагач: «Бу да имтиханмыни?» – диде дә тотынды көләргә! Аңар ияреп, без дә көләргә тотындык. Укытучы аптырап калды. Амбар янындагы эштән аерылып килгән бер төркем «колхозчы»ларда мәдәният өчен өмет күрмәгәне аның йөзенә чыккан иде. Хәзер уйлыйм, соңыннан безне музыка грамотасы дәресләреннән укыткан Бажинова апа бу хәлләрдән көлмичә ничек чыдады икән?!

Рус әдәбиятыннан гына сорадылар. Язып, тикшереп торырга укытучыларның вакыты булмагандыр, күрәсең. Без бит җитмәгәнгә алынучылар, бик тәфсилләп тормадылар инде. Миннән Максим Горький, аның балачагы турында сөйләттеләр. Нәрсә, нәрсә, без рус теле һәм әдәбиятыннан шәп белә идек. Беренчедән, рус теле укытучысы Әнисә Касыймовна үзе дә – Алабуга педогогия институтын тәмамлаган, рус теленә мөкиббән киткән, барлык язучыларның әсәрләрен яттан сөйләгән укытучы, безгә дә күп нәрсәләр өйрәтергә өлгергән иде. Рус телебез дә ярыйсы гына, чөнки Зина белән русча аралашырга мәҗбүр идек. Ул бишенче класска килсә дә, сигезенчегә кадәр татарчаны өйрәнгәнен сиздерми, гел русча гына сөйләште.

Имтиханнар артта калды. Без барыбыз да стипендиягә бирдек, дүрт тә биш куйдылар, ләкин тулай торак булмаячак диделәр. Тулай торак булмагач, ничек бүләргә ул стипендияне? Стипендия булгач, фатирга керергә була дип тә юаттылар. Стипендия 14 сум. Фатир бәясе 6 сум.

Без инде фатир бәясе булачак стипендиянең яртысын дип әйтерлек йотып алачагын белгән идек. Чөнки Зима белән Мәймүнә укыган җирдә тулай торак юк, аларга әтиләре инде табып биргән дип тә ишеттек. Аларга табырлар, аларның акчалары бар, ә менә миңа – ай-һай!

Без тулай тораксыз укырга мөмкин булмаячак дип, документларны кире алырга карар кылдык. Әй, Асия сөенде инде. Кадрия белән Миннебикә генә кара кайгыга баттылар. Юк, алар болай да укырга дип килмәделәр, паспорт алганчы гына укыйбыз да паспорт алгач таябыз дип авылда ук сөйләшеп куйганнар иде. Димәк, язмыш булмаган! Без кабул итү комиссиясе бүлмәсенә кердек тә документларны кире сорадык. Бирмиләр! Укучылары җитми бит! Без үзебез генә дә ярты класс булган идек. Безне калырга кыстый башладылар. «Стипендия була бит!» – дип кабатлыйлар. 14 сум! Искечә 140 сум! Кулга тигән акча түгел инде. Тулай тораксыз булмый дидек. Асия инде авыл рәхәтлекләрен сөйли. Ялына торгач документларны бирделәр. Башта тетеп сүктеләр әле! Барыбер алдык документларны, чыктык урамга. Автовокзал кайсы якта соң әле?.. Як-якка карана торгач, Шишкин музее янында торганыбызны аңладык. Ишеткән, күргән кеше түгел дисәм, кызлар беләләр икән. Алар бит Алабугага экскурсиягә барган кешеләр! Кая монда музейга керүләр! Автовокзалны эзләп киттек. Анысы да ерак түгел икән. Карасак, автовокзал янында капчыгын кочаклап, Зиманың әтисе Гомәр абый утыра. Зиманы фатирга урнаштырырга килгән икән. Безне күрүгә сикереп торды:

– Нишләп йөрисез монда? – ди.

– Менә авылга кайтырга йөрибез, документларны алдык, – дибез.

– Нәрсә, бирә алмадыгызмыни имтиханны?

– Бирдек, стипендиягә бирдек, тик торырга урын юк диделәр...

– Нинди кайту авылга, әйдәгез әле, әйдәгез, кире киттек училищега!

– Кире алмыйлар! Ачуланып калдылар. Кабат барырга оят!

– Укырга кермичә авылга кайтсагыз, менә оят була! Җан биргәнгә юнь бирә, киттек, киттек, кирәк булса, үзем сөйләшермен, – дип, Гомәр абый безне көтүебез белән яңадан училищега алып китте.

Көне матур, кояшлы. Алабуга да матур икән. Училище каршында гына әрәмәлек, астарак, ялтырап, Тойма елгасы ята. Аз гына аска төшсәң – Чулман. Ничек без, шушы матурлыкны ташлап, авылга кайтып китәргә уйладык икән? Анда бит безне тагы кычыткан капчыклар өстерәткән колхоз, басу эше көтеп торачак.

Икенче тапкыр училищега кергәндә, минем карар нык иде. Әлбәттә, бер көн эчендә без инде авылны сагынып өлгергән идек. Ләкин... Кемдер кайтып китәр, ә менә мин авылга кайтмаячакмын. Монда бит класс саен фортепьяно! Уйнап карадык без анда, көй чыгардык, чыга көе дә!

Гомәр абый безнең белән кереп тормады: «Автобуска соңга калам, тик сезгә кайтасы түгел, ишетәсезме!» – дип, безне озатып куйгач, кулындагы буш биштәрен селки-селки, автовокзал ягына йөгерде. Безнең бу карар белән бер дә килешмәгән Асия аның артыннан калмады. Шулай итеп, безнең төркемнән берәү кимеде. Без җидәү калдык. Җиде кыз. Монда символик мәгънә бар. Ул шулай булырга тиеш булган. Җиде кыз, җидегән йолдыз, җиде клуб мөдире!

Безнең инде артка борылырлык та урын юк иде. Гомәр абый алдында да оят, авылга кайтырга да уңайсыз. Документларны тотып, кабат язылырга кергәч, күрәбез: секретарь кыз янында таза гына бер абый басып тора. Секретарь кыз бу абыйга әйтә:

«Менә алар, менә! Газиз Сәләхетдинович!» – ди. Ул абыйның исеме каршыдагы кабинет ишегенә дә язылган иде, шундук аңладык – училищеның завучы. Сүз безнең килеп-китеп йөрүләр турында булган, күрәсең. Ул безгә күтәрелеп карады да, безгә бер сүз дә әйтмичә, секретарь кызга: «Теркәгез!» – диде.

Гомумән, бик яхшы кеше булып чыкты Газиз Сәләхетдинович. Безгә күп тапкырлар ярдәм итте. Үзе музыкант, композитор да икән әле! Бу хакта соңыннан белдек.

Ә тегесе инде безне исемлектән шытырдатып сызып аткан. Ачуыннан шундый каты сызган, хәтта кәгазе тишелеп чыккан. Карыйбыз, өстәп язарга урын да калмаган. Сөйләнергә үк тотынды:

– Йөриләр шунда, нәрсә теләгәннәрен үзләре дә белмиләр. Авыл көтүе! Деревня! – дигәнен дә ишеттек. Аңладык моның тел төбен. Яратмады бу безне.

Ләкин аның безне яңадан язып куюдан башка чарасы юк иде. Имтиханнар бирелгән, анысын сызып атып булмый. Без кирәк аларга. Аларның планы, тулмаган, безнеке түгел! Шулай итеп, безнең кулларыбызга училищега укырга алынды дигән документ та тоттырдылар!

Август ахыры иде. Бер атнадан килергә диделәр. Училищега кергәннәрне Алабуга районы авылларына бәрәңге алырга җибәрәселәр икән. Бер айга. Бу колхоздан укырга кергәч тә котыласы юк икән дип көлдек кызлар

белән. Ләкин бу инде җиңүчеләр көлүе иде. Укырга кердек бит! Укырга! Без, шаулашып, сөенечле авазлар чыгарып, училищеның икенче катыннан аска йөгердек. Биредә бездән башка әллә ни җанлылык юк. Күрәсең, училищега без генә җитмәгәнбез! Шулай итеп, без Гомәр абый автобусына да җитештек! Барыбыз бергә шатланышып, авылга кайтып киттек. Без – студентлар! Без Алабугада! Ләкин безгә тулай торак вәгъдә итмәделәр... Әле менә уйлап куям, Садретдин абый амбар янына килмәгән булса, Гомәр абый безне яңадан училищега кертеп җибәрмәгән булса, безнең тормыш ничек булыр иде икән? Менә кемнәр булган бит безгә юл күрсәтүчеләр! Искә төшкән саен аларга рәхмәт укыйм!

Монысы рәхәт булса да, мине авылда бик авыр сөйләшү көтә иде. Әти белән әни минем укырга баруыма аяк терәп каршы килделәр! Аларны укырга керү кызыксындырмады. Иң ачулары килгәне – Хәерниса ападан алган акча. «Әйтмичә, кешедән бурычка акча алып!» – дип кабатлады әти. Инде үсеп җитеп, эшкә ярый башлагач кына, олы кызының өйдән чыгып китүенә ул бигрәк тә риза түгел иде. Әле без бәләкәй чакта да әнигә: «Кызларны тик тотма! Берсе сыер саусын, икенчесе ашарга пешерсен», – ди торган иде. Әти үзе дә эшсез тормады. Мин аның ятып түгел, утырып торганын да хәтерләмим. Тиктормас, чәүчәлэк кеше иде ул. Шул ук вакытта аның әни фикеренә колак салуын да беләм. Әнине ничектер күндерсәм, әни әти белән сөйләшә белер иде. Тик әни дә каты тора, бармыйсың ди. Безнең әнигә киңәш сорап, хатын-кызлар гына түгел, ир-атлар да килә иде. Әни әйтсә, дөресен әйтә дип өйрәнгән инде без. Әти ничек кенә каршы торса да, бикләп, бәйләп куя алмый. Әни исә мине авылда калдырырлык көчле сүзләр таба алмагач, «саламга» ябышты:

– Кызым, мин бит әле сине күреп тә туя алганым юк. Шундый тиз үсеп җиттең. Мәктәп тә өй эше, мәктәп тә өй эше. Инде чыгып китәм дисең. Тагы бер ел гына яныбызда торсаң, әйбәт булыр иде. Лапас саласы бар. Печән, утын әзерләүләрдә дә кул арасына керәсең, китмә инде! – дип ялынды. Мине эш белән кызыктыра башлады.

– Әни! Син нәрсә? Киләсе елга кем белән укырга керермен? Безнең класслар икенче курста булачак, ә мин? Юк инде, китәм булгач китәм! – дидем.

– Барып җитүгә хат яз! Хәбәреңне башкача белдерә алмассың, – диде әни. – Хат язышырбыз...

Әтинең кибеткә йөри торган кирзовый сумкасы хәзер минеке булды. (Бездә кибеткә әти йөри иде, акча да аның кулында.) Аякта сигезенче классны бетергәндә алган, әни әйтмешли, «асты резин, өсте брезин» тапочкалар. Физкультура дәресләренә дә әйбәт булды ул. Колхозга эшкә барасы дигәч, кунычлы галушлар белән йон оек та салды әни кара сумкага. Өстә бишмәт. Ике кат күлмәк. Башка бернинди кием-салым юк.

Әни, тешен кысып булса да, ризалашты. Әти дә түзде. Авылдан мин генә булсам, гомердә дә җибәрәсе түгелләр иде инде. Ә без байтак! Кем әйтмешли, авылның абруйлы кешеләре – кибетче Садретдин белән бригадир Гомәр кызлары Зима белән Мәймүнә дә безнең белән кайталар, безнең белән китәләр. Алар янында без дә кеше рәтендә.

Шулай итеп, мин укырга китә алдым. Ләкин дүрт ел буена каникулларга, ялларга кайткан саен әти белән әни: «Бәлки җитәр инде ул укуларың,

кабат бармыйсыңмы әллә? Әнә, Мөршидә фермада аена кырык сум акча ала! Кырык сум! Синең стипендияне күргән юк бит безнең. Кая куеп бетерәсеңдер?» – дип аптыраталар иде. Бу 1962 ел.

Икенче курста безгә егерме сум түли башладылар. Бу инде акча иде. Ашарга да җитә, әйбер дә алган булам. Ярдәм бер тарафтан да юк! Чөнки минем стипендия акчасына өмет иткән өйдәгеләр мине иң бай кеше дип санныйлар иде!

...Ләкин аңа кадәр... Дүртенче курска җиткәнче, безгә байтак кына сынаулар узарга туры килде. Укырга керергә имтихан бирү берни түгел, менә фатирсыз яшәп, айлар буе укырга йөреп яшәп карагыз әле сез. Училище эшкә җибәргән колхозның бәрәңгесен алып бетереп, авылга әниләр янына кайтып килгәннән соң, җиде кызның икесе яшьләре җитүгә паспорт алдылар да, укуларын дәвам итмичә, болай яшәрлек хәлебез юк, эшкә керәбез дип, авылга кайттылар да киттеләр. Аларны училищеда стипендия дә тотып кала алмады. Кызлар ике генә ел эшләделәр, унсигезләре тулар-тулмас икесе дә кияүгә чыкты. Аларның тормышлары икенче юлдан китте. Очрашулар сирәгәйде. Шулай итеп, без бишәү калдык.

...Көз яңгырсыз булмый... Иртән укыйбыз. Кайтыр җир юк. Чөнки безгә тулай торак бирмәделәр. Бөтен әйберләребез, әни әйтмешли, «житияларыбыз» капчыкларда, минеке – әтинең кирзовый сумкасында. Дәресләрдән чыккач, яңгыр астында, күтәренеп, фатир эзләргә чыгабыз. Кем инде безне бер көтү авыл баласын октябрь аенда өенә кертсен, ди? Фатир бирәселәре инде кеше алган. Берничә көн парталар өстендә йокладык. Тулай торакка барабыз, коридорда утырабыз. Кайсысыдыр безгә «рязанские бабы» дип исем кушкан, бүлмәләргә кертәселәре килми, куып чыгаралар. Кайсыбер бүлмә кызлары мунчала матрасларын (аларның ике катлы, берсе мамыктан!) идәнгә җәеп, безне шунда йоклаталар. Бәдрәф урамда, юыныр урын юк... Ә без әлегә түзәбез...

Хәер, безнең беребезнең Алабугада әнисе ягыннан бертуган абыйсы бар иде. Беләсезме, ул кем? Алдарак ыштанын төшереп, тау башыннан авылга артын күрсәткән дип язган идем бит, әнә шул абзый иде ул. Алабуганың иң матур урынында, яшеллеккә баткан бер тыкрыкта аларның ике катлы, бакчалы өйләре бар иде. Ял көннәрендә Гөлфәния безне шул абыйларына кунакка алып бара. Кунак булу дигән нәрсә юк, әлбәттә. Без аларның өйләрен җыештырып, күгәреп беткән кашык-чәнечкеләрен комнар белән ышкып чистартып, бакча якларында эшләп, өстәлдә калган каткан ипиләрен ашап китә торган идек. Гөлфәниянең ул абыйсын бер генә тапкыр күрергә туры килде, ял көне эштә булмагандыр инде. Ул алагаем олы корсаклы иде, иреннәрендә елмаю булса да, безне сөзеп, маңгае белән караган карашы куркытты. Аны Ленинградта урман хуҗалыгы академиясен тәмамлап кайткан, олы урында эшләгән кеше буларак белеп калдык. Без анда сирәк бара идек. Бервакытны Гөлфәниягә:

– Кая югалдың син, килеп йөр, сарык! – дигәнен ишеткәч, бөтенләй бармас булдык. Без генә түгел, Гөлфәния дә бармады. Ул сеңлесенең кызына бер тиен белән ярдәм итмәде, үзләренә торырга да алмады.

...Түземлекнең соңгы көне булгандыр инде... Беркөнне шулай дәрестән соң безне завуч Газиз Сәләхетдинович үз янына чакырып алды. Аның

янында режиссёрлар группасы җитәкчесе Гәрәй Галимханович Әгъләмов утыра. Менә шул абый тулай торак бүлү комиссиясе рәисе икән!

Безнең бишебезне дә бер рәткә тезеп утырткач, Газиз Сәләхетдинович Әгъләмов абыйга:

– Менә, кара әле бу балаларга! Болар укырга килгән. Ике ай инде алар тулай торак бүлмәләренең идәнендә йоклап йөриләр икән. Бер көнне бер бүлмәдә, икенче көнне икенче бүлмәдә. Укытучылар әйтүенә караганда, әйбәт укыйлар, имтиханнарын стипендиягә биргәннәр. Әйбәт укыганнарны да тулай торак белән тәэмин итә алмагач, нигә кирәк без монда! Без авылларга барып эзләп йөрибез. Ә болар үзләре килгән! Кызлар матраслары белән бүлешеп, бер караватта икешәр кеше йоклый икән. Профком председателе Фәридә Шакирова кереп әйтте. Болар укырга килгән, укырга! Башкалар булса, күптән кайтып киткән булырлар иде. Тап боларга тулай торакта урын! – диде.

Шуннан соң безгә бүгенге көндә ремонт эшләнеп яткан 11 нче бүлмәдә урын булачак, анда 15 кеше торачаксыз диделәр. Сөенүен сөендек, әле ул ремонт беткәнче бер генә кич булса да, йокларга урын барыбер кирәк бит!

Беркөнне дәрестән соң, сумкаларыбызны күтәреп, шунда бүлмәгә киттек. Ул гомум коридорлы, агач барак кебек эшләнгән йортның икенче катында иде. Аңа каршы унынчы бүлмәдә инде торалар икән. Безгә булачак бүлмә бикле түгел. Стеналары акшарланган, идәннәр юылмаган, төрле якка, тәрәзәләргә буяу чәчрәгән, караватлар юк. Такта, буяу исе... Ләкин без шундый салкын бүлмәнең идәнендә дә йокларга әзер идек. Чөнки коры парталар өстендә дә бер генә тапкыр йокламадык бит инде! Каравылчы белеп алган, хәзер безне классларда калдырмый. Янгын чыгарырсыз диләр. Кичкә училищены биклиләр, безнең исә кереп сыеныр урын да юк.

10 нчы һәм 11 нче бүлмәләр өчен коридорның ике башына борынын кул белән күтәреп, су агыза торган юынгычлар куелган, астында юынтык су чиләге. Иртә белән чираттыр инде монда. Урамда кара көз, коридорда җылы. Оҗмах! 10 нчы бүлмәдә яшәүче кызлар кертерләр, идәндә булса да, кунып чыгарбыз дип уйладык. Аннан алдагы көннәрдә марҗа кызлары керттеләр бит әле. 10 нчы бүлмәдә училищеның китапханәчеләр әзерли торган бүлегендә укучы татар кызлары яши икән. Үзебезнекеләр! Беренче курслар түгел, икенче, өченче курсларда укыйлар. Менә сиңа мә! Безнең ишеләргә урын юк, муртаеп беткән икенче курслар тулай торакта рәхәтләнеп ята!

Без коридорның стенасына терәлеп, аякларны сузып, идәнгә утырдык та капчыкларыбыздан ипи, шикәр чыгарып тәмләп ашарга керештек. Шулвакыт унынчы бүлмәнең ишеге төбенә чаклы ачылып китте дә бер төркем матур-матур киенгән кызлар чыгып, безгә музейга кергән кебек карап тора башладылар. Ул вакытка инде безгә киемнәребез, кыяфәтләребез өчен «рязанские бабы» дигән кушамат тәмам береккән иде. Кызлар чыктылар да: «Бу «рязанские бабы»лар безгә дә килеп җиткән», – дип көләргә тотындылар. Шунда берсе нечкә тавыш белән:

– Кызлар! Монда утырырга ярамый, барыгыз чыгып китегез моннан! – дип, безне куалый ук башлады. – Мин – бу бүлмәнең старостасы, мин җаваплы кеше, әйберләр югалса, миңа җавап бирәсе! – диде ул.

– Нинди әйбер, без менә бу буш бүлмәдә булса да кунарга кергән идек, – дидек без. Югалса, юынгыч белән аның астындагы помой чиләге югалса

гына инде. Бу гомум коридорда башка берни дә юк иде.

Ләкин шул татар кызлары барыбер безне урамга куып чыгардылар. (Шуларның староста дигәне соңыннан танылган кеше булып китте. Аның тормышында да авыр чаклар булды. Мин ул вакытта Мәскәүдә яши идем. «Зыялылар Клубы»ның бик матур итеп эшләгән чагы иде. Аны Мәскәүгә чыгыш ясарга чакырдым. Аңар ярдәм итәрлек мөмкинлегем булды. Ул безне куып чыгарганнарын оныткандыр, бәлки мине дә оныткан дип уйлагандыр. Мин онытмадым, ләкин ярдәм иттем. Бик рәхмәтле булды. Миңа аның шунысы кадерле иде.)

Һаман оныта алмыйм шул вакытларны. Без, арыган, көне буе дәресләрдә утырган 15 яшьлек балалар, әйберләребезне өстерәп, тагы Алабуганың салкын урамына чыгып киттек. Шунда безне тулай торак ишегалдында бер рус кызы туктатып: «Как мне жалко вас...» – дип башлады. Без инде болай да елап барабыз, ә монысы ачу китереп!.. Каян көче, сүзе табылган диген, арабыздан беребез: «Себя жалей! Мы молодые, сильные, здоровые! У нас будет общежитие, только там ремонт!» – дип кырт кисте. Менә хәзер шуны уйлыйм: кайсыбыз әйтте икән? Мин түгел инде, чөнки андый ук батыр түгел идем. Әни әйткәннәр дә колакта: «Кеше йөзен ертып, авыр сүз әйтмә!» Ә кызлар батыр иде. Жәлләтәсе дә килми бит! Тагын икенче корпуста торган, безне бер тапкыр кундырып чыгарган, болай да 27 (!) кеше яшәгән бүлмәгә таба юл алдык. Безнең хәлне завучка сөйләгән Казан кызы Фәридә Шакирова да шул бүлмәдә тора иде. Бу юлы да киң итеп идәнгә урын түшәделәр, безне үзләренә алдылар, кумадылар.

Бу хәлләр 1962 елның көзендә булды. Иң кызыгы: ул елны Алабуганың барлык ашханәләрендә ипи бушка иде. Дүрт кеше утыра торган өстәлләрдә киселгән ак, кара ипиләр өелеп тора! Без ике тиенгә чәй, кайчагында манный боткасы алып ашап чыгабыз. Өстәл артына икешәрләп утырабыз. Кайчагында өстәлдә ипи беткән булса, батыраеп, ипи кисә торган бүлмәгә кереп, үзебез кисеп алабыз, ачуланмыйлар иде. Ләкин ул рәхәтлек озакка бармады. Педагогия институты ашханәсендә озаграк булды дип истә калган...

Икенче көнне бүлмәбезгә керергә рөхсәт бирделәр. Без дәресләрдә вакытта җыештырылган, караватлар кертелгән, тәрәзәләр юылган. Урын-җир бирә торган җиргә чакырып, аларын да бирделәр. Күп юудан соры төскә кергән иске җәймәләр, мендәр тышы, хәтта одеял да булды! Ярты елга өч сум илле тиен түлисе иде алар өчен. Шулай итеп, безнең дә рәхәт көннәр башланды! Рәхәтләнеп, тәмен белеп укыдык. Русча укытыла торган дәресләрдә безгә татарча сөйләргә дә рөхсәт иде. Физика, математика кебек дәресләрне татарча гына укыдык. Безгә хәтта татар теле һәм әдәбияты дәресләре дә керде, чөнки без бу училищедан 11 классны тәмамлаган булып чыгабыз. Ягъни безнең дипломдагы билгеләр белән теләсә нинди югары уку йортына да керергә була иде. Җылы, чиста караватларда йоклыйбыз, стипендия алабыз! Әнигә безнең интеккәннәребезнең берсен дә язмадым. Торыр урын булмаса да, адрес бар: хатлар училищега килә иде. Минем хат язар кешеләрем күп түгел – рус теле укытучысы Әнисә Касыймовна белән әни! (Укытучым белән гомер буе хат алыштык.) Әй, сагына идек авылны. Әниләрне генә түгел, урамны да, су буйларын да, урамдагы кешеләрне дә

сагына идем. Менә хәзер әнигә авыз тутырып, рәхәтләнеп, нинди матур тормышта яшәгәнебезне язарга була. Бер бүлмәдә 15 кыз яшибез! Бүлмәнең уртасында озын өстәл. Ике кешегә бер тумбочка, бүлмә уртасында түшәмдә бер Ильич лампочкасы эленеп тора. Минем урын мич артына туры килде. Җылы. Ләкин кичләрен кызлар киез итекләрен минем караватка кыстырып, мичкә терәтеп киптерергә куялар. Иртә белән бөтен бүлмә кызларының итеге минем өстә була! Бернәрсә эшләп булмый, Алабуга урамнарын гизгән киез итекләрне киптерергә кирәк бит! Икенче елны ул урынны Гөлсинә исемле кыз алды. Ләкин ул беребезгә дә итек киптерергә рөхсәт бирмәде, алып кына ата иде. Теләсә кайда киптер! Барысы да мин түгел шул дип уйлап куям хәзер. Әйе, бездә әле ул вакытта мич ягалар иде. Утынны бүлмәдә кизү торучы күтәреп алып кайта. Бер генә кочак бирәләр. Әле аны үзеңә ярырга кирәк. Без утын таныйбыз, шомарак, ботаксызларын табып, үзебез ярабыз. Мич коридор ягыннан ягыла. Җылысы бүлмәгә керә. Ләкин мичкә берни дә куеп пешереп булмый, ул җылы өчен генә иде. Безнең бүлмә иң кырыйда, почмак бүлмә булганга, бер кочак утын гына җитми, хәтта идәнгә түгелгән суның шакыраеп каткан чаклары да булгалады. Безгә утын таныган өчен хөрмәт йөзеннән күбрәк алырга рөхсәт итәләр иде.

Кичке 11 тулуга комендант Закир абый утны сүндерә. Унбер туларга унбиш минут кала утны бер сүндереп алып, хәбәр бирә. Без: «Закир абый күз кысты, йокларга!» – дип, тиз-тиз әзерләнә идек. Сәгать 11 гә чаклы дәресләреңне әзерләргә өлгермәсәң, шулай кала, берни эшләп булмый. Авылдагы кебек куыклы лампалар юк. Кеше барысына да ияләнә, монысына да ияләндек. Икенче корпуста титан эшли, иртәләрен анда су кайнаталар. Чәйгә яртышар чиләк кайнар су да бирәләр. Бүлмәгә кайтып җиткәнче, ул инде ярыйсы гына суынган була. Безнең калай кружкаларга салган грузин чәе бик пешеп тә җитми. Шул чәйгә ике шакмак шикәр салып эчәбез, булса, маргарин яккан бер телем кара ипи ашыйбыз да училищега йөгерәбез. Ашарга алар булса, син – бай! Кайчагында бер телем ипигә дә тилмерергә туры килде. Беренче курста әнә шулай авыр булды. Училище бинасы тулай торактан ерак кына, ләкин җәяү йөри торган юл иде. Башта дәресләр, аннары баян, фортепьяно, тавыш кую дәресләре. Шулай итеп, без көннәр буе училищеда! Буш фортепьянолы класс эзлибез, бирелгән дәресләрне өйрәнәбез. Аннары тулай торак корпусындагы бинада баян дәресләрен үзләштерәбез. Андагы баян тавышына колаклар тона иде. Адым саен баян белән утыралар! Һәркем үз дәресен өйрәнә. Шулай итеп, тулай торак белән училище арасында киләп сарабыз.

Бервакыт стипендия алгач, барыбыз да юл йөрергә бәләкәй генә кара чемоданнар алып җибәрдек. Әтинең кирзовый сумкасы үзенә кайтты. Шул чемоданны алгач, каникуллар якынлашканда, күчтәнәчләребезне тутырып, чемоданны тотып, торак ишегалларын әйләнеп керә идек. Сагына идек авылны! Бу хәлләргә алтмыш ел вакыт узган, һаман да онытылмый! Алабуганың «лаеш шулпасы»н без чүмечләп чөмердек инде!

Әлбәттә, мин әнигә хатларымда Алабуганың матур якларын гына, ипинең бушка булуын, укуны җиңел дип яза идем. Шулай булуга карамастан, шушы вакытларны, авылдагы авыр тормышны искә алыптыр, әнинең без укыган чакта түгел, 1983 елның сентябрь аенда язылган хатыннан бер өзек китерим

әле. Чөнки ул минем интегеп укыган көннәрем турында: «Кызым, бик сагынам сине, көне буе карточкаң белән сөйләшәм. Атаң да эчем поша ди. Кызым, мин сине кызганып сагынам. Тормышның иң авыр чакларында үстең. Читен чаклар күп очрады сиңа. Рәхәт тормышны өйдә күрә алмады дип кызганам. Сагынам. Олы бала булдың, бар авырлык сиңа туры килде. Хәзер картайдык, син дә ерак яшисең...»

(Бу хат язылганга инде 40 ел узганнан соң укып, күз яшьләремә манчылып утырам. Әни аны язганда, авылдан киткәнемә 21 ел. Шуның 14 елын Мәскәүдә яшим, татар кешесендә кияүдә, ике балабыз бар. Әнинең хыялы тормышка ашкан. Минем язмыш йомгагым да әкренләп сүтелә бара.)

Әйе, олы бала барысы өчен дә җаваплы. Өйдә миннән бәләкәй тагы бишәү калды бит әле. Арбаның алгы тәгәрмәче кайдан тәгәрәсә, арттагы тәгәрмәчләре дә аның артыннан тәгәри. Мин аларга үрнәк булырга тиеш.

Үрнәк була алганмындыр бәлки. Беренче курсны мин дүртле-бишле билгеләренә генә тәмамладым. Безгә ике айлык җәйге стипендия биреп кенә сөендермәделәр, хәтта авылга әти-әни исеменә «Кызыгыз тәртипле, әйбәт укый, башкаларга үрнәк» дигән сүзләр язылган хат та килгән! Анда мактау сүзләре күп иде, үзем дә укыдым. Хат балалар кулы тимәслек җиргә, хәстәрле – без үскәндәге сыек чыбык урынына матчага кыстырылган. Кем генә керсә дә, әти, мактанып, ул хатны аңа күрсәтә торган булган. Ләкин бу мактау хатлары гына семестр бетеп, ялга кайткан саен әтинең: «Җитәр инде! Ул укуыңның очы-кырые юк, ахры, бер военный налог булдың инде, кайчан эшли башлыйсың!» – дигән сүзләреннән арындырмады. Әти ул сүзләрне үзе биргән акчалары өчен түгел, мин аңар алып кайтмаган акчаларны санап әйтә торган иде. Җәйләрен, эшкә урнашып, акча эшлим, әйберләр ала идем. Икенче курста баедык: стипендия 20 сум булды. Кибеттән тукыма алып, күпереп тора торган модалы итәкләрне, кофталарны үзем тегә идем. Кулдан! Сирәк булса да, училище ашханәсендә ашыйбыз. Андагы бәяләр кыйммәт түгел дә кебек! Итсез ярты порция макаронлы аш – өч тиен. Котлетлар – 12 тиен. Винегрет – алты тиен. 20 тиенгә туйганчы ашарга була иде. Ләкин бер сәгатьтән, өзелеп, тагын тамак ача иде. Шундый заманалар килеп җитте, кая ул бушка ипи ашаган чаклар! Бер буханка кара ипигә сәгатьләр буе чират торабыз! Куба, Кариб кризисы, Хрущёвны эштән куарга торган сәяси киеренкелек ипи кибетенә дә кагылды. Чират урамнарга кадәр чыга иде. Әле ипие дә пешеп җитмәгән, кукуруз оны кушылган, тәмсез була торган иде. Ләкин ул ипи булса, без – бай кеше!

Икенче курс та тәмамланды. Өчле алганнарга стипендия юк. Нәкъ имтиханнарга әзерләнер вакытта Гөлфәнияне әниләре, бәрәңге утыртырга чакырып, авылдан җибәрми тордылар. Гөлфәния ике имтиханнан өчле алды. Димәк, аңар стипендия булмаячак! Аның Алабугадагы абыйсы турында әйткән идем. Шундый олы урында эшләгән абыйсы булгач, ул ярдәм итәр әле дип уйладык, Гөлфәния дә шулай уйлагандыр инде. Ләкин авылга артын күрсәтеп киткән абыйсы туганына карата алай ук катгый булмаса да, ярдәме дә тимәде. Безнең биш почмаклы йолдызның бер почмагы кителде, Гөлфәния училищедан китәргә мәҗбүр булды. Аның да абыйсы, апасы, әти-әнисе, шундый бай начальник абыйсы булуга карамастан, ярдәм итәр кешесе юк иде. Менә шундый замана! Ләкин ул

югалып калмады, пешерүчеләр әзерләүче техникумга укырга керде. Бер ел эчендә Алабуга ашханәләренең берсендә эшли башлады. «Кызлар, ниһаять, туйганчы ашыйм, бер кулым майда, икенчесе маргаринда!» – дип шатлана һәм безгә күчтәнәчләр алып килә торган иде. Соңыннан сәүдә техникумын тәмамлады. Алабуганың педагогика институты ашханәсендә шеф-повар, соңрак иң кәттә, үзәк ресторанында директор булып та эшләде. Ул үз эшеннән бик канәгать иде.

Безнең дә дүрт елга сузылган ачлы-туклы, авыр, ләкин бик бәхетле студент еллары узып китте. Алабугага укырга дип ашкынып килгән сигез кыздан диплом алу бәхете дүртебезгә генә тәтеде...

Каенанамның: «Яшьли өйдән чыгып киткәнсең, тулай торакларда яшәгәнсең, эш рәтенә кайда өйрәндең?» – дигән соравына җавабым бик озын булып чыкты бит әле...

«Әй нужа, нужа, нужа, ди,
Нужа килсә, килсен яшьли,
Яшьлек белән тиз уза, ди...»

Без яшьлек белән уздырып җибәрдек ул нужаларны. Мин менә шушы елларда бөтен гомеремә җитәрлек сабырлык, түземлекне туплаганмындыр, ахры... Нужалары кабат кайтмаса да, соңгылары бик кирәк булды тормышта...

## Минзәлә

1966 ел безнең чыгарылыш өчен бәхетле булды. Чөнки ул елны Татарстандагы һәрбер районның Мәдәният йортына «методист» дигән штат берәмлеге өстәделәр. Шулай итеп, без авыл клубларында түгел, район үзәкләрендә эшләргә тиеш идек. Бүгенгедәй хәтеремдә, практикага бару урыны соңыннан эш урыны да булачак. Эш урыннарын билгелисе комиссия директор кабинетында утырды. Өч кызны, алар арасында мин дә бар идем, беренчеләрдән булып директор бүлмәсенә чакырдылар. Комиссия составында Мәдәният министрлыгыннан килгән Асия ханым Һадиева да бар иде. Стенага Татарстан картасы эленгән. Сайла, юллар ачык, җаның кая теләсә, шунда бар! Мин тарихтан бик әйбәт укый идем. Ә инде тарих укытучысы – училище директоры, эш урыннарын билгеләүче Габдрахман Насыйбуллин! Кабинетка кереп, әле Татарстан картасына күз салганчы ук, ул миңа болай диде:

– Мин сезгә Минзәләне тәкъдим итәр идем. Беренчедән анда беренче категорияле мәдәният йорты, димәк, эш хакыгыз югары булачак, икенчедән, ул безнең база, без анда ел да практикага студентлар җибәрәбез. Өченчесе – үзебезнең яхшы укучыларыбыз белән базабызны ныгытырга кирәк дип уйлыйм, – диде ул, Мәдәният министрлыгыннан килгән ханымга карап. Аннан соң миңа борылды да: – Яшьләр шәһәре, анда училищелар да күп. Иң мөһиме: анда данлыклы Минзәлә театры бар! – диде.

Шулай дип торганда, бәхәсләшәмме соң инде! Ул бит миңа яхшылык тели. Бер дә икеләнмичә, юлламаны Минзәләгә алдым. Һәм бер тапкыр да үкенмәдем.

Минзәлә Мәскәүгә укырга барыр өчен миңа бер старт та булды. Мин анда тәҗрибә тупладым, талантлы кешеләр белән очраштым. Минзәлә театры артистлары, педагогика училищесы укытучылары белән аралаштым. Җәйләрен агитбригадалар белән йөрү, республика күләмендә фестивальләр оештырып, Казанда чыгышлар ясау мине профессиональ яктан үстерде. Минзәләдә концертлар алып барырга да, хәтта биергә дә өйрәндем. Танылган хореограф Әхмәт Кәлимуллин, Минзәләгә килеп, безнең Мәдәният йортында биюләр, хәтта сюиталар куйды. Ул биюләргә данлыклы композитор Заһид Хәбибуллин көйләр язды. Без шундый даһилар белән эшләдек. Минзәлә гөрли иде ул заманда! Казанда республика күләмендәге фестивальдә беренче урынны алгач, безнең 50 кешелек бию ансамбле Казанның опера һәм балет театры бинасында чыгыш ясаган иде. Ул ансамбльдә мин дә биегән идем!

Мәскәүгә укырга юллама биргән конкурста җиңеп чыгуым белән мин Минзәлә театрының баш режиссёры Сабир абый Өметбаевка, Минзәлә театрына спектакль куярга килгән Хәким абый Сәлимҗанов, бик кирәкле киңәшләр биргән Равил Шәрәфиев һәм Вера апа Минкинага рәхмәтле. Сәхнә монологларын миңа алар куйган иде.

## Хатлар

Тормышымда хатлар бик зур роль уйнагандыр дип уйлыйм хәзер. Әни хатлары, укытучым хатлары, соңыннан инде каенатай белән каенанай хатлары. Мин ул хатларны беркайчан да ташламадым. Чөнки алар минем өчен изге язмалар иде. Ташласам, гөнаһысыннан курыктым. Алар һәрвакыт янымда булды. Алабуга, Минзәлә, Мәскәү, авыл! Аның өстенә берничә тапкыр күченү, ләкин хатларның берсе дә югалмады... Бигрәк тә әни хатлары...

...Ә менә хәзер, туган авылымны калдырып киткәнгә ярты гасырдан артык вакыт узгач, туган төбәгемә яңадан кайттым. Гомер буе күпме юллар үтеп югалмаган, саклап җыелган әнием хатлары белән тулган чемодан да минем белән авылга кайтты. Мин әле берничә ел аларга кагылмадым. Истәлекләргә кагыласы көннәр килеп җиткәч, ачылды ул чемодан! Мине әниемнең хат өермәләре яңадан күтәреп алдылар да балачагыма, студент вакытларыма, тормыш башлаган көннәремә алып киттеләр. Ярты гасырдан артык дәвердә әнинең хатларда тамчылап җыелган моңнары, зарлары, ярату-сагынулары ташкынлы бер дәрья булып, баштанаяк күмеп китте. Мин, бүгенге көн хасиятеннән аерылып, башка бер дөньяга чумдым. Әни дөньясына, аның карашы чагылып калган тарихка кереп югалдым. Әни хатлары сакланган, ничә еллар ачып та карамаган чемоданны ачтым! Никадәр авыр буласын белсәм, бәлки ачмас та идем. Әнинең бөтен дөньям булганын әле хәзер генә аңлап утырган мәлем... Әйтерсең ул хатларны бер тапкыр да укымаганмын, әйтерсең аларны беренче тапкыр гына күрәм! Шул дөньям кечкенә бер чемоданга сыйган икән. Анда 1962 елдан башлап 2001 елга кадәр язылган авыл хәбәрләре, гаилә, туганнар, һава торышы, күршеләр, халыкара хәлләр тарихы да! Чөнки ул чемоданда шигъри күңелле, яшь ярымнан ятимлекне татыган, сугышның авыр елларын үз җилкәсендә күтәргән, 8 бала табып,

икесен җирләгән, алты бала үстереп, өч малаен армиягә озатып каршы алган, кызларын өч якка очырган әнием хатлары.

Яшәргә, кеше таныргa, ялгышмаска, ялгышсаң – еламаска, начарларны күреп, яхшы булырга, ялганчыларны танып, алдашмаска, ялкауларга карап, эшчән булырга мин үзлегемнән өйрәндем. Янымда акыл бирүче, өйрәтеп торучылар юк, ялгышларымны күреп битәрләүчеләр дә, яхшы эшләремә сөенеп мактаучылар да миннән ерак. Бары тик сагынуларга дәва булырлык әни хатларында гына боларның барысын да табарга була иде. Алар өзелми килеп тордылар. Мин аның хатларын беркайчан да ташламадым, шул хатлары белән әни һәрвакыт янәшәмдә булды.

## Әткәй дәресләре

Хатлар турында сүз киткәч, яшәү дәверемдә ул хатларны, әйткәнемчә, әнидән генә түгел, каенатамнан да, башкалардан да алганым булды. Безнең заман хатлар заманы иде бит. Менә хәзер шушы урында каенатам хатлары турында да сөйлисем килә. Ул мине хат язарга гына түгел, туган телемә хөрмәт күрсәтергә, телләрне бутамаска да өйрәтте. Ул хатның тарихы болай булды...

Бер елны, 1982 еллар тирәсе дип уйлыйм, җәй айлары иде, әткәй белән әнкәй безне балалар белән бергә Мәскәүдән Уфага чакырдылар. Әткәй болай диде:

– Без әнкәгез белән Пицундага язучыларның иҗат йортына барырга планлаштырабыз, юлламалар кулда. Айгөл белән Тимербулатны да алабыз. Ә менә сез – Нияз, Илгиз, Нәзифә – дачаны сакларга каласыз, – диде.

Әнкәй:

– Без кайтканчы, кыярлар өлгерер, өлгерә барганын тозлый торырсың, – дип, үзенең киңәшләрен дә бирде. – Җиләктән кайнатма ясарсың, әрәм булмасыннар.

Әткәй яшелчә-җимеш утыртма, базардан күпме кирәк алып кайтам дисә дә, әнкәй ел саен утыртмый калмый. Аның кыярлары да, помидорлары да бик уңа иде. Тозлау ысулы да үзенеке. Чолан 3 литрлы банкалар белән тулы. Шулай итеп, мин көннәр буе кыяр тозлыйм, җиләк эшкәртәм, кайнатма ясыйм. Банкаларны базга төшерәбез, берзаман баз да тулды!

Диңгез буеннан кайткач, әнкәй әйтә:

– Нигә шулхәтле күп тозладың, кая куябыз боларны? Үзегез белән Мәскәүгә алып китәрсез инде! – ди.

– Юк инде, – мин әйтәм, – быелга күрәсем дә килми, теләсә нишләтегез! Маемладым бу кыярдан, – дидем.

Бу сәяхәтне балалар да бик яхшы хәтерли икән. Кызым Айгөл сөйләгән иде:

– Пицундага киткәнче, без байтак кына дачада яшәдек. Без, бала-чага, икенче катта йоклый идек. Кемдер китапханәдә, кемдер картатайның кабинетында. Шунысы бик истә калган: көн саен иртән, икенче каттан төшә торган баскыч араталарында, юып, яфраклары белән аратага бәйләп куелган кишерләр безне көтә иде. Аны картатай көн саен безгә дип әзерләп куя иде. Без иртән иртүк, әле иртәнге ашка кадәр, кишер кетердәтә идек. Шундый күңелле булып истә калган ул җәй!

...Алар ялга киттеләр. Дачада телефон юк. Ул вакытта хатлар язышa идек. Алардан исән-имин барып җитүләре, матур яллары турында хат килүгә, мин дә җавап яздым. Инде кыярларны тозлый башлавымны да әйттем. Гомумән алганда, әнкәйнең үз хатлары кебек, мин дә хисап тоттым. Үземне тәрбиясез нәрсә димме, уйламыйча-нитмичә, хатларыма нәрсә телгә керә, шулай язганмын. «Кыярларны посолила... Вареньеларны да кайнаттым... Әле Уфага съездили...» Бәлки алай ук та булмагандыр инде... Ләкин Пицундадан килгән җавап хатында әткәй биргән кирәкне! «Нәрсә син телләрне бутыйсың?! Бу нинди әдәпсезлек! Үзен зыялы дип санаганның эшеме бу?» Әткәйнең бик үткәреп биргән тагы бер дәресе иде ул. Шуннан бирле минем беркайчан да телләрне бутаганым юк. Сөйләгәндә, башка милләт сүзләрен кушмыйча сөйләргә, язганда да, бары тик үз телебездә генә язарга тырышам. Телемне контрольдә тотам.

Әле кәгазьләрем арасыннан әткәйне 80 яшьлеге белән котлап язган хатым килеп чыкты. Хат та түгел инде ул, котлау открыткасына язасы сүзләр. Кызганычка каршы, ул елны аның юбилеенда була алмадым, Прагада командировкада идем. Ике айга эшкә чакырып алдылар, мин чарасыз идем, гафу үтендем. Прагадан котлау хаты:

«Хөрмәтле Әткәй! Туган көнең, юбилееӊ белән чын күңелдән котлыйм! Алга таба да бәхет дип аталган тойгы Сезнең күңелдә еш кунак булсын. Җан тынычлыгы, сәламәтлек телим.

Әткәй! 80 яшьлек дигән открытка таба алмадым, аннан соң күрсәм дә. Мин инде Сезне иң элек 10 яшьлек Кендек буларак котлыйм. Калган 70 яшь шуңа гына кушылып киткән бит барыбер. Минем шаяртуны аңлатып тормасам да, аңларсыз дип уйлыйм. Барыгызны да кочаклыйм, барыгызны да котлыйм! Прагадан киленегез Нәзифә».

(Хаттагы Кендек – «Озын-озак балачак» китабындагы төп геройның кушаматы.)

Прагадан кайткач, бүләк, күчтәнәчләремне алып, Уфага киттем. Әнкәй әле исән, ләкин саулыгы чамалы, бик каты авырый иде. Креслода гына йөртәләр үзен. Аңа мин кайтасын әйткәннәр. Ул көне буе, мин кайтып кергәнче минем исемне кабатлап утырган.

– Нәзифә кайттымы әле? Нәзифә кайчан кайта инде? – дип, минут саен сораган.

Мин кайткач, аның сөенүләрен күрсәгез иде. Бала кебек. Гел миңа карап елмая, кырыннан җибәрми, аркамнан сөеп утырды. Бу аның минем белән саубуллашып, үзе турында якты истәлек калдыруы булдымы? Төрле чаклар булгандыр дип, бәхиллегемне алуы булдымы? Хәзер инде боларның барысын да искә төшерәм дә йөрәкләрем чеметеп куя. Нигә ешрак кайтмадым икән дип, үземне ачуланам. Ул көнне күз алдыма китерәм... Әткәйгә 80 яшь... Алар инде бик үзгәргәннәр... Әткәйнең дә җанын борчыган, дәва табылмаслык ил кайгысы иңнәренә басылганы сизелә. Әнкәйнең авыруы... Әткәйнең йөзендә чарасызлык... Ә мин аңа элеккечә шаяртулы котлау язам, акылсыз да инде үзем... Әлбәттә, бу хатта бер генә чит сүз дә юк. Барысы да үзебезчә, татарча. Тик аның шушы халәтендә кирәк булдымы икән мондый сүзләр? Әткәй бу котлау хакында миңа ни яхшыдан, ни яманнан бер сүз дә әйтмәде. Ул чын зыялы кеше иде шул. Мин генә бигрәк бернәрсә дә аңламаганмын инде.

Мин аларны байтактан күргәнем юк иде ул вакытта. Бу кайту әнкәй белән бәхилләшү иде. Әнкәйне соңгы юлга озатырга без барыбыз да Уфага кайттык.

«Килен кайнә туфрагыннан». Миндә дә әнкәйдә булган чалымнарны күрәләр иде. Илгиз пәрәмәчең әнкәйнеке кебек тәмле булган дип әйтсә, бу инде – иң югары бәя! Әнкәй ризыклары – эталон! Бервакыт Илгизнең туганнан-туган энесе Марат минем катгый итеп әйткән сүзләремне тыңлап: «Рауза абыстакай тавышы ишетелеп китте!» – дип көлдергән иде. Кая инде миңа! Әткәйнең әнкәй турында: «Әгәр дә әнкәгезгә Европа белән Азия киселешендә бер бәләкәй генә дәүләт бирсәләр, менә ул җитәкчелек итә белүен күрсәтер иде, илне гөл итәр иде!» – дигәне бар.

Сүз каенанам турында киткәч, әткәйнең бер кызыклы итеп сөйләгән истәлеген шушы урынга куясым килде.

Әткәй бер кичне соң гына бер төркем салмыш язучыларны ияртеп кайта. «Бәйрәмне» өйдә дәвам итмәкче булалар. Мыштым гына чишенеп, кухняга узарга торганда, әнкәй чыга да: «Бүгенгә булган, барыгыз өйләрегезгә, хатыннарыгыз югалткандыр!» – ди ачулы тавыш белән.

Шунда бер язучы, Игебай дигән иде шикелле, элгечтән пәлтәсен ала да: «Ну, Мостай, усал да инде безнең хатыннар!» – дип, барысын да ияртеп чыгып китә. Әткәй шунда: «Синең хатын дип әйтергә теле бармады, безнең хатыннар диде. Раузаны бик хөрмәт итәләр иде шул», – дигән иде.

Инде үземнән өстим. Хатынны ире хөрмәт итсә, башкалар да хөрмәт итә! Ир какканны ил кага.

Мин әткәй белән әнкәйгә гомер буе «сез» дип эндәштем. Әткәй бервакытны бу турыда сүз дә кузгаткан иде.

– Без – бер гаилә, әткәй-әнкәй дисең, «син» дип әйт безгә. Үзеңә дә кыендыр «сез» дип әйтүе, – дигән иде. Ләкин әнкәй бу сүзләрне ишеткәннән соң:

– Әйтсен, миңа ошый Нәзифәнең безгә «сез» дип дәшүе, нишләп кыен булсын инде аңар, – диде.

Әткәй кабат сүз кузгатмады, мин аларга «сез» дидем. Чөнки хөрмәтем зур иде. Белмим, әнкәйнең бу сүзгә нинди мәгънә саласы килгәндер, ләкин мин үземчә эшләдем.

## Тагы хатлар...

Әнинең беренче хатлары миңа Алабугада укыганда килә башлады. Аңа ул вакытта 39 яшь булган! Яхшылыкларга үзлегемнән өйрәндем дисәм дә, хәзер әни хатлары өйрәткән дип уйлыйм. Ул вакыттагы сагынуларны берни белән дә үлчәп, аңлатып булмый торгандыр. Әни хатлары коткаргандыр инде.

Әни хатларының үз стиле, үз кагыйдәсе бар иде. Кыз чагымда язылган хатлар болай башлана иде: «Сагынычлы хат башы! Сезки безнең өчен бик тә кадерле булган кызыбыз Нәзифәгә синең өчен дә кадерле булган әтиең белән әниеңнән бик сагынып, бик күп кайнар сәламнәр җибәреп калабыз». Тормышка чыкканнан соң, беренче урынга кияү чыкты. «Сезки безнең өчен бик тә кадерле булган олы киявебез Илгизгә...» Тора-бара еллар үтү белән балалар тезелде. Сәламнәр аның белән генә бетми, әлбәттә, вакытына карап, өйдә кемнәр бар, барысыннан да аерым сәлам. Чөнки әнинең хатлары килеп

торган күп еллар арасында, малайлар, кызлар үсеп җитеп, алар да туган өйдән чыгып киттеләр. Сәламнәрдән соң дәвам итеп: «Сәлам соңында хәл белмәк теләсәгез, һәрбарчабыз исән-сау, сәламәт, сезләрне дә сәламәттер дип белеп калабыз. Кызым, синең язып салган хатыңны алып укыдык, бик зур рәхмәт, хатыңны укыгач, үзеңне күреп сөйләшкәндәй булдык».

...Әни бер хатында болай дип язган: «Әле Уфа кодалардан посылка килде. Без кодачаның улы Тимербулатка киез итек бастырып, йон носкилар белән бәләкәй генә посылка салган идек. Алар безгә зурлап посылка җибәргәннәр. Кеше арасында бик күңелле булды. Рәхмәт инде. Мәшәкатьләнмәсәләр дә, ярар иде. Мин балага гына җибәргән идем бит. Кызым, үзебез исән-сау әле. Атаң да әйбәт кенә йөри. Теге син җибәргән түбәтәй кыйбатмы ул, кызым? Күрше Сәлиха апа акча салыр идем, миңа да алсын әле, ди. Сау бул, кызым». Минем әни кайчагында хатларны шулай кисәк кенә дә тәмамлап куя торган иде.

## Вакыт кадере

Әткәй мине күп нәрсәләргә өйрәтте дип әйткән идем. Ул, әлбәттә, болай эшләгез, тегеләй эшләгез дип өйрәтеп утырмады. Ләкин тормыштан дәрес алырлык, аны кулланырлык, хакыйкатьнең шул булуына ышанырлык мисаллары күп. Башлангычымда әни, аның хатлары өйрәтсә, олы тормышта безнең яныбызда күбрәк әткәй, ягъни каенатай булды.

Теге яки бу җыелышка дип Мәскәүгә килгәндә, әткәй безнең белән очрашуларны файдалы һәм күңелле итеп оештыра белә иде. Шуларның берсе – безне ресторанга чакыра торган иде. Ул иртәнге аш та, көндезгесе дә булырга мөмкин, безгә бик ошый иде андый очрашулар. Әткәй күбрәк «Москва» кунакханәсендә туктый дип әйткән идем. Бервакыт ул безне иртәнге ашка чакырды. Вакытын да билгеләде:

– Мин сезне кунакханәнең өченче катындагы ресторанга иртәнге ашка чакырам, – диде ул. Ял көне иде. Без инде өйләнешкән, бала юк иде әле. Соң чыктыкмы, белмим, ниндидер сәбәп белән без соңга калдык. Әткәй безне кунакханәдә сәгатенә карап каршы алды.

– Җиде минутка соңгы калдыгыз! Минем җиде минут вакытымны әрәм иттегез, – диде ул.

Юк, мин ул вакытта «харап икән, җиде минут!» дип уйламадым. Мин ул вакытта әткәй янына барганда, очрашканда бер генә минутка да соңга калырга ярамаганлыкны аңладым. Шул вакыттан бирле мин әткәй белән очрашуга гына түгел, гомер буена, беркайчан да, беркая да соңга калганым юк. Алданрак чыгам, алданрак киләм. Бу минем каенатамның гомер буена җитәрлек итеп биргән тагы бер сабагы иде.

## Академиклар белән очрашу

Туксанынчы еллар башы. Әткәй Переделкинода. Әле кесә телефоннары юк чак. Ул торган номерда да телефон юк. Бары тик директор кабинеты белән дежурныйда гына бар. Автомат телефон да булгандыр дип уйлыйм. Белгәнемчә, анда һәрвакыт чират иде. Әткәй, безгә ике көннең берендә шалтыратып, хәлләребезне белә, үз хәлен дә сөйли. Ул соңгы елларда иҗат

йортына Муса Гали белән килә, аннан да һәрвакыт сәлам әйтә иде. Шулай итеп, безнең аңар шалтыратырга мөмкинлек юк, ул үзе шалтыратса гына, сөйләшә алабыз. Бик ашыгыч булганда, дежурныйга шалтыратып, үзе шалтыратсын әле дигән үтенеч калдыра торган мөмкинлек бар тагын...

Менә хәзер сөйлисе вакыйга турында каенатай үзенең «Көндәлекләр»ендә дә язган иде. Ләкин ул вакыйга турында минем үземдә дә бик тәфсилле мәгълүматлар бар.

Әйткәнемчә, әткәй белән элемтә бер яклы гына иде. Бервакытны безгә профессор Рәшит Сүнәев шалтырата. Мостай абыйны табарга иде, ди. Рәшит Сүнәев белән без академик Роберт Нигъмәтулиннарда танышкан идек. Тыгыз аралашмасак та, чараларда очрашканда исәнләшеп сөйләшә идек. Аның тормыш иптәше Гүзәл белән дә танышбыз. Инде бер-ике адым бу темадан алга китеп, шуны да өстисем килә: Германиягә күченеп киткәнче, Рәшит Сүнәев белән Гүзәл ханым безнең «Зыялылар Клубы»ның очрашуларын калдырмыйлар иде. Татар теленә зур хөрмәт белән караган, сөйләшкән, балаларын милли традициядә тәрбияләгән, татар булуы белән горурланган зыялыларыбыз алар.

Мин аңар каенатамның Переделкинода икәнлеген, әле анда байтак кына булачагын әйттем.

Рәшит Сүнәев миңа ул вакытта Роальд Зиннур улының өйләнергә ниятләве, Америка илчелегендә туе булачак дигән хәбәрне әйтте. Туйга чакыру турында әле сүз булмады. Ул Сәгъдиевнең һәм тагы берничә галимнең – ике академик, бер профессорның Мостай Кәрим белән очрашасылары килә иде, шуны ничек оештырырга икән дип сорады.

Белмим, әткәй үзе шалтыраттымы икән, әллә дежур телефоны аша хәбәр иттеме, хәтерләмим. Әткәй үзен аларга караганда да мәшгуль кеше дип санагандыр дип уйлыйм. Чөнки теге як Мостай Кәримнең очрашуны кайсы көнгә билгеләвен көтте. Әткәй көнен әйтте. «Фәлән көнне, фәлән сәгатькә килсеннәр, Рәшит Сүнәевка әйт, мин аларны шул көнне, шул вакытта көтәчәкмен», – диде.

Мостай Кәрим кунак чакырса, аның өстәле муллыктан сыгылып торырга тиеш. Ул, шундый очраклар булу ихтималын истә тотып, бу юлы да Уфадан ат итләре, казылыклар алып килгән булган. Кухняга биреп пешертеп, калганын хәстәрләп, әткәй боларны көтә башлаган. Биш минутка соңга калучыларны өнәмәгән кеше икәнен без беләбез дә аның... Ә кунаклар биш минутка гына соңарып калмаган, ул көнне, гомумән, килмәгән! Әткәйнең ни дәрәҗәдә ачулануын күз алдына китереп була. Башта ул миңа шалтыратып, бик каты итеп, мине сүкте, аннары тегеләргә дә эләкте: «Эзләре дә булмасын! Күпме вакытым әрәм булды! Әйт үзләренә, килеп тә йөрмәсеннәр! Мин аларны кабул итмәячәкмен!» – диде. Мин моны Рәшиткә җиткердем. Ул миңа: «Ничек инде шундый данлыклы академикларны кабул итмәсен?» – дип ышанмады. Мин Рәшиткә Мостай Кәримнең бернәрсәне дә онытмый, вәгъдәсен үти торган кеше булуын әйттем. «Үгетләмим дә, риза булмаячак», – дидем. Әлбәттә, әткәй бу хәлне санга сукмау дип кабул иткән. Әткәй игътибарсызлыкка, алай гына да түгел, илтифатсызлыкка үпкәли, тиз генә үткәреп җибәрә торган кеше түгел иде.

Рәшит шунда әллә чынлап, әллә шаяртып:

– Мерседеска утырып, фикерләшер өчен янына өч академик бара, ничек инде кабул итмәсен?! – диде.

Шулай итеп, болар берничә көннән чынлап та Мерседесларга утырып, хәбәр итми-нитми, Переделкинога килеп төшкәннәр. Әлбәттә, никадәр ачуы килсә дә, эткәй ул олы галимнәрне, академикларны хөрмәт иткән. Ачуы да озакка бармагандыр. Барлык ваклыкларын белмим, шунысы гына мәгълүм: күрәсең, язучының йөрәген эретә алганнар, Мостай Кәрим аларны кабул иткән, очрашканнар. Янә табын әзерләнгән, сыйлар куелган. Роальд Сәгъдиев үзенең Эйзенхауэр оныгы Сьюзенга өйләнергә ниятләвен, аны АКШ илчелегендә үткәреләчәк туйга чакыруын да әйткән. Әлбәттә, монда сөйләшергә, киңәшергә дип уйланган мәсьәлә икенче, хәтта сәяси мәсьәлә булган.

Туй икән туй! Рәшит Сүнәев миннән Равил хәзрәт Гайнетдиннең дә телефонын сорап алды. Аның сөйләвенчә, туйга протестант дин әһелләре ягыннан вәкилләр, хәтта православие чиркәвенең хор капелласы да чакырылган икән. Чөнки Сьюзен Эйзенхауэр – протестант динен тотучы. «Сәгъдиев татар кешесе бит, нигә әле мөселманнар ягыннан да вәкилләр булмаска тиеш дип уйладык», – диде Рәшит. Шулай итеп, алар Зөһрә абыстай белән Равил хәзрәт Гайнетдинне дә туйга чакырганнар. Мостай Кәримгә дигән чакыруны Рәшит Сүнәев миңа тапшырды. Каенатай аны безгә кереп алырга тиеш иде. Шулай сөйләштек. Ләкин эткәй, безгә кереп тормыйча гына, турыдан-туры илчелеккә киткән. Җитмәсә, паспортын да алмаган. Чөнки ул документлардан депутат таныклыгы белән генә йөри иде. Илчелекнең ишек төбе сакчылары, беренче чиратта, туйга чакыруны, икенче чиратта, паспортны таләп иткәннәр. Эткәйдә аларның берсе дә юк! (Туйга барсаң, туеп бар, тукмагыңны куеп бар. Ләкин илчелеккә барганда, документларны алып бар!) Ул инде борылып китәргә торганда гына, Равил хәзрәт Гайнетдин килеп кермәсенме! Эткәйнең китәргә җыенуын күреп, хәзрәт аптырап киткән. «Чакыру билеты өйдә калган», – дигән ул. Хәзрәт: «Минем чакыру ике кешелек, мин үзем генә, Зөһрә килә алмады», – дигән. Шулай итеп, хәзрәтнең ике урынлык чакыруы булгач, боларны үткәргәннәр. Илчелек сакчылары өчен иң мөһиме – билет! Документ та, кем булуың да мөһим түгел. Бер кинода төрмә сакчыларының «Ключ!» дип кычкырганнары искә төште. Монда да «Чакыру!» Ике персонага язылган, димәк, ике кеше үтә ала. Соңыннан бу турыда эткәй: «Сәгъдиевның туенда мин абыстай булып йөрдем», – дип көлдергән иде. Ни өчен билетсыз булган соң ул? Ни өчендер, аның туйга барасы килмәгән. Чөнки ул вакытта аның күңеле бик төшенке иде. Илдә глобаль үзгәрешләр бара, аның – Мостай Кәримнең дөньясы җимерелә, ә монда туй! Муса Галинең бик каты үгетләве, Сәгъдиевның кат-кат шалтыратуы сәбәп булгандыр инде. (Алар ул вакытта минем аша түгел, турыдан-туры Язучылар йортының директорына шалтыратып сөйләшкәннәр.) Ә инде туй турында эткәй хәтта истәлекләрендә дә язган.

Туй турында каенатай сүзләре белән болай дип өстәргә була: «Килен буласы ханым озын буйлы, бабасына охшаган. Бик ачык, мөлаем. Туй барышында минем белән 2-3 тапкыр сөйләшеп алды. Сәгъдиев куанычын яшерми. Ул инде өйләнгән кеше булган. Аерылган. Беренче хатыны ниндидер

академик кызы булган. Аның хәтта җитлеккән ике улы, бер оныгы да бар икән. Сьюзенның да өч баласы бар икән. Ул бирегә әтисе һәм кечкенә кызы белән килгәнен белдем. Мин Сәгъдиевтан әле Переделкинода өйләнү турында сүз чыккач: «Яратыпмы соң?» – дип сорадым. Ул: «Әйе, бары тик шулай!» – дип җавап биргән иде. Кунаклар 120-140 кеше тирәсе. Барысы да танылган кешеләр, галимнәр, депутатлар. Алар арасында шагыйрь Евгений Евтушенко да бар иде».

Бу вакыйга турында хатирәсен үзенең көндәлекләрендә Мостай Кәрим болай дип тәмамлый: «Гәҗәеп нәрсәләр булып ята бу тилергән дөньяда. Кан түгәләр, якыннарын таптыйлар. Пастернак хөрмәтенә дип, Переделкино чиркәвендә дини мәрәсимнәр башкаралар, башка сыймаслык, шаккатыргыч туйлар уздыралар... Туй озак барган диделәр. Мин ахыргача калмадым. Туйда Рәшит Сүнәев, аның хатыны Гүзәл, Сәгъдиевның туганнары Ренат белән Руслан мине үзләренең игътибарында тоттылар».

Галимнәр Мостай Кәрим белән нәрсә турында киңәшергә теләгәннәр соң? 90 еллар башы, февраль. Милли хәрәкәтнең көч алган вакыты. Татар-башкорт шаулый. Бу турыда Үзәккә дә мәгълүм. Милли оешмалар, партияләр төзелә, Милли-мәдәни мохтарият проектлары тикшерелә. Мәскәү дә шаулый.

Бик эчкә кереп кайнамасалар да, фәнни яктан күп мәсьәләләрне чишкән, галәмне тикшерү эшләрендә зур уңышларга ирешкән бу галимнәр дә тиз генә милли мәсьәләне чишеп атмакчы булганнар. Дөньякүләм танылган галимнәр, академиклар бит! Әткәй белән бу очрашу шул хакта киңәшләшү өчен була. Әткәй ул очрашулар турында көндәлекләрендә болай дип яза: «Әйткәнемчә, Муса бүлмәсендә (Муса Гали) баллап чәй эчтек. Балны кашыклап ефырдылар, чәкчәк тә бар иде. Мәйне дә ихлас күтәрделәр. Сәгъдиев сәясәткә кереп, татар-башкорт мәсьәләсенә кагылды, шул эш белән кызыксынуын әйтте, минем фикерне сорашты». Әткәй бу сөйләшүләр хакында артык язмаган дияргә була. Очрашудан соң ул миңа галимнәрнең нинди мәсьәлә белән килгәннәрен сөйләде. Алар ике республиканы кушып, уртак башкала ясасак, татар белән башкорт арасы җайлашыр иде дигәннәр. («Как далеки были они от народа!» Биредә бу тарихи сүзләр үзеннән-үзе искә төшә.) Шул ук вакытта милли мәсьәләләрдән дә еракта булуларын аңлата. Ә инде Мостай Кәрим аларга: «Куегыз моны. Сезнең эшегез – фән. Үз эшегезне бик яхшы башкарасыз. Шулай гына дәвам итегез», – дигән.

## Кош теледәй бер хат

...Әнинең тагы бер хатын кулыма алам.

Минем әни Мәскәүгә күп тапкырлар килде. Гомумән, ерак юл дип тормый иде. Әни Башкортстанда яшәүче энем Миннулла янына барырга җыенганнары турында яза: «Кызым, бу хатны Мамадыштан язам. Мин Әлфияләрдә (сеңлем) утырам әле. Ике кич кундым инде. Миннуллаларга бармакчы идек. Өйдән чыкмаслык, яңгыр коя. Сукыр тычкан юлга чыкса, аршин ярым кар явар, ди. Атаң тиз кайт дип калган иде. Ике көн узды, әле юлга чыкмаган. Кызым, үзем дә картайдым инде быел. Үзегез нихәлдә? Гөлфәния әнисен Алабугага алып китте. Торырга. Газизә апа сиңа сәлам әйтте. Сау бул, кызым. Бик сагынам сине, бала җимешем».

Шушы юлларны укыганнан соң нишләргә дә белмисең...

Дөнья кем өчен бетә?

Мәскәүдә укыган вакытта әнидән килгән тагы бер кызыклы гына хатка тукталып китәсем килә. Башта гадәти сәламнәр белән башланган. Тагы яз көне. Әни болай дип яза: «Быел ләйсәннәр дә яумады, җәе нинди булыр икән бу елның. Күңел тыныч түгел. Безнең авылга Амур якларыннан 250 кеше киләсе, ди. Аккош тавында окоп казыйсылар икән. Дөнья бетә диләр шунда качып калырга, яшеренер урын әзерлиләр, ди. Сезнең укытучы Хуҗи абыегыз үлгән, аның өчен дөнья бетте» дип язган әни. Ул кешеләр килгәндерме авылга, әни ул турыда кабат язмады. Ә менә авылга су кертәчәкләр, колонкалар куялар икән дип, бик сөенеп язган иде шул ук хатында. Көянтә-чиләк белән чишмәгә суга йөрү авыр да, ерак та инде. «Менә Сәмигуллалар турына калункы куйдылар. Суы гына чыкмый. Насосы күгәргән икән, шуны алыштыргач булачак» дип язган әни.

Хәзер инде чишмә суы һәр кешенең өенә кергән. Чишмә буйлары бөтнек, үги ана яфракларына күмелгән. Авылда көянтә-чиләк белән суга баручы күренмәгән кебек чишмә сукмаклары да күренми.

## «Урыска чыга күрмә!»

Мин кияүгә чыкканчы, әни минем өчен бик кайгырды. Кемгә чыгар, ничек яшәр? Бер хатында ул болай дип язган: «Кызым, сезнең Казанда укыган бер классташыгыз марҗа кызына өйләнгән, ди. Кемдер кайтып, анасына әйткән. Анасы барып кайткан яннарына. Биш айлык балалары да бар, ди, инде. Анасы бик рәнҗегән. «Кеше арасына чыгарлыгымны калдырмадың!» – дигән. Балакаем, башка милләт кешесенә генә кияүгә чыга күрмә. Атаң да берүк руска чыга күрмәсен ди».

Мин бу хатны укыганымны да хәтерләмим. Илле биш ел элек язылган хат. Әни кабат бер тапкыр да бу сүзләрне әйтмәде. Мин үзем дә бу хакта әниләр шикелле уйлый идем. Әти белән әнинең теләкләре кабул булды, мин үзебезнең кешегә кияүгә чыктым. Әнинең алты баласыннан берсе дә башка милләт кешесенә өйләнмәде, кияүгә чыкмады. Барысында да – үзебезнең милләт кешеләре.

«Кызым, күләрсең микән инде, бер шигырь язам әле сиңа.

Яшьлегем үтеп китсә дә,
Яшьләрдән һич көнләшмим,
Тик шулай да яшьлегемне
Искә алам көн дә мин.

Ә яшьлегем кайтып керә,
Сагынганымны белеп!
Яшьлегем – кызым Нәзифәм
Каршымда тора көлеп».

Әнинең хатлары җырсыз да булмый:

«Аклы ситсы монда юк дип,
Казаннардан алдырма.
Мин сагынып хатлар язам,
Син җавапсыз калдырма».

Әнинең хатларына караганда, әллә мин аларга ай саен посылка салып торганмын! Хат саен посылка өчен рәхмәттән башлый. Ә мин хәтерләмим дә.

«1986 ел, 19 март көнне посылкаңны алдык. Бик тәмле әйберләр җибәргәнсең. Атаң да бик яратып ашады. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын, кызым. Атаң тәрәзәдән карап, өйдә генә утыра. Тышка чыкмый хәзер. Бик каты чирләп алды. Чүт калды, әҗәл җитмәгәнгә бер сәбәптер. Әлфия дарулар алып кайтып тора. Рәхмәт аңар. Балакайларым, рәхәт яшәгез инде, мәңге хәер-дога, бигрәк тә кызларыма. Малайлар кайтмый. Грипп каты булды, атаң грипптан тернәкләнеп китә алмый әле. Быел кар күп булды, язгы ташулар шәп булыр диләр. Кызым, ничекләр җитешәсең син, шул тикле әйбер җибәргәнсең. Быелгы синең мәшәкатеңне әйтеп бетерә торган түгел бит. (Без яңа фатирга күчкән вакыт.) Сүзем бик күп иде. Кабат язармын. Сагынып, анаң».

Әти бик каты авыруыннан соң 1988 елның апрелендә бакыйлыкка күчте. Ул елны мин авылга алты тапкыр кайттым. Ул вакытта хат язарга әнинең дә вакыты булмагандыр...

### Мостай Кәрим Арташта

1989 елның маенда Татарстанга Башкортстан язучылары килеп, Казанда очрашканнан соң, боларны ике төркемгә бүлеп, районнарга җибәргәннәр. Әткәй әйткән: «Минем кодагый Мамадыш районында, мине шунда алып барыгыз әле», – дигән. Мин аның килүен «Кода килде» дигән хикәямдә тасвирлаган идем. Ул вакытта әткәй бүләкләр, күчтәнәчләр белән килгән. Ул бүләк иткән чуклы яулыкны әни калган гомере буена әткәй төсе итеп саклады.

Мин: «Илгизгә кияүгә чыгам, әти-әниләре Уфада яши» дип язгач, әни: «Кода-кодагыйлар бик еракта була икән, кунакка да йөрешеп булмас инде», – дип көрсенгән иде. Әткәйнең авылга килеп, әни белән очрашуы да көтелмәгән тарихи вакыйга булды. Бу вакыйгаларны күрсәткән берничә фоторәсем дә сакланган. Әниләр кунакларны бик матур итеп каршылап кунак иткән. Инде озата чыккач, капка төбендә саубуллашканда, әткәй автограф язылым дисә, үзе белән алган китаплары инде таралган булган. Фотографка Мостай Кәримнең китапка кул язмасын куюны төшерергә кирәк булган. «Китап чыгарыгыз, китап!» – диюгә, машина капоты алдына әнинең сандыгында сакланган, яраткан китабы «Кыссаи Йосыф» килеп яткан. Әткәй шул китапка үзенең автографын калдырган. Фотографиядә шул мизгел төшерелгән. Ә китапта мондый сүзләр: «Минем өчен бик истәлекле көндә язам бу сүзләрне. Бүген мин бик шатмын якын кешеләрем белән очрашуга. Мостай Кәрим, 30 май, 1989 ел, Арташ». (Әлбәттә, бу язма татар телендә.)

Әткәй авылдан Уфага кайткач, фотографияләрне күрсәтеп, әнкәйгә бик мактап сөйләгән: «Нәзифәнең әнисе, туганнары матур яшиләр икән, хөрмәтле кешеләр икән», – дигән. Фотографиядә әллә ни булмаса да, өйнең эчен дә, урам яктан да күргән каенанам:

– Кара, өйләрегез матур икән бит! Тыштан да, эчтән дә! Ә син алай дип сөйләмәгән идең! – диде.

– Мин бит сезнеке белән чагыштырганда дип әйткән идем ул вакытта, – дидем әнкәйгә.

– Безнеке белән чагыштырырга кирәкми, – диде әнкәй. – Безнеке «вне конкурса»!

Ничек ризалашмыйсың инде бу дөреслек белән.

Әткәй белән бергә китапка автограф язган вакытта төшерелгән фотографиядә әнинең өстендәге зәңгәрсу атлас күлмәккә тукыманы Илгиз кияү бүләге итеп алып кайткан иде. Ә менә кара читле роза чәчәкләре төшкән яулыкның үз тарихы бар. Әни бер хатында миңа: «Кызым, хәзер авылда әбиләр ашка барганда, кызыл роза чәчәге төшкән кара читле яулык ябалар. Айсылуттигә дә кызлары җибәргән, Гөлбикәнеке дә бар, миңа да таба алмассыңмы?» дигәч, Мәскәүдән посылка салганда, шушы яулыкны да табып җибәргән идем. Әни әнә шул «модный» яулыкны япкан булган. Әткәйгә сөйләмәдем инде әнинең «модница» икәнен. Үзем генә белдем.

Әткәйгә минем әни белән сөйләшү бик ошаган. «Әниең бик акыллы кеше икән», – диде. Бәлки минем күңелемне күрергә теләгәндер. Беләм: безнең әни, чынлап та, бик акыллы, күп укый торган, мәгълүматлы, зирәк һәм җор кеше иде. Сүзләре килешкәндер дип уйлыйм.

## Кода килде

– Әй кызым, кода килеп китте бит әле безгә быел!

– И әни, ничәнче кат сөйлисең инде син аны миңа.

– Сөйләрсең дә! Кодаң шундый кеше булсын да, шаккатып сөйләрлек кенә итеп очраш инде гомереңдә…

– Тормыш шундый булгач…

– Ярый, анысына үпкәләрлек түгел, Аллага шөкер! Әле сөйлисем килгәнен синең ишеткәнең юк. Син бит коданың килүен дә китүен генә беләсең, бер тамаша булды бит ул! Ул көнне… Юк, нишләп ул көнне генә булсын, бер ел алдан башланды ул көн… Бер ел алдан… Апрель аенда әтиеңне җирләдек…

– Әни!

– Шул хәтле ятимлекне, шул хәтле ялгызлыкны тоярга Ходай язмасын… Әтиеңне җирләгәч, минем өчен дөнья тарайды, караңгыланды… Авызымда аш, күземдә яшь… Ятсам да, күз алдымда, торсам да… Кайтып тордыгыз берәм-берәм, рәхмәт анысына… Авырган чагында барыгыз да кайтып, бигрәк тә сөендергән идегез әтиегезне. Хәтерлисеңме, сез кайткач, урыныннан торып та утырган иде.

– Хәтерлим… Беләсеңме, әни, ул нәрсә дигән иде безгә ул вакытта?

– Тагы бер кат сөйлә әле…

– Балалар… бәләкәй чагыгызда кебек өй уртасында барыгыз да әүмәкләшеп, бер уйнагыз әле дигән иде.

– Сирәк җыелышасыз шул, сирәк. Тәрәзәдән күзен алмый көтә иде. Ә монда бөтенегез бергә бит, алтыгыз да!

– Без бәләкәй чакта сыек чыбык матчадан төшмәде инде. Талаша башласак, барыбызны да почмак саен өләшә иде.

– Ул чыбык истә калган синең, ә сукканын хәтерлисеңме соң?

– Юк, бер тапкыр да кул күтәреп сукканы булмады.

– Тәрбия чыбыгы иде ул, тәрбия! Әтиегез әүмәкләшеп уйнагыз дигәч, нәрсә эшләдегез, оныттым да инде?

– Син нәрсә, әни! Миңа кырык яшь, Әлфиягә утыз сигез, Миннуллага утыз биш, Хәлимгә егерме җиде, Алфирага егерме! Әнә шул тикле чәчләренә чал кергән олы хәлләр әүмәкләшә башласа!

– Әтиегезнең сезне балалар итеп күрәсе килгәндер шул.

– Көлештек барыбыз да әйткән сүзеннән, ул да елмайгандай итте.

– Хәле авыр иде шул. Үләр, өзелер, күрми калырсыз дип, барыгызны да чакырган идек ул чакта. Сез кайтып киткән дәва булып, тагы ике ай торды бит.

– Нәкъ ике ай, көнгә-көн.

– Озатырга бөтен авыл килгән иде…

– Әнә, кода килгәч тә, әтигез кайткан кебек булды. Анда да бөтен авыл җыелган иде. Ул елны печән бик күп булган иде урманда.

– Әни, нишләп әле берсен башлыйсың, берсен ташлыйсың дигәндәй…

– Һаман шул бер сүз инде ул, очына гына чыга алмыйм. Печән өешергә дип, күрше Сәвия дә барган иде. Җәйге эш кайнап торган чакта вакыт табып барды, рәхмәт төшсен.

– Соң?

– Ә инде Сәвиягә утынга турарга дип, капка төпләренә каен керәже кайтарып аудардылар. Хәлимгә әйттем, улым, турап бир әле Сәвиягә шул утынны дидем. Бәйрәм ашы кара-каршы бит.

– Соң?

– Нәрсә дисен, тураса да турый, турамаса да турый. «Дружба»сы бар бит аның. Бер-береңә ярдәм итеп яшәмәсәң, күршелекнең ни хаҗәте бар? Юк икән, ул көнне генә турый алмады, әллә яңгыр яуды, әллә башка эш булды. Ул көнне бөтен урамны каплап калды теге ботаклары чатаклы өрлеккә салырдай каен керәжләре Сәвияләр турында. Әле икенче көнне дә Хәлимнең кулы җитмәс иде, болай булды… Төнлә белән Рәшит тракторында олы юлга малаен каршы алырга чыккан чакта теге утынга дигән агачның берсен эләктереп, байтак кына өстерәгән, караңгы бит, күрмәгән инде…Ул агач өстерәлү бер нәрсә, аңар ияреп өй каршысындагы рәшәткә дә киткән, рәшәткәгә ияреп ничә еллар буе балаларның авыз суын китереп, ел саен манчыгандай кызыл алма сырып ала торган алмагач та төбе – тамыры белән килеп чыккан. Ярый әле, абайлап калган, шушы өемгә Сәвиянең өе дә эләккән булса, Рәшиткә өй салып бирәсе була иде, Ходай саклаган.

Икенче көнне таң белән бу хәлне күрдек тә, әйтәм Хәлимгә: «Улым, кисеп бир Сәвиянең утыннарын, эш олыга киткәнче», – дим. Хәлим әйтә: «Мин как раз шунда чыгарга гына тора идем, эшләпәмне таба алмыйм, кайда микән?» – ди. Мин әйтәм: «Нәрсәгә сиңа ул эшләпә, атаңның кәләпүшен ки әле, синнән башка аны кияр кеше юк бит», – дим. Хәлим көзге каршысына килеп, менә шул кәләпүшне генә киям дип торганда, күзләрен тасырайтып килен килеп керде.

– Хәлим! Бар әле, ишек алдына перси белән әллә нинди кешеләр керде, тагы сиңа штраф салырга йөриләр микән, – ди.

– Калхуз персидәтелен шулай «перси» дип йөртәләр алар. Штраф дигәннән, Хәлим колхозда түгел бит хәзер. Шуңа күрә бакча сукалатырга булса, аларча сука чираты безгә иң соңыннан җитәргә тиеш. Атаң мескен дә колхозда бер генә көн калдырмыйча эшләсә дә, сука чиратын көтеп алырга түземлеге җитмичә, бакчаны көрәк белән казый иде. Шул авырлыклар алып

киткәндер инде… Хәлим колхоз сукасына ялынып тормады, суканы үзе ясады да кеше чиратында сукалап та чыкты. Шуңа персинең ачуы чыккан, ди, шуңа штраф салам дип йөри дип әйттеләр анысын. Мин әйтәм, туктагыз әле, бакча кайгысы түгелдер, колхоз бәрәңгесен утыртырга, бәрәңге ярырга дип, миңа эшкә әйтергә килгәндер дип, алар каршысына үзем чыктым. Чыксам, ике-өч чибәр кеше басып тора, өсләрендә парачкы кәчтүм, муеннарында гластук, атаң башы, киенеп куя инде урындагы кеше, карап туя алмассың.

– Апа, нихәлең бар? – ди персидәтел.

– Аллага шөкер, – дим. Үзем эчемнән генә, шулай ул, безнең ише пенсионерларсыз барыбер эшегез бармый, өйгә чаклы килеп җиттеңме дип уйлап куйдым.

– Апа, – ди бу, – сезнең Мостафа дигән кодагыз бар икән Уфада, безгә хәбәр иттеләр, бүген ул сезгә килергә тиеш икән, шуны беләсезме, – ди.

– Бик әйбәт мин әйтәм, килсен! Нишләп соң аны сезнең аша әйттерәләр, туры үземә генә килмәгәннәр, эш вакытында сезне йөртәләр, – дим.

– Апа, зур кеше икән сезнең кода, нишләп аны башта ук әйтмәгән идегез? – ди бу.

– Кайсы баштан? – мин әйтәм.

– Бакча сукалаткан чакта и таки дали, – ди бу.

– Шулай инде, – мин әйтәм, – ятим карчыкка яклаучысыз булмый икән, минем ирем дә шушы колхозда эшләп, яшәп, шушы өйдә торган кеше, – дим.

– Апа, ярар инде, биредә ят кешеләр дә бар бит, безне гел бетереп ташлама. Кунак каршы алырлык хәстәрләрегез бармы соң? – ди.

– Аллага шөкер, бар нәрсәм дә бар, килсен генә, мин әйтәм, күптән очрашканыбыз юк иде, – дим.

– Итең бармы? Маең бармы?

– Коданы сыйларлык та сый тапмагач, ничу яшәргә бу дөнья йөзендә тере кешегә сан булып. Кайчан киләсе, ди?

– Бер-ике сәгатьтән…

– Алай булгач, аш салыйм… Озын сүз бозау имезә…

– Ярдәмчеләр кирәкме? – дип сорый бу.

– Булса – килсеннәр, эш җитәрлек булыр, болай булгач…

Шул сөйләшүдән соң аш салдым. Табын әзерләргә тотындык. Хәлим тагы кисә алмый калды теге бүрәнәне. Анысы ишегалды себерергә тотынды. Һаман шул Сәвия инде, рәхмәт төшкере! Йөгереп килеп керде. Бигрәк илгәзәк җан инде. Нинди эш бар дип кенә тора. Персидәтел аны урам буйлап карап кайт әле, урам ямен җибәреп, берәрсенең ыштан балагы коймада эленеп тормый микән дип йөгертте. Сәвия койма башларын карап кайтканчы, Рәшит абыең бульдозеры белән урамны тигезләп чыкты. Язгы пычрактан урам кантар-кантар, кеше генәме сиңа, ат та йөри алмаслык хәлгә килгән иде. Инде, мин әйтәм, шушы урамны тигезләтер өчен авылга кунак килүен көтәргә кирәк микәнни, дим. Урамыбыз чирәм генә иде сез үскәндә. Тракторлар белән бетерделәр урамны. Шул арада Кирмән очлары менеп җиткән. «Мәүҗидә, Суык Урамда торсаң да, туган урамың Кирмән очы бит, әйт әле персидәтелгә безнең урамны да тигезләсеннәр әле», – дип. Килен йөгерде үзләренең киленнәренә. Аны да ярдәмгә алып менде. Мәш киләбез. Өй тулы хатын-кыз! Киленнең энесе дә менеп җитте. «Җизни, нәрсә эшлим?» – дип уаланып тора. Хәлим әллә кайчаннан бирле яңа болдыр ясыйм

дип тора иде, кода килүне сәбәп итеп, кайнеше белән икесе иске болдырны төбе-тамыры белән куптарып алдылар да утынлыкка илтеп ыргыттылар. Ул арада болдыр ясамадылар инде. Кода киткәч ясалды бу яңасы. Кода килмәгән булса, булмый иде! Уен эш түгел бит, ни гомердә яраткан кодаң бусагаңны атлап керә икән, безгә дә сынатмаска кирәк!

Олы якка озын итеп табын кордык. Килен мунча ягып җибәрде. Сәвия салат-малат ясый башлады. Урам тулып халык чыкты. Бервакытны, асфальт кебек тип-тигез урамнан, мин сиңа әйтим, кара Волга машинасы, тузаннар туздырып, капка төбенә килеп туктамасынмы! Өскә менә шушы күлмәкне кигән идем. Үзе атлас, үзе ялтыравыклы, бу кияү бүләге иде, әллә ничә еллар сандык төбендә яткырып саклаган идем. Кода алдында да кияргә насыйп булды. Калган эшне киленгә тапшырдым. Табын тирәсенә җыелыштык. Кода әйтә: «Кодагый белән рәттән утырам», – ди. Тәки утыртты шул. Ул үзе генә булса бер хәл, кара машина эче тулы кеше булды анда. Барысы да ят кешеләр дисәм, авызын ерып, кулын сузып, үзебезнең авыл Шаһинур да килеп чыкты. Ашарга утыргач, авызым бик оялган иде, коданың тәмләп ашавын күргәч, үзем дә бер-ике кашык кабып куйдым. Шул аш белән страмга да калдым бит кода алдында. Токмач ягын киленгә тапшырган идем. Ашыгыч дип, ул токмач басып тормаган, син җибәргән теге импыртный шүре тукмачны гына салган да җибәргән. Кода бер-ике кашык капты да:

– Кодагый, синең килен минекенә караганда уңганрак икән, токмач саен тишек тә тишеп чыгарга өлгергән, – ди.

Көлештеләр барысы да, аның шаяртканын аңладылар инде, укыган кешеләр бит. Мин генә көләргәме, көлмәскәме дип торам. Шул тикле кеше алдында авыз күтәреп көлеп утыруы да уңайсыз бит. Безнең кода шикелле дөньяда юк! Дөресен дә әйтте, үпкәләтмәде дә. Килен басмаган икәнен күреп тора бит ул. Күрмәгән нәрсәсе түгел. Киленгә дә әйбәт сабак булды, олы кунак алдына кибет токмачыннан аш куярга кирәкми, димәк. Шулай көлеп утырганда, кәртечкәгә дә төшереп алганнар. Хат белән безгә килеп төште ул кәртечкәләр. Ничек туры китергән диген! Шул кәртечкәгә карасам, коданың сүзләре искә төшә дә рәхәтләнеп көләм, ул чакта оялган булсам да. Ашлар ашап, чәйләр эчкәннән соң, кода коданың каберен дә зиярәт итеп кайтыйк ди. Шул сүзне ишетүгә персидәтелнең авызы бер карыш ачылып калды. Нәрсә булды микән дисәм: «Ул урамны тигезләтмәгән идек!» – дип пышылдый бу миңа. Ничек кенә матурлап күрсәтергә тырышса да, барып чыкмады бит. Кода аның урамына карыймы инде? Колхозга тикшерүче булып килмәгән бит ул, безгә кунак булып килгән.

Аларны анда Хәлим белән Шаһинур алып китте. Мин иярмәдем. Артларыннан елап калдым.

Аннан соң яңадан өйгә кайттылар. Мунчалар җитешкән булса да, кода мунча кереп тормады. Тагы да барасы җирләре бар икән. Менә шушы китабын безгә истәлеккә дип, бик матур сүзләр язып калдырды. Ә менә бу шәлне бүләк итеп бирде. Ничәмә айлар кайгы белән йөргән җаныма коданың килеп китүе бер җан азыгы булды. Ходай озын гомер насыйп итсен үзенә. Балаларының рәхәтен күрсен, матур-матур китаплар язсын дип теләп торам. Мәңге хәер-фатиха аңар.

*(Дәвамы киләсе санда.)*



*Фирдәүсә Бикмәтова – Зәй районының Карман авылы кызы. Белеме буенча инглиз, немец телләре укытучысы булырга тиешле кызның тормыш юлы бөтенләй башка юнәлешкә борыла. Әүвәл ул журналист булып китә – Чаллы телерадиокомпаниясендә корреспондент булып эшли, «Тормыш мизгелләре», «Кизү бүлеге» тапшыруларын алып бара. Алга таба хезмәтен хокук саклау органнары системасының җәмәгатьчелек белән элемтә бүлегендә дәвам итә. Соңрак үзенчәлекле вә четерекле өлкәдә – җинаятьләре өчен җәза алучылар өчен рус телендә чыга торган «Другая сторона» газетасында эшли. Бу юнәлештә шактый тәҗрибә туплагач, хокук саклау органнарының җинаять кылган яшүсмер балалар белән эшләү бүлегендә җитәкчелек итә. Майор дәрәҗәсенә ирешеп, отставкага чыга.*

*Менә шуннан соң балачактан ук күңелендә йөрткән, төрле елларда төрткәләп барган шигъри юлларын барларга, тупларга керешә ул. Быел шәхси нәшриятта «Балачак иле» шигырьләр җыентыгын да бастырып чыгара, Татарстан китап нәшриятына да балалар өчен язган яңа шигырьләр кулъязмасын тапшыра. Иҗат җимешләре «Мәйдан» журналы, «Ватаным Татарстан», «Мәдәни җомга», «Зәй офыклары» газеталарында даими басыла.*

Фирдәүсә
Бикмәтова

# ТАУЛАР ТҮБӘСЕНДӘ КЫЛДАЙ ХЫЯЛ...

## Нәрсә җитми адәм баласына?

Матурлыкны күрер өчен күзләрем бар.
Ис китәрдәй тылсымнарны күргәнем бар.
Һәр күргәннән тәмнәр табып йөргәнем бар.
Тынгы тапмый нәүмизләнгән көннәрем бар.
Нәрсә җитми адәм баласына?

Бәйнә-бәйнә сөйләр өчен сүзләрем бар.
Сагышлардан өзелердәй үзәгем бар.
Дөнья ямен сыйдырырлык йөрәгем бар.
Шул йөрәкне битәрләгән көннәрем бар.
Нәрсә җитми адәм баласына?

Киләчәкне нурга төргән максатым бар.
Болытларны кисәр ике канатым бар.
Тагын күпме еллар санап барасым бар?

Яшәү белән үлем арасында
Күңелләргә сеңеп каласым бар!
Нәрсә җитми адәм баласына?

## Ярату ул

Ярату ул – яшәү түгел көн дә
Сөйгәнеңнең куенында оеп.
Каршылыклар кичеп, сабыр калу,
Авыр чакта, ныклы иңне тоеп.

Ярату ул – икең белгән шатлык,
Бергә кичкән авыр газап та.
Сөтләп ясап куйган иртәнге чәй,
Вакытында каккан кадак та.

Җан җылысы салган пешкән ризык,
Кайрап куйган үткен пычаклар.
Юеш борыннарны сөрткән куллар,
Балаларны сөйгән кочаклар.

Ярату ул – купшы сөйләп кенә
Яшәү түгел, карап күзгә-күз.
Тынгы бирмәс борчылу да кайчак,
Ялгышлардан тыйган каты сүз.

Төчеләнеп, бер-береңә карап
Яшәү түзми, әлбәт, озакка.
Ярату ул – бер ниятtә булып,
Караганда икең бер якка.

Ярату ул – гафу итә алу,
Үз ярыңны сөю эчкерсез.
Утлар-сулар йотып, ваклыклардан
Өстен кала белү, һичшиксез!

## Бүген яшә икән!

Гомер дигән биек тауга карап
Менгән чакта йөрәк тала икән.
Дәрт булса да, дәрман саекканда,
Тау башында хыял яна икән.

Таулар түбәсендә кылдай хыял
Чыңлап өзелгәндә упкын икән.

Киләчәкне уйлап юл барганда,
Яшәү ямен таты бүген икән!

Хатирәләр күлен кичкән чакта,
Узган гомер артка дәшә икән.
Томан сарган күлгә керми генә,
Бүген яшә, бүген яшә икән!

## Бер күрешик әле, туганнар!

Бу арада җирсеп йөрим әле,
Җанга урын тапмый зарыгып.
Эчтән генә җырлар көйләп йөдим,
Туганнарым, сезне сагынып.

Тормыш мәшәкате диеп тормыйк,
Ерак диеп тормыйк арабыз.
Бер җыелып кайтып төшик әле,
Шушы йортта үскән бала без.

Көлә-көлә хатирәләр барлыйк,
Йөз тыңлаган бәян булса да.
Моң-зарларны себеркеләп куыйк
Абый салган яңа мунчада.

Кайнар чәйгә кәҗә сөте өстәп,
Салмак кына корып әңгәмә,
Кич утырыйк, рәхмәт укый-укый
Бәлеш салып көткән җиңгәмә.

Бер абыйга биш кыз бала бит без,
Бер түтәлдә үскән гөл генә.
Әби торган саен әйтер иде,
«Сез күп әле, абыең – бер генә».

Хатирәле, ямьле булсын бу көн,
Нурлар белән тулсын кичебез.
Абый үзе – уң кул анысы безгә,
Бер уч инде калган бишебез.

Дәртле көй дә, моңсу көй дә сузыйк.
Хисләр китсен, әйдә, сүтелеп.
Очраша да алмый калдык диеп
Сөйләмәслек булсын үкенеп.

Ямансулап эч пошулар калмас,
Матур бер юл булыр узганнар!
Бер сәбәпсез, тора салып кына,
Бер күрешик әле, туганнар!

## Исән ул...

Менә хәзер ишек ачылыр да
Әни керер кебек җил атлап.

Түтәлләрен бераз уаштырып,
Тавыкларга гына җим ташлап.

Табагачын мичкә терәп куйган
Чиләгенә салган тамгасын.
Чәйнегендә чәе җылыдыр күк,
Мич алдында тора табасы.

Дисбеләрен җайлап чөйгә элгән.
Намазлыгын төргән хәстәрләп.
Күзлеген дә ипләп кенә куйган,
Ята гәҗитләре өстендә.

Бөтен нәрсә әни истәлеге,
Бар нәрсә дә монда урынлы.
Исән әни... Ник соң бертуктаусыз
Хәсрәт тора тырнап карынны?

Күлмәкләре, әнә, ничә дистә,
Яулыклары күпме сандыкта!
Бәяләр дә алынмаган икән,
Карамаган, ахры, алып та.

Ул бәйләгән җылы оекбашлар
Көткән капчыгында хуҗасын.
Алыйм әле берсен истәлеккә,
Саклап тотыйм, кимим, тузмасын.

Тәрәз төбе саен чәчәкле гөл.
Боекканнар... Кылыйм ни чара?!
Тамчылы гөл әни төсе иде...
Башын игән сулып бичара.

Тик шулай да күңел һич ышанмый,
Юк, үлмәгән әни, исән ул...
Ишегалдын урап керер өчен
Тышка гына чыгып киткән ул.

## Әтигә

Көлемсерәп карап торуыңны
Күз алдымда тотам өн кебек.
Синсез гомер бармак арасыннан
Саркыган да киткән ком кебек.

Бозлы йөрәкләрне эретердәй
Җылы иде, әти, күңелең.
Күзләреңә зәңгәрлеге сыйган
Балачакның гәүһәр күгенең.

«Аһаһайлап», хуплап чөяр идең
Һәр гамәлне, күккә күтәреп.
Ягымлы сүз белән очындырып,
Күңел түрләренә үтәрлек.

Тау башына басып җырлаганда,
Йолдызлы юл миңа юрадың.
Җырчы булмасам да... иңнәремдә
Йолдызларның йөрттем зурларын.

Чандыр иңне әти сөйсә әгәр,
Үсәр иде indә канатлар.
Димәк, күкне иңләп очарыңа,
Таулар кочарыңа сәбәп бар.

Кешеләргә игелекле булдың,
Эчкерсез дә гади, мөлаем.
Кер кунмастай чиста исемеңне
Вакламадың бер дә, мөгаен.

Киң күңелле идең, яшәмәдең
Тыштан балкып, эчтән (э)череп.
Ак тасмадай хатирәләр калды
Хушланырлык, искә төшереп.

Булгалады авыр мизгелләр дә,
Туфрак булсын, әйдә, узганы.
Балкып елмаюың себерер ата
Балачакның иске тузанын.

Тын торалмый әле дә ашкын күңел,
Инде таудан төшеп барышым.
Вакыт-выкыт сиңа илтә, әти,
Балачакның якты сагышы.

## Сөю орлыгы

Чирек кенә минем кан да синдә,
Минем дәвам, минем эзем бар.
Тыңла әле, кызым, мине бераз,
Әбиеңнең әйтер сүзе бар!

Сынмас сабыр канатларың булсын,
Җиңеләйтер өчен үтәреңне!
Матурлыкны тоеп яшәр өчен,
Чәчәккә күм гомер түтәлеңне!

Хатын-кыз күк йомшак, назлы бул син!
Гыйшык тотып йөрсен ир-егетләр.
Горур да бул, тик тәкәббер булма,
Кылып яшә җирдә игелекләр!

Җиңәр өчен тормыш киртәләрен
Үткен бул син, мәми авыз булма!
Җае белән каты да тора бел,
Усал бул, тик берүк явыз булма!

Сәламәт бул, кызым, хәсрәт күрмә!
Йөрәгеңдә кояш яшәсен!

Һәр көнеңнең тәмен тоеп яшә,
һәр мизгелең сөеп яшә син!

Аңламыйсың әле мине, кызым...
Бүгенгә син курчак зурлыгы.
Безнең йортка сүнмәс шатлык өстәп,
Үс син, әйдә, сөю орлыгы.

## Халәт

Эңгер-меңгер әле тышта,
Йорт башлары күксел-көрән.
Таң алдыннан сихри тынлык,
Уянмаган күрше-күлән.

Яшел чәйдән авыз итеп,
Карап торам тәрәзәдән.
Табигатьнең иң саф чагы,
Тибрәлми дә чыклы үлән.

Селкенми дә агач, яфрак,
Тирә-якта сихри тынлык.
Көн уяна иренеп кенә,
Кызылланып килә офык.

Карап торам тәрәзәдән,
Төпсез тирән, күгелҗем күк.
Табигатьнең бу халәте,
Минем шигъри күңелем күк.

## Яздан – көзгә

Алтын көзнең соңгы җылы көне.
Түбә кыегына посып, җил тынган.
Күкләр сыек зәңгәр, табигатьтә
Көз ямьнәре көзләрчә мулдан.

Җиңел сулап кырлар тып-тын ята,
Көмәненнән гүя арынган.
Күзен күккә терәп, уйчанланып,
Салкын кышны кочар алдыннан.

Күзем белән дөнья йотып йөрим,
Көзге халәт бераз моң хисле.
Урта яшькә җиткән хатын-кыздай,
Көзнең бизәкләре мең төсле.

Муллык, байлык биреп тереклеккә,
Бу көзем дә бүген хушлаша.
Кышлар, язлар, җәйләр шаулап узгач,
Тагын очрашырбыз, кыскача.

## Яшәү барда

Кемнән кала улга, кемнән кала кызга.
Күчә кулдан-кулга серле фани дөнья.

Яшем атлый көзгә, бер дә күңел күнми.
Алҗыса да йөрәк, яшәү уты сүнми.

Утта чыныгылган корыч туза икән.
Корыч сындырсаң да, гомер уза икән.

Кызым искә алыр догасында безне.
Улым атлап барыр, суындырмый эзне.

Минем нәсел җебе калыр оныкларда.
Дөнья кулдан-кулга күчәр яшәү барда!



Фәнүзә Якупова

# ГЫЙБРӘТЛЕ ХАТА

ХИКӘЯ

Кыш. Зәмһәрир суыклар. 1976 елның декабрь азаклары. Көн кичкә авышып бара. Сәлимә ялгызы гына бәйләм бәйли. Аяк очында, иркәләнеп, мәчесе ята. Кинәт каты итеп ишек дөбердәттеләр. Сукрана-сукрана: «Кем йөри икән? Нинди нужалары төште? Йа Ходай, хәерлегә генә булсын», – дип укына-укына, ишеген ачты һәм... аптырап калды. Бусагада бер ир, ике яшь кенә хатын басып тора. Берсенең кулында юрганга төрелгән яңа туган сабый. Икенчесендә – таушалып, пычранып беткән чүпрәк сумка. Үзләре бик өшегән. Ялварулы карашлары Сәлимәгә төбәлгән. Ир кеше Кавказ ягыннан, күрәсең. Ул сүзләрне вата-җимерә, бер русча, бер татарча сөйләп, нидер аңлатырга тырышты. «Кундырып кына чыгармассызмы икән?» – дип үтенде. Сәлимә башта каушап калды. Мондый каты суыкта этне дә урамга куып чыгармыйлар. «Әйдәгез! Өйгә үтегез», – диде ул. Яшь хатынның баласын кулына алды һәм үзенең бала тудыру йортында Зөлфиясен беренче тапкыр күкрәгенә кысуын хәтергә төшерде. Уйларыннан айнып китеп, юлчыларга юыну бүлмәсен күрсәтте. Үзе исә, сабыйны күкрәгенә кысып, йокы бүлмәсенә алып керде. Баланың юрганын ачып җибәрсә... шаккатты. Пычрак чүпрәкләр арасында, авыр сулыш алып, сабый ята. Күзләрен дә ачарга хәле юк аның. Тәне ут кебек яна, бот аралары катып укмашкан.

Бу кадәр битарафлык белән очрашканы юк иде Сәлимәнең. Җан ачуы белән кычкырып җибәрүен сизми дә калды ул: «Кайсыгыз әнисе? Тизрәк минем янга! Балагыз үлеп бара бит. Ачы суыкта юлга чыгалармыни? Күкрәк сөте имезәсезме? Кая юл тоттыгыз?» Сәлимә сорау артыннан сорау яудырды. Йөрәге әрнеде. «Нигә Ходай, тәрбияли алмаса да, кемгәдер бала бирә, кемнеңдер исә газиз баласын тартып ала?!» дигән уй үтте башыннан. Дөнья шулай корылган. Кайчак бик мәкерле ул. Шул арада хатыннарның берсе чүпрәк сумкадан сөткә охшаган сыекча салынган шешә тартып чыгарды. Ул әллә туңган, әллә оеган – белмәссең. «Апа, җылытып бирсәгезче», – дип, шешәне Сәлимәгә сузды. Сәлимә бу сыекчаны юынтык суга охшатты. Аш бүлмәсенә чыгып, бераз шикәр салып, сөт кайнатты.

Балага башта су, аннары сөт биреп карады. Тәннәрен юып, крем сөртеп, өстен алыштырды. Кызы Зөлфиядән калган бик күп бала әйберләрен сандык төбендә саклый иде. Менә бүген кирәге чыкты аларның. Сәлимә бала белән мәш килде, юлчыларга аш бүлеп бирде дә: «Түр бүлмәдә йокларсыз», – дип, үз бүлмәсенә үтте.

Кышкы төн озын. Керфек тә йоммый, яшь чакларын, шатлыклы минутларын, бөтен тормышын башыннан үткәрде ул.

***

Яшьли тормышка чыкты Сәлимә. Рәфисе ике йорт аша гына яши, биш яшькә өлкән. Авыл бәләкәй, башлангыч мәктәптә 4 сыйныф кына укыйлар. Аннары күрше авылга йөреп укыдылар. Рәфис, Сәлимәгә ярдәмләшеп, китап-дәфтәрләрен гел күтәреп йөрде. Сәлимәнең Сәҗидә исемле сеңлесе дә бар. Рәфис аңа да ярдәм итте. Сәлимәнең әти-әнисе – гади кешеләр. Әтисе Хәмит – алдынгы механизатор, трактор, комбайнда эшләде. Ул аз сүзле, акыллы, сабыр кеше, гел елмаеп кына тора, ярдәмчел. Әнисе Саймә – алдынгы савучы. Эшне ут кебек ялмап ала, күрми дә каласың, җиренә җиткереп эшләп тә куя. Тату, үрнәк гаилә. Балалары китапка мөкиббән булды. Сәлимәгә төннәр дә җитмәс иде. Шигырьләр, төрле романнардан өзекләрне яттан укый иде. Аеруча Зәйнәп Биишеваның «Кимсетелгәннәр», «Олы Иек буенда», «Җимеш» әсәрләрен яратты. Габдрахман Әпсәләмов һәм башка бик күп язучылар белән китаплары аша танышты ул. Сәлимә мәктәпне яхшы билгеләргә генә тәмамлады. Китапханәчеләр техникумына укырга керде. Фатирда Заһидә атлы хатында торды. Ул, ялгызы ике ул үстереп, югары белем алырга ярдәм иткән. Алар икесе дә башлы-күзле. Себер якларында яшиләр. Дүрт оныгы бар. Елына ике-өч тапкыр әниләренең хәлен белергә кайталар югыйсә. Әни кешегә бу да аз. Заһидә – авыр язмышлы кеше. Үзе бер китап язарлык. 42 яшендә иренең атлап барган җирдән йөрәге туктаган. Ике улын Заһидәгә калдырып, бакыйлыкка күчкән. Заһидәгә нибары 38 яшь булган. Кияүгә чыкмаган. Сорап килүчеләр дә булган. Балаларын үстерергә көч тапкан үзендә.

Сәлимә анда өч ел яшәде. Аларны читтән карап торсаң, әниле-кызлы кебек. Аерылу сәгатьләрен бик авыр кичерделәр.

***

Сеңлесе Сәҗидә югары уку йортының физика-математика факультетына укырга керде. Кызлар киткәч, өй эче бушап, шыксыз булып калды. Атна саен кайтып тора алар югыйсә. Саймә апа барыбер сагына. Үскәннәрен сизми дә калды, кошчыкларын читкә очырды.

Җәйнең матур мизгелләре. Һич туктамый кошлар сайрый. Тирә-якта яшеллек. Инеш, елгалар челтерәп ага. Якында гына кәккүк кычкыра. Җәйнең шушы ямьле көннәрендә Сәлимә, кулына диплом алып, туган ягына әти-әнисе янына ашыкты.

Авылда тормыш гөрли. Сәлимәне туган авылына китапханәче итеп тәгаенләделәр. Аның авылга кайтуына ышанып та бетмәделәр. Чөнки яшьләр бүген шәһәргә атлыгып тора. Шунысы кызганыч: авыллар бетүгә таба бара.

Сәлимәне әти-әнисе бик сагынган. Сөйләшер сүзләре бетми. Тик әтисе Хәмит абый бик йончыган. Ябыккан, күзләре тоныкланып калган. Сәлимә бер атна гына ял итте дә башы-аягы белән эшкә чумды. Әнисенең дә кул-аяклары сызлый. Аеруча явым-төшем булса. Алар икесе дә лаеклы ялда.

Көз айлары керде. Туктаусыз яңгыр ява. Игеннәрне дә чиле-пешле җыеп алдылар. Әтисенә, лаеклы ялга киткәндә, зурлап, тракторын бирделәр. Ул шуның белән авыл халкына ярдәмләшә. Акча бирсәләр дә, алмый. Бер көнне өзлегеп китте. Сәлимә районнан «ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртты. Табиб, җентекләп карагач: «Хәлегез мөшкел. Хастаханәгә җыеныгыз!» – диде. Хәмит абый карышып тормады, чөнки эченең авыртуына чыдарлык түгел иде. Әтисендә яман шеш авыруы таптылар. Саймә үзенә урын таба алмады. Тиз арада операция ясарга кирәк иде. Тик Хәмит абый ризалашмады.

Сәлимәнең сөйгәне Рәфис тә, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, диплом алып кайтты. Сәлимә Рәфиснең өенә барып йөри, әти-әнисенә булыша. Рәфисне күрше авылга агроном итеп билгеләделәр. Бер көн күрешми торсалар, бер ел кебек тоела. Яшь чак – дәртле чак, көчләре ташып тора. Мәхәббәт шундый изге, көчле, сихри шул. Рәфис Сәлимәсен зәңгәр кыңгырау чәчәккә охшата. Дулкынланып торган, алтын төсендәге чәч. Офык төсле зәп-зәңгәр, сөрмәле күзләр. Кыйгач карасу кашлар. Җыйнак борыны, чия кебек ирене ымсындырып тора. Аяклары төз. Гәүдәсе сылу. Йөзе көләч, елмайганда, ап-ак тешләре күзне чагылдыра. Сокланып туймаслык хур кызы инде менә. Рәфис тә мәһабәт сынлы. Кап-кара, куе чәч. Чем-кара күзләр. Мускуллары йомры. Эре-эре атлап йөри. Авызы гел ерык. Сабантуйларында көрәшеп, һәрвакыт җиңүче була. Табигать икесенә дә матурлыкны юмарт биргән. Рәфис җырга һәвәс, моңлы тавышы йөрәккә үтеп керә. Әмма ул бик сирәк җырлый. Әнисе бервакыт: «Моңлы кеше бәхетсез була ул», – дип әйтеп куйган иде. Сәлимә биюгә оста. Төрле бәйгеләрдә катнашып, дипломант, хәтта лауреат булды. Яшьләр, эшне озакка сузмыйча, язгы чәчүне тәмамлап, ике яктан әти-әни фатихасын алып, өйләнешеп тә куйды. Туй мәҗлесе бик шәп узды. Кара диңгез буенда ун көн ял итеп, кояшта кызынып, көч җыеп кайттылар. Авылда тормыш гөрли. Яшьләргә йорт салырга түләүсез җир, чыршы бүрәнә бирделәр. Авыл халкы да ярдәмләште. Сәлимә белән Рәфис, өмә ясап, йортны күтәреп тә куйдылар. Рәфиснең әти-әнисе дә өлкән яшьтә инде. Ике апасы читтә, үз тормышы, гаиләләре белән яши. Ике яктан да әти-әниләре: «Әллә, балалар, бергә торабызмы? Йорт зур, сыярбыз», – дип әйтеп карады. Рәфис, аларны кочып: «Йортны сезнең янда гына салабыз бит. Ир кеше үз гомерендә йорт салырга, ул үстерергә, агач утыртырга, үз буразнасын сызарга тиеш. Нәселебез тамыр җибәрсен өчен», – диде. Бер ел үтүгә, кызлары туды. Яңа алты почмаклы йорт, тормышлары түгәрәк. Кызларына Зөлфия дип исем куштылар. Рәфисе, районга китсә, сагынып, йөгереп кайтыр булды. Сәлимәсенә, кызына нинди генә кием-салым ташымады. «Син – минем фәрештәм. Барча хатын-кызлардан аерылып торырга тиешсең».

Саймәнең дә, әтисенең дә тазалыгы көннән-көн какшый. Хәмит абый сөяккә калды, сөйләшмәс булды. Инде эш операциядән узган иде. Эре малларын бетереп, кош-корт асрыйлар. Сәлимә хәзер өч йортка йөгерә. Мунчага чакыра. Ике якны да тигез күреп, пешкән ашын да илтә.

Саҗидә дә уку йортын кызыл дипломга тәмамлады. Беркөнне аңа көтелмәгән хәбәр әйттеләр. Укуын дәвам итәргә тәкъдим иттеләр. Саҗидә, икеләнсә дә, ризалашты. Авылга кайтып, бераз ял итеп килергә булды ул. Зөлфияне бигрәк якын итә. Кызга ике яшь тулып узды. Бик теремек. Әтисенә охшаган. Саҗидә бик күп күчтәнәч, бүләк, Зөлфиягә уенчыклар төяде.

Июль башлары. Табигатьнең иң матур мизгеле. Җиләк пешкән чор. Менә озакламый печәнгә төшәрләр. Саҗидә чалгы тавышын, күкенең гомер санаганын тыңларга ярата. Авылына якынлашкан саен йөрәге дөп-дөп типте аның. Автобустан төшеп, акрын гына туган йортына атлады. Әллә сирәк кайтканга, бик сагынган ул авылын. Саҗидә кайтуын хәбәр итеп тормады. Мәшәкатьләмәскә уйлады. Эш чоры бит, бер көн елны туйдыра. Ишектән атлап керүгә, борынына дару исе килеп бәрелде. Әнисе аш бүлмәсендә нидер әзерли. Әтисе күренми. Урамдадыр дигән уй үтте башыннан. Саймә, кызын күргәч, кулындагы чынаягын төшереп җибәрә язды: «Балам, сагындырдың бит, көн дә көттек үзеңне!» Әнисен кочаклаган Саҗидә күзләре белән әтисен эзләде. Ул акрын гына әтисе яткан бүлмәгә керде. Газиз кешесе сөяк тә тире, Саҗидәне күргәч, торып утырырга уйлады, тик булдыра алмады, хәле юк иде. Саҗидәнең йөрәге чеметеп куйды. Әтисен кочаклап, янында байтак утырды ул. Озак сөйләштеләр. Эчтән генә үзен тиргәде. «Башта ук үзем белән Уфага алып китәсе булган. Авыру тырнагыннан йолып алып калган булыр идек. Медицина көчле хәзер» дип уйлады. Әнисенә күз төшерде. Аягында киез итекләр. Күрәсең, аяклары сизми. Бүрәнә кебек шеш. Сәлимә апасы да ябыгып, тартылып киткән. Апасын кызганып куйды ул. Өч йортка өлгерә. Өстәвенә, эшкә дә чыкты. Зөлфиясен яслегә урнаштырырга уйлыйлар. Бик үткен кыз. Әтисе кебек кара күзле. Ә елмаюы – әнисенеке. Гүзәллекне әти-әнисеннән тигез алган. Саҗидәнең исә йөргән егете дә юк иде. Кино, театрга чакыручылар булды, әмма ул вакытын кызганды. Яшьлек бит бер генә килә! Аңа хәтта бераз куркыныч булып китте. Әти-әнисен янә шәһәргә хастаханәгә барырга үгетләп карады. Зур табибларга күрсәтергә вәгъдә итте. «Юк, кызым, әтиеңә соң инде. Мин исә аны ташлап китә алмыйм», – диде әнисе. Аш бүлмәсендә әнисе белән икәү генә калдылар. «Син, балам, үзеңә берәр Рәфис кебек кияү эзлә. Белем алу яхшы, әлбәттә. Тормыш корып, вакытында бәби алып кайтырга кирәк. Чәчкә дә, үз вакытында атса гына, матур», – диде әнисе.

Авылда да тормыш итү җиңел хәзер. Йортларга газ кергән. Кайберәүләр суын да өйгә керткән, бәдрәф өйдә хәтта. Авыл шәһәрдән калышырга теләми. Кибетләрдә ни телисең, шул бар. Авыл халкы эшчән, бер-берсе белән ярышып дөнья кора. Авылда мәчет тә бар. Олылар һәр җомга шунда җыела. Корбан һәм Ураза бәйрәмнәрендә халык аеруча күп була. Борынгы йолалар тергезелә.

Сәлимә баштанаяк эшкә чумды. Иҗат кичәләре, төрле бәйгеләр үткәрә. Балаларны язучылар белән очраштыра, концертлар оештыра. Сабантуй, Шәҗәрә бәйрәмнәре үтә. Өендә дә тәртип. Өе күркәм, нур уйный.

Хәмит абый 66 яшендә бакыйлыкка күчте. Бик зурлап озаттылар үзен, урыны оҗмахта булсын.

Саҗидә студентларга белем бирә. Диссертация яза. Әтисенең вафатын авыр кичерде. Өзгәләнде. Әнисен кызганды. Олы йортта ялгызы ничек

яшәр?! Сәлимә белән Рәфис, киңәшләшеп, аны үзләренә алып килде. «Зөлфиягә иптәш, безгә терәк булырсың». Җәй дә үтеп бара. Саймә елның һәр мизгелен көтеп ала. Хәмитен оныта алмый. Матур яшәде алар. Бербарсенә юл куя белделәр.

Зөлфия кайтып керсә, өй анның шат тавышыннан яңгырап тора. Тәтелдеге чыга инде менә. Эшеңне онытасың. Балалы йорт изге, нурлы була бит ул. Беркөн Саймә кызына: «Әллә кияүгә берәр малай алып кайтып бирәсеңме? Тормышыгыз түгәрәкләнер иде», – диде. «Азрак сабыр итәргә иде, әнием. Рәфиснең җиңел машинага чираты җитә, аннары уйларбыз», – диде кызы, әнисен кочып алып.

Менә Рәфисе машина алырга барырга әзерләнә. Сәлимәсен, кызын утыртып йөрергә хыялланды ул. Рәфис ике колхозда агроном булып эшли. Тырыша. Җиргә гашыйк. Ашлык игүдә дисеңме, яшелчә-җимеш үстерүдәме – гел алдынгы. Аны радио-телевизорда, гәзитләрдә гел мактап телгә алалар. Эшен яратып, җиренә җиткереп үти яшь белгеч. Кешеләр белән уртак тел таба белә. Беркөн Рәфис Сәлимәсенең саташып кычкыруына куркып уянды. Хатыны шыбыр тиргә баткан, үзе калтырана. Рәфис аны кочагына алып юатты. «Куркыныч төш күрдем. Ап-ак машинадабыз. Өчәүләп каядыр юл алдык. Бервакыт әтием пәйда булды. Сөйләшми, кулы белән нидер ишарәли. Безне чакыра. Кызым белән син юк булдың. Тонык кына булып әтинең көлгән тавышы ишетелә. Сезгә кычкырам, ишетмисез. Рәфис җаным, бу төш хәерлегә булса ярар иде дә соң. Куркам, нидер сизенәм». «Арыгансың, бастырылгансың. Ничә ел инде ял күргәнебез юк. Әбине, әти-әниләрне алып, бергәләп Кара диңгезгә барырга ниятләп торам. Әбинең аякларына диңгез суының шифасы тияр бәлки. Юраганың юш килә ул. Әйбәткә юра. Тынычлан, йокла», – диде Рәфис. Сәлимә йоклый алмады. Әнисе өйрәткән догаларны укыды. Иртән мал-туарын карап, Зөлфиясен балалар бакчасына, Рәфисен эшкә озатты. Әнисенә чәй эчерде. Саймә инәй Сәлимәнең агарып киткән йөзен күреп борчылды. «Әни, әтиемне бик еш төштә күрәм», – дип, төшен сөйләп бирде Сәлимә. Әнисенең дә төшенә еш керә икән әтисе. Хәер өмет итәдер дип уйладылар.

Күршедә дүрт балалы гаилә бар. Бик каты эчәләр. Балалары тәрбия, җылы аш күргәне юк. Интернатка да алып китеп караганнар иде аларны. Әти-әнисе, айнып, бераз кешечә яши башлагач, кире кайтардылар. Мондый тормыш озакка бармады. Авыл халкы, сабыйларны кызганып, ризыгын, киемен биреп тора. Сәлимә дә, күп итеп аш, тәбикмәк пешереп, балаларны сыйлап чыкты. Тик эшендә дә, өендә дә төше исеннән чыкмады.

Көткән көн килеп җитте. Рәфисе ап-ак төстәге «Жигули» машинасын алып кайтты. Август ае иде. Иген дә, бакчадагы яшелчә-җимеш тә котырып уңды. Рәфисе очып кына йөри. Сәлимәне, көчле кулларына күтәреп, зыр әйләндерде. Балалар кебек шаярышып алдылар. Араларында Зөлфия йөгереп йөри. Шуннан да зуррак бәхет буламы соң?! Саймә сөенеп бетәлми. Кичке аштан соң Рәфис сүз башлады: «Сәлимә, безгә әзерләнергә кирәктер. Диңгезгә дигән идем бит. Әйткән сүз – аткан ук диләрме әле? Мин үземнең әти-әнине искәртәм. Аннары путёвка хәстәрләрбез». Сәлимә карышмады. Әмма күңеле тыныч түгел иде. Саймә инәй дә сүзгә кушылды. «Олы юлда йөрергә тазалыгым юк. Кодаларны алып барыгыз. Йортка да күз-колак кирәк.

Рәхмәт, балалар, мин болай да оҗмахта яшим». Ул Рәфискә гел «балам» дип кенә дәште. Рәфиснең буш вакыты булса, онытылып дөнья хәлләрен сөйләшәләр. Сәлимәнең бераз сабыр итәргә теләге бар. Бакчасындагы яшелчә-җимешне җыеп аласы, язучылар белән очрашу үткәрәсе – тагын әллә күпме эш көтә аны. Тик Рәфисенең дә күңелен төшерәсе килми. Рәфисе очып кайтып керде дә тиз генә капкалап алды. «Кайда әле Зөлфиям? Үзем белән алам, – диде. – Әниләргә дә кереп чыгабыз. Алдан әйтергә кирәк. Әзерләнә торсыннар». Зөлфия әтисенең кочагына ташланды. «Әллә бүген үк китәбез диңгезгә? Минем йөзәргә өйрәнәсем килә». Сәлимәсен кочып-үбеп, Зөлфиясен кулына күтәреп, елмаеп, күз кысып чыгып китте Рәфис. Машинасын кычкыртып торды бераз. Кем уйлаган соңгы очрашу булыр дип... Сәлимәнең йөрәге тыныч түгел. Язмыш сынаулары һәр кешенең маңгаена язып куела диләр бит. Аллаһы Тәгалә безне сынмыйча-бөгелмичә авырлыкларны җиңәр өчен яраткан. Сәлимә белән Саймә чәй эчеп алды. Урамнан машина үткән саен тәрәзәгә йөгереп барды Сәлимә. Байтак вакыт узды. Ике күзе гел юлда булды. Бәлки берәр танышы очрагандыр дип юатты үзен. Кояш түм-түгәрәк булып офыкка тәгәрәде. Җилнең әсәре дә юк. Кулы эшкә бармады яшь хатынның. Тоткан әйбере төшеп китә. Җанына урын табалмаса да, әнисенә сиздермәде. Кош-кортларга җим салып, яшелчә-җимешкә су сибәргә дип ихатага чыкты. Эш белән мәшгуль булса, вакыт тизрәк үтәр бәлки. Киткәннәренә алты сәгать үтте. Бу вакытта районны өч тапкыр урарга була. Ниһаять, капка төбенә бер җиңел машина килеп туктады. Сәлимә бакчадан йөгереп чыкты. Бер полиция хезмәткәре, ике таныш булмаган кеше басып тора. Баш кагып исәнләштеләр. «Сез Рәфис әфәнденең хатынымы?» Сәлимәнең күз аллары караңгыланды. «Ханым, нык булыгыз! Сезгә бик авыр хәбәр алып килдек», – диде ирләрнең берсе. Күрше-күлән җыелды. Сәлимә аларның нәрсә сөйләгәнен аңларлык хәлдә түгел иде. Кемдер килеп кочаклый, кемдер елый. Аны, машинага утыртып, район үзәгенә, моргка алып киттеләр. Бер бүлмәгә алып кереп, укол ясадылар. Кан басымы күтәрелгән.

Рәфиснең машинасы өстенә «КамАЗ» барып менгән. Бер мизгелдә берьюлы иң газиз ике кешесен югалтты Сәлимә. Акылдан шашарлык. Ул үз эченә бикләнде. Кайгы диңгезендә йөзәргә насыйп иткән икән Ходай. Биреште, ябыкты. Рәфиснең әтисе Радик әфәндене өч айдан йөрәк өянәге китереп сукты. Ике ай гына урын өстендә ятты да гүр иясе булды. Саймәнең дә хәле шәп түгел. Кызының өзгәләнүен күреп, йөрәге әрнеде. Аның да башына кан сауды. Телдән язды. Саҗидә дә тиз кайтып җитте. Әнисе өч кенә көн ятты. Ул да бакыйлыкка күчте. Бөтен шартын китереп, ире Хәмит абый янәшәсенә җирләделәр аны. Саҗидә апасына кияүгә чыгуын, авырга узуын, диссертация яклавын әйтергә көч тапмады.

Сәлимә зиратка еш барды. Рәфисе кашкарый чәчәкләрен ярата иде, шуларны утыртты. Якыннарының бер рәткә тезелеп киткән каберләрен карап, чистартып торды ул. Аларга бөтен яңалыгын сөйләде, күңеле бушаганчы елады. Ялгызы яшәү бик авыр иде аңа. Ул Рәфиснең әнисен үзенә чакырды. «Ташлама мине. Кайгыбыз уртак. Җылы сүзең белән булса да ярдәмләшерсең», – дип, бианасының иңенә башын салып, озак елады ул. Зөбәйдә апа аның укытучысы да бит әле. Ул киленен кочагына алды.

Аның да йөрәге сыкрый иде. Үзенең дә аның янына барып торырга исәбе бар иде. Әйтергә җөрьәт итмәде. «Яшь бит әле. Бәлки, кияүгә чыгар» дип уйлады. Бүген исә килене үзе өзгәләнеп чакыра. Сәлимә икенче көнне үк Зөбәйдә әнисен алып та килде. Кышкы озын кичләрне бергә үткәрде алар. Яңа ел да якынлаша. Сәлимә бераз тынычлана төште. Зөбәйдә апа ул эштән кайтуга тәмле ризыклар пешереп куя. Бер-берсенең күңелен күреп яшиләр шулай. Башка чара юк. Кайгыларны вакыт тигезли. Зөбәйдә апа белән биш ел әниле-кызлы яшәде алар. Бер-берсенә шулкадәр ияләштеләр. Килене кайтмый торса, Зөбәйдә тәрәзәдән тәрәзәгә йөри, үзенә урын таба алмый. Язның ямьле бер көнендә, мунча кереп чыккач, Зөбәйдә: «Хәлем китеп тора, балам», – дип, ятып торырга булды. Шул килеш мәңгелеккә күзен йомды ул. Сәлимәнең һич тә ышанасы килмәде. Дару төймәсе дә капканы юк иде бит аның. Төрле үлән чәйләре эчеп, дөрес тукланып яшәде. Сәлимә тагын ялгыз калды. Көндез эштә, кич мал-туар арасында, бакча карый. Җәй көне ялгызлык артык сизелми. Кышкы кичләрдә авыр. Үзен кая куярга белми. Кулын сорап килүчеләр дә, димләүчеләр дә күп булды. Йөрәгенә берсен дә кертә алмады ул. Мәхәббәтенә тугры калды.

***

Ә менә бүген тормышында көтмәгәндә сәер юлчылар пәйда булды. Уйларыннан арынып, алардан нидер сорамакчы булган иде дә, тегеләре йоклап та киткән. Баланың хәле начар. Авылда фельдшер бар да ул, тик вакыт соң инде. Бераз уйланып торгач, Сәлимә, киенеп, Гадилә апага китте. «Төнге ачы суыкта кем йөри тагын?» – дип, ишекне ачты фельдшер. Ишек катында, елардай булып, Сәлимә басып тора. Ул аны өйгә чакырды. Сәлимә барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Гадилә, кирәк-ярагын алып, ашыга-ашыга, Сәлимәгә иярде. Баланы карады. «Үпкәсе кабарган. Тиз арада хастаханәгә илтергә кирәк», – диде. Укол ясады, дару төймәләре эчертеп китте. Зур кара күзле, матур кыз бала. Иртәнге якка бала да, Сәлимә дә йоклап китте. Шундый каты йоклаган ул, хәтта юлчыларның өйне актарып йөргәнен дә сизмәгән. Мәчесенең мыраулаганына уянып китте Сәлимә. Җәһәт кенә торып, аш бүлмәсенә керде. Өстәл әзерләп, ишекләрен шакып караса, җавап бирүче юк. Ишекне ачса, «кунакларыннан» җилләр искән. Ары сугылды, бире сугылды Сәлимә, күршеләрен чакыртып кертте. «Баланы онытканнар бит. Тукта, берәр язулары бардыр, бәлки». Ул залга кереп китте, үз күзләренә үзе ышанмыйча, туктап калды. Сервант ишекләре шар ачык. Пыяла чәйнүктә алтыннарын саклый иде. Ул өстәлдә тора. Алтыннар да, саклаган акчалары да юк. Сәлимәнең күз аллары караңгыланды. Чайкалып куйды. Ярый, Гадилә апасы тотып калды. Кәгазь кисәге табып алдылар. Бик хаталы язылган, аңлап бетерерлек түгел. «Сәлимә апа, кызыбызны сезгә калдырабыз. Бүләк итәбез. Яшәр урыныбыз да, ашарга бер сынык икмәгебез дә юк. Бу безнең баладан баш тарту турындагы имзабыз булыр. Акчаларыңны, алтыннарыңны без алдык. Безне эзләтмә. Гомер булса, бәлки, китерербез. Хушыгыз. Декабрь, 1976 ел».

«Бу Ходайның бүләге бит. Зөлфия дип кушам исемен. Ишетәсеңме, Гадилә апа, Зөлфия! – дип, кат-кат кабатлады Сәлимә. – Тик берәр чарасын күрик инде. Районга хастаханәгә алып барыйк». Күрше-күлән:

«Милициягә хәбәр итәргә кирәк, – дип борчылды. – Оятсызлар, талап чыгып киткәннәр». Сәлимә сабыйны күкрәгенә кысты, баланы тартып алырлар дип курыкты. Башын югары күтәреп: «Рәхмәт сезгә. Авыр хәлдә ташламадыгыз. Миңа тиз арада машина кирәк. Һәр минут кадерле. Бернинди милициягә әйтмәскә», – диде ул. Бу хәбәр дулкын кебек авылны айкап чыкты. Олы яшьтәге бер абзый «Нива» машинасы белән районнан көн дә гәзит-журнал, хатлар ташый. Суык дими, буран, яңгыр дими. Елмаеп килеп керде дә: «Сезгә җыеныргa 15 минут. Китәбез», – диде. «Йортың өчен кайгырма. Исән-имин терелеп кайтыгыз», – дип озатып калды күршеләре. «Юлда балага ярдәмем кирәк булыр», – дип, фельдшер да утырып барасы итте. Сәлимә бала белән ай ярым хастаханәдә ятты. Табиблар үлем кочагыннан йолкып алып калды сабыйны. «Исәпкә куябыз, язлы-көзле дәваланмыйча булмас. Үсә төшкәч, диңгез һавасы таләп ителер, санаторийларга йөрергә туры килер», – диде алар. Сабый кайсы ягы беләндер Зөлфиясен хәтерләтте Сәлимәгә. Аңа бер ел декрет ялы бирделәр. Янә тормышына ямь керде. Ул хәзер ялгыз түгел. Яшәү максатына ия булды. Сыерын бетереп, кәҗәләр алды. Балага кәҗә сөте файдалы диделәр. Балага нәрсә генә бәйләп кидермәде ул.

Беркөнне сеңлесе Саҗидәгә ике бит хат язып җибәрде. Бик горурлана аның белән Сәлимә. Профессор дәрәҗәсенә үрләде. Иптәше Надыйр да – зур галим, икесе дә институтта эшли. Кызлары Раушаниягә биш яшь. Тормышлары түгәрәк. Шәһәр үзәгендә дүрт бүлмәле фатирда яшиләр. Күзләр генә тимәсен. Әти-әнисе генә күрә алмады. Җәй көне гаиләсе белән Саҗидә кайтып төште. Үз машиналарына күп итеп күчтәнәч, бүләкләр төягәннәр. Саҗидә тагын да чибәрләнгән. Чәчләрен кистергән, шәһәр хатыннарына охшап калган. Бераз түгәрәкләнгән. Зөлфиягә бер яшь тә тулмады әле. Уйный, алдата башлады. Раушания белән бик тиз дуслаштылар.

Сәлимә – уңган хуҗабикә. Өе пөхтә, аш-суга оста, бәйрәмнәрдә, Коръән ашларында камыр ризыкларын аңардан пешертәләр. Әнисеннән өйрәнеп калды ул аш-су пешерү серләренә. Тәмле аштан соң мунча да өлгерде. Мәтрүшкәле себерке, кәҗә сөтеннән кымыз, каклаган каз, корт, сөт өсте, чөгендерле катык, мичтә бәлеш – җаның ни тели, барысы бар. Икенче көнне әти-әнисе, ире, кызына багышлап, Коръән укыттылар. Каберләрне тазартып, буяп кайттылар.

Сәлимәнең күптән борчыган уе бар иде. Икәү генә калгач, сүзне кайдан башларга белми аптырап бетте ул. «Йә, апа, тыңлыйм. Ниләр борчый үзеңне?» – диде Саҗидә. «Бер үтенечем бар. Әти-әни йортын сатсак, ничек булыр икән? Зөлфияне дәваларга акча кирәк. Чире көчәеп китәр дип куркам. Ул йорт синеке дә бит». Саҗидә, апасын кочып: «Ул йорт синеке генә. Әти белән әнине карадың. Мине укытырга ярдәм иттең. Акчаң җитмәсә, үзем дә өстәрмен», – диде. Сәлимә сеңлесенең каршы килмәсен белә иде. Әмма үзе генә сатып җибәрергә батырчылык итмәде.

Бер атна рәхәтләнеп ял итте алар. Бернинди чит яклар кирәкми. Табигате, урман-тавы, җиләк-җимеше дисеңме. Сокланып туя алмаслык! Надыйр су буенда балык чирттерә. Саф һава сулап кинәнде, хозурланды ул. Юлга чыгар алдыннан зиратка барып килделәр.

Сәлимә йортны сатып җибәрде. Акчасын саклык кенәгәсенә күчерде. Аның бар максаты – баланы аякка бастыру. Зөлфиясе быел беренче сыйныфка барды. Укырга тиз өйрәнде ул. Исәп-хисабы исә авыррак. Беркөнне Сәлимә эштән кайтып килә иде, күршедә торган югары сыйныф укучысы бер кәгазь тоттырып китте. Аны мәктәпкә чакыртканнар иде. Бераз каушап калды. Башыннан мең төрле уй узды. Йөгерә-атлый мәктәпкә ашыкты: «Авырып китмәсен тагын», – дип, сулышы кабып, Зөлфиянең сыйныф бүлмәсенә барып керде. Дәрес беткән, балалар таралмаган. Укытучы олы яшьтә. «Борчылмагыз, бар да яхшы. Чакыртуымның сәбәбе башка. Кызыгызның тавышы бик моңлы. Җыр дәресендә аны тыңлап карадык. Җыр түгәрәгенә язылсагыз, сезгә авыр булмасмы? Кайсы баланың нәрсәгә сәләте барлыгын җентекләп тикшерергә һәм ул сәләтне үстерергә ярдәм итәргә тиеш без. Тормышта дөрес юл сайларга. Без һәр баланың җәмгыятькә файдалы кеше булып үсүен телибез. Дөрес сулыш алып җырлау кызыгызга файдага гына булыр», – диде ул. Сәлимә бераз икеләнеп калды. Алай да каршы киләлмәде.

Гомер уза торды. Кызы дүртенче сыйныфны тәмамлый инде хәзер. Вак-төяк эшләрен төгәлләп, тагын диңгез буена барып кайтырга ниятли Сәлимә. Кызына диңгез һавасы бик килеште. Соңгы тапкыр күренгәндә, табиб кызның тәмам савыгуын әйтте. Тик сакланырга киңәш итте. Рәфиснең апалары да үзләренең йортын сатарга ризалашты. Алар да Сәлимәгә кайтып йөри. Бик хөрмәт итәләр үзен. Сәлимә йорт акчасын тигез итеп барысына бүлеп бирде. Апалары баш тартып караса да, кире алмады. Үз өлешен банкка салып куйды. Кызы үскән саен күңеле тыныч түгел иде. Үз әнисе килеп алып китәр төсле. Кайчак саташып, куркып уяна. Кызы тирә-як авылларга барып җырлап йөри башлады. Авыл халкы серне саклый белде. Зөлфиягә дөресен сөйләргә берәү дә җөрьәт итмәде. Кыз үзе генә кайчак әтисе турында кызыксынды. Юл казасына очрады диюдән ары узалмады Сәлимә.

Бүген нишләптер йөрәге сыкрый әле. Нидер сизенгән кебек. Эшендә бар да яхшы. Янына бер яшь кыз китерделәр. Аны эшкә өйрәтә. Бик тырыш кыз. Сәлимәнең эше күпкә җиңеләйде. Шулай уйга чумып утырганда, китапханәгә иптәш кызы белән Зөлфиясе йөгереп килеп керде. «Әнием, әнием. Безгә ике апа килеп керде. Сине сорадылар. Берсе миңа шундый итеп карады, башымнан сыйпамакчы булды. Мин кулын этеп җибәрдем. Үзләре сәләмә киемдә. Әнием, аларны йортыбызга кертмә, ярыймы», – дип ачыргаланды бала. Сәлимәнең кулыннан китаплары төшеп китте. Башы әйләнде, күз аллары караңгыланды. Тиз генә үзен кулга алып, Зөлфиясен күкрәгенә кысты да: «Балам, сез мин килгәнче биредә торыгыз. Беркая чыкмагыз. Зинһар өчен, сүземне тыңлагыз!» – диде. Бу сүзләр балаларга ничектер сәер тоелды. Тик әнисе сүзен тыңлады Зөлфия. Юлда очраган кешеләргә баш кына какты Сәлимә. Хәле бетте, йөрәге дөп-дөп типте. Йорты янында ике хатын тәмәке көйрәтеп тора. Үзләре әшәке итеп сүгенә.

Сәлимә аларны тиз таныды. «Ун елдан соң бу бәдбәхетләргә ни кирәк тагын?» дигән уй үтте башыннан. Чирканып, нәфрәтле карашын ташлады. «Сөйләшәсе сүз бар. Өйгә узыйк», – дип әмер бирде тегеләр. Әйтерсең хуҗалар.

Сәлимә чәй куеп җибәрде. «Бәлки явыз ният белән йөрмиләрдер. Урлаган алтыннарымны, акчаларымны китергәннәрдер». Сәлимә аларны өстәл артына чакырды. Кабалана-кабалана ашарга тотындылар. Берсе пакетыннан сыра, ислəнгән колбаса тартып чыгарды. «Өстәлдә азык җитәрлек. Үзегез белән алыгыз. Юлда ашарсыз», – дип кырт кисте Сәлимә. Этләрдән юньсез икән болар, ашый да белмиләр. Газиз әниләре күкрәк сөтен имезеп үстергәндер бит инде аларны да. Ун елда күпкә картайган бу хатыннар. Авызларында тешләре юк. Чәчләре каткан, яртысы агарган. Зөлфияне тудырган кешенең күз төбе күгәргән. Кулларында, хәтта бармакларында әллә нинди сурәтләр. Кот очарлык. Хатын-кыз исеменә тап төшереп яши бу хәшәрәтләр.

Тамакларын туйдыргач, иркенләп сүз башлады «кунаклар». «Менә нәрсә, чибәркәй. Безгә күп акча кирәк, сиңа өч көн вакыт бирәбез. Теләсә кайдан тап. Бер дә булмаса, йортыңны сат, ишетәсеңме?» Сәлимәнең эченә җылы йөгерде. «Бу адәм актыкларын акча гына кызыксындыра икән. Бала кирәкми, телгә дә алмыйлар», – дип уйлады ул. «Мин ул акчаны каян алыйм? Кызым авыру. Әти-әниемнең йортын сатып, баланы дәваладым», – диде ул. «Ә син табарга тырыш. Кызың кадерле булса». «Бала минеке. Ташлап качтыгыз. Мин аның әнисе. Шул бала өчен генә яшим». Тегеләр хатынның йөрәк авазын ишетмәде дә. Бу вөҗдансызлар кеше затыннан түгелдер. Сүз көрәштереп тормаска булды Сәлимә. Акчаның ни өчен кирәклеге белән кызыксынасы итте. «Урлашкан өчен, өлкәннәрне алдап, акчаларын талаган өчен төрмәгә утырттылар безне. Икешәр тапкыр утырдык. Бүген торыр урыныбыз юк. Эшкә алмыйлар. Һөнәребез дә юк», – дип сөйләп бирде Зөлфиянең «анасы». Сәлимә тынын, ушын җыялмыйча утырды. «Баш исән булса, акчасы табылыр. Сынаулар бетмәгән икән әле. Балама гына тимәсеннәр», – дип юатты ул үзен.

Кызын танылган җырчы итеп күз алдына китереп, киләчәкнең матур мизгелләрен көтеп яши иде. Быел иң яхшы шифаханәгә бармакчылар иде. Ходай кушмагандыр, күрәсең. Өч көн ашамады, йокламады. Зөлфиясен күрше авылга, әнисе ягыннан туган тиешле агасына кунакка җибәрде. Агасы белән җиңгәсенә хәлен сөйләп бирде. Рәфис туып-үскән йортның акчасын, ачы күз яшьләренә төелә-төелә, теге кабахәтләргә әзерләде. Өч көн дигәндә килеп керделәр. Бер ир дә ияргәннәр. Чәй кузгатмады. Алдым-бирдем дигән язуына имза куйдырды. Артларына әйләнеп тә карамыйча, авылдан чыгып чаптылар.

Бер-бер артлы еллар узды. Зөлфия 10 нчы сыйныфны тәмамлый. Аны зур концертларга чакыралар. «Сандугач» дип йөртә авыл халкы. Бәйгеләрдә, фестивальләрдә катнашып, лауреат булды. Сәлимә кызы белән горурланып бетә алмый. Иртә-кич догаларын укый. Начар күзләрдән сакласын Ходай дип тели. Концерттан соң Сәлимәгә рәхмәт әйтәләр. Кунакка чакырып йөдәтәләр. Ул – бәхетле ана.

Беркөнне ул Саҗидәләргә кунакка җыенды. Күптән кайтканнары юк. Сагынды үзләрен. Раушания әти-әнисе юлын сайлады. Институт тәмамлый. Уллары Илдар алтынчы сыйныфта. Җәй җитсә, Сәлимәдән китми дә. Авыл малае була да куя. Балык тота, җиләк-җимеш җыя. Чүкеч-кадак тотып, ихата-кураны төзәтә. Апасын йөдәтә, шаяралар, җырлата. Көн буе мәш

киләләр. Йортка бала тавышы ямь өсти. Саймә: «Балалы йортта фәрештәләр канат җәя», – дияр иде.

Зөлфия белән иртәнге автобуска утырдылар. Районга кадәр баралар. Аннары электричкада. Саҗидә Зөлфияне зур җырчыларга тыңлаттырган иде инде. «Укуын бетерсен, көтәбез», – диделәр. Менә ул көн килде. Электричка көтеп торганда, почта ташучы абый пәйда булды. «Сезне Уфага китте диделәр. Чак өлгердем. Телеграмма бар сезгә». Сәлимә аптырап калды. Телеграмма көтми иде ул. Уфага чакырганнар булып чыкты. Урамы да, телеграмманы җибәргән кеше дә таныш түгел.

Поезддан Саҗидәнең ире белән улы каршы алды аларны. Төн буе сөйләшеп, яшьлек хатирәләрен искә төшереп утырдылар. Бәндә олыгая барган саен туганлык хисләре көчәя төшә шул. Саҗидә, апасына карап, сокланып утырды. Бүгеннән кияүгә чыгып, ир иркәсе булып яшәрлеге бар. Ул исә Рәфисенә тугры. Шулкадәр көчле мәхәббәт булган, күрәсең.

Сәлимә сеңлесенә телеграмманы күрсәтте. «Апам, без өчәү барырбыз анда. Балалар өйдә калып торыр», – диде Саҗидә. Иртән торгач, Саҗидә иренә хәлне аңлатып бирде. «Ярый, сөеклем. Сез әзерләнә торыгыз. Мин хәзер машинаны кабызам», – диде ире. Саҗидә иренә назлы карашын ташлады. Алар бер-берсен ярты сүздән аңлый иде. Шундый тату гаиләдә тәрбияләнгән балалар да җәмгыятькә кирәкле кеше булып үсә.

Догалар укып, юлга кузгалдылар. Шәһәрнең читендә урнашкан урам. Искергән авыл йортлары. Бараклары да байтак. Урам шыксыз, пычрак, бар җирдә чүп-чар. Үзләренә кирәк йортны чак эзләп таптылар. Йорт авышкан, бик иске, йорт димәсәң, хәтере калыр. Капка төбе саен кеше өелешеп тора. Сәрхушләрдер, күрәсең. Машина туктауга, урта яшьләрдәге бер хатын килде. «Сез Сәлимә буласызмы?» – дип сорады ул. Сәлимә аптырап калды. Аны каян беләләр икән? «Әйдәгез, хәзер барысын да аңлатам», – дип, өйгә чакырды аларны хатын. Өй җиргә сеңгән, ишек ачып керүгә, борынны ярып, сасы ис килеп бәрелде. Җимерелеп беткән җиһаз. Алгы якта түрдә мәет ята. Өстенә кайчандыр ак булган чүпрәк япканнар. Сәлимәгә аңлатып торуның кирәге калмады. Бу Зөлфияне тудырган хатын – Клара иде. Каршы алган хатын бер язу белән пакет тоттырды. Язуны Клара язып калдырган иде: «Үткән тормышны кире кайтарып булсачы... Сәлимә ханым, сезгә үтенечем зур. Мине соңгы юлга бөтен шартын китереп озатыгызчы, зинһар! Сезнең олы йөрәкле кеше икәнегезне белеп язам бу юлларны. Бу иске йорт яны биләмәсе – 15 сотый. Кызыма яздырдым. Сезне каршы алган хатын Рәшидә – минем ерак туганым. Ул сезгә документлар бирер. Зөлфия кызыма, кирәк дип тапсагыз, сөйләрсез. Үз ихтыярыгыз. Зинһар, барысы өчен дә кичерегез мине». Бу хатын соңгы минутында булса да үзенең нинди хата эшләвен аңлаган, димәк. Сәлимә, күз яшьләренә төелеп, Клараның табуты янында байтак басып торды. Күңелендә аңа карата кызгану хисе дә, нәфрәт хисе дә урын алган иде. «Тынычлан, апам, барысына да үзе гаепле. Җирләү хәстәрен күрик», – диде Саҗидә.

Кларaны, бөтен шартына туры китереп, җир куенына тапшырдылар. Рәшидәдән башка туганнары күренмәде. Сәлимә сукбайларга хәер, ризык таратып чыкты. «Җир йөзендә кеше кебек яшәсәләр, ни була инде?! Ходаем, яман-явызлардан үзең сакла», – дип, тизрәк бу упкыннан китәргә ашыкты ул.

Тагын бер ел вакыт узды. Зөлфия җыр буенча укырга керде. Үзен бик тиз танытты ул. Композиторлар аңа атап җыр иҗат итте. Саҗидә апасында тора. Раушания апасы Мәскәүдә аспирантурада укый. Илдар әле мәктәптә. Сәлимә кызына, тотылган булса да пианино сатып алды. Саҗидәгә дә рәхәт Зөлфия белән. Аның җырлаганын тыңлап туялмый. Ире Надыйр да шат. Өйгә сандугач очып кердемени! Кунак килсә, бәйрәм табыннарында кат-кат җырлаталар. Сәлимә ике атна саен төянеп килеп йөри. Саҗидә орышып та ала аны. Юк, тыңламый. «Берьялгызым бит мин. Бу кадәр ризыкны ничек ашап бетерим? Шул кызым дип яшим дә инде мин. Бер сүз әйтмәгез...» – ди. Зөлфия әнисен, авылын, күрше-күләннәрен өзелеп сагына. Ике атнадан каникуллары башлана. Түземсезлек белән көтә ул аны.

Соңгы килүендә әнисе ачылмаган сере барлыгын әйтте, авылга кайткач, иркенләп сөйләргә вәгъдә итте. Зөлфиягә әнисе белән икесе арасында бернинди сер дә юк кебек тоела иде. Әнисенең бу сүзләре бик кызыксындырды аны.

Укуының беренче елын бик яхшы билгеләргә генә тәмамлады Зөлфия. Саҗидә белән Надыйр, күчтәнәчләр төяп, Илдарны да алып, үзләре кайтарды аны. Июнь ае. Гүзәллеккә сокланып туймаслык. Зөлфия шатлыктан күкнең җиденче катында йөзә. Ул туган авылының тугай-басуларын, урман-күлләрен, бигрәк тә әнисен өзелеп сагынган. Авылга бер-ике километр чамасы калгач, Зөлфия машинадан төшеп калды. Урман кырыендагы бер аланда туктап, яшел хәтфә үләнгә сузылып ятты. Офыктагы ак болытларны күзәтте. Төрле рәвешкә кереп агыла алар. Берсен-берсе уздырып, кошлар сайрый. Сирәк кенә күке кычкырып куя. Агачлар ямь-яшел күлмәктә. Биектә-биектә, ак юл сузып, самолёт оча. Эх, шул самолётларга утырып, хыялыңа каршы очсаң иде! Янында гына нидер кыштырдады. Караса... йомран. Зөлфия кычкырып җибәрде. Йомран, минем синдә эшем юк дигәндәй, үз юлына китеп барды. Хыял диңгезендә йөзгәннән соң, Зөлфия авылына таба атлады. Кычкырып «Сәлимәкәй»не җырлап җибәрде. Моңургылды. Урман шаулады. Җырлап бетерүгә, ул кемнеңдер кул чабуына сискәнеп китте. Күрше абыйсы икән. «Һай, кызым, афәрин! Үзәкләрне өздең. Бәхетең генә булсын инде. Әйдә, утыр арбага». Зөлфия, рәхмәт әйтеп, баш тартты. Болын чәчәкләре җыя-җыя, алга атлады. Күбәләкләр, бал кортларын күзәтте. Авылда яшәгәндә, бу гүзәллеккә игътибар итмәгән ләбаса ул! Ул кайтып кергәндә, өйгә тәмле бәлеш исе таралган иде. Мунча да өлгергән. Әнисе кызын кочаклап алды. «Әнием, өзелеп сагындым сине». Өч атна өч ел кебек тоелды. Табынга утырдылар. Әнисенең һәр ризыгы ашап туймаслык иде. Илдар, аннан-моннан капкалап, урамга чыгып чапты. Дуслары көтә иде. Саҗидәләр мунчага китте. Зөлфия әнисе белән генә калды. «Әнием, минем сиңа бүләкләрем бар». Зур сумкасыннан мамык шәл, йон кофта, күннән тегелгән аяк киемен чыгарды. Бераз акча да чыгарып салды. Сәлимә каушап: «Балам, чын дөресен әйт. Бу кадәр акчаны кайдан алдың? Апаң беләме?» – дип сорады. «Әни, җаным! Утыр әле. Хәзер сөйлим. Мин бит булачак җырчы. Безне, сирәк кенә булса да, концертларга катнаштыралар. Төрле бәйгеләргә чакыралар. Стипендия дә алам. Апаларда бушка яшим бит. Бар акча янга кала». Сәлименең күзләреннән шатлык яшьләре акты. «Әнием, елама. Апама, җизнәмә, Илдарга да бүләкләр

алдым». «Ышанам, балам. Сайраган сандугачны туктатырга хакым юк минем. Син – Ходай бүләге. Кешеләргә рухи азык өләшәсең. Моңың белән шатлыкларын уртаклашасың, кайгыларын таратасың». Ул кызын күкрәгенә кочты. Бу минутта алар икесе дә бик бәхетле иде.

Саҗидәләр бер атна кунак булды. Илдарны авылда калдырдылар. Сәлимә, күңелендә йөрткән серне чишәргәме-юкмы дип, озак икеләнде. «Мин әйтмәсәм, барыбер берәрсе әйтәчәк» дип уйлады. Кызы белән алмагач төбенә эшләнгән эскәмиягә чыгып утырдылар. Ялгыз калган чакларда шул алмагачларны кочып серләшә иде Сәлимә. Елап, аларга күңелен бушата иде. Төнгә авышып бара. Күктә йолдызлар күз кыса. Йомшак кына җил исә. Хозурлык! Тамагындагы төерне йотып, акрын гына сөйли башлады Сәлимә. «Балам, башымнан үткәннәр әкият итеп сөйләрлек. Тыңла». Күпме утырганнардыр, сәгатькә карамадылар. Зөлфия, әнисенә сыенып, мыш-мыш елый иде. Юатмады аны Сәлимә. Зөлфия, кинәт кенә урыныннан торып, әнисенең сөялле кулларыннан, күзләреннән үпте. «Әни, җаным. Синең кебек кеше Җир йөзендә юк. Яшьлегеңне, тоташ гомереңне кеше баласына багышлагансың. Минем өчен нинди авырлыклар кичергәнсең син. Рәфис абыйга, саф мәхәббәтеңә гомер буе тугры калгансың. Бу – зур батырлык. Синең белән горурланам мин, әнием». Сәлимә кызының тирән мәгънәле сүзләренә куанып утырды. Дөрес тәрбия бирә алган ул аңа, димәк. «Кызым, соң инде. Кереп ятыйк, әйдә», – диде Сәлимә. Шулвакыт күктә йолдыз атылды. Ана белән кыз йолдызларга сәлам бирде. «Әнием, борчылма, барысы да артта калды. Бу вакыйгаларны бер авыр төш кенә дип исәплик». Сәлимә иңендәге авыр йөктән котылды бүген. «Кызым, әнә тагын бер йолдыз атылды. Бу безнең йолдызыбыз булсын. Киләчәк тормышыбыз шушы якты йолдыздай балкысын», – диде Сәлимә. Алар, кочаклашып, өйгә атлады.



*Сагыныш Мохит кызы 1986 елда Казакъстанның Кызылорда өлкәсе Казалы районы Майдакөл авылында туган. 2007 елда Коркыт Ата исемендәге Кызылорда университетының филология факультетын тәмамлый. Бүгенге көндә ул – казакъ теле һәм әдәбияты укытучысы.*

*2019 елда «Сырүя» исемле җырлар җыентыгы дөнья күрә.*

Сагыныш
Мохит кызы

# АНА ТЕЛЕМ – АЛГА ӘЙДӘР БАЙРАГЫМ!

## Туган җир белән сөйләшү

Көнчыгыштан кояш чыкты, сәлам бирде,
Бәхетле мәл: шигырь туды шулчак җанда.
Кулымда ак каурый каләм: язам, язам,
Күзем күргән һәр мизгелем, әйе, алда.

Күгем кебек ерак булды хыялларым,
Тыңлап барамын кәс-кәс кенә басканым.
Мин әле дә үзем өчен борчылмыймын,
Уемда хәле үз халкымның, башканың...

Янам барлап тарихым  чын йөрәктән,
Күпме көнем үткән шулай, ел үткән.
Мин бер кызың, халкым, сине яраткан,
Илем диеп яшим элек-электән.

Җилең булыйм микән әллә, әй дала,
Халкымның бит мөлкәт, нары син генә.
Кара җирем –  минем кара байлыгым,
Бер карышын бирмәм ятка, чигенмәм!

Тауларың да, үрләрең дә – минеке,
Җилләрең дә минеке бит, комың да.
Әйтерсең лә баштагы таҗ һәр үрең,
Далада ятар мөлкәт инде чынында!

Йә, исәнме, маңгаемнан үпкән җил,
Бабаларым йорты – далам – минем ил.
Дала сөяр ак нурга гашыйк җан булсаң,
Җырлыйк бергә, янәшәрәк, әйдә, кил!

## Газиз кешем

Туры килгән син генәдер холкыма,
Бәхет көтеп менәм яшәү үренә,
Мәхәббәтең җитәдер бер гомеремә,
Газиз кешем.

Чебен тимәс чер итүче холкыма
Түзүче, сөенүче уңышыма,
Син генә бит, сокланамын ушыңа,
Газиз кешем!

Игелек аша баккан күзең моңына,
Яратыплар каравыңа толымыма,
Сөенәм аны мөлкәт дип торуыңа,
Газиз кешем!

Йөрәгеңә тик мин генә сыялган җан –
Кадерле кешем!

***

Бер мизгел бар
Өметләрне өздермичә ялгаучы,
Бер мизгел бар
Хыялымны янган уттай ялмаучы.

Бер мизгел бар
Танытыр ялган һәм хакны,
Бер мизгел бар
Хәтерләткән учакны.

Бер бакча бар –
Гөлләреннән ямь алдым.
Бер бакча бар
Ераклыкта мең адым.

Бер бакча бар –
Мин омтылып торамын.
Бер бакча бар –
Сокланудан армамын.

Бер кеше бар
Җан-күңлемә нур бөркер.
Бер кеше бар
Таң нурыдай сирпелер.
Бер кеше бар
Буйсынмаган миңа да.
Бер кеше бар
Яшәвем бит шуңа да.

## Алмачы гаепкә

Сабырым, син җанга керерсең,
Мин түгел, көемнең син име.
Күңелгә син дәва. – Билгеле
Сәбәбе.

Килерсең көттерми бер көнне,
Көтәм дә, килмисең дип янмам.
Сабырым – калканым, шуңа мин
Ышанам.

Тәкъдирем йөрткән юлларда
Җанымны моңнарым дәвалар.
Сабырсыз көн кичү кыен дип,
Сүз елар.

Сабырлык, китмәче калдырып,
Мин сиңа рәхмәтле, юк үпкә!
Яшәвем – яратып, ышанып,
Алмачы гаепкә!

## Ана теле

Ана телем – минем рухи бәйрәмем,
Туган телдән табалмадым баерагын.
Синең аша әйттем бары сүземне
Ана телем – алга әйдәр байрагым!

Ана телем!
Синең аша белдерә алам серемне,
Туган телдә язам бары җырымны.
Яман уйлар буып торса тынымны,
Ак хисләрем биләп ала моңымны.

Телем белән бәйле гомер, насыйбым,
Телем барда куркусыз мин, көчлемен.
«Тел белгече» саналамын.
Иң гадел
Бәһасе шул минем Тәкъдир эшенең.

*Казакъчадан* **Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА** *тәрҗемәләре.*

# КИЛӘЧӘККӘ ЙӨЗ ТОТЫП

Иҗтимагый-мәдәни тормышның һәр өлкәсендә үсеш-үзгәреш аерым шәхесләр эшчәнлегенә бәйле. Милли мәдәнияттә гаять мөһим урын алып торган матур әдәбият һәм аны өйрәнү фәне үсешенә зур өлеш керткән әнә шундый шәхесләрнең берсе – филология фәннәре докторы, профессор, академик, ТРның атказанган фән эшлеклесе Дания Фатих кызы Заһидуллина. Аллаһка шөкер, әдәбиятыбыз зур булган кебек, аны тикшерү, бәяләү фәне дә, соңарып мәйданга чыгуга карамастан, бу өлкәдәге ихтыяҗга җавап биреп килә. XX йөз башында Җ.Вәлиди, Г.Сәгъди, Г.Баттал, Г.Ибраһимов, Г.Исхакый һ.б. тырышлыгы белән беренче адымнарын ясаган әдәбият белеме, берничә буын галим-голәмә тырышлыгы белән татар сүз сәнгатенең ерак тамырларыннан алып хәзергесенә кадәрге тарихын, халык тормышы белән тыгыз бәйләнешен, традицияләрен һәм закончалыкларын, аерым шәхесләрнең ролен һ.б. тикшерүдә җитди казанышларга ирешә. Аерым мәктәпләр, фәнни концепцияләр ил күләмендә, шулай ук төрки дөньяда танылу ала. Д.Ф.Заһидуллина әдәбият фәне өлкәсенә XX гасыр ахырында килә һәм танылган галимнәр, укытучы-остазлары М.Хәсәнов, Й.Нигъмәтуллина, Р.Ганиева, Т.Галиуллин, Г.Халит, Н.Юзиев, Н.Хисамов, М.Гайнетдинов, А.Әхмәдуллин, Х.Миңнегулов, М.Бакиров, М.Мәһдиев, Ф.Галимуллин, А.Яхин һ.б. ярдәмендә әзерлекле, киң белемле, эрудицияле белгеч булып җитешә. Аларның эшләрен уңышлы дәвам итеп, үзенең мәктәбен булдыра, соңгы еллар татар әдәбияты фәнен әйдәп баручы галим булып үсә. Билгеле, бу өлкәдә эшләүче галимнәребез шактый күп булып, һәрберсенең үз урыны бар. Дания Фатих кызының эшчәнлеге исә киңлеге, масштаблы булуы, әдәбият теориясе, әдәбият тарихы, әдәби тәнкыйть өлкәләрен иңләп алуы һәм аларны ил, дөнья әдәбияты фәне яссылыгында тикшерүе белән аерылып тора. Төрле халыклар әдәбиятын һәм фәлсәфә, сәнгать, психология, социология, тарих, педагогика кебек фәннәрне яхшы белүе аңа милли әдәбиятларны тикшерү методологиясен, методларының яңа юлларын, форма-алымнарын табу, үстерү мөмкинлеге бирә. Бу көннәрдә үзенең гомер бәйрәмен – юбилеен билгеләп үтүче Дания Фатих кызы Заһидуллинаны киң җәмәгатьчелек күпсанлы шәкертләрнең укытучы-остазы, мәктәп укытучыларының киңәшчесе, принципиаль тәнкыйтьче һәм әдәби-мәдәни мирасны киң катлам укучыларга җиткерүдә күп көч куючы әдәбиятчы-галим буларак белә. Аның кебек үз эшенең чын профессионалы һәм шәхес буларак, зыялылык үрнәге күрсәтеп, шул ук вакытта гадел һәм киң күңелле, намуслы һәм тыйнак, ярдәмчел һәм гади булып кала алу бик азларга бирелә. Боларның нигезе, билгеле инде, гаиләдә, ул тәрбияләнеп үскән мохит аша салына.

Дания Фатих кызы Заһидуллина 1964 елның 1 октябрендә Мөслим районы Әмәкәй авылында туган. Мәктәптә укыган елларда ук әдәбият-сәнгать дөньясы белән кызыксына башлый, шигырьләре район газетасы битләрендә дөнья күрә. Дөньяга карашын формалаштыруда, әдәбиятка тартылуда сыйныф җитәкчесе Гөлсәрия, рус теле һәм әдәбияты укытучысы Асия апаларының, башка укытучыларның йогынтысы зур була. Татар теле һәм әдәбияты укытучы буларак мәктәпкә яшь язучы Факил Сафинның кайтуы, әдәби иҗат белән кызыксынуны, омтылышны бермә-бер арттыра. Район газетасы каршындагы әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе Фоат Садриевның җылы сүзен ишетү дә яшь авторның хыял-омтылышларын үстереп җибәрә. Гомумән,

әдәбиятка булган игътибар, мәктәптәге һәм районнагы иҗади мохит Дания Салиховага (кыз фамилиясе – ред.) беренче чирканчык алырга, иҗат серләренә төшенергә ярдәм итә. Башка фәннәрдән дә бик яхшы укуына карамастан, ул киләчәген әдәбият белән бәйләү фикеренә килә һәм Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә юл тота. Университетта уку еллары яшь кызга яңа канатлар куя. Ул М.Мәһдиев җитәкчелегендәге «Әллүки» түгәрәгенә йөри. Проза остасы булып танылган, әдәбиятны шәхесләр аша һәм архив материаллары белән үреп, гаять кызыклы, гыйбрәтле итеп студентларга җиткерүче Мөхәммәт абыйны остазларының берсе дип саный. Аның татар сүз сәнгате, бигрәк тә XX йөз башына караган лекцияләре Дания Салиховага әдәбият фәненең мавыктыргыч дөньясын ача. Ә инде танылган әдәбият галиме Йолдыз Нигъмәтуллина алып барган семинарларда ул әдәбиятны өйрәнүнең мәктәпләре, фәннең яңа концепцияләре белән таныша, татар әдәбият фәненең рус һәм дөнья казанышларына нигезләнеп, шул ук вакытта милли үзенчәлекләрен саклау аша үсү юлларын эзләвенә төшенә.

1986 елны Д.Заһидуллина гаиләсе белән Балтач районы Түнтәр авылына күчеп килә һәм мәктәптә татар теле, әдәбияты укытучысы булып эшли башлый. Өч елдан соң, Казанга кайтып, укытучылык эшен дәвам итә, аспирантурага укырга керә. 1992 елны аны Казан дәүләт университетына ассистент итеп эшкә чакыралар. Студентларга белем бирү белән бергә, Дания Фатих кызы тиз арада кандидатлык (1993) һәм докторлык (2001) диссертацияләре яклый, доцент, профессор, кафедра мөдире дәрәҗәсенә ирешә. Үзенең белеме, һәркемгә ихтирамлы һәм игътибарлы булуы белән студентлар һәм коллегалары арасында тирән ихтирам яулап ала. Аның лекцияләре фәннилеге, фактик материалларга байлыгы, татар әдәбиятын, укыту методикасын башка халыкларныкы белән чагыштырып бәяләве белән аерылып тора. Гуманитар фәннәрне тикшерү методологиясен яхшы белгән галимә аспирантлар һәм докторантлар белән җитәкчелек итә башлый. 2007 елда ул ТР Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы итеп сайлана һәм фәнни оешманың гыйльми сәркатибе булып эшли башлый. Ә инде 2011 елда ТР ФА хокукый әгъзасы дәрәҗәсенә ирешә һәм 2016–2023 елларда ТР Фәннәр академиясенең вице-президенты булып хезмәт итә. Бу чорда ул баш-аягы белән оештыру эшләренә чума: республикада гуманитар фәннәрне үстерү һәм заманча тикшеренүләр алып баруны оештыру, аеруча татар теле, әдәбияты һәм сәнгате буенча өр-яңа проектларны башлап җибәрү, Идел буе республикаларында, төрки халыкларда танылу алган хезмәтләр бастырып чыгару һ.б.

Дания Фатих кызының фәнни-методик һәм әдәби-теоретик эшчәнлеге киңкырлы булып, ул аларда җитди башлангычларга нигез сала, үсеш-үзгәреш юлларын билгели. Укытучы буларак алган тәҗрибәсенә таянып, мәктәптә татар телен һәм әдәбиятын укыту мәсьәләләрен тикшерүгә килә. Лирик әсәрләрне өйрәнү барышында укучыларны әхлакый-эстетик тәрбияләүгә багышланган кандидатлык диссертациясе (1993) татар әдәбиятын укытуны яңача оештыру мәсьәләләрен алга куюы белән аерылып тора. Автор әдәбиятны марксистик идеология йогынтысыннан арындырып, сүз сәнгатенең үз закончалыкларына бәйле өйрәнү концепциясенә нигезләнә. Бу өлкәдәге тикшеренүләренең нәтиҗәле дәвамы буларак «Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту» (2000, 2004) хезмәте басылып чыга. Аның кыйммәте, бер яктан, сүз сәнгатен укытуның мәктәп-мәдрәсәләрдә тупланган бай тәҗрибәсен ачуда булса, икенче яктан, рус һәм башка халыклар әдәбиятын өйрәнүдәге казанышларга нигезләнүе, өченчедән, татар әдәбиятын укытудагы шәхсән тәҗрибәсенә нигезләнүе, гамәлгә юнәлтелгән булуы белән аңлатыла. Шуңа да әлеге хезмәт, шулай ук алдагы елларда коллегалары белән берлектә бастырып чыгарган «Татар әдәбияты: Теория. Тарих» (2004, 2006), «Әдәби әсәргә анализ ясау» (2005), «Әдәби әсәр: өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз» (2007) дәреслекләре тиз арада укытучыларның өстәл китабына әйләнә.

Д.Заһидуллина тикшеренүләре арасында татар әдәбият теориясенең барлыкка килү,

үсү-үзгәрү тарихын һәм хәзерге вакыттагы торышын үз эченә алган хезмәтләре үзгә урын алып тора. Әлеге мәсьәләне беренче булып һәм максатчан өйрәнгән «Әдәбият кануннары һәм заман» (2000) хезмәтендә татар әдәбиятын, фәлсәфи-эстетик фикер үсешен тикшерү аша әдәби-теоретик карашларның эзлекле рәвештә җирләшүен, шулай ук фән буларак әдәбият теориясенең милли үзенчәлекләрен ачуга килә. Галимә фикеренчә, татар әдәби-теоретик фикере үсешендә өч баскыч-чор күзәтелә: 1) борынгы заманнардан алып XX йөз башына кадәрге чор; 2) XX йөз башында татар әдәбият теориясенең формалашу чоры; 3) 1920 нче еллардан башлап 1990 нчы елларга кадәр сузылган чор. Д.Заһидуллина татар әдәбияты белән генә чикләнеп калмыйча, татар иҗтимагый фикеренә, Шәрык һәм Гаребнең әдәби-фәлсәфи карашларына иркен мөрәҗәгать итә һәм, шуларга таянып, күзәтүләрен төзек фәнни системага сала. XX гасырның беренче ун елында әдәбият теориясе формалашу өчен шартлар өлгереп җитә дип саный автор. Бу, бер яктан, әдәби казанышлар һәм шуңа бәйле теорияне үстерүгә ихтыяҗ туу белән аңлатыла, икенче яктан, татар әдәби тәнкыйте дә формалашу чорын кичерә һәм теоретик мәсьәләләр тәнкыйть белән бергә күтәрелә, өченче яктан, татар дөньясына рус-Европаның фәлсәфи, эстетик карашлары үтеп керә.

Татар әдәбиятының кызу темплар белән үсеше, анда реализм һәм романтизмга нисбәтле төрле юнәлешләр барлыкка килү әдәбият фәне белән шөгыльләнүчеләр арасында бәхәсләр, фикер каршылыклары китереп чыгара. Соңгысы исә әдәбиятны аңлатуда билгеле бер принципларга таянган кешеләрне бергә туплаган фәнни-әдәби мәктәп оешуга китерә. Әдәбиятның иҗтимагый ягын алгы планга чыгаручыларны хезмәт авторы «җәмгыятьчеләр» дип атый. Әлеге мәктәпне оештыручы булып, эстетик һәм фәлсәфи карашларны көрәш идеясе белән бәйләгән Г.Исхакый тора. Ә инде кешенең эчке дөньясын тасвирлау, яшәешнең психологик нигезләрен аңлату-күрсәтүне алга чыгарып өйрәнүчеләр «рухиятчеләр» мәктәбен оештыра. Аның башлангычында Г.Ибраһимов тора. Д.Заһидуллина монографиясе татар әдәбияты белеме тарихына яңача карарга этәрә. Автор аерым китап булып яисә күпсанлы газета-журналларда сакланып килгән, моңа кадәр игътибардан читтә калган бай әдәби-теоретик мирасыбызны барлый, җентекле анализ ясый һәм татар әдәбияты теориясенә XX гасыр башында гаять талантлы шәхесләр тарафыннан нигез салынуын дәлилләп, соңгыларының фәнни-гамәли табышларын ача, әдәбият фәнендәге урынын билгели. Аның бу өлкәдәге эзләнүләре студентлар өчен чыгарылган «История науки о литературе у татар» (2011) хезмәтендә тагы да тирәнәя, яңа факт-мисаллар белән баетыла һәм татарларда әдәбият фәне үсеше гарәп-фарсы һәм төрки телле халыклар фәне казанышлары яссылыгында бәяләнә.

XX йөз башында татар әдәбияты үзенең «алтын чоры»н кичереп, иҗат мәйданына йөзләгән шәхесне чыгара. Эзләнүләр гаять киң колач алып, бер яктан, шәрык, икенче яктан рус-Европа әдәбиятларындагы табышларны үз эченә ала һәм дөнья әдәбиятының бер өлеше буларак үсә башлый. Д.Заһидуллина әлеге чорның әдәби җәмәгатьчелектән читтәрәк калып килгән катламын өйрәнүгә алына һәм җитди яңалык алып килә. Ул татар әдипләренең, реалистик һәм романтик сурәтләү белән бергә, модернизм дип аталган юнәлешкә актив мөрәҗәгать итүе белән бәйле. Аның аерым үрнәкләр буларак урын алуы Г.Сәгъди, Г.Халит, Й.Нигъмәтуллина, И.Нуруллин, Р.Ганиева кебек галимнәр тарафыннан билгеләнгән булса, галимә бу күренешнең киң җирләшүен, модернистик агымнар буларак символизм, экзистенциализм, импрессионизм һәм экспрессионизмның асыл сыйфатлары Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Н.Думави, М.Хәнәфи, Ф.Әмирхан һ.б. әсәрләрендә чагылышын дәлилли. «Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы» (2003) хезмәтендә Яңарыш юлына чыккан татар сүз сәнгатендә фани һәм бакый дөнья турында уйлану, җир тормышының чикләнгәнлеген, кеше гомеренең кыскалыгын аңлау, шуңа бәйле яшәү мәгънәсенә, Хакыйкатькә төшенү һәм әлеге фәлсәфи карашларны әдәби чараларда чагылдыру омтылышының көчәюен күрсәтә.

Автор билгеләгәнчә, модернизм «әдәбияттагы күнегелгән алым һәм ысулларны кире кага, әдәбиятның торышы-хәле белән риза булмаудан килеп чыга. Шул ук вакытта ул әдәбиятны камилләштерү-үзгәртүгә этәргеч бирә, үзгә юллар эзли». Шунысы игътибарга лаек: яңа алым-формаларда чагылыш тапкан югалту, кайгы, өметсезлек, курку мотивлары аша әлеге фаҗигалелекне булдырмау юллары эзләнә, Яшәешне хәрәкәткә китерүче көч буларак, Өметкә йөз тотыла. Мондый сыйфат-үзгәрешләр яңа эзләнүләрнең, бер яктан, Коръән фәлсәфәсенә, аерым алганда, суфичылык әдәбиятындагы караш-фикерләргә барып тоташуын күрсәтсә, икенче яктан һәм өстенлекле рәвештә, Европада киң таралган А.Шопенгауэр, Ф.Ницше, Вл.Соловьев карашларына таянуын ачыклый.

Тормыш-яшәеш катлаулы, каршылыклы булып, анда барган Яхшылык һәм Явызлык көрәше аерым кеше күңелендәге матурлык һәм ямьсезлек, өмет һәм өметсезлек, ышану һәм шикләнү тартышы-каршылыгына килеп тоташа. Еш кына әдәбиятта «ялгыз кеше трагедиясе» дип аталган сызлану яисә экзистенциализм фәлсәфәсенең нигезендә Яшәешнең камил булмавы, гомернең кыскалыгы, кеше ялгызлыгы һәм көчсезлеге хакындагы фикерләр ята. Шулар җирлегендә Яшәү һәм Үлем, Гөнаһ һәм Җәза, Өмет һәм Хакыйкать кебек төшенчәләргә бәйле бәхәсләр егерменче йөз башында күпсанлы әсәрләр иҗат ителүгә китерә. Аларны тирәнтен шәрехләү барышында Д.Заһидуллина сызлану фәлсәфәсенең төрлелеген, катлаулылыгын һәм гаять үзенчәлекле сәнгати фикерләүгә китерүен ача. Шул рәвешле Ф.Әмирхан, М.Хәнәфи, Б.Мансур, Г.Рәхим, М.Гафури, Ә.Тангатаров, Г.Газиз һ.б. проза әсәрләренә этрафлы бәя бирелеп, аларның иҗат йөзе, язу стиле күз алдына бастырыла. Галимәнең бу төр эзләнүләре дәвамы буларак «Модернизм в татарской литературе первой трети XX века» (2013) монографиясе дөнья күрә. Хезмәттә Дәрдемәнд, Н.Думави, Г.Газиз, Ф.Әмирхан һ.б. авторларның киң катлам укучыларга таныш әсәрләре дә «яңача» укыла, аларның әлеге чор әдәбият тарихындагы урыны билгеләнә. Октябрь инкыйлабыннан соңгы әдәбият буенча тикшеренүләр бу чор сүз сәнгатенә бәйле фикер-карашларны бермә-бер киңәйтеп җибәрә. Татар әдәбияты фәнендә беренчеләрдән булып XX йөз башындагы модернистик эзләнүләрнең яңа шартларда да үзгә юллар, алым-чаралар белән дәвам ителүе, аларның социалистик реализм иҗат методы белән катлаулы мөнәсәбәте билгеләнә. Рус әдәбиятының көчле йогынтысында булган авангард әдәбият форма һәм эчтәлекне яңарту юлларын эзли. Шул рәвешле имажинизм һәм футуризм дип аталган агымнар мәйданга килә. Автор фикеренчә, аларда билгеле бер дәрәҗәдә XX йөз башы модернизм әдәбияты билгеләре саклана. Әмма бу күренеш озакка бармый. 1920 нче елларның икенче яртысында сүз сәнгатендә бертөрлелек көчәя, һәм ул әдипләрнең сәнгати эзләнүләрен бермә-бер тарайта. Галимәнең «Дөнья сурәте үзгәрү» (2006) китабы да әлеге тикшеренүләр уңаенда каралырга тиеш. Әдәбият яңарышы, беренче чиратта, әдипнең чынбарлыкны кабул итүе, аны үзгә сурәтләрдә, әдәби чаралар ярдәмендә ачуы белән бәйле. Д.Заһидуллина, татар әдәбиятының күпгасырлык тарихына күз ташлап, анда яшәеш сурәтләренең ни сәбәпле һәм ни рәвешле үзгәрүен тикшерә. Автор фикеренчә, XX гасыр башында дөньяның яңа моделе формалаша, яңа тип геройлар мәйданга килә. Әлеге контекстта Дәрдемәнд, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Н.Думави һ.б. иҗатындагы милли дөнья сурәте чыгылышын тикшереп, әдәбиятыбызның классик чорына яңача карау һәм аны бәяләү мөмкинлеге бирелә. Шуңа да Н.Йосыпова белән берлектә чыгарган «XX гасыр татар әдәбияты тарихы» (2011) дәреслеге татар әдәбияты тарихы буенча яңа концепциягә нигезләнгән бөтенлекле күзәтү буларак яңгыраш ала. Авторлар, әлеге чордагы сүз сәнгатен бербөтен күренеш буларак һәм фәннең соңгы казанышларына нисбәтле тикшереп, гаять кызыклы нәтиҗәләргә киләләр.

Соңгы дистә елда Д.Заһидуллина татар әдәбияты тарихы буенча алып барылган тикшеренүләрнең үзәгендә тора. Бу чорда алгы планга әдәбият тарихының сигез

томлы академик басмасын әзерләү чыга (2014–2021). Дания Фатих кызы әлеге җитди бурычның концепциясен эшләүдә актив катнаша. Галимә, сигезтомлык әдәбият тарихының методологик һәм концептуаль нигезе булып, рухи мирасны бөтен тулылыгында һәм бербөтен күренеш буларак һәм халыкның яшәү рәвешен милли идея чагылышында, үзенең эчке закончалыкларына бәйле үсеп-үзгәреп торучы иҗтимагый күренеш итеп, шулай ук әдәбият фәне казанышларына нигезләнеп, әдәби-эстетик, фәлсәфи һәм әхлакый яссылыкта өйрәнү кирәклеген яклып чыга. Аның тарафыннан язылган күпсанлы күзәтү мәкаләләре, иҗат портретлары концептуаль нигезе, фәнни-теоретик киңлеге, фактик байлыгы белән аерылып тора.

Әлеге җитди хезмәтне әзерләү барышында ул бигрәк тә 1960–1980 еллар әдәбиятын яңача бәяләү кирәклегенә төшенә һәм «1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр» (2015) монографиясендә әлеге чор сүз сәнгате яңа концепциягә нигезләнеп тикшерелә. Теге яисә бу әдәби чорда күзәтелгән сыйфат үзгәреше, традицияләр дәвамчанлыгына һәм яңа юллар эзләүгә бәйле булып, яңарыш әйдәп баручы әдипләрнең традицион әдәбият янында үзгә формалар, алымнар эзләве белән бәйле була. Д.Заһидуллина фикеренчә, әлеге авангард эзләнүләр башлап шигърияттә урын ала, аннары драматургиягә һәм прозага үтеп керә. Нәтиҗәдә автор 1960–80 еллар татар шигъриятен әдәби кыйбла үзгәрү, милли нигезләргә әйләнеп кайту вакыты дип бәяләүгә килә. Авангард эзләнүләргә нисбәтле хезмәттә Р.Фәйзуллин, Г.Афзал, И.Юзеев, Р.Әхмәтҗанов, Р.Гаташ, Ш.Анак, Р.Харис, М.Әгъләмов, Зөлфәт иҗатлары тикшереп бәяләнә. Ә инде прозасында милли нигезләргә кайтуның аерым үрнәкләре алдарак чорда күренсә дә, тулы канлы рәвештә ул әлеге чорда Ә.Еники, Г.Әпсәләмов, Г.Бәширов, Г.Ахунов, Н.Фәттах, Х.Сарьян, Ш.Хөсәенов, Ә.Баян, М.Юныс, А.Гыйләҗев, М.Галиев иҗатларында урын ала һәм иҗтимагый тормышка да зур йогынты ясый. Хезмәттә тикшерелә торган чор XX гасыр башы әдәбияты белән гасыр ахырындагы әдәби эзләнүләрне үзара тоташтыручы күпер буларак бәяләнә. Автор фикеренчә, хәзерге татар әдәбиятындагы сан һәм сыйфат үзгәрешләре, сүз сәнгатендәге синтетизм, төрле юнәлешләрнең үзара керешүе кебек күренешләрнең асылын әнә шуннан эзләргә кирәк.

Д.Заһидуллинаның киңкырлы эшчәнлегендә хәзерге әдәбият һәрдаим игътибар үзәгендә тора. Ул беренчеләрдән булып XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар әдәбиятында күзәтелгән әдәби-эстетик эзләнүләрне, аларның табигатен, әдипләрнең тема-мотивлар, жанр һәм жанр формалары, аеруча сәнгати алымнар һәм чаралар өлкәсендәге табышларын җентекләп барлау, аларның әдәби процесстагы урынын билгеләү буенча тикшеренү башлый. «Яңа дулкында» (2006) дип аталган тәнкыйди язмалар җыентыгы татар әдәбияты фәнендә яңа сүз буларак кабул ителә. Хезмәтләрдә урын алган Ф.Садриев, Т.Миңнуллин, Т.Галиуллин, Ф.Бәйрәмова, Н.Гыйматдинова, М.Галиев, Ф.Сафин, Р.Зәйдулла, Г.Гыйльманов, М.Кәбиров һ.б. иҗат портретлары фәнни нигезе, аналитик бәяләмәсе, әдипнең сәнгати дөньясын дәлилле ачуның үрнәге булып торалар.

Татар әдәбиятының үсеш-үзгәрешен, анда барган кызыклы эзләнүләр белән башка милләт укучыларын да таныштыру максатында рус телендә дөнья күргән «Хәзерге татар прозасы (1986–2016)» (2017) һәм «XX-XXI гасырлар чигендә татар поэзиясе (1986–2016)» (2017) монографияләре ике гасыр чиге әдәбиятын өйрәнүдә яңа башлангыч булып тора. Автор безнең күз алдында барган әдәби процессны фәнни казанышларга нигезләнеп бәяли, җитди гипотезалар белән чыгыш ясый. XX гасыр ахырында татар әдәбияты үсешенең яңа этабына керде дип саный галимә. Бу, беренче чиратта, сүз сәнгатенең төрлелегендә чагыла. Классик традицияләрне аеруча үз иткән әдәбиятыбыз, модернизм һәм постмодернизм алымнарына да бик теләп мөрәҗәгать итә, чынбарлыкны чагылдыруның яңадан-яңа юлларын эзли. Бу исә XX йөз башы традицияләрен, шулай ук гасырның 60 елларында урын алган милли хасиятләрне

калкытып куюга, аларда урын алган тема һәм проблема, жанр һәм мотив эзләнүләрен, сәнгати чаралар байлыгын яңа заманга бәйле ачуда, бәяләүдә, киң планда укучыга җиткерүдә чагыла.

Д.Заһидуллинаның соңгы елларда басылып чыккан «Татарская литература XX – нач. XXI вв.: «мягкость» модернизма-авангарда-постмодернизма (к постановке проблемы)» (2020) хезмәте алдагы тикшернүләренең дәвамы һәм аларның бөтенлекле нәтиҗәсе дә булып тора. Монографиядә дөнья әдәбиятына зур йогынты ясаган модернизм күренешенең татар әдәбиятында милли үзенчәлекләргә нисбәтле «йомшак» формада чагылыш табуы дәлилләнә. Бу исә, үз чиратында, XX гасыр уртасында күзәтелгән яңарышка – авангард эзләнүләргә көчле йогынты ясаган кебек, гасыр ахырында һәм XXI гасыр башында әдәбиятта шактый киң урын алган постмодернизмда да үзенең эзләрен саклый. Автор эзлекле рәвештә XX гасыр башында татар әдәбиятының шәрык һәм рус-Европа әдәбиятларындагы казанышларга нигезләнгән, шуңа да синтетик табигатьле булуын билгели. Ягъни бер әсәр кысаларында төрле әдәби юнәлеш, алым-формаларын, иҗат стильләрен күзәтергә мөмкин була. Әнә шулар аның «йомшак»лыгын тәэмин итә дә инде. Ни кызганыч, совет чорында мондый эзләнүләр туктап кала, «революцион үсеш» идеологиясе кеше табигатен бертөрле генә сурәтләүне таләп итә. Әмма гасыр уртасында сүз сәнгате тирән торгынлыкка керә, алга таба үсеше туктала. «Җепшеклек» дулкыны әдипләрне кузгатып җибәрә һәм алар традиция эзләп халык авыз иҗатына һәм XX йөз башы классик әдәбиятына мөрәҗәгать итәләр. Реализм һәм романтизм белән бергә, модернистик алым-формалар да урын ала. Чикләү шартларында әдипләр читләтеп әйтүгә – «эзоп» теленә дә күпләп мөрәҗәгать итә, сатира шактый киңәеп китә, сүз сәнгате төрле юллар белән яшәп килгән җәмгыятьне тәнкыйтьләүгә килә. Д.Заһидуллина фикеренчә, әлеге үзенчәлекләр татар әдәбиятындагы авангард эзләнүләрнең «йомшак»лыгын тәэмин итә. Ул, үз чиратында, милли сүз сәнгатендә лирик-шартлы формаларның, психологизмның, символларның, фәлсәфи эчтәлекнең, тәнкыйди башлангычның көчәюенә китерә.

Җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле ике гасыр чигендә татар әдәбиятында классик төсмер алган күптөрлелек белән янәшә, классик булмаган метод-алымнарга нигезләнгән парадигма урын ала. Рус һәм дөнья әдәбиятында ул берсен икенчесе кире кагу, алдагы традицияләрдән китү рәвешендә күзәтелсә, татар әдәбиятында исә алдагы чор традицияләре яшәвен дәвам итә, аларга яңа төр алым-формалар өстәлә. Төрле юнәлешләр, берсен-берсе тулыландырып, үзара бәйләнештә яшәвен дәвам итә. Шул рәвешле, автор фикеренчә, татар әдәбиятында постмодернистик сурәтлелекнең «йомшак» формасы урын ала.

Галимәнең «Художественные приемы и стилевые обновления в татарской литературе (в контексте тюркских литератур XX-XXI вв.)» (2022) хезмәте татар әдәбиятының үсеш-үзгәреш тарихына караган нәтиҗәләрне төрки халыклар әдәбияты үсеш-үзгәрешенә нисбәтле тикшерүне максат итә. Татар сүз сәнгате күпгасырлык тарихында, шул исәптән совет чорында да үзенең милли үзенчәлеген саклап кала. Бу исә аны башка төрки халыклар сүз сәнгате белән чагыштырып карауга китерә. Эзлекле рәвештә стиль үзенчәлеге, теге ясә бу чорда өстенлекле урын алган поэтик билге буларак а) психологизм алымнары; б) «эзоп» теленә мөрәҗәгать итү; в) әсәрдә автор һәм геройлар позициясенә бәйле күзәтелгән полифонизм (тигез күптөрлелек); г) урта гасырлар суфичылык әдәбиятында Аллаһыны ярату идеясе чагылышы; д) гомумтөрки һәм татар әдәбиятында традицияләр дәвамчанлыгының аерым лейтмотивлар рәвешендә урын алуы; е) төрки әдәбиятларда проза текстының орнаментализм, ягъни поэтиканың сюжеттан тыш элементлары булган интонация, лейтмотив, ритм һ.б. бәйле оештырылуы кебек җитди мәсьәләләр азәрбайҗан, үзбәк, чуваш һ.б. әдәбиятлар үрнәкләре белән янәшә куеп тикшерелә. Әнә шундый чагыштырма анализ аша татар әдәбиятының үзенә хас закончалыклары тагын да тулырак ачыла.

Дания Фатих кызы – үзенең фәнни мәктәбен булдырган, дистәләрчә шәкертенә фән юлын ачкан галимә, 450 дән артык басма хезмәт авторы. Аның җитәкчелегендә ике докторлык, тугыз кандидатлык диссертациясе яклана. Ул бүген дә әдәбият фәне методологиясенең аерым аспектлары буенча проектларда катнаша, аспирантларга җитәкчелек итә. Галимә 20 ел дәвамында докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау советларында, шулай ук берничә фәнни һәм фәнни-популяр журналның редколлегиясендә әгъза булып тора.

Ул бүген дә актив иҗатта булып, татар әдәбияты тарихын тикшерүнең яңадан-яңа юлларын, нәтиҗәле метод-алымнарын эзләүне дәвам итә. «Җыен» фонды тарафыннан чыгарыла торган «Шәхесләребез» сериясендәге җыентыкларның фәнни җитәкчесе буларак та күп эш башкара. Аның җитәкчелегендә татар әдәбияты тарихының рус телендә биштомлыгын эшләү башланды. К.Насыйри һәм Г.Тукайның алдагы юбилейлары уңаеннан яңа проектларда актив катнаша. Хәзерге әдәби тәнкыйтьтә иң актив эшләүче авторларның берсе буларак, Д.Заһидуллинаның «Казан утлары», «Мәйдан», «Мәдәни җомга», «Идел» кебек газета-журналларда, төрле фәнни җыентыкларда урын алган күзәтүләре яисә иҗат портретлары һәрвакыт зур кызыксыну уята. Аның язмалары фәнни-теоретик төшенчәләргә нигезләнүе, сүз сәнгате үзенчәлекләрен тирәнтен аңлап язуы, фикер киңлеге, татар әдәбиятын башка халыклар әдәбияты белән чагыштырып яисә тыгыз бәйлелектә тикшерүе белән аерылып тора.

Галимә хезмәтләре республика Хөкүмәте тарафыннан югары бәяләнә. Ул «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» (2007), «Фидакарь хезмәт өчен» (2019) медальләре белән бүләкләнә, «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» (2014) дигән мактаулы исемгә һәм Язучылар берлегенең Җ.Вәлиди (2006), И.Юзеев (2005) исемендәге әдәби бүләкләренә лаек була.

Д.Ф.Заһидуллинаның бөтен эшчәнлеге халкыбыз мәнфәгатен кайгыртуга, татар фәнен үстерүгә, аның иҗтимагый-мәдәни тормышыбызга йогынтысын баетуга юнәлтелгән. Күптөрле халыкара конференцияләрдә катнашып, татар әдәбият фәнен дөньякүләм танытуга зур көч сала, аның бүгенгесен кайгыртып һәм киләчәгенә йөз тотып яши. Бу көннәрдә үзенең гомер бәйрәмен билгеләп үтүче каләмдәшебезгә сәламәтлек, яңа фәнни казанышлар, хезмәт уңышлары теләп калабыз.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ,**
*филология фәннәре докторы,*
*ТР ФА Г.Ибраһимов исем. ТӘһСИның бүлек мөдире.*

# *Дания Заһидуллинаның тормыш мизгелләре*




*Тукай клубы. Әдәби җомга. 5 март, 1982 ел.*



*X Венчур ярминкәсендә Татарстан Фәннәр академиясе төркеме. 23 апрель, 2015 ел.*



*Күренекле татар галиме, дипломат, Румыния галимнәр академиясе әгъзасы Тасин Җәмил белән. 2016 ел, октябрь.*




*Халыкара Төрки академия утырышында. Сулдан уңга: Халыкара Төрки академия президенты академик Шаин Мәҗит улы Мостафаев, Кыргызстан Фәннәр академиясе президенты академик Канатбек Ермек улы Абдрахманов, Казакъстан Республикасының Фән һәм югары мәктәп министры Сәясәт Нурбәк, Казакъстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Көнсылу Дальтан кызы Закарья. Алма-Ата, 14 апрель, 2023 ел.*



*Бишкәк шәһәрендә Роза Торекул кызы Айтматова белән.12 декабрь, 2023 ел.*




*Конференциядә остазы Х.Миңнегулов һәм укучылары, фән докторлары Венера Әминева, Венера Макарова белән. 25 апрель, 2023 ел.*




*Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында. 8 май, 2024 ел.*

*Фотолар Д.ЗАҺИДУЛЛИНАның шәхси архивыннан алынды.*

# ЯШЬ ГАЛИМНӘРЕБЕЗГӘ ЮЛ ҺӘРВАКЫТ АЧЫК

*Күптән түгел Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры итеп моңа кадәр ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының Милли мәгариф идарәсе җитәкчесе булган Илгиз Халиков билгеләнде. Әңгәмә барышында без гуманитар фәннәр өлкәсендә заманча белем бирүнең мөһим аспектлары, шулай ук мәдәни киңлек формалаштыруда институтның роле турында фикер алыштык.*

**– 2024 ел – Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты өчен юбилей елы. 85 еллык тарихы булган институтның йөзен нинди галимнәр, нинди хезмәтләр билгели?**

– Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән төрле елларда Миргали Нигъмәтуллин, Хәсән Шабанов, Хәмит Ярми, Мөхәммәт Гайнуллин, Хәсән Хәйри, Камил Фәсиев, Мидхәт Мөхәррәмов, Яхья Абдуллин, Ким Миңнуллин кебек фәнгә тугрылыклы шәхесләр җитәкчелек итә, ә катлаулы реформа елларында фәнни учреждениебез башында Мирфатыйх Зәки улы Зәкиев һәм Нурмөхәммәт Шаһвәли улы Хисамов торалар.

Исеменнән үк күренгәнчә, институт татар филологиясе һәм сәнгать белеменең фундаменталь проблемалары белән шөгыльләнә, атап әйткәндә, татар тел белеме, әдәбият белеме, археография, текстология, фольклористика, театр, музыка һәм рәсем сәнгатенең актуаль мәсьәләләрен өйрәнә.

Бүген фәнни тикшеренүләребездә безнең фәнни кыйблабызны билгеләгән галимнәрнең исемнәрен тирән хөрмәт белән искә алабыз. Бу – Нил Юзеев, Ләйлә Мәхмүтова, Рашат Гайнанов, Әбрар Кәримуллин, Латыйф Җәләй, Вәли Хангилдин, Риза Газизов, Гали Халит, Николай Воробьёв, Хәйри Гыймади, Николай Калинин, Альфред Халиков. Аларның исемнәре институт тарихына алтын хәрефләр белән язылган.




*Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының бүгенге коллективы.*

Танылган тел белгечләре Мирфатыйх Зәкиев, Фоат Ганиев, әдәбият галиме Нурмөхәммәт Хисамов, фольклорчы Фатих Урманчеев, археограф Марсель Әхмәтҗанов һәм башка галимнәребез хезмәтләренең бөтен төрки дөньяда танылу алуы – безнең өчен зур дәрәҗә.

**– Киләсе биш елда институтны алга таба үстерү өчен нинди стратегия билгеләнде? Институтның киләчәген ничек күз алдына китерәсез? Бу вазифада үз миссиягезне ничек билгелисез?**

– Бәлки, стратегия түгел, ә үсеш нокталары дип әйтсәк, дөресрәк булыр. Стратегия, нигездә, күләмле документны тәшкил итә һәм аны язуда зур төркем белгечләр катнаша. Үсеш нокталары, үз чиратында, булган традицияләргә таянып, перспектив үсеш юлларын билгеләүне күз уңында тота.

85 еллык тарихы булган институтыбызның фәнни тарихы һәм үз традицияләре бар. Бу урында Галимҗан Ибраһимовның «Фәнни истыйляхлар» мәкаләсендә әйтелгән: «Бер төркем халыкның аерым бер милләт мәртәбәсенә күтәрелүе өчен ана телендә әдәбияты булу гына җитми, аның үз телендә фәне дә булырга тиеш» дигән фикерен ассызыклыйсы килә. Әлбәттә, татар гуманитар фәненең үсешен тәэмин итү – төп максатыбыз. Шул ук вакытта, заман таләпләрен истә тотып, яңалыкларны инкарь итмичә, гуманитар өлкәдәге алдынгы тикшеренүләргә дә игътибар бирү зарур.

Мәгълүм булганча, институтыбыз – татар гуманитар фәне өлкәсендәге фундаменталь тикшеренүләре белән дан казанган фәнни оешма. Шул ук вакытта соңгы елларда институт галимнәре тарафыннан фундаменталь материалларга нигезләнгән гамәли проектлар әзерләнде, киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителде. Менә шушы фундаменталь һәм гамәли өлкәләрдә балансны табу киләчәктә институтыбызның үсеш юлларын билгеләр дип уйлыйбыз.

Шәхсән үземә килгәндә, юбилей елында минем өчен фәнни Alma mater булган институтны җитәкләү – ул зур җаваплылык һәм горурлык. Бүген күренекле якташым Галимҗан Ибраһимов исемен йөрткән институт – татар академик фәне өлкәсендә танылган оешма. Институт галимнәре һәм аларның фәнни хезмәтләре дөнья күләмендә билгеле. Менә шушы югары позицияләрне саклау һәм яңа үсеш нокталарын табу минем миссиямне тәшкил итә.

**– Институтта тел, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә нинди тикшеренүләр үткәрелә? Яшь галимнәргә һәм аларның проектларына ничек ярдәм итәсез?**

– Бүгенге көндә институт – татар телен, әдәбиятын һәм сәнгатен комплекслы рәвештә фундаменталь өйрәнә торган бердәнбер фәнни оешма.

Татар тел белемен төрки телләр эволюциясе контекстында өйрәнү, дөнья мәдәнияте контекстында татар әдәбияты теориясен, тарихын, аның үсешенең хәзерге тенденцияләрен бәяләү, татар әдәбияты классиклары мирасын бербөтен һәм системалы тикшерү, сүзлекләр төзү өлкәсендә сизелерлек нәтиҗәләргә ирешелде. Сынлы сәнгать, декоратив-гамәли сәнгать, театр, музыка, Татарстан халыклары хореографиясе буенча күпкырлы фәнни тикшеренүләр алып барыла.

Заман таләпләрен дә искә алып, әлеге эзләнүләрнең нәтиҗәләрен татар телендә генә түгел, рус телендә дә бастырып чыгару юнәлешендә зур эш алып барыла. Әйтик, «Татар әдәби теле тарихы», «Татар лексикологиясе», «Татар әдәбияты тарихы» кебек күптомлы фундаменталь хезмәтләр дөнья күрә. Татар халкының фольклорын өйрәнүгә аеруча игътибар бирелә. «Татар халык иҗаты» хезмәтен татар телендә 25 томда һәм рус телендә 15 томда бастырып чыгару күздә тотыла. Бүгенге көндә һәркайсының 9 томы киң җәмәгатьчелеккә җиткерелде инде.

«Туган тел (татар теле)» һәм «Туган телдә (татар телендә) әдәбият» предметлары буенча укыту-методик комплектлары федераль исемлеккә кертелде һәм республикабыз мәктәпләрендә киң кулланылыш алды.

Хәзерге вакытта Татарстанда яшь галимнәр санын арттыруны тәэмин итүгә зур

игътибар бирелә. Федераль дәрәҗәдә яшьләргә ярдәм итү һәм аларны фәнгә җәлеп итү дәүләт күләмендә системалы рәвештә тормышка ашырыла. Республикабызда да яшь галимнәргә ярдәм итү программалары бар. Институтка килсәк, яшь галимнәребезгә юл һәрвакыт ачык.

2023 елда фәнни хезмәткәребез Татарстан Республикасы яшь галимнәре грантын алды. Алга таба да бу юнәлештә актив эш алып барылачак.

Аспирантураның көндезге бүлегендә дүрт фәнни юнәлештә кадрлар әзерләү программалары буенча белем бирелә. Ел саен 6 бюджет урыны каралган.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе базасында диссертация советы эшли. Анда «Рус әдәбияты һәм Россия Федерациясе халыклары әдәбиятлары», «Фольклористика», «Рус теле. Россия халыклары телләре» белгечлекләре буенча кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау мөмкинлеге бирелә. Соңгы 3-4 елда гына да уннан артык докторлык, биш кандидатлык диссертациясе якланды.

**– Сез «Мирасханә» – язма мирас үзәге киләчәген ничек күзаллыйсыз?**

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе тарафыннан кулъязмаларны реставрацияләү лабораториясен булдыру мәсьәләсе карала. Махсуслаштырылган лаборатория булдыру мәсьәләсе күптән туды. Иң элек бу сан күрсәткечләрендә чагылыш таба. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма мирас үзәгендә кулдан язылган китаплар саны 8000 берәмлектән артык, гарәп графикасында басма китаплар – 2000 берәмлектән артык. Ни кызганыч, кулдан язылган китапларның 30%ка якыны реставрацияләүне сорый.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: «Мирасханә» фондлары ел саен археография, фольклор, диалектология һәм этнография экспедицияләре материаллары хисабына тулылана. Әлеге кулъязма һәм басма китапларны өйрәнелергә һәм фәнни әйләнешкә кертелергә тиешле мирас итеп сакларга кирәк. Нәкъ менә шушы максаттан заманча җиһазландырылган лаборатория төзелә һәм аның ярдәмендә борынгы мирасны цифрлы форматка күчерергә мөмкин булачак.

Мондый лаборатория моңа чаклы Фәннәр академиясендә булмаган. Лаборатория төзелгәч, галимнәр академик хезмәтләр, монографияләр һәм диссертацияләр язганда, энциклопедияләр, сүзлекләр һәм библиографик күрсәткечләр төзегәндә, әлеге кулъязмаларны куллана алачак.

**– Институт республика дәрәҗәсендә башка фәнни һәм мәдәни оешмалар, төбәкнең мәдәният һәм сәнгать мохите белән ничек хезмәттәшлек итә?**

– Институт Татарстан академик фәне системасындагы әйдәп баручы фәнни-тикшеренү учреждениеләренең берсе булып тора. Соңгы 5 елда институт гуманитар фәннәр буенча төбәкара координацияләү үзәге статусын алды дисәк, хата булмас. Институт көче белән Урал-Идел буе халыклары проблемаларын үз эченә алган фәнни чаралар үткәрелә («Идел һәм Урал буе милли әдәбиятлары: тикшеренү парадигмалары һәм практикалар» гомумроссия фәнни-гамәли семинары, 2024 ел; «Хәзерге дөньяда традицион мәдәниятне саклау һәм үстерү тәҗрибәсе. Халык кул сәнгатьләре» II халыкара фәнни-гамәли конференциясе, 2023 ел; «Татар гыйлеме» халыкара яшьләр фәнни мәктәбе, 2023 ел һ.б.).

Татар халкының сәнгате Татарстан һәм Россиянең башка халыклары сәнгате белән үзара бәйләнештә өйрәнелә.

Диссертация Советында Удмуртия республикасыннан, Кырымнан килгән яшь белгечләр кандидатлык диссертациясе, Алтай дәүләт университеты хезмәткәре докторлык диссертациясе яклады.

Институт тарафыннан Татарстан Республикасы районнарына һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләрендә һәм чит илләрдә татарлар тупланып яши торган урыннарга үткәрелгән комплекслы фәнни экспедицияләр Россия Федерациясенең полиэтник һәм мультимәдәни халкын саклау эшенә зур өлеш кертә. 2009 елдан

фольклорчылар, диалектологлар, археографлар, музыка, сәнгать белгечләре катнашында Татарстан районнарына 21 комплекслы экспедиция оештырылды.

**– Тикшеренү проектларын формалаштырганда, нәрсәгә игътибар итәргә кирәк дип саныйсыз?**

– Фәнни тикшеренүләр, һичшиксез, күп еллык традицияләргә, алда ясалган ачышларга нигезләнеп алып барыла. Татар гуманитар фәненең үз юлы, үз кануннары бар. Яңа проектларны үткәнгә таянып, бүгенге көн таләпләрен исәпкә алып формалаштыру зарур.

**– Фәнни тикшеренүләр үткәргәндә, институтка нинди кыенлыклар белән очрашырга туры килә?**

– Гуманитар фән, бүгенге көн күзлегеннән караганда, бераз икенчел планга күчте. Шуңа күрә институт алып барган төп фәнни юнәлешләргә яшьләрне җәлеп итү көннән-көн авырлаша. Шулай да өметле яшьләребез бар, алар фәнгә тартыла.

Тулаем алганда, нindидер зур авырлыклар бар дип әйтмәс идем. Теге яки бу мәсьәләләр булуы – гадәти күренеш. Системалы эшләү нәтиҗәсендә барлык проблемаларны да хәл итәргә мөмкин. Моның өчен институтыбызның потенциалы югары.

**– Сез киң аудитория белән элемтәдә торасызмы? Фән һәм әдәбиятны популярлаштыру өчен нинди программалар яки чаралар бар?**

– Институт тарафыннан даими рәвештә халыкларның тарихи-мәдәни мирасын саклау һәм өйрәнүнең актуаль мәсьәләләренә багышланган халыкара һәм бөтенроссия фәнни конференцияләр, семинарлар һәм симпозиумнар уздырыла («Европа цивилизациясенең язмачылык тарихы һәм Россия халыкларының язма мәдәнияте» халыкара фәнни конференциясе, 2023; татар әдәбияты классигы, танылган публицист һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакыйның тууына 145 ел тулуга багышланган «Парадигмалар алмашыну шартларында татар белеме: теория, методология, гамәл» халыкара фәнни-гамәли семинары, 2023; татар сәнгать белеменә нигез салучы Ф.Х.Вәлиевнның (1921–1984) тууына 100 ел тулуга багышланган «Күпмилләтле туку сәнгате» халыкара симпозиумы, 2021 һ.б.). Ел саен уздырыла торган «Татар гыйлеме» халыкара яшьләр фәнни мәктәбенә Россия Федерациясе төбәкләреннән, Мәскәү, Санкт-Петербург кебек шәһәрләрнең фәнни оешмаларыннан, югары уку йортларыннан әйдәп баручы галимнәр лекция уку, тәҗрибәләре белән уртаклашу өчен чакырыла, төбәкләрнең төрле вузларыннан студентлар, аспирантлар, яшь галимнәр катнаша.

2021 елда Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты инициативасы белән республикада Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы чаралары планын тормышка ашыру кысаларында «Татарстан халкының мәдәниятләр калейдоскобы» төбәкара проекты гамәлгә ашырылды. Әлеге масштаблы проектның максаты республика территориясендә яшәүче чуваш, удмурт, мари, мордва халкының рухи мирасын фәнни яктан өйрәнү иде. Проект кысаларында Мордовия Республикасы хөкүмәте каршындагы Гуманитар фәннәр институты, Чуваш дәүләт гуманитар фәннәр институты, В.М.Васильев исемендәге Мари тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре катнашында Татарстан районнарына экспедицияләр оештырылды. ТӘһСИ галимнәренең күрше республикалардагы коллегалары белән мондый хезмәттәшлеге нәтиҗәсе буларак, «Татарстан халкының мәдәниятләр калейдоскобы» коллектив монографиясе нәшер ителде һәм төбәкара түгәрәк өстәл үткәрелде.

2014 елдан институт тарафыннан татар телендә бердәнбер «Фәнни Татарстан» фәнни журналы чыгарыла, материаллар РИНЦ системасына кертелә. Бу шулай ук татар телен фән теле буларак куллануга этәргеч ясый.

Гомумән алганда, фәнне популярлаштыру, аны халыкка җиткерү – безнең төп бурычларыбызның берсе. Шул максаттан без институт проектларын, аерым фәнни басмаларны киң җәмәгатьчелеккә җиткерергә тырышабыз. Һәр хезмәтнең электрон

варианты институтның рәсми сайтына урнаштырыла. Социаль челтәрләр аша төрле бәйгеләр уздырабыз һәм җиңүчеләргә Институт галимнәре тарафыннан әзерләнгән хезмәтләрне бүләк итәбез. Соңгы арада Татар теле укытучылары ассоциациясе белән бик яхшы хезмәттәшлек урнаштырылды. Мөгаллимнәребез ихластан безнең эшчәнлек белән кызыксыналар һәм институт галимнәрен төрле методик семинарларга чакыралар.

**– Тикшеренүләрне финанслауда дәүләт һәм шәхси фондларның ролен ничек бәялисез?**

– Институт «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» һәм «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» дәүләт программаларын гамәлгә ашыруда актив катнаша. Ел саен әлеге программалар кысасында кырыкка якын проект гамәлгә ашырыла. Шулай ук соңгы бер-ике елда Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясенең ярдәме белән дә берничә проект тормышка ашырылды. Әлбәттә, безнең галимнәребез өчен бу бик зур ярдәм. Институт планында карламаган һәм финанс яктан хәл ителмәгән, әмма ихтыяҗы зур булган проектларны гамәлгә ашыруда дәүләт программасы һәм Комиссия ярдәме бүген бәяләп бетергесез.

**– Заманча технологияләр һәм җәмгыятьтәге үзгәрешләр яссылыгында Татарстанда тел, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге тикшеренүләрнең киләчәген ничек күзаллыйсыз?**

– Институтта фундаменталь фәннәр өлкәсендәге фәнни эш белән беррәттән күпсанлы фәнни-гамәли тикшеренүләр дә алып барыла.

Аерым игътибар электрон проектларга бирелә. 2018 елда Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе порталы базасында электрон сүзлекләр фондын, татар теленең электрон этнолингвистик терминологик сүзлеген, Татарстан Республикасы топонимнарының электрон каталогын, татар матур әдәбияты корпусын, Идел буе һәм Урал төрки телләренең интерактив картасын (татар, башкорт һәм чуваш телләре), Татар диалектлары атласын үз эченә алган «TATZET» электрон проектлар җыентыгы һәм башкалар булдырылды.

Шулай ук институт эшчәнлегенең бер мөһим юнәлеше булып милли мәгариф өлкәсенә караган мәсьәләләр белән шөгыльләнү тора. Биредә соңгы елларда туган телләрне һәм әдәбиятларны укыту системасында барган үзгәрешләрне исәпкә алып, төрле мәсьәләләр өйрәнелә һәм хәл ителә. Милли мәгариф бүлеге хезмәткәрләре туган (татар) тел һәм әдәбият предметы өлкәсенә караган заманча белем бирү программаларын төзүдә актив катнашалар. Әлеге программаларга нигезләнеп һәм яңартылган ФДББСларга туры китереп, яңа буын дәреслекләр әзерләнә.

Институтыбыз инерт оешма түгел, ул заман үзгәрешләрен тоеп яши һәм галимнәребез бер адым алда булырга тырыша.

**– Тел һәм әдәбият өлкәсендәге тикшеренүләргә цифрлаштыру йогынтысын ничек бәялисез? Тикшеренү эшләрендә нинди заманча технологияләр һәм ысуллар кулланыла?**

– Киләчәктә дә үз позицияләрен саклау, яңа үрләр яулау өчен институтка заман сулышын тоеп эш алып бару зарур. Цифрлаштыру – бүгенге заманның аерылгысыз өлеше. Татар теле, әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендәге тикшеренүләргә дә үтеп керде ул.

Институтның электрон проектларга зур игътибар бирүе хакында инде әйтеп уздык. Фразеологизмнарның электрон белешмәлеген төзү, сүзлекләрнең күпфункцияле электрон фондын эшләү һәм гамәлгә кертү буенча системалы эш дәвам итә. Татар теленең электрон фольклор фонды (tatfolkfound) ел саен 600 берәмлек цифрлаштырылган фольклор материалы белән тулыландырыла. Язма мирас үзәге хезмәткәрләре ел саен Цифрлы фотобанкны 500 иллюстратив материал – фотосурәтләрнең цифрлы күчермәләре белән баета.

Гарәп графикасындагы текстларны уку һәм кириллицага тәрҗемә итү программасы борынгы татар басмалары белән танышуга, аларны фәнни кулланылышка кертүгә юл ача.

Туган (татар) телен һәм әдәбиятын укытуда уңышлы гына кулланыла торган медиаматериаллар эшләү институт эшчәнлегенең бер өлеше булып тора. Аерым алганда, 1–11 сыйныфлар өчен видеодәресләр циклы, СберКласс электрон белем бирү платформасы өчен татар теле һәм әдәбиятыннан 5–9 сыйныфлар өчен белем бирү контенты эшләнде. Һәм иң яңа проектыбыз, шушы материалларны да үз эченә алган – «Мәгърифәт» дип исемләнгән укытучылар, балалар, әти-әниләр өчен мәгълүмати ресурс.

Татар теле һәм әдәбиятыннан төзелгән яңа УМКларның компоненты булган электрон дәреслекләр татар телен һәм әдәбиятын укытуда актив кулланыла. Быелдан татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә файдалану өчен презентацияләр әзерләү юнәлешендә эш алып барыла. «Татарстан Республикасының электрон мәгарифе» яңартылган сайтында галимнәребез тарафыннан әзерләнгән аудио һәм видео материаллар урын алды.

**– Тел һәм сәнгать өлкәсендә карьера ясарга теләгән студентларга нинди киңәшләр бирер идегез?**

– Үзләренең киләчәкләрен татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен һәм сәнгатен өйрәнүгә багышларга теләгән студентларга әлеге юнәлешне сайлаудан курыкмаска киңәш итәр идем. Нигездә, бу студентлар инде аңлы рәвештә татар гуманитар фәне өлкәсенә килә. Туган телебез, меңъеллык тарихы булган әдәбиятыбыз актуальлеген беркайчан да югалтмаячак. Яшьләрнең кыю адымнар белән фәнгә килеп керүләрен телəр идем.

**– Институтның җәмгыятьтә һәм академик тирәлектә ничек кабул ителүен теләр идегез? Уңай имидж булдыру өчен нинди чаралар күрергә кирәк дип саныйсыз?**

– Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына – 85 ел. Институтны республикабызда да, аннан читтә дә беләләр, таныйлар, аның эшчәнлеген югары бәялиләр. Аның инде җәмгыятьтә дә һәм академик тирәлектә дә «уңай имиджы» формалашкан. Шул мөнәсәбәтне алга таба да саклау, югалтмау – безнең төп бурычыбыз.

Уңай имидж ул турыдан-туры эшчәнлеккә, аның нәтиҗәле булуына кайтып кала. Чаралар дигәндә, әлбәттә, бүген медиа мохиттә активрак булырга кирәк. Без социаль челтәрләр, мессенджерлар һәм төрле видеохостингларның актив үсеш кичергән чорында яшибез, һәм аларның мөмкинлекләрен киңрәк кулланырга кирәк дип уйлыйм.

**– Сез үзегезнең җитәкчелек эшендә нинди кыйммәтләр һәм принципларга таянасыз?**

– Төп принцип – ул профессиональлек һәм эшеңне җиренә җиткереп башкару. Кыйммәтләргә килгәндә, гаилә факторы зур рольне уйный. Шәхсән, мине бала чакта әти-әни: «Йөзгә кызыллык китермә!» – дип тәрбияләде. Аннары минем өчен кешелекле булу бик мөһим, аеруча җитәкче вазифасында.

*Әңгәмәдәш* – **Алинә ХӘБИБУЛЛИНА**.

# ХЕМИНГУЭЙЛАР БЕЗДӘН ЕРАКМЫ?..

Кайчагында үз-үзеңне милләтебезнең газиз баласы итеп кенә түгел, бөтен планетага сибелгән татарларның бер вәкиле, бер якын кешесе итеп тоясың. Шушы халәт, әллә кайларда, ерак илләрдә, хәтта океан артларында иҗат ителеп, безгә килеп җиткән, яшьтән таныш булган китапларны актарганда барлыкка килә. Жюль Верның «Серле утрау», «Капитан Грант балалары», Сент-Экзюпериның «Нәни принц», Эрих Мария Ремаркның «Көнбатыш фронтта үзгәрешләр юк», Эрнест Хемингуэйның «Карт һәм диңгез» кебек әсәрләре әле дә яшьлек истәлекләрен, хисләрен яңарта. Андый әсәрләр нык рухлы ихтыяр көченә ия булырга, әйткән сүзеңдә тора белү, намуслылык, теләсә нинди шартларда да кеше булып кала белү кебек чын ир-ат сыйфатларын үстерә, үзеңдә һәртөрле икейөзлелек, ялагайлык, хыянәт кебек әшәкелекләрдән арыну кебек сыйфатларны тәрбияли.

Шушы урында бер уй туа. Мондый китаплар дөнья әдәбиятында гына түгел, үзебезнең милли әдәбиятыбызда, аның хәзерге этабында да туып тора бит. Аларны гел ерактан, чит илләрдән, океан артларыннан эзләп торасы юк.

Мин бу язмаларымда бөтендөнья әдәбиятындагы кайбер күренешләр янәшәсенә үзебезнең милли әдәбиятыбыздагы мисалларны куеп карарга җөрьәт итмәкче булам.

Шулай да соңгы елларда бөтендөнья әдәбият байлыкларыннан, кыйммәтләреннән без бераз читләштек, дөресрәге, безне читләштерделәр, әле алга таба да читләштермәкче булалар. Моның тамырлары, серләре бәлки читтә, әллә кайлардадыр, мин әлегә бу мәсьәләгә кагылмыйм. Сүз бу турыда түгел, ә дөнья кыйммәтләренең бер өлешен, аның прозасының кайбер вәкилләрен мисалга алмакчы гына булам. Менә шундыйлардан күренекле Эрих Мария Ремарк, Эрнест Хемингуэйның әсәрләре белән якыннан танышкач, күңелемне уйлар, хисләр өермәсе бөтереп алды. Ник шундыйларны үзебезнең иҗатчылар белән янәшә куеп карамаска?! Уртаклыклары сизелеп тора бит. Әлегә Көнбатыш әдәбияты белән үзебезнекен янәшә куеп өйрәнүче, тикшеренүчеләрне очратканым юк. Шулай да моны эшләргә кирәктер дип уйлыйм.

Әдәбият-сәнгатьнең нечкә, яшерен серләрен ачарга, аларны яшәеш кануннары белән бәйләргә омтылганда, Эрнест Хемингуэй кебек классикларның иҗади табышлары китап яратучы һәммәбезгә ярдәм итәр кебек тоела. Чөнки мондый табышлар аша һәркемнең күңеленә намуслылык, гаделлек, тугрылык, үз сүзеңдә тора белү кебек кешелек сыйфатлары сеңдерелә.

Бу иҗатка күз салганда, А.С.Пушкинның мәгълүм билгеләмәсе дә искә төшә: «В жизни счастья нет, а есть воля и покой». Моның татарчасы: «Бәхет юк нәрсә ул, ә менә ихтыяр ныклыгы һәм тынычлык, тыныч ләззәт дигәне бар». Боларны истә тотсак, тормышта бәхет эзләп йөрүче Эрнест Хемингуэйның экстремаль омтылышлар һәм эмоциональ тирбәлешләр белән тулы иҗатын ныграк аңлаячакбыз. Бу гыйбарәләрнең тәэсире, әлбәттә, үзебезнең әдәбиятта да чагыла.

Шулай да Көнбатыш әдәбияты белән СССР халыклары әдәбиятларының бер-берсеннән шактый аерылган, хәтта капма-каршы вазгыять шартларында үскәнлеген дә онытып бетермик. Дөрес, татар классик прозасының дөньяның алдынгы проза юнәлешенә бик якын торган чаклары да бар иде. Мәхмүт Галәүнең «Мөһаҗирләр», Шәриф Камалның «Акчарлаклар», Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы», Мәҗит

Гафуриның «Кара йөзләр» әсәрләре шул чордагы дөнья әдәбиятындагылардан һич тә кайтыш түгел. Тора-бара Советлар Союзындагы әдәбиятлар тормышны ничек бар, шулай, үз матурлыгында, үз каршылыкларында күрсәтүгә юнәлгән дөнья әдәбиятыннан читләшә башлады.

Әмма ничек кенә булмасын, бәлки, чыннан да, нәкъ шушы сәясәт аша олы әдәбият билгеле бер казанышларга ирешә алгандыр. Ул чордагы Совет әдәбияты «социалистик реализм» дигән исем белән тамгаланды. Арттырып, булмаганны бар итеп, алдап-йолдап булса да, халыкны бөек матурлык, коммунизм тантанасы якынлашачагына ышандырдылар. Асылда, шул чорның кырыс чынбарлыгы яхшы максатлар гүзәллегеннән бик ерак тора иде.

Җитәкчелек, ул чактагы әдәбият-сәнгатьнең халыкка тәэсир итүдә гаять көчле чара икәнлеген белеп торды һәм аның белән идарә итәргә, аңа тиешле юнәлешләр бирергә тырышты. Сугыштан соң туган әсәрләрдән, Габдрахман Әпсәләмовның «Алтын йолдыз», «Сүнмәс утлар», «Мәңгелек кеше», Кави Нәҗминең «Язгы җилләр», Гомәр Бәшировның «Намус», Шәйхи Маннурның «Муса», Мирсәй Әмирнең «Саф күңел» романнары бик югары бәяләнде. Социалистик реализм тәгълиматы үзе үк әдәбиятның төп вазифасы бүгенге көн хәлләрен түгел, ә укучыга ул хыялланган тормыш перспективасын җиткерү дип өзлексез тукып, шуңа ышанырга чакырып торды. Бик күпләр бу әле генә санап үткән әсәрләрне яраттылар, шулар рухында тәрбияләнделәр.

Инде бүгенге яңа иҗтимагый вазгыять шартларында әдәбиятта, аерым алганда, татар прозасында кискен зур борылышлар булыр дип ышанучылар нык ялгыштылар. Идеологик басымнан тиз арынабыз дигән өметләр җиңел һәм тиз тормышка ашмый икән. Элек үткәрелгән генераль сызык, таләпләр әдәби процесста үз көчләрен югалтмый. Әдәбиятчылар инде сүрелә башлаган ватанпәрвәрлек идеяләренә реанимация ясарга кирәклеген дә яхшы аңлыйлар. Әмма борылыш җиңел генә бирелми. Советлар Союзы җимерелеп, 30 ел үткәч, бөтенләй башка шартлар туды. Капитализм мохитендә бизнес, кредитлар, инфляция, штрафлар, бәяләрнең күтәрелеп, көннән-көн аза баруы гади кешеләрнең баш миләрен һаман да ныграк били, элек без белгән олы категорияләрдән читләштерә.

Шулай да бүген дә татар прозасында дөньяның бөек классиклары белән янәшә куеп чагыштырырлык әсәрләр дә туып тора. Элек балалар шагыйре дип йөртелгән Рафис Корбан соңгы елларда нәкъ менә шундый, дөньякүләм әһәмиятле мәсьәләләрне сәнгатьчә сурәтләүгә ирешкән әсәрләр тудырды. Соңгы 5-6 ел эчендә бу әдипнең иҗатында, чыннан да, зур үсеш һәм активлык күзәтелә. Аның каләме бөтенләй яңа яссылыкта активлашып китте. Бүгенге татар прозасында аның белән тиңләшерлек, биш ел эчендә биш роман иҗат иткән бер генә әдипне дә таба алмассыз. Һәм хикмәт саннарда гына да түгел. Сүз бередә милли әдәбиятыбызның глобаль масштабларга тиңләшерлек гаять әһәмиятле, саллы функцияләре, тәрбия юнәлешендә, әдәбият-сәнгать әһелләренең олы бурычлары турында да бара. Моны әдипләребезнең мәртәбәле урыны – ул ил, дөнья әдәбиятларының бер кисәге дип тә аңларга кирәктер.

Бер-бер артлы тезелеп дөньяга килгән романнар барысы да халкыбызның олы шәхесләрен, милли каһарманнарын сурәтли: Муса Җәлил, Исхак Әхмәров, Салих Сәйдәшев, Нәкый Исәнбәт, Абдулла Алиш – боларның һәркайсы милләтебезнең горурлыгы, дөнья күләмендә чиксез югары бәяләнерлек мөхтәрәм шәхес, асыл зат. Рафис Корбан шуларның һәркайсының исемнәрен халык күңелендә яңарта, аларның үлмәс образларын җанландыра.

Әлбәттә, аларның исемнәре укучыларга таныш. Әмма һәркайсы турында саллы, күләмле романнар тудыру – бу инде башка мәсьәлә.

Игътибар итегез: болар барысы да бөек кешеләр – аларның һәркайсын «Мәшһүр кешеләр тормышы» дигән ЖЗЛ сериясенә кертеп булыр иде. Шулай итеп, шушы сайланышы белән Рафис Корбан, шул ЖЗЛның бер филиалын ясап, аның үсешенә үзеннән өлеш кертә.

Икенчедән, әле без югарыда телгә алган һәм озак еллар әдәбиятыбызны иңләп алган социалистик реализм идеологиясе дә биредә юк түгел кебек. Ул гына да түгел – бер роман хәтта «Муса» дип түгел (монысы Шәйхи Маннур әсәренең исемен кабатлау булыр иде), ә «Ватан» (2018) дип аталган. 2019 елда ул «Отчизна» дигән исем белән русча, «Ата журт» дигән исемдә балкарча Нальчикта дөнья күрде.

Муса Җәлил – газиз Ватаны өчен гомерен биргән кеше. Шуңа күрә әсәрнең шагыйрь исеме белән түгел, ә олы төшенчә – «Ватан» дип аталуы, бер карасаң, аңлашыла да кебек. Укучысының яңа сәяси шартларга карашлары инде үзгәрә төшкәнлеген белә торып, әсәрне «Ватан» дип атаса да, ул укучының игътибарын әсәр исеменең яңгырашына түгел, ә Муса Җәлил образының элеккегә караганда яңачарак чагылышына юнәлтә, ул укучының яңалыкларны әсәрнең сюжет тукымасыннан үзе табып алачагына ышана.

Инде күп тапкырлар әдәбиятта яктыртылган Муса Җәлил образы аша автор үзенең героена беркадәр башка ракурслардан якынлаша. Ул бик кыю рәвештә шагыйрь биографиясендәге табу дип саналган ак тапларны юкка чыгара. Укучыларга моңарчы күрсәтелмәгән һәм күрсәтергә ярамый дип саналган ялганнарны бетерә, тормышында чыннан да булган очрашуларны, көрәшүләрне документлардагы төгәллек белән җиткерә – тормыш дөреслеген ачып бирә. Әсәрнең яңалык интригасы да – бу сүзләрне яхшы мәгънәсендә алганда – нәкъ шул тирәлеккә нигезләнгәндер. «Ватан» романында Муса Җәлилнең танышлары, очрашулары, балалары, оныклары турында документаль фактлар бар, һәм алар байтак күп. Болар барысы да укучыларда зур кызыксыну тудыра, әсәр җиңел телдә, аңлаешлы язылган һәм шагыйрь турындагы әсәрләр исемлеген, биографиясен яңа яктан ача һәм тулыландыра. Бу урында шагыйребез Муса Җәлилнең татар баласы гына түгел, ә илебез горурланырлык шәхес, хәтта бөтен кешелек дөньясы өчен бик кадерле зат икәнлеге хакында уйласак, романның «Ватан» дип аталышы аклана дибез.

«Әхмәров» (2020) романы да – аерым бер халыкның гына түгел, бөтен дөньяның яшәеш хәрәкәте, язмышы белән нык бәйләнгән әсәр. Мәгълүм ки, Икенче Бөтендөнья сугышында фашизмны җиңүдә хәлиткеч рольне берләшкән илләрнең каолициясе, Советлар Союзы, Англия, АКШның бердәм тупланып көрәшүе зур роль уйнады. Америка сугышка 1941 елның декабрендә Пёрл-Харбор фаҗигасен кичергәннән соң гына тартылды. Әлеге борылышны әзерләүдә совет разведчикларының, беренче чиратта, чыгышы белән Рафисның авылдашы булган Исхак Әхмәров исемле якташыбызның роле аеруча зур. Әнә шул операциянең барышы, механизмы автобиографик штрихлар, документаль фактларга нигезләнгән очрашулар аша искиткеч дөрес күрсәтелгән. Сюжетның, вакыйгаларның масштаблыгына, киң колачлы булуына укучылар игътибар иткәндер. Рафис Корбан әнә шундый масштаблы, дөньякүләм хәлиткеч вакыйгаларның үзебезнең туган якка килеп тоташканлыгын образлы төшендереп бирә. Туган җир, туган ил хәлләре, үзебезнең як, үзебезнең язмыш бөтен дөнья яссылыгына килеп чыга.

Бу мәшһүрлек әлеге романнарның барысын да сугарып тора. Якташлык җепләре мәшһүр композитор Салих Сәйдәшев биографиясендә дә ачык күренә. Милләт каһарманнары Нәкый Исәнбәт, Абдулла Алиш кебек үзебезнең тирәлектә, җирлектә үсеп чыккан талантлар, чыннан да, бөтен дөнья җәмгыяте уллары-кызларын сокландырырлык.

Рафис Корбан геройлары һәм персонажлары ил, бөтен дөнья проблемалары, киләчәге, перспективалары, бәхете өчен янып яшиләр, көрәшәләр, юлларында күп җәберләүләр, кыенлыклар, фаҗигаләр кичерәләр, әмма чын кешеләр булып калалар. Илебез үткән фаҗигале хәлләр, җәзалаулар, репрессияләр алар биографиясендә дә чагыла. Бернигә дә карамастан, барысы да чын каһарманнар, милләт уллары, асыл затлар булып калалар.

Рафис Корбанның иҗатында дөньякүләм әһәмиятле вакыйгаларны бирергә

омтылыш аның иҗатын дөнья классигы Эрнест Хемингуэй шәхесенә яисә аның иҗатына якынайта. Бу, чыннан да, шулай, әмма биредә төп-төгәл параллельләр, янәшәлекләр эзләү артык кебек тә тоеладыр. Стильләрендә аерма шактый ук зур. Әмма бу ике шәхесне бер-берсенә якынайткан билгеләрне дә юк дип әйтеп булмый. Биографияләренең билгеле бер өлешендә үзләрен журналистлар дип санаган бу ике художник бик тә актив рәвештә яңалык эзләүчеләр буларак, әлбәттә, бер-берсенә тартым.

Экстремальлеккә омтылыш Хемингуэйны яшьтән сугыш кырларына китерә. Ул анда канлы фаҗигаләрне күреп кенә калмый, үзе дә авыр тән җәрәхәтләре ала. Бәхетебезгә, бу канлы эпопея аның гомере буена дәвам итми. Соңрак экстремальлеккә омтылу коррида (үгезләр белән сугыш), сафари, табигать давылларына юлыгу, балык тоту бәйрәмнәре стихиясенә бирелү кебек күренешләргә күчә.

Рафис Корбанның илгизәрлеге, экстремальлеге, яңалыкка һичнидән курыкмыйча ыргылып торуы, әлбәттә, башка масштабтарак. Әмма монысын да охшашлык дип әйтеп була. Университетта укуын ташлап, укыган белгечлеге буенча эшкә күчүе, әледән-әле эш урыннарын алыштырып торуы, теләсә нинди эшкә куркып тормыйча алынуы шундый холкының билгеләре бит.

Әлбәттә, иң зур охшашлыкны аларның чын гуманистлыгы, кешелеклелек, намуслылык, ир-атларча ныклык дигән төшенчәләрне яклауда бик тиз табып була. Кызыксынучанлык, тормышның яңа якларын ачарга омтылу – һәр язучы өчен бик табигый әйбер. Һәркем бу юнәлештә нәрсәдер эшли, нидер таба. Бу хәл, әлбәттә, тик кенә бер урында тормыйча, хәрәкәтләнүне, эзләнүләрне сорый. Хемингуэйлар өчен ил чикләре, планета ызаннары аша атлауның һич кыенлыгы юк. Безнең әдипләр өчен чит җирләрдә тормышны күзәтү, өйрәнү, әлбәттә, мәшәкатьлерәк. Рафис Корбан үз профессиясе кешеләре – журналистлар, каләмдәшләре, язучылар белән очрашырга ярата. Ил киңлекләрендә якут, алтай, башкорт, балкар, авар, нугай, кумык, мари, чуваш, казакъ, төрек илләрендә аның иҗатташ дуслары байтак. Алар белән очрашулар төрле милләт әдәбиятларының бер-берсе белән аралашуына, аңлашуына, иҗади багланышларга китерә.

Э.Хемингуэй, язучылык һөнәрен үзләштергәндә, үзенә рус әдипләре И.Тургенев, Ф.Достоевский, А.Чехов, И.Бабель, В.Кольцовларның тәэсире шактый зур булганлыгын билгеләп үтә. Ә инде утызынчы елларда аңа республикачыларны яклап көрәшкән хәрбиләр, журналистлар белән очрашырга, сөйләшергә дә туры килгән. Тормыш дәвамында ул бик күп Америка һәм Көнбатыш әдипләре белән дә аралашкан, әсәрләрендә язучылардан Гертруда Стайн (1872–1946), Шервуд Андерсон (1876–1941), Эзра Паунд (1885–1972), Форд Медонс (1873–1939) тормышлары һәм иҗатлары бәяләнә.

Эрнест Хемингуэйның үзе турында аның романнарында, повестьларында язылганнардан да белеп була. Дөрес, ул үзе турында беренче заттан, ягъни «мин» исеменнән язмый, әмма беренче заттан сөйләүче журналистларның, язучыларның төрле исемнәр аша бирелгәннәре байтак. Алар үзләренең иҗатлары, әсәрләрен ничек язулары турында сөйлиләр һәм аларның күбесендә, чыннан да, автор күргәннәр, кичергәннәр, кичерешләр һәм аның үз характеры чагыла. Мондый урыннарда гыйбрәт, тәҗрибә алырлык итеп язылган иҗат психологиясе турында кызыклы юллар бар.

Ни өчендер безнең татар әдәбиятында әдипләрнең үз иҗат процессы, иҗат психологиясенә мөрәҗәгать итү, шуны яктырту бик сирәк күренеш. Әллә бу тагын үзебезнең йомыкыйлыгыбыздан, үзең турында язу тыйнаксызлык була дип, артык тыйнак булып кыланганнан киләме?

Безнең язучыларыбыз, шул исәптән Рафис Корбан, үзләренең бай иҗат тәҗрибәләрен, геройлары аша үз исемнәреннән ачсалар, бу укучылар өчен бик кызыклы булыр, күңелләрен баетыр иде. Чыннан да, иҗат тәҗрибәң белән уртаклашу

традицияләре татар әдәбиятында әлегә аз шул. Бу юнәлештә соңгы елларда (алар да әле 30-40 ел элек) Әмирхан Еникинең «Кояш баер алдыннан» әсәрен генә күрсәтә алам.

Бәлки әдипләребезгә, чыннан да, тыйнаклык күрсәтеп, кояшлары баеганны көтеп утырмаска, язучылык һөнәре белән бәйле иҗат байлыкларын башкаларга өләшергә вакыт җиткәндер инде.

Әле әйтелгәннәр безнең бу хезмәтебезнең үзәгенә куеп тикшерелгән Рафис Корбанга да турыдан-туры кагыла. Әлбәттә, Р.Корбанның эчке халәте, эчке кичерешләре, автобиографик дөньяны ачу юнәлешендә Э.Хемингуэйдан күп нәрсә ала алыр иде. Монда татар язучысына ялган тыйнаклык, үз-үзең турында күп сөйләргә ярамый – моны мактану шикелле кабул итәрләр дигән, безнең каныбызга сеңгән чикләү комачаулык итә кебек тоела.

Э.Хемингуэй геройларына (алар төрле исемнәр белән аның әсәрләрендә бирелсә дә) авторның шәхси, автобиографик хәлләре салынганлыгы шиксез. Күпне күргән, олы тормыш юлы үткән, күп очрашулар шаһиты булган олпат язучы, чын художник, үзенең бай тәҗрибәсен укучылары белән уртаклашса, ул җәмәгатьчелеккә бик зур тормыш мәктәбе була ала. Үзебезнең татар язучыларының да шушы юнәлештә укучыларга җиткерерлек зур мәгълүматы, эстетик бай багажлары бар. Ә аны ачу-ачмау үзебезнең авторлардан, үзебезнең егет-кызларыбыздан тора. Бу тупланманы укучыларга мулдан өләшсәләр, безнең язучыларыбыз да отар, ныграк танылырлар иде. Рафис Корбан каләменнән төшкән юлларны укыганда, мин шуңа кат-кат ышандым.

Олы изге төшенчәләрне плакатлардагыча төртеп, кычкырып торгандай итеп күрсәтү укучыда әдәби зәвык тәрбияләми, ә, киресенчә, бик күп әдипләрнең иҗат фантазиясен тышаулап тора. Мондый очракларда героик шәхес табигый кешелек сыйфатларыннан мәхрүм кала, ышандыру көчен югалта һәм аяклы лозунг яисә аяклы плакатка, гел дөрес сүзләр генә сөйләп йөрүчегә, бер дә ялгышмый, абынмый торганга әверелә – сәнгати образ булып яшәүдән туктый. Татар прозасында моның мисаллары күп булды. Әмма Рафис Корбан каләменә андый куркыныч янамый. Ул үзенең геройларын чынбарлыкта, ничек булганча, көндәлек тормыш ваклыклары, стихиясе эчендә күрсәтергә тырыша. Тагын бер тапкыр Хемингуэйның иҗади принцибы искә төшә: ул вакыйгаларны, тормыш агышын сурәтләү белән мавыкмый, сурәтләүне түгел, күрсәтүне өстен итеп куя.

Хемингуэй героеның үз-үзен тотышы, сөйләме, кәефе, күз алдыннан кичергәннәре аша аның эчке дөньясы ачыла. Шуннан чыгып, без әйләнә-тирәне, тирәлекне, хәтта бик зур иҗтимагый вакыйгаларны күз алдыбызга китерә алабыз. Тормышта гына түгел, әдәбиятта-сәнгатьтә дә элеккеге, искергән кануннарны теләсә кем җимерә дә алмый. Моның өчен яңача масштаблы рәвештә тормышны киң күзаллау, яңача уйлану кебек сыйфатлар үзләре генә җитмәскә дә мөмкин.

Хәзерге татар прозасында әнә шундый яңалык тарафдарлары күп түгел. Искергән, таушалган алымнарны, өрлекләрне сүтеп, алар урынына яңаларын торгызу һәркемнең кулыннан килми. Шулай яңалыкны яклаучы эшенә ник Рафис Корбан алынды дигән сорауга җавап биргәндә, мин әдипнең характер сыйфатларына укучының игътибарын юнәлтер идем. Кешелеклелек, кыюлык, хөр фикерләү, яңалыкка омтылу кебек нәрсәләр иҗат энергияң ташып торса гына, яңалык тормышка ашырыла ала. Менә шушы гаять тә кызыклы һәм уңдырышлы тупланма яшәп, ныгып, ачылып китсен өчен яшәешнең, шәхси тормышының ниндидер борылышларының туры килүе, аерым шартлар да кирәк була торгандыр.

Әдипнең «Болдин көзе», әнә шушы соңгы 5-6 ел дәверенә, иҗат алиһәләренең «Амин» дип әйткән чакларына туры килгәндер. Иң зур кыенлык, әлбәттә, әдәби стиль чараларын кулланганда, шуларны үзгәрткәндә генә очрый һәм табыла ала.

Рафис Корбан әсәрләрендә авторның үзен очрату кыенрак, ул үзе бөтенләй күренми дисәң дә була торгандыр. Әгәр дә зур зыялы шәхес буларак әсәрләрдә ул үзе килеп керсә, хәл-вакыйгаларга герой-персонажларга үз мөнәсәбәтен белдерсә, бу аның

язганнарын нык җанландырыр иде. Очрашу, күрешү, әңгәмәләр аша тупланган бу иҗат багажының файдаланылмыйча ятуы үземә аяныч тоела.

Хәлбуки, Э.Хемингуэй автор образын ачуның зур мөмкинлекләрен таба алган. Ул бу вазифаны үзенең геройлары-персонажларына йөкли. Байтак әсәрләрдә ул язучы, автор образын бирә һәм шуларның хәл-әхвәлләре, уйланулары-кичерешләре аша иҗат процессы гәүдәләнә. Бер романында ул үз-үзенә көненә билгеле бер сәгатьләрдә өстәл артына утыру таләбен куя. Билгеле бер күләмдә нәрсәдер язмыйча, ул өстәл яныннан кузгалмаска тиеш.

Рафис Корбан иҗаты дигән феномен – ярыйсы ук панорамалы күренеш. Мәсәлән, бүгенге күзлектән карап, үткәннәрне иңләгәндә, милләт каһарманнары образларын тудыру өчен үзеңдә дә чын милли халыкчан һәм кешелек сыйфатларының булуы зарур. Башкаларны, моңарчы язганнарны кабатламаска да кирәк. Шуңа күрә Рафис Корбан үз геройлары тормышындагы хәлиткеч борылышлар, иң экстремаль вакыйгаларны гына үзәккә куя, аларны вакыт ягыннан тыгызлап, концентрацияләп бирә. «Ватан», «Алиш», «Әхмәров», «Җидегәннән төшкән нур», «Артык кешеләр» романнарының теләсә кайсын алыгыз – аларда геройларның берсенең дә бөтен биографияләре тормышларының эзлекле һәм киң агышында түгел, ә шул экстремаль, хәлиткеч вакыйгаларның тыгыз концентрациясе рәвешендә бирелә. Шулар гына бирелсә дә, һәр геройның кемлеге, казанышлары, мәсләкләре тулысынча ачыла. Бу алым, әлбәттә, скульптор-художниклардан һәр артык детальне кисеп, төшереп калдыруны сорый.

Шушы мөнәсәбәттә Рафис Корбан язганнар Эрнест Хемингуэй алга сөргән алымнарга, аның экстремаль вакыйгалары сайланышына һәм лаконик стиленә якыная. Әлбәттә, моңа тулысынча ирешү бигүк җиңел түгел, чөнки дөнья художнигы Хемингуэй һәм татар язучысы Рафис Корбан биографияләрендә шактый зур аерма бар. Дөнья язучысы өчен күргәннәрен үз эчеңә генә салып, бикләп калдырмау бик әһәмиятле. Әдипләребез дә бу юнәлештә классиклар салган юлларны сайласалар иде.

Хемингуэйның, Гертруда Стайн, Скотт Фицджеральд кебек мәшһүрләрнең күрсәткән юллары, бәяләмәләре дөнья бәясенә торырлык. Рафис Корбанның да хәзерге әдәбият процессында үз ягындагы шәхесләр белән аралашу тәҗрибәсе бик зур. Дөрес, үз романнарында ул классиклар аша безне бик күпләр белән таныштыра. Ә менә бүгенге танышларын үз күзләре, үз карашлары күрсәткәнчә сурәтләсә, бу бик әйбәт булыр иде. Мәсәлән, замандашлары, каләмдәшләренә дә герое исеменнән генә түгел, үз исеменнән бәя бирү начар булмас иде. Хемингуэйда әнә шул бар, безнекеләрдә бу юк – чөнки әле яшисе бар, якындагы кешеләр турында ничек сөйләргә? Э.Хемингуэйда мондый курку, шикләнү, сагаюлар булмады.

Минем үземне бу әдипнең бигрәк тә ихласлыгы, тормыш вакыйгаларын башкалар боерыгы яисә кушуы буенча түгел, үзенчә күрүе, бәяләве сокландыра. Үзеннән-үзе уңай герой кебек яшисе килә башлый. Хәтта аның героен яисә персонажын беркадәр үзең дип аңлый башлыйсың, һәрнәрсәне аларча, алар булып, үзең бәяләргә керешәсең.

Янәсе шушы минутларда мин Испаниядә йөрим. Памплона, Сарагоса, Бискайя буйларында йөрим, корридада үгезләр белән сугышам яисә, этиемә ияреп, филләр эзәрлеклим, арысландай киекләрне күзәтәм, елгаларда форель, диңгез-океаннарда зур балыклар тотам, Париж, Наварра, Мадрид отельләрендә, кафеларында күңел ачам, ул арада озакламый кулыма корал алып, Испания республикачыларын яклап, сугыш кырларына китәм. Кайда гына булсам да, мин һаман да гап-гади бер кеше булып калам.

Менә мондый халәт, шушы классик әдипнең әсәрләрен укыганда, үзеннән-үзе килә. Каян килә икән ул? Авторның кабатланмас стиленнәнме? Әллә нәкъ безнең үзебезнең милләт кешесенеке кебек гап-гади уйларыннанмы?

Классиклар сихере сине бөтереп, әнә шулай әллә кайларга алып китә.

Ә бит бу сихер әллә кайларда түгел, үзебезнең каләмдәшләребез әсәрләрендә дә туып тора торгандыр. Мин шушы хакыйкатькә ышанам.

Халәтеңне, хәтта яшәешеңне авторныкы белән янәшә кую алымы татар прозасында бигүк еш очрамый. Биредә сүз хикәяләрнең мин исеменнән сөйләү турында гына бармый. Автор мин исеменнән сөйләгәндә дә, гадәттә, ул башка бер затныкы булып тоела – синең үзеңнеке түгел. Ә менә Хемингуэйны укыганда, син укучы буларак үзеңнән-үзең шул шәхес булып яшисең, аның күргәннәре, кичерешләре шәхси үзеңнеке булып тоела. Син – укучы – үзең шул кичерешләр, күргәннәр дөньясында яши башлыйсың. Бу халәткә художник безне ничек алып килә соң?

Мәгълүм ки, беркем дә – ул хет әллә нинди милләтпәрвәр, ватан патриоты, милли каһарман булмасын, гел шулай бөек уйлар белән генә яшәми. Аның шушы мизгелдәге, шушы минуттагы хәле, халәте бар. Хемингуэй әнә шуларны күрсәтү белән укучыны үз артыннан ияртеп алып китә, аны үзенеке итә. Монда бөек гыйбарәләр, зур тасвирлау алымнары соралмый. Тасвирлау түгел, күрсәтү аша ирешә моңа бөек художник. Моңа үзенә бер стиль ярдәмендә ирешелә. Хемингуэй исә искиткеч кыскалык һәм конкретлык стиле белән дөньяга танылды бит. Моңа һәркем ирешә алмый. Шул исәптән безнең татар прозасы вәкилләре дә. Шулай да нәкъ шушы стильгә омтылыш бар – һәм ул безнең прозаикларыбыздан Рафис Корбанда сизелә. Әлбәттә, ул моны Хемингуэйга иярәм дип язмый торгандыр. Әмма аның прозасында шундый охшашлык бар.

Кешенең күңелендә бөеклек, олылык, югары уйлар салынып, шулар аның кешелеклелеген тәэмин итсә дә, ул гел шулар белән генә яши дип күрсәтелсә, һич тә дөрес булмас иде. Әле аның кешеләргә гадилеге, көн итү мәшәкатьләре, бүгенге торышы, яшәеше бар – герой шулардан читләштерелсә, укучы аңа ышанмас иде. Менә шушы бүгенге көндәлек халәтне бирә, җентекләп күрсәтә белү Рафис Корбан әсәрләрендә бар – һәм менә нәкъ шулар әлегә милли прозабызда моңарчы күрелмәгән стиль – Рафис Корбан стиле турында сүз куертырга мөмкинлек бирә.

Күп әсәрләрендә Хемингуэй үзенең язучы яисә хәбәрче, корреспондент икәнлеген яшерми һәм турыдан-туры үзенең язучылык хезмәте турында, бу эшнең никадәр мавыктыргыч булуы турында сөйли. Үз-үзеңне эшкә мәҗбүр итү, язу дисциплинасы турында да кызыклы юллар бар. Бер урында ул, кулыңа каләм алып, үзеңне мәҗбүр итеп утырту һәм 700-800 юл язмыйча өстәл артыннан җибәрмәү турында сөйли.

Ник безнең язучыларга да үзенең иҗат тәҗрибәсен, әдәби процессны бүген ничек аңлавын, әдәбият мәсьәләләре турында фикерләрен каләмдәшләре белән бәхәсләшүен яисә шул уңайдагы карашларын үзенең укучысы белән уртаклашмаска?!

Рафис Корбан моны эшли дә, булдыра да алыр иде. «Артык кешеләр», «Җидегәннән төшкән нур», «Алиш» романнарында Нәкый Исәнбәт, Салих Сәйдәшев, Кәрим Тинчурин, Таҗи Гыйззәт, шул ук Абдулла Алиш кебек бөек шәхесләрнең иҗат дөньялары, шәхси тормышлары белән бәйләнештә бик җылы итеп, җентекләп күрсәтелгән бит. Без бу урында мәсьәләгә Рафис Корбанның үз шәхси дөньясы аша заманыбызның әйләнә-тирәдәге бүгенге кешеләр, әйләнә-тирәдәге күренеп, очраштырып йөри торган талантларыбыз турында да күп нәрсәләр яза алу мөмкинлеге, перспективасы барлыгын гына искәртеп үттек.

Җәмгыять, тормыш, яшәеш – бер яктан, икенче яктан, художник мәсьәләсе әдәбиятның үзәгендә торды. Ягъни художникның һәм аның җәмгыятьтәге урыны, тормыштагы, яшәештәге роле. Чыннан да, бу мәсьәлә бервакытта да, бер чорда да көн кадагыннан төшмәде, гел актуаль булып кала бирде.

Күзәтүләребезнең, хезмәтебезнең үзәгенә куелган бөек әдип Эрнест Хемингуэй иҗатында бу чагыштырма, капма-каршылык яисә янәшәлек аеруча ачык сизелә. Әмма бу очракта янәшәлектән дә бигрәк, күбрәк капма-каршылык турында сөйләшергә мәҗбүр булабыз. Бу мәсьәләне олы художник күбрәк үзенең героен экстремаль, кайчагында хәтта чыгып булмаслык ситуацияләр, вакыйгалар, хәлләр аша чишәргә омтыла.

Героебызның хәле еш кына әсәрләрдә фаҗигале чикләргә барып җитә һәм һәлакәт баскычына күтәрелгән хәлдә өзелә.

Әсәрләренә генә түгел, әдипнең үз тормышының фаҗигале тәмамлануына да күз салсак, тормыш пикларыннан чыга алмаган әдипнең олы фаҗигале бәйләнешен ачыграк аңларбыз.

Үзебезнең татар прозасы әһелләрен дә мондый ситуация яисә контрапункт читләтеп үтмәде. Аларның тормышлары да авыр, хәтта чыга алмаслык хәлләргә куелды. Егерменче гасырның утызынчы – илленче елларында атып, җәзалап үтерелгән талантларын гына искә төшерегез.

Әлеге хезмәттә без карый торган Рафис Корбан иҗатында талант һәм җәмгыять темасына бик зур урын бирелә. Фашистлар төрмәләрендә гомерләре өзелгән Муса Җәлил һәм Абдулла Алиш, узган гасырда үзебезнең илдә кыерсытылган Салих Сәйдәшев, Нәкый Исәнбәт, Таҗи Гыйззәт һәм җәзаланган Галимҗан Ибраһимов, Кәрим Тинчурин, Шамил Усманов, Фәтхи Бурнаш кебек талантларны ул әсәрләрнең үзәгенә куеп тикшерә, анализлый. Һәм хикмәт фаҗигаләрдә генә дә түгел. Автор әлеге шәхесләрнең үзенә бер төрле энциклопедиясен тудыра. Укучы әлеге шәхесләр яшәешенең яңа, әлегә без белмәгән яклары белән таныша. Бу очракта да дөньяның бөек художнигы белән милли язучыбыз арасында фикер, тема, сюжет, проблемалар уртаклыгы турында сүз йөртү мөмкинлекләре ачыла.

Чыннан да, шушы мөнәсәбәттә дә, шулай ук фәкать татар прозасы турында гына сөйләгәндә дә, Рафис Корбан иҗаты аша укучыга нинди күп яңалык килгәне аңлашыла. Дөрестән дә, төп стимуллар булып бу урында кыюлык, яңалыкны эзләү һәм ачу, моны эшләү өчен геройларның экстремаль шартларда эш-хәрәкәтләре сайлана. Әлбәттә, болар барысы да «Ватан», «Алиш», «Артык кешеләр», «Җидегәннән төшкән нур» әсәрләрендәге әдәбият-сәнгать әһелләренә генә түгел, бу өлкәдән читтәрәк торган профессия вәкиле Исхак Әхмәров образына да кагыла.

Әлегә без әдипнең тормышта булган, чыннан да, эз калдырган, документаль фактларга нигезләнгән биографияләр, талантлар турындагы әсәрләре хакында сөйләдек. Әмма шушы урында тагын бер хакыйкать ачылып килгәне сизелә. Рафис Корбанның төп максаты аерым шәхесләрнең образларын гәүдәләндерү генә түгел икән. Ул, гомумән, халкыбыз, илебез үткән, кичергәннәр аша бүгенге яшәешне, үзебезнең, илебезнең, төбәгебезнең бүгенге хәлләре панорамасын ачарга тели икән. Моны раслау өчен документаль фактлардан да бигрәк, язучының уйлап чыгару сәләтенә нигезләнгән, әмма барыбер әйләнә-тирәбездәге тормыштан алып язылган «Тәүбә көне» исемле яңа повестена мөрәҗәгать итү дә җитә.

Моны шул геройның маҗаралары сюжеты дип кенә бәяләү аз булыр иде.

Хемингуэйның проза стилендә күзгә нык ташлана торган берничә сыйфат бар. Күзгә нык ташлансалар да, алар шактый ук табигый тоелалар. Шуларның берсе – аның су агышы шикелле эзлекле табигыйлеге. Укучысын ул әнә шулай агып торган инеш суы эзлеклелеге сыман салмак кына алып кереп китә. Гадәттә, башта персонажның карашы аша әйләнә-тирәсе, күз күреме ераклыгындагы күренеш, антураж бирелә. Кыска гына җөмләләр аша шул минуттагы картина гәүдәләнә. Тыныч кына сөйләм алымы укучыны да шул тыныч тонга, шул эзлеклелеккә көйли һәм тыныч, ипле тонга, ипле сөйләмгә җайлаштыра. Биредә авторның артык хисләргә бирелүе дә, обстановканы, шартларны бәяләү дә юк диярлек. Бәяләү булганда, ул авторның ләззәте яисә кабул итмәве рәвешендә күренеп китүе мөмкин. Әмма озаклап, җентекләп аңлатулар очрамый. Укучының үзенә дә сизгер булырга кирәк. Язучы вакыйгаларны, күренешләрне тезеп барганда, кирәксез икәнлеген безгә төшендереп, аңлатып тормый. Бик кискен, фаҗигале күренешләр янында озаклап тукталмый, битараф кына шул күренешләр, вакыйгалар яныннан узып китә кебек. Нәрсәнең эре, нәрсәнең вак, нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнлеген дә укучы андый урыннарны үзе аерып алырга тиеш. Әсәрләрдән моның конкрет мисалларын да күрсәтергә була. Хемингуэй, моны укучының үзенә тапшырып, аның зирәклеге,

акылы, зәвыгының камиллегенә исәп тота сыман. Аның каравы, кирәкле эпизодлар, күренешләр үтә конкретлыгында укучыга җиткерелә. Мондый конкрет күрсәтү, ишеттерү алымы диалогларга да карый. Хемингуэйны чын-чыннан диалоглар остасы дип санарга мөмкин. Автор кабатлауларны ярата. Кабатлана торган фразалар, фикерләр, гыйбарәләр ярдәмендә геройның бу минутларда нинди уйлар эчендә булуын, күңеленең нинди утларда кайнаганын яисә нәрсәнедер күңеленә салмавын, яисә алардан читләшергә теләвен дә аңлап-аңлатып була. Боларны, әлбәттә, автор стиленең үзенчәлекләрен, алымнарын, аның фикерләү һәм күрсәтү алымнарын үз иткән, яраткан укучы берниндикыенсынусыз, каршылыксыз кабул итә. Монда купшы сүзләр, буш яңгыравыклы фразаларның әсәре дә юк.

Мондый стиль белән якыннан таныша алган татар прозачылары үзләренең иҗат багажларына, әйтергә яраса, арсеналларына күп нәрсә ала алырлар иде.

Төп фикерне нык туплап, концентрацияләп бирү омтылышы да үз язучыларыбыз әсәрләрендә дә, Аллага шөкер, бар. Бу бик әйбәт һәм укучыларыбызны шатландыра.

«Тәүбә көне» повестенда төп фикер, төп проблема, әсәрнең төп мәгънәсе бер, әмма бик ачык, конкрет сюжет интригасы аша, кабатлап өстәүләр һәм лирик, психологик кичерешләр аша ачыла. Сюжет интригасы бик гади сыман булса да, ул геройны гайре табигый, ягъни гадәттән тыш, хәтта экстремаль хәлләр уртасына кую яисә аны шунда ыргыту ярдәмендә башкарыла.

Әле генә коры җирдә көн иткән герой, онытылып китүе аркасында, океандай киң диңгез, су кочагында һәлакәт алдында кала. Моннан чыгу, котылу, исән калу хәзер аның үз кулында, үз теләгендә генә түгел. Шунда ук язмыш вердикты, язмыш җәзасы дигән нәрсә калка. Автор җавапны да бик тиз таба, бу хәл геройның бозыклыгы, юньсезлеге, әшәкелеге өчен күкләр җәзасы кебек аңлашыла, гәүдәләнә башлый.

Кеше һәм табигать бөеклеге, яшәешнең котылгысыз үз кануннары, гасырлар буена үтәлеп килгән тәртипләр янәшәсендә яисә каршысында үземчә яшим һәм булдырам дип бәргәләнү, көчәнү, әллә кем булам дип мактанулар бик вак нәрсәләр булып кала. «Тәүбә көне»ндәге Ислам Мөхәммәтович су стихиясендә очраклы рәвештә генә исән кала. Чынбарлык, язмыш тарафыннан ул тиешле җәзасын да ала. Әмма бу бәндә өчен язмыш җәзасы чын сабак булырмы, юкмы? Мөгаен, тормыш биргән сабакларны ул аңламас та, кабул да итмәс, чөнки кешеләрне, беркемне дә санламаска гадәтләнгән.

«Бер уч туфрак» повестенда, соң булса да, атасы туган җирләрдән бер уч туфрак алып кайтып, каберенә салу теләге тормышка ашмый кала. Барысын да вакытында башкарырга кирәк, һай, кеше гомере кыска, көннәре санаулы шул.

Хемингуэйның «Карт һәм диңгез» повестеның нигезенә тирән фәлсәфә уйлар салынган. Кеше җиңәме, әллә стихияме? Бу дилемма зур сорау астында.

Бөек акыллы затлар гомерләре буена шул сорауга җавап эзләгәннәр. А.С.Пушкинның, «Дар счастливый, дар случайный – жизнь, зачем ты нам дана?» дип, шигъри фәлсәфи аваз салуы очраклы түгел. Ягъни «Тормыш – бәхетле бүләк, очраклы бүләк, ни өчен безгә бирелгән ул?!» дигән бит бөек Пушкин...

Әнә шулай итеп, һәр язучы безне тормыш агышына, көрәш, яшәеш стихиясенә юнәлтә.

Биредә сюжет интригасын кору аеруча әһәмиятле. Әлбәттә, бу интриганың үзенә геройның максатка баруы куелган. Шулай да нинди максатлар?

Максатның конкретлыгы еш кына әсәрне әсәр итә, укучыны кызыксындыра, автор артыннан алып китә һәм бу үзара бәйләнеш әсәр дәвамында югалмый. «Кыңгырау кемгә карата чыңлый?!» исемле мәшһүр романда утызынчы елларда Испаниядә фашистларга каршы барган сугышның конкрет өлеше бирелә. Романның персонажлары һәм төп герое бер максат белән яшиләр. Фашистлар өчен үтә дә әһәмиятле булган стратегик күперне үз вакытында, иң кирәкле вакытында шартлату. Максат та, уйлар да шул операция тирәсендә, шуның фонында – ахыр чиктә моңа ирешелә дә, әмма

вазгыять инде үзгәргән була, аның әһәмияте калмый диярлек, максатка ирешелә, әмма зур югалтулар хисабына, әсәрнең төп герое тормышының соңгы минутлары килеп җиткәндә, шушы 700 битле романның соңгы бите ябыла. Шушы сюжет интригасы фонында бер мизгелдә әсәр барышына, вакыйгаларына игътибар кимеми, мәсьәләләр, геройлар, персонажлар тулысынча ачыла.

Максатка бару интригасы һәрвакыт зур масштабларда, күләмнәрдә булмаска да мөмкин. «Карт һәм диңгез»дә карт балыкчы зур балык тоту турында хыяллана. Гомере буе хыялланып яшәп, инде шуңа ирештем дип, көймәгә шул зур балыкны тагып алып кайтканда, аның табышын акулалар ашап бетерәләр – балыгының башы гына кала. Ә яшәргә кирәк – тормыш барыбер дәвам итә.

Рафис Корбанның «Тәүбә көне» белән «Бер уч туфрак» повестьларында геройларың максатка ничек барулары хакында әйттек инде. «Әхмәров», «Ватан», «Алиш» романнарында төп максат – фашизмны җиңү икәне дә әйтелде. Бу – бик зур, хәтта корбаннар сорый торган максат. «Артык кешеләр»дәге төп сюжет интригасы авыр шартларда сәнгатькә хезмәт итүгә корылган.

Күрәсез, анализлый торган язучылар әдәбият-сәнгать кануннарын бик дөрес аңлыйлар. Әсәрләренең бөтен компонентларын әнә шундый олы һәм кечкенә сюжет интригаларына нигезли беләләр.

Ничек кенә сөйләсәң дә, кешенең яшәү рәвеше кечкенә һәм зур шатлыклардан, ләззәтләрдән тора. Әсәрләрдәге герой-персонажлар да тормышның ләззәт-шатлыкларыннан үзләрен мәхрүм итмәскә тырышалар. Монысы да үзенә күрә бер максат – ягъни тормышның гүзәллеген, матурлыгын тоеп яшәү ләззәтенә ирешү. Әмма шундый омтылыш үзмаксатка әверелсә, башка мәнфәгатьләр онытылып яисә кичерелеп, туйдыра башласа – монысының башка көтелмәгән борылышларын көт тә тор. Тормыш, яшәеш фәлсәфәсенә бәйле кичерешләр муллыгы, күп нәрсәләргә ирешелгәч, яшәүнең кызыгы калмавына төшендем инде дип ялгыш уйлап, психологик планда авышулар бөек художникның шәхси һәлакәтенә алып килә.

Олы язучылар ирешелгәннәрдә туктап кала алмыйлар – алар гел хәрәкәттә, яңалык эзләүдә һәм, күңелендәгене үз эчендә калдырмыйча, башкалар белән аралашуда. Әнә шундый хәрәкәт, тормыш давылларында кайнап тору, аның дулкыннарында кая табадыр омтылу, йөзү, бәхетебезгә күрә безнең әдәбиятыбызның, аерым алганда, прозаның йөзен билгели. Бүгенге көндә шушы юнәлештә үсәргә татар прозасының көче җитәрлек. Яңа исемнәр калка, үсә тора.

Хәрәкәт тизлеге үсә. Гомумән, бүгенге яшәешнең темпы, хәрәкәте тизләнештә. Бәлки шуңа күрәдер, китап укучылар да бүген инде элеккеге, салмак, озын су буе җәелгән романнарга исәп тотмыйлар.

Прозаның киләчәге тормышның үзе кебек мобиль жанрларда. Алар төрле исемнәр белән аталсалар да, бу шулай.

Укучы игътибары кискен, энергияле, яңалыгы ташып торган дәртле жанрларга күчә. Рафис Корбан, Марат Кәбиров, Рүзәл Мөхәммәтшин, Рөстәм Галиуллин, Рәдиф Сәгъди, Вахит Имамов, Солтан Шәмси, Фирдүс Гыймалтдинов һәм башкалар. Санап бетергесез күп исемнәр, аларның әсәрләре бүген татар прозасының умыртка баганасы булып тора.

Әлегә без өлкән язучыларыбызның исемнәрен атамадык. Санап кителгән казанышлар бары тик өлкәннәр тудырган җирлектә генә барлыкка килә алалар. Мәсәлән, Вакыйф Нуруллин, Марат Әмирханов, Айдар Хәлим, Фоат Садриев кебек остазларның әсәрләре җирлегендә. Шулай ук мин бу урында аңлы рәвештә бүгенге прозаның гаять көчле ташкынын искә алмадым. Бәлки мине гендер күренешен яклауда гаепләрләр. Әмма ничек кенә булмасын, татар әдәбиятында хатын-кызлар прозасы да үз кануннары буенча үсә һәм мул җимешләрен бирә. Аларның әсәрләрендә дөнья хәлләрен, кешеләрнең тормышларын, көнкүрешләрен дөресрәк итеп аңлату да бар. Без

ир-ат затлары алар белән бәхәсләшмибез – гомумән, прозабызның шушы тармагына анализны башка вакытка калдырып торыйк. Дөресен әйткәндә, әлегә шушы минутта гүзәл затлар тудырган байлыкны аңлатырга һәм үзләштерергә мин фәкать эстетик яктан әзер түгел. Әлегә гафу итеп, кичереп торыгыз.

Төп темадан – ә ул дөнья әдәбияты классигы белән милләт прозаигы иҗатларын мөмкин кадәр янәшәрәк, якынайтыбрак куеп караудан, анализлаудан гыйбарәт иде – мин шуннан читләшә башладым кебек.

Заман агышына иңләп, аның панорамасын күзәтеп, бүгенге хәлләребезне, яшәеш күренешләрен янәшә куеп, ихластан аңлату, тикшерү сәләте Ходайдан һәркемгә дә бирелгән әйбер түгел.

Прозаикларыбызның күбесе тарих турында язалар. Бүгенге тормышның проблемаларын, кыенлыкларын, авыр хәлләрен һәм шуннан чыгу юлларын тикшергән әдипләр бармак белән генә санарлык.

Бозык капитализм, акча, базар мөнәсәбәтләрендәге гаделсезлек, коррупция, интернет баткаклыгына кереп батып, шундагы фейклар, тәртипсезлекләргә ияреп, кешечә йөзеңне югалтулар... Боларны әдәбиятчылар күреп тора, тик шушы баткаклыктан чыгу юлларын алар да белеп бетерми торганнардыр. Җәмгыятебезнең кая таба баруына чаң сугып кисәтүчеләр дә шулар булырга тиеш иде кебек лабаса!

Әмма татар прозасының һаман да юк-бар тормыш ваклыкларының тузаннарын кагынган көне. Чаң сугарга күптән вакыт, чаң сугып кына котылып булса! Татар телебез үзебезнең күз алдында мескенләнеп, югалып бетеп бара. Тормышыбызда халык бәйрәмнәре, спорт ярышлары, шоу, күңел ачулар көннән-көн зуррак урын били. Испания халкы өчен коррида – үгезләр сугыштыру, үгезләр артыннан йөгерешү кебек күңел ачулар иң яратыла торган бәйрәмнәрдән санала. Шушы бәйрәмнең барышын, бөтен матурлыгында, кискенлегендә ничек үткәрелүен аеруча ачык итеп Эрнест Хемингуэй сурәтли алды. Без ул бәйрәмнең нәрсә һәм нинди икәнлеген нәкъ шул Хемингуэй язмалары аша гына күз алдына китереп яшәдек дисәк, һич тә арттыру булмас. Дөрес, еллар үткән саен корриданың үзен барып күрү мөмкинлеге гел арта бара. Әмма татар баласы өчен аеруча кадерле күренеш ул испан корридасы түгел, ә «Рубин» һәм «Ак барс» уенчылары тарафыннан футбол һәм хоккей уеннары. Тик әдәбиятыбызда шушы чит җирләрдән килгән уенчылардан төзелгән командалар катнашындагы уеннарның хозурлыгын, популярлыгын, драматизмын күңелләргә сеңдерерлек итеп түгел, хәтта гади генә итеп, художество дәрәҗәсенә җиткереп дип әйтеп тә тормыйм – әлегәчә сурәтләп тә, аңлатып-аңлатмыйча да әйтеп бирүче татар әдибе әсәрен күргәнем юк.

Юк, күңелне бик төшермик әле. Аның каравы үзебезнең Сабан туебыз бар! Менә кайда ул халык тантанасы, халык бәйрәме! Корридалар бер якта торсын. Менә бу урында татар прозачылары үзләрен күрсәтә алалар. Бу бәйрәм турында белеп, яратып язган язучылардан зур исемлек төзеп булыр иде. Мин инде Галимҗан Ибраһимов («Алмачуар»), Фатих Хөсни («Йөзек кашы») исемнәрен әйтеп тә тормыйм. Бүгенге прозаикларыбызның теләсә кайсын алсаң да, Сабан туе тирәсендә һәркем ат уйната белә. Шул исәптән бу язмада иҗаты турында сүз барган Рафис Корбаныбыз да. Күптән түгел генә ул «Соңгы Сабантуй» дигән бик матур хикәя язды.

**Рифат СВЕРИГИН.**

# ШӘХЕС ТӘРБИЯЛӘҮ – ТӨП БУРЫЧЫБЫЗ!

*«Татарча да яхшы бел,*
*Русча да яхшы бел.*
*Икесе дә безнең өчен*
*Иң кирәкле затлы тел».*

Мәктәп бусагасын атлап кергәндә, Шәйхи Маннурның бу шигъри юлларын яттан белә идек без. Ә бүгенге – 21 нче гасыр балалары, татар һәм рус теле белән генә чикләнмичә, чит телләрне күбрәк белгән саен уңышлырак, дәрәҗәлерәк санала. Әмма чит телләргә өстенлек биреп, бала ана теленнән читләшмәсме соң? Берничә елдан ана телен чит тел буларак өйрәнә башламасмы?

Милли мәгариф системасында ана телләрен саклау, укыту кебек сораулар беркайчан да җиңел булмаган. Кайчандыр республикабыз өчен полилингваль мәктәп төшенчәсе дә чит-ят сүз иде. Ләкин республикабызның төрле шәһәрләрендә ачылган полилингваль мәктәпләр татар телендә укытуга яңа сулыш өргәндәй булды. Ана теле – татар телендә дә, дәүләт теле – рус телендә дә уку, чит тел – инглиз телен дә өйрәнү бүгенге заман укучысына зур мөмкинлекләр ачты. Хәзерге вакытта республикабызда «Адымнар» мәктәбе алтау. Чаллы шәһәрендә өченче мәктәп булып, 2021 елның 1 сентябрендә ул үз ишекләрен ача. Шәһәр тарихында булган зур вакыйга – мәктәп ачылышында күп кенә дәрәҗәле кунаклар белән беррәттән, Россия Федерациясенең Хезмәт Герое, ТР Дәүләт Киңәшчесе киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиев та катнаша. Аның хәер-фатихасы белән ачылган белем йортында бүгенге көндә 1008 бала гыйлемне өч телдә ала.

– Безнең гимназиядә фәннәр татар, рус, инглиз телләрендә укытыла. Мәсәлән, 5 нче сыйныфтан башлап 9 нчы сыйныфка кадәр тарих, физкультура дәресләре татар телендә; биология, музыка, география фәннәре инглиз телендә; ә математика фәне рус телендә алып барыла. Дәрестән тыш чаралар да мөмкин хәтле шушы өч телдә үтә. Дөрес, мәктәп үзенчәлекле, ул – полилингваль. Безгә балаларын алып килгән ата-




*ТР Дәүләт Киңәшчесе М.Ш.Шәймиев Чаллыдагы «Адымнар» мәктәбен ачу тантанасында сертификат тапшыра.*

аналар да шуны аңлыйлар. Телләр өйрәнү һәм традицияләрне саклау максатыннан, гимназиягә укырга киләләр. Безнең гимназиядә моның өчен бөтен шартлар да тудырылган. Укучылар 2 нче сыйныфтан кабул ителә. Укуларын 11 нче сыйныфка кадәр дәвам итәләр. Күптелле «Адымнар-Чаллы» гимназиясендә эшли торган укытучылар да башка мөгаллимнәрдән аерылып тора. Алар өчен махсус таләпләр бар: укыта торган фәннәрне укыту планында билгеләнгән телдә алып бару. Бу эштә безнең төп ярдәмчеләребез – Яр Чаллы дәүләт педагогика университеты һәм педагогика көллияте. Укытучыларыбыз барысы да югары педагогик белемле. Белем йортына һөнәри дәрәҗәләрен даими күтәреп торучы кадрлар тупланган. Укытучы гомере буена үзлегеннән укып, белемен арттырырга, үз өстендә эшләргә, ягъни эрудицияле булырга тиеш, – ди «59 нчы күптелле гимназия «Адымнар-Чаллы» директоры Азат Галиев.

Республикада эшләп килүче «Адымнар» комплекслары үзара даими тыгыз элемтәдә эшли икән. Тәҗрибә уртаклашу максатыннан, төрле дәрәҗәдәге семинарлар үткәрелү дисеңме... Күрше Башкортстан Республикасының Нефтекама шәһәрендәге татар «Белем» мәктәбе дә уртак семинарларда көтелгән кунак булып санала. Шулай ук «Яңарыш фонды», Мәгариф һәм фән министрлыгы белән дә гимназиянең элемтәләре ныклы.

Соңгы елларда белем йортының уңышлары турында сүз кузгаткач, беренче чиратта, бердәм дәүләт имтиханнары нәтиҗәләре телгә алына. «59 нчы күптелле гимназия «Адымнар-Чаллы»ның да бу юнәлештә күрсәткечләре мактап сөйләрлек: «Барлык 9 нчы сыйныф укучыларыбыз да имтиханнарны «4» һәм «5» билгеләренә генә тапшырды, дисәк, ялган булмас. Укучыларыбыз фән олимпиадаларында, төрле бәйгеләрдә уңышлы чыгыш ясыйлар. Бу гимназиядә эшли торган укытучыларның югары дәрәҗәдәге белгеч икәнен исбатлый бит. Компетентлы укытучы гына компетентлы шәхес тәрбияли ала», – ди Азат Таһир улы.

Язмам башында күтәргән төп сорау – ана теле – татар теленең мондагы хәлен сорамыйча булдыра алмадым. Татар теле фән буларак укытылса да, балалар татар телен сөйләмдә тиешле дәрәҗәдә куллана микән? Аны үзара аралашуга кертү өчен нинди эшләр башкарыла? Бу мәсьәләдә әти-әниләр белән эш ничек тора? Директорның бу өлкәдә дә үз фикере бар.

«Соңгы вакытта шуңа игътибар итәм: укытучылар үзара да, укучылар белән дә татар телендә аралашырга тырыша. Смс-хәбәрләрне татар хәрефләре белән яза башладылар. Менә шуның алга таба да дәвам итүен телим. Ягъни яшьләр арасында бу модага кереп китсен иде.

Өйдә татарча аралашкан бала ана телен онытмый. Шулай ук ата-ананың телгә мөнәсәбәте нинди, баланыкы да шундый. Иң төп киңәшем шул: ата-аналары – балалары, әби-бабайлары оныклары белән күбрәк татар телендә аралашсын иде. Ни дисәң дә, тәрбия өйдән башлана. «Ана сөте белән кермәгәнне, тана сөте белән кермәс» дигән мәкаль бар. Бу юнәлештә, мәктәп белән гаилә тыгыз элемтәдә торырга тиеш. Уку-укыту процессының үзәгендә укучы шәхесе тора. Уку, билгеле инде, җиңел булмый, әмма без – укытучылар, бу процессны кызыклы һәм мавыктыргыч итәргә бурычлы. Беренче урында милләтпәрвәрлек булырга тиеш дип саныйм. Без, укытучылар, ихлас күңелдән эшлибез икән, татар теленең киләчәге якты булыр, безнең укучыларыбыз киләчәктә татар милләтен үстерүгә үз өлешләрен кертерләр дигән өметтә калам», – ди Азат әфәнде.

**Руфия МӨХЕТДИНОВА.**

# НАСЫЙРИНЫҢ КАЗАН РУХАНИ СЕМИНАРИЯСЕНДӘ УКЫТУ-МЕТОДИК ҺӘМ ГЫЙЛЬМИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Каюм Насыйри семинариядә аралашкан шәхесләрне барлыйк.

Алар арасында иң мәшһүре – тюрколог һәм ислам белгече Н.И.Ильминский. Насыйри Казан рухани семинариясендә укыта башлаганда, Н.И.Ильминский, татар теле укытучысы буларак, аның өчен өлкән укытучы була. Ләкин 1858–1859 уку елында Казан рухани академиясе ректоры белән уртак тел таба алмау сәбәпле, академиянең миссионерлар бүлегендә Мөселманлыкка каршы юнәлеш җитәкчесе Н.И.Ильминский Оренбургка китәргә мәҗбүр була. Архивта Насыйриның 1859 елда Ильминскийга аны бик якын итеп язган хаты сакланган, ул хатында укучылар өчен «Мәҗмәгыль әхвал» китабын һәм татар теле сүзлеген әзерләве турында хәбәр итә, шулай ук Ильминскийның хатыны Екатерина Степановнага сәламләү сүзләре юллый (*Гали М. Каюм Насыйриның кулъязма мирасы // Каюм Насыйри. 1825–1945. Тууына 120 ел тулуга багышланган гыйльми сессия материаллары / җаваплы редактор Ш.А.Рамазанов. Казан, 1948. Б.127).* Димәк, бу чорда Насыйри Ильминский белән тыгыз аралашкан, аны күренекле тюркологның гаиләсенә кунакка чакыра торган булганнар.

1859–1961 елларда Ильминский Оренбургта казакълар белән җитәкчелек итә торган хөкүмәт оешмасында – Оренбург тәрҗемә комиссиясендә эшли, шунда аның җитәкчесе көнчыгышны өйрәнүче галим В.В.Григорьев йогынтысына эләгә. Григорьев хакимияткә татарларның мәдәни-дини уянуы куркынычы барлыгын хәбәр итеп тора, шулай ук бу уянуның күрше төрки халыкларга йогынтысы булачагын да кисәтә.

Н.И.Ильминский Казанга университетта төрек-татар теле кафедрасында эш урыны пәйда булу форсатыннан файдаланып кайта, әмма ул фәнни эзләнүләр алып бармый, игътибарын күбрәк Казан рухани академиясендә укытуга һәм миссионерлык эшчәнлегенә юнәлтә. 1862-1863 елларда – укытучы, 1863–1872 елларда университетның төрек-татар теле кафедрасында экстраординар профессор булып эшли, 1867–1872 елларда «Казан университетының гыйльми язмалары»н редакцияли, 1863–1870 елларда Казан рухани академиясендә төрек һәм гарәп телләре кафедрасында профессор була, 1872 елда Казан укытучылар семинариясенә директор вазифасына билгеләнә.

Казанга кайткач, Н.И.Ильминский, асылда, К.Насыйри белән бер мәйданга эшли: дәреслекләр яза һәм татар керәшеннәренә белем бирә. Тюрколог һәм миссионер буларак, ул 1862 елда татар керәшеннәре өчен «Букварь, краткая священная история, сокращённый катехизис и молитвы» дигән беренче әлифба әзерләп бастыра. Үзенең белемнәрен миссионерлыкны көчәйтүгә юнәлтеп, Н.И.Ильминский гарәп графикасыннан баш тарта һәм татар керәшеннәре өчен әлифба сыйфатында кирилл хәрефләрен кертә. Әмма «Букварь... » семинария укытучысы һәм галимнең элеккеге укучысы Я.И.Фортунатов авторлыгында дөнья күрә. Хезмәт урыны белән бәйле чикләүләр чын авторның фамилиясен куярга комачаулый: Ильминский бу дәвердә университетта укыта, ә җирле рухани цензура бары тик дин әһелләренең хезмәтләрен бастырырга гына юл ача *(Сальникова А.А., Галиуллина Д.М. Буквари для крещёных*

*татар второй половины XIX – первых десятилетий XX в. // Вестник ПСТГУ. Серия IV: Педагогика. Психология. 2019. Вып. 53. С. 92, 93).*

Н.И.Ильминский укучыларның туган телләрендә белем бирә торган башлангыч православие миссионерлык мәктәпләре оештыра, аларда уку-укыту программаларыннан дөньяви предметларны төшереп калдырып, татар керәшеннәрен Рус православие чиркәве кулында тотарга һәм алар арасындагы исламга кайту хәрәкәтен туктатырга мөмкин булыр дип фаразлый. Вакыт күрсәткәнчә, ул бу юлда гаять зур казанышларга ирешә.

1860 нчы еллар уртасыннан Насыйри һәм Ильминский арасыннан кара мәче үтүе турында мәгълүматлар бар.

1867 елда Насыйри 87 битлек «Буш вакытларда укырга сүзләр. Берничә төрле нәрсәләр хакында. Бу дөньяларда ни-нәрсәләр бар, ни эшләр бар – белемгә мәел нтелүчеләрне белешләндерер өчен» китабының икенче, тулыландырылган басмасын эшли. Бу китапны сату турында русча белешмәдә аның исеме үзгәртелеп, «Сборник статей о преметах видимой природы» дип атала *(ТӘһСИның Язма һәм музыкаль мирас үзәге, 11 ф., 1 тасв., 15 сакл. берәмлеге, 1 б.).* Басманың 44 битендә татарча-русча сүзлек, калган битләрендә кеше анатомиясе, минерология, башка табигыять фәннәре буенча фәнни-популяр мәгълүматлар һәм үгет-нәсихәт бирүче хикәятләр китерелә, соңгылары грамматика дәресләрендә уку өчен дип күрсәтелә.

Бу ярдәмлекне төзүнең инициаторы Н.И.Ильминский булган икән. Әмма ул Насыйрига әлеге тәкъдим белән турыдан-туры мөрәҗәгать итмичә, Каюм белән бергә эшләгән Я.И.Фортунатов аша астыртын эш йөрткән. Миссионер мондый басманың кирәклеген, структурасын Я.И.Фортунатовка аңлаткан, анысы Насыйрины әлеге хезмәтен киңәйтеп һәм зурайтып язарга ризалаткан *(Шунда ук).*

Бу дәвердә Насыйриның миссионер Н.И.Ильминский белән аралашып яшәве хакында мәгълүматлар юк. Моңа Каюмның ул чорда булып узган кайбер вакыйгалардан хәбәрдар булуы сәбәпчедер. Насыйриның авылдашлары исламга күчәргә сорап, патшага язган үтенечкә җавап итеп, 1866 елның 1 октябрендә Ильминский, Казан губернаторы вазифаларын башкаручы вице-губернатор Е.А.Розов казаклар отряды, җирле хакимият һәм православие чиркәве вәкилләре белән бергә, Шырданга һәм күршедәге авылларга килә. Бу төркем аларның патшага язган үтенечләренең кире кагылуны әйтеп, православие диненә кайтырга өнди. Әмма үгетләү нәтиҗә бирми *(Представление исправляющего должность казанского губернатора вице-губернатора Е.А.Розова от 5 декабря 1866 года за № 5505 // Ильминский Н.И. Казанская крещёно-татарская школа. Материалы для истории христианского просвещения крещёных татар. Казань: Типогр. В.М. Ключникова, 1887. С.294)*. Нәтиҗәдә Казан губернасында кулга алынганнардан 31 кеше Себергә сөрелә, алар арасында мөселманнар да була. Исламга кайткан бик күп татар керәшеннәре хөкемгә тартыла, төрле срокларга төрмәгә ябыла. Хакимият исламга кайткан татар керәшеннәрен «иманнан ваз кичкән һәм хакимияткә каршы төшкәннәр» белән тигезли *(Загидуллин И.К. К вопросу отпадения крещёных татар Казанской губернии в мусульманство 1866 года // Национальный вопрос в Татарии дооктябрьского периода: Сб. статей. Казань, 1990. С.75, 77).* (Насыйриның авылдашлары 1905 елдан соң гына рәсми рәвештә җирле мөселман мәхәлләсенә язылу бәхетенә ирешәләр.)

Күрәсең, Ильминскийның мөселманлыкка каршы юнәлтелгән гамәли эшчәнлеген күреп, Насыйри аның белән аралашудан ваз кичә. Чөнки Каюм туган авылындагы хәлләрне бик яхшы белеп тора: анда 1864 елдан мулла булып кече энесе Габделкави хезмәт итә.

Насыйриның тикшеренүче буларак формалашуында гарәп теле укытучысы, Алтын Урда тарихы буенча тарихи-археологик тикшеренүләр алып барган Г.С.Саблуков (1804–1880) әһәмиятле роль уйный. 1858–1859 уку елында аның семинариядән китүен

Насыйри бик авыр кичерә. Аның китkәнен ишетеп, Насыйри, укытучының өенә килеп, бик нык борчылуын һәм аңа теләктәш булуын әйтә. Семинариядән – Н.И.Ильминский белән Г.С.Саблуков, Академиядән татар теле укытучысы Биктимер Йосыпов китkәч, Насыйри семинариядә үзе генә калуы өчен хафалана. Ильминскийга 1859 елда язган югарыда аталган хатында «Мин ялгыз калдым. Йа Алла!» дип яза *(Гали М. Каюм Насыйриның кулъязма мирасы. Б.127).*

1858 елның 23 апрелендә олы абыйсы Габделхәйгә язган хатында Насыйри болай дигән була: «…Семинариядә ике ел торамын, анда һәм ялгыз. Ни итмәк кирәк. Әмма сез ничек чыдыйсыз? Хәер, сезнең шөгылеңез күп, тоелмай торгандыр. Белмим, миңа, кая барсам да, дөнья тар, эчем вәсвәсә берлән тулган, һәммәсе хыяле батыйль (буш хыял). Ник вәсвәсә булмасын, һәр җанибтан җәмигъноксанат (һәр яктан бөтен кимчелек) миндә җыелган» *(Каюм Насыйри язган хатлар // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. 4 томда. 3 нче том / Төзүче, гарәп графикасыннан аерым текстларны гамәлдәге язуга күчерүче һәм кереш мәкалә авторы Хуҗиәхмәт Мәхмүтов. Казан, 2004. Б.355).*

Күренеп тора, Насыйри, бер яктан, бер күзенең тумыштан сукыр, икенче күзенә бераз ак төшкән булуыннан уңайсызлана, икенче яктан, руханилар семинариясендә укыта башлагач, үзенә якты йөз күрсәткән һәм ярдәм иткән хезмәттәшләре эштән киткәч, ялгызлык халәтен кичерә. Күрәсең, бу шәхесләр Насыйриның семинариядә эшли башлаган елларда аның иң якын аралашкан хезмәттәшләр даирәсен тәшкил иткәннәр.

Ильминскийдан соң татар телен Насыйри белән беррәттән Казан рухани академиясен тәмамлаган Яков Иванович Фортунатов укыта. Насыйри аның белән дә дустанә һәм эшлекле мөнәсәбәтләрдә була: архивында хезмәттәшен чәй эчәргә чакырган язу да сакланган *(Гали М. Каюм Насыйриның кулъязма мирасы. Б.127).* 1860 елларда икесе дә «Русча-татарча сүзлек» төзиләр, бу да аларның тыгыз хезмәттәшлеге турында сөйли. Кызганыч ки, Я.Фортунатов сүзлеге, авторның 1870 елның июлендә вафаты сәбәпле, кулъязмада килеш кала, Насыйри исә, үзенең хезмәтен 1878 елда бастырып чыгара (*Шунда ук*. Б.127).

Бу елларда Казан рухани академиясе укытучысы А.Д.Троянский Насыйриның «Кыскача татар нәхүе» («Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах») (Казан, 1860) дәреслеген редакцияли *(Гали М. Каюм Насыйриның кулъязма мирасы Б.127).*

Фәнни һәм педагогик эзләнүләре барышында Насыйри Казанның рус фәнни интеллигенциясе белән үзара аңлашып эшләүгә ирешә. Ул Казан рухани семинариясендә эшли башлаганда, Казан университетының «көнчыгыш разряды» башкала университетына күчерелә, анда көнчыгыш факультеты итеп оештырыла. Көнчыгышны өйрәнүчеләрнең – ориенталистларның – элекке составыннан И.Готвальд (1813–1897) кына кала, ул 1849 елда Санкт-Петербургка киткән профессор А.К.Казембек урынына көнчыгыш телләре укытучысы була. «Көнчыгыш разряды» башкала университетына күчкәч, студентларсыз калган И.Готвальд университетның фәнни китапханәчесе булып эшли башлый *(Ермолаева Г. Готвальд Иосиф Фёдорович // Научная библиотека Казанского университета в лицах Ч.1. Сотрудники библиотеки, 1806-2007 гг. / сост. В.И.Шишкин, Ж.В. Щелыванова. Казань, 2011. С. 95-98).*

Насыйри семинариядә укыткан укучылар һәм Казан рухани академиясеннән аңа консультациягә яки өстәмә дәресләр алырга йөргән студентлар, нигездә, православие руханиларының уллары була.

Насыйрида укыган кайбер укучылар белем алуларын Казан рухани академиясендә дәвам итә. Аның шәкертләре арасыннан иң зур карьера ясаган шәхес дип Василий Владимирович Катаринскийны (1846–1902) атарга мөмкин. Ул, 1872 елда Казан рухани академиясен уңышлы тәмамлап, башта Чабаксар руханилар училищесында рус теле һәм чиркәү-славян теле укытучысы булып эшли. 1874 елда

Пермь, Оренбург, Уфа губернияләре, Урал һәм Тургай өлкәләре составында Оренбург укыту округы оештырылгач, Катаринский 1875 елда Н.И.Ильминский тәкъдиме белән бу округтагы татар, башкорт һәм казакъ мәктәпләренең инспекторы итеп билгеләнә.

Бу вазифаны 1902 елга кадәр башкарган В.В.Катаринский кыргызларга русча «Букварь для киргиз», «Первоначальный учебник русского языка для киргиз» (1894) китапларын нәшер итә. «Грамматика киргизского языка» (1897), «Материалы по этнографии киргиз» (1899) исемле хезмәтләр яза. Русчадан казакъчага дини «Изге Иосиф» һәм «Изге гайыб» китапларын тәрҗемә итеп, аларны рус-казакъ башлангыч училищеларына дәреслекләр сыйфатында тәкъдим итә *(Катаринский Василий Владимирович // «Казакстан». Национальная энциклопедия. Т.3 / Гл. ред. Б.Аяан. Алматы, 2005. С. 186-187).*

Инспектор Катаринский – шулай ук авторсыз гына нәшер ителгән «Башкортлар өчен әлифба» (1892) әзерләүче: анда кириллицага нигезләнгән 39 хәрефле алфавит тәкъдим ителә; шулай ук 43 тематик бүлектән гыйбарәт, 2 мең сүзне эченә алган «Кыскача рус-башкорт сүзлеге»нең (1893); 2600 язма сыйдырган «Башкортча-русча сүзлек»нең төзүчесе *(Латыпова Р.М. Катаринский Василий Владимирович // Башкирская энциклопедия. Т.3. З-К. Уфа, 2007. С.372).*

Тел белеменнән иң яхшы укучыларның берсе П.П.Масловский татар теленә – руханилар училищесында, 1860 елдан семинариядә, Насыйрида укыганда өйрәнә. Дәресләрдән тыш, еш кына Насыйри белән әңгәмәләр кора, укытучысына «педагогик максатларда» халык иҗаты үрнәкләрен эшкәртергә ярдәм итә *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле // Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар = Духовное наследие: поиски и открытия / редкол.: И.Г.Гомәров (проект җит. һәм җавап. мөх.), З.З.Рәмиев, А.М.Ахунов; төзүчеләр: Л.Ш.Гарипова, Г.М.Ханнанова. Казан, 2020. Б. 71*), күрәсең, кульязма текстларны әдәбиләштерә.

Казан рухани академиясенең К.Насыйридан консультацияләр алган студентлары арасында Төркестанның булачак зур түрәсе, Көнчыгышны өйрәнүче, этнограф һәм миссионер Н.П. Остроумов (1846–1930) та бар. Ул Казан рухани академиясендә укыган 1866–1870 елларны болай дип искә ала: «Дүртенче елымда Е.А.Малов күрсәтмәсе белән мин гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация язу белән шөгыльләндем, һәм темам буенча Рабгузиның «Кыйссас әл-әнбия» китабын тәрҗемә итәргә тиеш идем. Тәрҗемә миңа гарәп телен тирәнрәк өйрәнергә ярдәм итте. К.Насыйри ярдәмендә мин аны әдәби татар теленә яхшы гына аударып чыга алдым» *(Шарафутдинов З.Т., Ханбиков Я.И. История педагогики Татарстана. Казань, 1998. С.32).*

Мөгаллимнең һөнәри кызыксынулары басмага әзерләнгән һәм инде нәшер ителгән хезмәтләрендә ачык чагыла.

Казан рухани семинариясенең татар теле укытучысы булганда, Насыйри мөселман дине буенча ике китап яза. Сүз, беренче чиратта, 1859 елда һәрбер татар кешесенә аңлаешлы телдә язылган 173 битлек «Мәҗмәгыль әхвал» (1895 елда нәшер ителгән) турында бара, аның нигезен «Сират ән-нәби» тәшкил итә *(Рәхим Г. Каюм Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б. 71).* Мөхәммәт пәйгамбәрнең игелекле гамәлләре һәм сәхабәләрнең, табигыйннарның тормышлары турындагы бу китап Насыйриның мөгаллимлек эшчәнлеге кысаларында әзерләнгән һәм семинария укучыларын ислам тарихы белән таныштыруны күздә тоткан дип уйлыйбыз. Татар теле укытучысы Я.И.Фортунатовка язган хатларының берсендә Насыйри, аны чәйгә чакырганда, башка материаллар белән беррәттән «Мәҗмәгыль әхвал» китабын да кайтаруын үтенгән *(Гали М. Каюм Насыйриның кульязма мирасы Б.127).*

Насыйри, югарыда аталган хезмәтенең беренче кисәген, «Шәҗәрәи мөбарәкәи пәйгамбәр» дигән исем куеп, 1860 елда нәшер иткән. Бу китап «1800–1896 елларда Казан имп. университеты типографиясендә басылган китаплар каталогы»нда (Казан, 1896) исәпкә алынган *(Каюм Насыйриның басылып чыккан хезмәтләре // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Икенче том. Казан, 1975. Б.289).*

Насыйриның семинариядә эшләгәндә язган беренче фәнни хезмәте – «Кыскача татар нәхүе» 1860 елда басыла, ул рус телен өйрәнүче татарларга, татар телен өйрәнүче русларга адреслана. Әлеге басманы бәяләп, әдәбият белгече Г.Сәгъди 35 яшьлек Каюм Насыйрины ул замандагы иң алдынгы һәм өлгереп җиткән филолог һәм татар теле белгече дип бәяли *(Сәгъди Г. Татар халкының үсешендә Каюм Насыйриның роле // Совет әдәбияты. 1944. № 10. Б.53).*

1860 елда К.Насыйри уку өчен 12 битлек «Буш вакытларда укырга сүзләр. Берничә төрле нәрсәләр хакында» китабын да бастырып чыгара, ул балалар һәм үзлегеннән укырга өйрәнүчеләр өчен тәгаенләнә. Бу китап татар телендәге беренче фәнни-популяр басма һәм беренче балалар әдәбияты үрнәге булып тора *(Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбиятын укыту методикасы: Метод. кулланма. Казан, 2000. Б.27).* (Инде әйтелгәнчә, 1867 елда китапның тулыландырылган варианты нәшер ителә).

Каюм Насыйриның семинариядәге беренче биш еллык укыту-методик хезмәтенең нәтиҗәләре шундый.

Аннан соңгы елларда наширлек эшчәнлегендәге беркадәр өзеклекне исә күпмедер дәрәҗәдә Насыйриның 1865 елда өйләнүе һәм 1866 елда сөекле хатынының вафаты белән аңлатып була.

Алга таба Насыйриның фәнни һәм методик эзләнүләр тематикасы киңәя. Бер яктан, ул фәнни мәкаләләр яза башлый. Икенче яктан, хезмәтләрен семинариядә укучылар өчен түгел, ә мөселманнарны күздә тотып төзи.

Аның 1867 елда нәшер ителгән 23 битлек ислам гакыйдәсе турындагы «Гакаид исламия» исемле китабы татар шәкертләренә тәгаенләнә, бу хезмәт шул ук елны кабат «Гакаид рисаләсе» исеме куелып дөнья күрә.

1868 елда Насыйриның төрек теленнән тәрҗемә иткән «Кырык вәзир» китабы чыга, ул китап сөючеләр тарафыннан яратып кабул ителә һәм мәгърифәтче үзе исән вакытта берничә тапкыр кабатлап нәшер ителә *Каюм Насыйриның басылып чыккан хезмәтләре // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Икенче том. Казан, 1975. Б.290).*

Җәйге ялы көннәрендә крестьяннарның көнкүрешен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнү, туган халкының мәдәнияте турында материаллар туплау максаты белән Тау ягындагы татар авылларына сәфәрләре Насыйриның туган якны өйрәнү, этнография һәм фольклор белән кызыксынуын тагын да арттырып җибәрә.

Шулай комплекслы экспедицияләргә чыгу, эзләнүләр алып бару һәм фәнни әдәбиятны өйрәнү нәтиҗәсендә Насыйри этнограф-галим булып җитешә. Насыйриның антрополог-тикшеренүче буларак өлгерүен аның 1867 елда язылган авыл халкының синкретик характердагы дини күзаллауларына багышланган «Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр» дигән русча фәнни хезмәте раслый. Автор халыкның көнкүрешендә һәм телендә сакланып калган борынгы кыйммәтләргә игътибар итә. Мәкалә Рус географик җәмгыятенә җибәрелә һәм 1880 елда басыла.

Профессор В.В.Григорьев бу мәкаләгә кереш сүзе рәвешендә язган бәяләмәсендә (1868 ел) Насыйри хезмәтенең гадәти түгеллегенә игътибар итә, тикшеренүне татарларның борынгы ышанулары турындагы беренче тәҗрибә дип бәяли. Рецензия авторы татар теле укытучысын рус телле укучыга «ислам пәрдәсе»н күтәреп күрсәтүче тикшеренүче дип атый. Профессор мәкаләдән алган тәэссоратлары белән уртаклашканда, хисләрен яшерми: «Татар-мөселманнар арасында Насыйров әфәнде кебек күзәтүче булганы юк иде әле, бөтен мөселман дөньясында була да алмый. Казан университетында Европача белем алуы (биредә Григорьев автор университетта укыган дип ялгыша. – *И.З.*) аны, мөселманнардан беренче буларак, акыл ягыннан шундый югарылыкка күтәргән, ул ислам диненә объектив рәвештә карый алган. Татарларны шактый яхшы белгәнгә, мин мондый күренеш мөмкин дип башыма да китермәгән идем» *(Насыри К. Обряды и поверья казанских татар, образовавшиеся помимо*

*влияния на жизнь их суннитского магометанства // Записки императорского Русского географического общества. По отделению этнографии. 1880. Т.6. С.241).*

Күрәсең, семинариянең татар теле укытучысын булачак православие дине руханилары арасында ислам динен пропагандалауда гаепләүләрдән якларга теләп, В.В.Григорьев авторга татар керәшеннәре диненең синкретик характерын өйрәнергә тәкъдим итә һәм, рухани семинариясе җитәкчелегенә мөрәҗәгать иткәндәй, кереш сүзенең ахырын болай тәмамлый: «Аның башкаларныкыннан аерылып торган карашларында, фәннилеккә якын тикшеренүләрендә мөселман динен пропагандалау итеп кабул итәрлек нигез юк» (*Шунда ук. С.242*).

Каюм Насыйриның семинариядә мәгърифәтче буларак формалашуының иң ачык чагылышы һәм кире кагылмаслык дәлиле булып аның Мөхәммәтвәли Яхин белән бергә 1862 елда хакимияттән Казанда татар телендә «Таң йолдызы» дигән атналык газета чыгарырга рөхсәт соравы тора.

Шул рәвешле, 1855–1860 елларда үзенең дөньяви һәм дини эчтәлекле хезмәтләрен әзерләгәндә, укытучы буларак, Насыйри Казан рухани семинариясе укучыларына йөз тотса, аннан соңгы елларда туган халкының рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү бурычы алгы планга чыга башлый.

Семинариядә эшләгәндә әти-әнисенә язган бер хатында ул болай ди: «... бик скучно, белмәймен, ничек дөньяны уздырырга кирәк. Гомер тизрәк бетсә иде. Бертөрле кеше булса, әллә ни эшләр кылыр иде. Аллага шөкер, мин – Әюб галәйһиссәламнең энесе, ягъни сабыр. Нух галәйһиссәламнең энесе булып, Сөләйман пәйгамбәрнең энесе дә булмасаң, дөньяда торырга бер дә ярамый» (*Рәхим Г.Насыйриның тәрҗемәи хәле. Б.60-61).*

Насыйри бу пәйгамбәрләрнең кайсы гүзәл сыйфатларының үзендә булуын теләгәндер – төгәл генә әйтүе кыен, чөнки аларның тормышы тоташ сынаулардан гына торган. Әюб пәйгамбәр какшамас ныклык һәм сабырлык сыйфатлары белән танылган. Сөләйман пәйгамбәр бик күп телләр белгән, хайваннар һәм кошлар телен аңлаган – табигать белән гармониядә яшәгән. Нух пәйгамбәр кяферләр тарафыннан күп газаплар күргән, әмма Аллаһ кушканны үтәгән, кешелекне бөтендөнья туфаныннан коткарган, шуннан соң Җирдә яңа тормыш башланган: ул Кешелекнең бөек максатына хезмәт иткән.

Шул рәвешле, «кечкенә секуляр җәмгыятьтә», рус зыялылары һәм рус мәдәнияте белән таныш татар зыялылары, интеллектуаллары арасында Насыйри кайсыдыр бер мизгелдә иҗтимагый ялгызлыкта кала, аның педагогик эшчәнлеге никадәр генә тыгыз булмасын, никадәр генә методик һәм фәнни эзләнүләр белән мавыкмасын, иҗтимагый ялгызлыктан барыбер котыла алмый.

Насыйриның, семинариядән киткәч, нәрсә белән шөгыльләнүе безгә мәгълүм түгел. Күрәсең, кешеләр соравы буенча рәсми кәгазьләр тәрҗемә итеп һәм аларга русча гаризалар язып биреп акча эшләгәндер.

Билгеле булганча, ул 1870 елда Казан календаренең беренче чыгарылышын әзерләп бастыра. Ә 1871 елдан үзенең фатирында рус теленә өйрәтү буенча шәхси мәктәп оештыра – бу турыда киләсе язмаларда сөйләрбез.

1871 елның ноябрендә Насыйри янына инспектор В.В.Радлов килеп, үзенең мөселманнарны рус грамотасына өйрәтү буенча училищеларның инспекторы итеп билгеләнүен әйтә. Насыйриның, фәкать аның гына русча-татарча мәктәп оештыра алуын ассызыклый. Шунда Насыйри кабат үзенең җәмгыятькә кирәклеген тоя. Инспекторның ихластан әйтелгән сүзләренә тәэсирләнеп, Насыйри да, ачылып китеп, эчкерсез рәвештә элекке эшеннән бик моңсу, төшенке халәттә китүе турында җиткерә. «Казан шәһәрендә мөселман балалары урысча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы» дигән истәлек язмасында Насыйри үзе хакында өченче заттан болай дип яза: «Вә һәм шул инспектор хәзрәтләренә үзенең элгәре хезмәтеннән нәүмиз булып чыкканын шикаять

итеп сөйләшкәч, инспектор хәзрәтләре һәм һавадагы торналар белән күп бәшарәтләр (сөенечләр) биреп, бу адәмнең һәм күңелен берничә тәшвиштән (борчудан) чыгарып, үз файдасына күндерде» *(Насыйри К. Казан шәһәрендә мөселман балалары русча укый торган мәдрәсәнең ибтидасы // Насыйри К. Сайланма әсәрләр. Ике томда. Беренче том. Казан, 1874. Б.49).* В.В.Радлов җавап сүзендә үзенең халык мәгарифе министры белән яхшы мөнәсәбәттә булуын һәм Насыйрига яңа башлангычларында һәрьяклап ярдәм күрсәтергә әзер булуын ышандыра.

К.Насыйри язган тексттан ул элекке эшеннән педагогик хезмәтенә бәйле җитәкчелек белән килеп чыккан ниндидер килешмәүчелек һәм укытучы тарафыннан бик авыр кабул ителгән ниндидер мәсьәлә сәбәпле киткән дигән тәэсир кала. Шулай да бу җәһәттән төгәллек кертергә нинди дә булса яңа чыганаклар әлегә табылмады.

Бу мәсьәләдә К.В.Харламповичның Насыйри семинариядән 1870 елда Я.И.Фортунатов вафатыннан соң Казан архиепископы Антоний тәкъдиме яисә Н.И.Ильминский әйтүе белән киткән дигән версияләр белән килешәбез *(Харлампович К. П.П.Масловский и его переписка с Н.И.Ильминским. С.78).*


Тулаем алганда, 1855–1870 елларда православие дини уку йортларында укыту Насыйрига Казанның гыйльми интеллигенциясе белән аралашу мөмкинлеге бирә, бу аралашу аңа үзенең дәреслекләрен язганда һәм үзлегеннән яңа белемнәр алганда, фәнни-эзләнү алымнарын үзләштерүдә бик нык ярдәм итә. Белемен тирәнәйтүдә 1860 елларда аның Казан университетында иректе тыңлаучы буларак лекцияләргә йөрүе дә зур роль уйный.

Каюм яшәгән «кечкенә секуляр җәмгыять», бер яклап, аның традицион мөселман җәмәгатьчелеге белән элемтәләрен беркадәр чикли, икенче яклап, аның чит телле аудиторияләрдә татар телен укыту методисты, тикшеренүче буларак формалашуына җирлек әзерли. Үзенең иҗади эшчәнлегендә ул уңышлы рәвештә кадими мәдрәсәдә алган күнекмәләрен дә файдалана.

Сыйныф белән укыту күнекмәләрен үзләштерү, рус телен һәм әдәбиятын, Европа белем бирү системасын һәм Россия уку йортларында кулланыла торган методикаларны тирәнтен өйрәнү алга таба мәгърифәтченең педагогик, тикшеренү һәм наширлек эшчәнлегендә әһәмиятле роль уйный.

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы.*

# ЯНЫП-БАЛКЫП ЯШӘҮЧЕ ФӘРИД МИҢНЕӘХМӘТОВ



Татар халкы, кайда гына яшәсә дә, милләтебез йөзенә тап төшерми, аның киләчәге өчен көч-хезмәт куеп, сокланырлык эшләр башкарып, башкаларны да шул эшләргә илһамландырып яши белә. Яңа танышым Фәрид абый Миңнеәхмәтов һәм аның гаиләсе белән аралашканнан соң моңа кабат инандым. Бүгенге көндә Фәрид абый гаиләсе белән Свердловск өлкәсе Березовский шәһәрендә гомер кичерә, «Березовский рудник» оешмасында шахтёр булып эшли. Моннан тыш, Свердловск өлкәсендә Милли көрәш федерациясе башлыгы да ул. Тумышы белән Пермь якларыннан. Бу якларга ничек килеп урнашты икән дисезме? Бәлки Урал тауларының гүзәллеге гашыйк иткәндер аны? Хәер, язмыш адәм баласын кайларда гына йөртми бит... Гомер йомгагын сүтеп, Фәрид абыйның язмышы белән дә якыннан танышыйк әле.

Фәрид абый 1959 елда Пермь өлкәсе Октябрь районының Янапай татар авылында өч балалы гаиләдә иң олысы булып дөньяга килгән. Авылга Казан ягыннан килгән татарлар нигез салган, диләр. Мондагы борынгы каберлекләр 17 нче гасырга карый. Өлкәннәр сөйләвенә караганда, бу урыннарга беренче тапкыр өч карт килеп урнашкан була. Янапай бабай исеме белән бәйле Янапай авылы барлыкка килгән булса, икенче бабай Кашку авылына нигез салган, ә өченчесенеке онытылган дип сөйлиләр. Тирә-ягында сазлык булганга күрә, элек Янапай авылын Саз авылы дип тә йөрткәннәр икән. Фәрид абыйның әтисе колхозда тракторчы, әнисе сыер савучы булган. Шушы җирлектә белем алып, Фәрид абый 1978 елда армия сафына алына. 1980 елда армия хезмәтеннән кайткач, озак та тормый, үз авылының иң матур, чибәр кызы – классташы Гөлсирәгә тәкъдим ясый. Бик тәвәккәл, үҗәт була яшь егет. Армиядән генә кайткан егеткә Гөлсирә тиз ризалык белдерә. Риза булмый кара, буе дисәң, буе, матурлыгы дисәң, матурлыгы – мондый баһадир, җитмәсә көрәшче дә егетне тормыш иптәше итеп сайлаганга бүгенге көнгә кадәр шатланып туя алмый Гөлсирә апа. Свердловск өлкәсенә беренче булып Фәрид абый барып төпләнә. Совхозда эшкә урнашкач, гаилә фатирлы да була. Аннары Гөлсирә апаны да Урал якларына алып килә. Свердловскида техникум тәмамлап, Фәрид эретеп ябыштыручы булып эшкә урнаша. Соңгы ун елда шахтада ремонт бригадасында хезмәт куя. Еракларга китеп төпләнсә дә, тамырларын онытмыйлар Миңнеәхмәтовлар. «Шөкер, туган нигезебез бар. Янапайда туган-тумачаларыбыз яши. Туган якларга сукмагыбыз суынмый. Кайтып, нәсел дәвамчыларыбыз белән аралашып яшибез, – ди Фәрид абый. – Балаларыбыз Руслан белән Гөлнара да, бүгенге көндә тормышта үз урыннарын табып, җәмгыятьтә кирәкле, файдалы эштә эшлиләр. Гаиләнең тамырлары нык булса, киләчәге дә якты. Балаларыбыз йөзебезгә кызыллык китермәде. Үзебез алар өчен үрнәк булып яшәдек. Алты бөртек оныгыбыз – кызларыбыз бар. Карт әти, карт әни дип өзелеп торалар. Алар килүенә Гөлсирә милли ризыклар әзерләп тора. Кыстыбый, бәлешләрне яратып ашыйлар». Әле үзләренең хуҗалыклары да бар. Яшелчә, җиләк-җимеш, бәрәңге үстереп, бакча эшләре белән дә шөгыльләнергә яраталар икән.

Шахта эше – авыр хезмәт. Ләкин татар халкы эштән куркып кала торганнардан түгел. Тарихка күз салсак та, милләттәшләребез, бәхет эзләп, Донбасс, Кузбасс, Урал якларына шахтада эшләргә чит җирләргә чыгып киткән бит. Фәрид абый эшли

торган «Березовский рудинк» оешмасы исә Уралда файдалы казылмалар чыгаручы иң борынгы шахта булып санала. 1745 елда барлыкка килгән предприятие 279 ел дәвамында илебезне кыйммәтле чимал белән тәэмин итә. 712 метр тирәнлектә казу эшләре алып бару, ай-һай, җиңел эш түгел. Җир асты юлларының озынлыгы да 25 чакрым. Замана белән бергә атлап, монда яңа технологияләр өйрәнелә, кулланыла. Березовский шәһәрендәге күп кенә милләттәшләребез дә биредә эшли икән. «Җитәкчебез Фәрит Нәбиуллин – үзебезнең кеше. Татарстаннан ул. Татар милләте өчен җаны-тәне белән янып, тырышып эшләүче шәхес. Башкарган эшләренең исәбе-хисабы юк. Кайсы гына өлкәне алма, бар җирдә дә ярдәм итүче олы йөрәкле кеше. Ишеген шакып кергән берәүне дә кире борып чыгармый, ярдәм итә. Без аңа бик рәхмәтле. Ул безнең Березовский шәһәре татарларын берләштереп торучы дисәм дә, артык булмас», – ди аның адашы Фәрид абый, җитәкчесе белән горурланып.

Язмам герое Фәрид Миңнеәхмәтовның көрәш белән мавыгуы турында алдан әйткән идем инде. Свердловск өлкәсендә 30 елдан артык Көрәш федерациясе эшләп килә. «Мин үзем көрәш белән 9 сыйныфта укыганда шөгыльләнә башладым. Күп тапкырлар Сабантуй батыры, төрле ярышларда җиңүче булдым. Җиңүләремнең санын әйтә алмыйм инде. Хәзер дә, Аллаһка шөкер, көрәшәм. Үзебезнең Березовский шәһәре егетләрен көрәш серләренә төшендерәм. Тренировкаларны элек спорт комплексында оештыра идем. Фәрит Нәбиуллин ярдәме белән аерым биналы булдык. Укучыларым Свердловск, Россия һәм Бөтендөнья чемпионатларында призлы урыннар яулый. Аларның җиңүләре мине тагын да тырышыбрак эшләргә этәрә, канатландыра. Көрәш бит ул спорт төре генә түгел, ул – тормыш мәктәбе. Килеп туган авырлыкларны җиңеп, алга барырга өйрәтә. Спортчыларны да тырышырга, бирешмәскә, кыенлыклар алдында сыгылып төшмәскә, бары тик алга барырга кирәк дип өйрәтәм. Биредә төрле милләт вәкилләре шөгыльләнә. Татар, башкорт, рус, үзбәк, таҗик – көрәш мәйданы безне берләштерә. Безнең шәһәрдә татар көрәше зур үсештә. Әлбәттә, ярдәм итүчеләребез – спонсорларыбыз бар. Андый шәхесләр булганда милләтебез дә яши әле», – ди әңгәмәдәшем.

Свердловск өлкәсендә иганәчеләр милләт өчен берсен-берсе уздырып ярдәм итәргә ашкынып кына торалар икән. «Сапфир» фәнни-җитештерү берләшмәсе генераль директоры Ришад Серажетдинов та шундыйлардан. «Татар көрәше Фәрид Миңнеәхмәтовның канына сеңгән. Бу спорт төренә ул теләсә кемне гашыйк итә ала. Тырышлыгы, максатчан булуы белән ул күпләргә үрнәк. Көрәш белән шулкадәр мавыгуы, шәһәребез яшүсмерләрен дә шул юнәлештә тәрбияләргә тырышуы мактауга лаек. Без аңа һәрвакыт теләктәш», – ди Ришад Галям улы. Свердловск өлкәсе законнар чыгару җыелышы депутаты, «Эшмәкәрлек» партпроектының төбәк координаторы Абзалов Альберт Феликс улы да Фәрид абыйның тырышлыгына соклануын яшерми. Шуңа да татар көрәше буенча ярышлар уздырырга даими ярдәм итә.

Чыннан да, милләттәшләребез монда үз ана телләрендә иркен сөйләшеп, җырлап-биеп, укып, бәйрәмнәр үткәреп яши. Үзләренең «Курай» халык ансамбле милли көйләребезне җиткерсә, мәчетләрендә намазлар укыла, телне өйрәнергә теләүчеләр өчен татар теле дәресләре даими уздырыла. Татарстаннан килгән концертларны да калдырмый монда халык. Милли бәйрәмебез Сабан туе турында әйтәсе дә юк. Ул инде хәзер татар халкының гына түгел, ә илебездәге төрле милләт халыкларының да көтеп алган бәйрәме.

Эштә дә, тормышта да, гаиләдә, дә, спортта да Фәрид абый Миңнеәхмәтовның девизы – «Алга!» Теләкләре дә изге аның: «Милләтебез яшәсен, гөрләсен, яңалыкка омтылсын! Безнең халык тырыш, уңган, моңлы халык бит. Шул сыйфатларыбызны җуймасак иде. Татар гаиләләре артып торсын. Балалар туып торсын, тормышыбызны бизәсен! Һәр яктан үрнәк булып, янып-балкып яшик!»

**Руфия МӨХЕТДИНОВА**

# ӘДӘБИ СКАНВОРД

Тәрҗемәче ... Миңлебаев

Шагыйрь Мөхәммәт ...



Җәя һәм ук савыты

Туфан Миңнуллин драмасы

Бүлмә гөле

Мирсәй ...

... Сакаева

Кыйммәтле мехлы җәнлек

Композитор ... Тухманов

«Чук һәм ...» (А.Гайдар)

Северне яулаган казак атаманы

... Руставели

... Ярмәки

Борынгы грек шагыйре

Рифкать Гомәров оештырган ансамбль

Ачык зәңгәр

Тәлгат Галиуллин романы

Аллага якын, изге кеше (иск.)

Урта гасыр төрки-татар шагыйре

Уразада кич укыла торган намаз

... де Мопассан

Швеция машинасы

Илсөяр Иксанова туган район

Өслегенә бизәк төшерелгән кәгазь

Борынгы фарсы шагыйре

Колбаса төре

Язучының иҗат җимеше

Тур Хейердал көймәсе

Чуваш халкының милли бәйрәме

Уй-план, теләк

Бильярд таягы

«Шкода» моделе

Зөянең сул кушылдыгы

Хуҗа Насретдин транспорты

Киленең төйгече

Үтәлүе мәҗбүри таләп



... Ерикәй

... Лорак

«... әфәнде өйләнә» (Ш.Камал)

... Байҗиев (кыргыз әдибе)

Шагыйрь ... Кари

Нота

Казандагы мәчет

Гарәп хәрефе

Файдалы казылмалар тупланган урын

Рәис **ГАБДУЛЛА** *төзеде.*

***Үткән санда чыккан сканворд җаваплары. Сулдан уңга:*** *Газиз, Әхәт, йөк, киле, ирис, Мәрзия, Мин, әл, юкә, шелтә, Атос, «Намус», Дейл, балта, Даллас, Рим, имән, журнал, Сахара, бас, аренда, Камю.* ***Өстән аска:*** *Дали, бик, әлеге, «Рәссам», Гыйззәтуллина, Рю, илә, Зәкия, Жанна, абажур, Зәки, Камал, «Рамай», Хисмәтуллин, шәл, оста, теннис, асыл.*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## САЙЛАУ

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлауда тавыш бирү хокукына ия булган халыкның 71,6 проценты катнашты. Сайлаучыларның 76,7 проценты «Бердәм Россия» партиясе кандидатлары өчен тавыш бирде, 10,5 проценты – КПРФ, 4,4 проценты – ЛДПР, 4,2 проценты – «Яңа кешеләр» һәм 3,2 проценты – «Гадел Россия – Патриотлар – Дөреслек өчен» партиясе өчен. Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов татарстанлыларга ТР Дәүләт Советына сайлауда актив катнашулары өчен рәхмәт белдерде. «Татарстанлылар чираттагы мәртәбә бердәмлек һәм республикада уздырыла торган социаль-икътисади курсларга ярдәм күрсәттеләр. Республикабыз киләчәктә дә ныклы үсеш юлында булсын, Татарстан Дәүләт Советына сайланган депутатлар халык мәнфәгатьләрен яклап хезмәт итсен!» дип язды ул үзенең телеграм-каналында.

## ЯЗУЧЫ – ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНДА

Җиденче чакырылыш ТР Дәүләт Советының беренче сессиясендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла ТР Дәүләт Советы Президиумына сайланды.

## БРИКСНЫҢ ӘДӘБИ ФОРУМЫ

Татарстан Язучылар берлегендә БРИКСның әдәби форумы кысаларында тәрҗемә мәсьәләләренә багышланган түгәрәк өстәл утырышы булды. Анда Россия язучыларыннан тыш, төрле илләрдән, шул исәптән Кытай, Һиндстан, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Бразилия, Иран, Үзбәкстан, Азәрбайҗан һ.б. илләрнең әдипләре катнашты. Утырышны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла белән Мәскәүдә нәшер ителүче «Октябрь» журналының баш мөхәррире Ирина Барметова алып барды.

## ҖӘЛИЛГӘ – ЧӘЧӘКЛӘР

ТР Премьер-министры урынбасары – Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура Рәисе Васил Шәйхразыев эш сәфәре белән Саха (Якутия) Республикасында булды, Якутскида каһарман-шагыйрь Муса Җәлил бюстына чәчәкләр салды.

## ДӘРДЕМӘНДКӘ –ҺӘЙКӘЛ

Башкортстанның Мәләвез районы Җиргән авылында бөек татар шагыйре Дәрдемәндкә (Закир Рәмиев) һәйкәл куелды. Аның авторы – сынчы Илдус Закиров.

## БӘЙГЕ

Әлмәт шәһәренең «Нефтьче» мәдәният йорты китапханәсендә «Татнефть» хәйрия фонды «Рухият» нәшрият эшчәнлегенә ярдәм программасының «Рухият» китапларын укыйм» бәйгесен йомгаклау тантанасы булды. Татарстан Язучылар берлеге белән бергә уздырылган бу конкурска 240 китап тәкъдим ителде. Җиңүчеләргә диплом һәм Рәхмәт хатлары тапшырылды.

## АЛИШНЫҢ ТУГАН КӨНЕНДӘ

Казандагы Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиянең ишегалдында, каһарман-шагыйрьнең бюсты янында тантаналы митинг булды. Анда катнашучыларны гимназия директоры, шагыйрә, А.Алиш премиясе лауреаты Рәхимә Арсланова сәламләде. Митингта Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Рифат Җамал, язучылар, А.Алиш премиясе лауреатлары Ленар Шәех, Галимҗан Гыйльманов, Алишның туганнары Гөлшат Сөнкишева, Фәридә Аишева, галим Марс Гаитов чыгыш ясады.

## ГАМЗАТОВ ФЕСТИВАЛЕ

6–10 сентябрь көннәрендә Дагстан Республикасының башкаласы Махачкалада ЮНЕСКО эгидасы астында XXXVIII Халыкара «Ак торналар көннәре» дип аталган Гамзатов фестивале булып узды. Фестиваль кысаларында Дагстан Язучылар берлегенең 90 еллык юбилее билгеләп үтелде. Рәсүл Гамзатов туган көн уңаеннан үткәрелә торган әдәбият бәйрәменә Азәрбайҗан, Белоруссия, Ливан, Непал илләреннән, Россия төбәкләреннән өч дистәгә якын язучы чакырылган иде. Чараларда Татарстаннан хезмәттәшебез, «Казан утлары» журналының проза бүлеге мөхәррире Рафис Корбан да катнашты. Кунаклар Язучылар берлеге юбилее уңаеннан үткәрелгән тантаналы кичәдә, республика телевидениесе оештырган түгәрәк өстәлдә, Рәсүл Гамзатов һәм аның атасы Гамзат Цадаса, күренекле

авар язучысы Магомед Әхмәтов туган Цада, Хунзах һәм Гуниб авылларында, борынгы Дербент каласында булдылар, халык алдында чыгышлар ясадылар. Р.Гамзатовның Тарки-Тау зиратындагы каберенә, Сугыш каһарманнарына куелган һәйкәлгә һәм Р.Гамзатов белән Ф.Алиева һәйкәлләренә чәчәкләр салдылар. Рәсүл Гамзатов һәм Дагстанның халык шагыйре Әнвәр Аджиев музеен карадылар. Рафис Корбан үз тәрҗемәсендә Дагстан язучылары Рәсүл Гамзатов, Мөхәммәт Әхмәтов, Бикә Колончакова, Кадрия, Баһаветдин Аджиев, Марина Колюбакина әсәрләре басылган «Казан утлары» журналын һәм «Мәдәни җомга» газеталарын, Рәсүл Гамзатовның Нәсим Акмал һәм Лилия Фәттахова тәрҗемәсендә Татарстан Язучылар берлеге чыгарган «Минем Дагстаным» китабын Дагстан Язучылар берлеге идарәсенә бүләк итте.

## ГАРИФ АХУНОВНЫҢ ТУУЫНА – 99 ЕЛ

Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гариф Ахуновның туган көне уңаеннан Арча районының «Казан арты» тарих-этнография музеенда әдипне искә алу кичәсе булды. Анда Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары Рәмис Аймәт белән Наилә Ахунова (Г.Ахуновның кызы) катнашты.

## ИСКӘ АЛУ

Чистай шәһәренең музей-күргәзмә комплексында шагыйрә, тәрҗемәче, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты Флёра Тархmanaged исkә алу кичәсе үткәрелде. Анда Татарстан Язучылар берлеге вәкилләре Фоат Галимуллин, Хатыйп Миңнегулов, Хәбир Ибраһимов, Рәҗәп Бәдретдинов, Миңзифа Әхмәтшина, шагыйрәнең дуслары, туганнары Ф.Тарханова турында истәлек-хатирәләре белән уртаклаштылар. Шунда ук аның тормыш һәм иҗат юлын чагылдырган күргәзмә дә ачылды.

## АРЧА РАЙОНЫНА СӘФӘР

«Казан утлары» журналы кысаларында гамәлгә куелган «Яңа исем» иҗат лабораториясе» проектында катнашучылар Арча районына сәфәр кылды. Монда алар Арчадагы әдәбият һәм сәнгать, Гөберчәк авылындагы Мөхәммәт Мәһдиев музейларында булдылар. Сәфәрдә «Мәдәни җомга» газетасы, «Безнең мирас», «Казан утлары», «Мәгариф» журналллары баш мөхәррирләре Вахит Имамов, Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин, Гөлүсә Закирова, язучылар Гәүһәр Хәсәнова (М.Мәһдиевнең кызы), Вакыйф Нуриев, Лилия Гыйбадуллина, Рифат Сәлах һәм яшь язучылар катнашты. Аларны музей мөдирләре Дамир Абдуллин Һәм Халидә Габидуллина каршы алды.

Сәфәр ахырында кунаклар Гөберчәк авылы зиратында да булды. Монда җирләнгән Мөхәммәт Мәһдиев белән аның хатыны Лилия Мәһдиева рухына дога кылдылар.

## ТАТАР БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ АНТОЛОГИЯСЕ

Мәскәүнең Берләшкән гуманитар нәшриятында Татарстан Язучылар берлегенең Әдәби тәрҗемә үзәге әзерләгән «Хәзерге заман татар балалар әдәбияты антологиясе» рус телендә басылып чыкты. Анда 35 язучының әсәрләре кертелгән.

## ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда Берлек рәисе урынбасарлары Илсөяр Иксанова, Факил Сафин ике утырыш арасында башкарылган эшләргә хисап бирделәр. Идарә әгъзалары татар әдәбиятының бүгенге торышы, алдагы перспективалары турында фикер алыштылар. БРИКС саммиты кысаларында әдәби чаралар турында сөйләштеләр. Идарә прозаик, тәнкыйтьче, галим Рәҗәп Бәдретдинов белән шагыйрә, прозаик Люция Әблиеваны Татарстан Язучылар берлегенә кабул итте. Утырышны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла алып барды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

7 октябрь – шагыйрь, прозаик, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты Рәшит Бәшәргә 75 яшь.

10 октябрь – «Сабантуй» журналына (1991 елга кадәр «Яшь ленинчы» исеме белән чыга) 100 ел.

11 октябрь – шагыйрә, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты Фирдәвес Әһлиягә 70 яшь.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман З.ХУСНИЯРА «Аллюки», документальная повесть Р.КУРБАНА «Танкисты», повесть Н.КАРИМОВОЙ ««Долгие-долгие судьбы»; стихи И.ИКСАНОВОЙ, Г.АХТЯМОВОЙ, поэма Р.МУХАММЕТШИНА.*
*«Новые имена»: стихи Ф.БИКМАТОВОЙ.*
*Литературный конкурс «Нравы отчего дома...»: рассказ Ф.ЯКУПОВОЙ «Поучительная ошибка».*
*«Литература родственных народов»: стихи С.МУХИТ КЫЗЫ.*
*«Юбилеи»: статья А.ЗАКИРЗЯНОВА.*
*Фотоархив, посвящённый юбилею Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«Институту языка, литературы, и искусства имени Г.Ибрагимова – 85 лет»: интервью А.ХАБИБУЛЛИНОЙ с директором Института языка, литературы и искусства им.Г.Ибрагимова И.ХАЛИКОВЫМ.*
*Литературная критика: статья Р.СВЕРИГИНА.*
*«Национальное образование»: статья Р.МУХУТДИНОВОЙ.*
*«Грот Абугалисины»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА, посвященная 200-летию К.Насыри.*
*«Современник»: статья Р.МУХУТДИНОВОЙ.*
*Литературный сканворд. Составил Р.АБДУЛЛА.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Казанский Кремль. Фото И.АБРАМОВОЙ;*
*директор Института языка, литературы и искусства им. Г.Ибрагимова И.ХАЛИКОВ.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by Z.KHUSNIYAR «Allyuki», documentary story by R.KURBAN «Tankers», story by N.KARIMOVA «Long, long destinies»; poems by I.IKSANOVA, G.AKHTYAMOVA, poem by R.MUKHAMETSHIN.*
*«New names»: poems by F.BICMATOVA.*
*Literary competition «Morals of the father's house...»: story by F.YAKUPOVA «Instructive mistake».*
*«Literature of kindred peoples»: poems by S.MUKHIT KYZY.*
*«Anniversaries«: article by A.ZAKIRZYANOVA.*
*Photo archive dedicated to the anniversary of D.ZAGIDULLINA.*
*«The Institute of Language, Literature and Art named after G.Ibragimov is 85 years old»: interview by A.KHABIBULLINA with the director of the Institute I.KHALIKOV.*
*Literary criticism: article by R.SVERIGIN.*
*«National Education»: article by R.MUKHUTDINOVA.*
*«Grotto of Abugalisina»: article by I.ZAGIDULLINA dedicated to the 200th anniversary of K.Nasiri.*
*«Contemporary»: article by R.MUKHUTDINOVA.*
*Literary crossword puzzle. Compiled by R.ABDULLAH.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Kazan Kremlin. Photo by I.ABRAMOVA;*
*Director of the Institute of Language, Literature and Art named after G.Ibragimov I.KHALIKOV.*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан Кремлендә. *И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә*: Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, галим Илгиз Халиков.